ISSN 0206—4189

КАЗАН УТЛАРЫ

1.2003

YAZUÇILAR ÇİT İLLƏRDƏ

Tərki telle illər şağirlərenen III Xalıqara oçraşuında qatnaşuçılardan ber tərkem. Uŋnan əçençe—şağir **Zinnur Mansurov**.
Tərkiə, Malatiə şəhəre, oktəbr 2002 yıl.

Yazuçı **Əxət Muşinskiy** Xalıqara Pen-klubnıŋ Makedoniədə ütkərelgən Bətendənya yazuçılar kongressı kənnərendə.
Oxrida şəhəre, sentəbr 2002 yıl.

Казан утлары
Qazan utları

2003

1

(963)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

Татарстан хөкүмәте,
Татарстан Язучылар берлеге,
редакциянең хезмәт коллективы

БАШ МӨХӘРРИР

Равил Фәйзуллин

ИДАРӘ:

Харрас Әюпов
Зилә Вәлиева
Фоат Галимуллин
Тәлгат Галиуллин
Миркасыйм Госманов
Алмаз Гыймадиев
(җаваплы сәркатип)
Флүс Латыйфи
(баш мөхәррир урынбасары)
Салих Маннапов
Мирза Мәхмүтов
Туфан Миңнуллин
Хатип Миңнегулов
Гәрәй Рәхим
Факил Сафин
Ренат Харис
Зиннур Хөснияр
Розалина Шаһиева

Мөхәррирләр: **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

Гамәли хезмәткәрләр: **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Альбина Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
Исәп-хисап бүлеге: **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Иле барнын—теле бар 5

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Илдар ЮЗЕЕВ. Кәккүккә гомерләр юрыймын. *Шигырьләр* 8
Марат ӘМИРХАНОВ. Тояк эзе. *Роман* 13
Айдар ХӘЛИМ. Кичке жайдак. *Шигырьләр* 59
Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Идел яры. *Повесть* 64
Мөхәммәт МИРЗА. Киек каз юлында. *Шигырьләр (М. Әгъләмнең кереш сүзе белән)* 106
Әхәт ГАФФАР. *Хикәяләр* 112
Фәрит ГАБДЕРӘХИМ. Милләт бурасына—бөртекләрем. *Шигырьләр. (С. Сафуановның кереш сүзе белән)* 119

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА. Нәрсә булды безгә?.. *Трагедия* 125

ИЛДАР ЮЗЕЕВКА 70 ЯШЬ

Суфиян ПОВАРИСОВ. Моң эчендә асылташ 145
Шагыйрь турында—каләмдәшләре *(Х. Туфан, С. Хәким, Р. Хәсни, А. Әхмәдуллин)*.. 150

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Яңа дулкында 152

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Сулмас гөлләрнең берсе. *(Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре язылуга 660 ел)* 160

СӘНГАТЬ

Фәүзия КАДЫЙРОВА. Сәхнә сәнгатенә бер караш 169

КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

37—Саффат (Сафлар) сүрәсе 176

УТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Флүс ЛАТЫЙФИ. Тоталитаризм шәүләсе 181

ЮМОР-САТИРА

Ләбиб ЛЕРОН. Үртәмешләр 183
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан 190

В НАШЕМ НОМЕРЕ:

Журнал выходит один раз в месяц

Вступительное слово главного редактора Р. Файзуллина.
«Проза и поэзия»: М. АМИРХАНОВ. *Роман* «Следы копыт» *(начало)*; повесть М. ВАЛИЕВА «На берегу»; рассказы А. ГАФФАРА; стихи И. ЮЗЕЕВА, А. ХАЛИМА, М. МИРЗЫ *(с предисловием М. Агляма)*, Г. ГАБДРАХИМА *(с предисловием С. Сафуанова)*.
«Драматургия»: Г. ЗАЙНАШЕВА. Трагедия «Что с нами случилось?»
«К 70-летию народного поэта республики Татарстан И. Юзеева»: статья С. ПОВАРИСОВА «Мелодии драгоценный камень»; о поэте—Х. ТУФАН, С. ХАКИМ, Ф. ХУСНИ, А. АХМАДУЛЛИН.
«Литературная критика»: статья Д. ЗАГИДУЛЛИНОЙ «На новой волне».
«К истории литературы»: статья Х. МИННЕГУЛОВА посвящается к 660-летию поэмы Котби «Хөсрәү вә Ширин».
«Искусство»: статья Ф. КАДЫРОВОЙ «Взгляд на сценическое искусство».
Коран на татарском языке.
«Актуальная проблема»: Ф. ЛАТЫФИ. «Призрак тоталитаризма».
«Юмор-сатира»: эпиграммы Л. ЛЕРОНА.
Слово читателя.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Мусульманский религиозно-просветительский центр в г. Альметьевске; писательница Г. Зайнашева.

IN OUR ISSUE:

The magazin edits monthly

Editor´s word: R. Faizullin.
"Prose and poetry": M. AMIRHANOV´S novel «Hood´s scent» *(begining)*; M. VALIYE´S narrative «On the coast»; A. GAFFAR´S stories; verses of I. UZEEV, A. KHALIM, M. MIRZA *(with M. Aglyam´s preface)*, G. GABDRAHIM *(with S. Safuanov´s preface)*.
"Dramatics": G. ZAYNASHEVA. Tragedy «What happened with us?».
"Commemorating the 70th anniversary of national poet republic of Tatarstan I. Uzeev": S. POVARISOV´S article «Gem´s melody»; about poet - H. TUFAN, S. KHAKIM, F. KHUSNI, A. AKHMADULLIN.
"Literary criticism": D. ZAGIDULLINA´S article «On the new wave».
"Leterary history": article of H. Minnegulov dedicates to commemorating the 660th anniversary of Kotby´s poem «Khasrau va Shirin».
"Art": F. KADIROVA´s article «Gaze on scenic art».
Koran in Tatar language.
"The actual problem": F. LATIFI. «Totalitarism´s spectre».
"Humour-satire": epigrammes L. LERON.
Reader´s word.
The diary of social and cultural life.
On our covers: Muslim religioua - educational center on Almetyevsk; writer G. Zaynasheva.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә жыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 19.12.2003 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9134. Заказ Б—785
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2003 ел.

Баш мөхәррир сүзе

ИЛЕ БАРНЫҢ—ТЕЛЕ БАР

Жир кемнеке булса,
жил—шуныкы.

Тел дигән Бөек Хәзинә турында яңа нәрсә әйтеп була икән? Читен эш. Ә әйтергә кирәк. Бүген әйтмәсәк, иртәгә соң булуы бар. Сүзнең атасы—акыл, анасы—тел, дигәннәр борынгылар. Бар булган акыл белән, киңәш-табыш итеп уйлану-фикерләшү өчен, әнә шул Ана дигәннәренә, баш иеп дигәндәй, якынрак килеп карыйк әле...

Әйе, телне бөек хәзинә, байлык диләр. Ә Табигатьтәге һәр нәрсә үз урынында, үзенчә байлык түгелмени? Һәркайсының үз үлчәү-бәяләү берәмлеге. Тауларның биеклеге, җимешнең тәме, диңгезләрнең тирәнлеге, йолдызларның яктылыгы, далаларның киңлеге... Ә тел байлыгын, тел кыйммәтен ничек бәяләргә? Сүзләрнең күплеге, сөйләшүчеләрнең ишлеге беләнме? Озак яшәүчәнлеге, кешелек тәрәккыятенә керткән өлеше беләнме? Бу әйтелгәннәр тел зурлыгын дәлили тасвирласалар да, барыбер төгәл билгеләмә үк түгел. Һәр тел—үзенчә бөек. Җәмгыятьтә урын тоткан һәр тел турында бәлки гади генә болайрак әйтеп буладыр: тел ул—иксез-чиксез, төпсез-кырыйсыз, хисапсыз-бәясез...

Җир йөзендә телләр бик күп. Аларның төгәл санын әйтү дә кыендыр. Бер иш галимнәр алты мең ярым тел бар дип исәплиләр. Бар миллиардлап кеше сөйләшкән кытай, инглиз телләре, бар берничә мең, хәтта берничә йөз кеше сөйләшкәннәре... Мисалга ерак барасы түгел, үзебезнең Казаныбызда борынгы ассирия телендә сөйләшүче берничә дистә гаилә бар.

Төркем-төркем кошлар һавада!

Шуларның берәрсе
минем телдә сөйләшәдер күк.

Ә үзебезнең—татар теле дип йөртелгән Туган Телебез ни хәлдә соң бүген? Заманында халыкара телләрнең берсе булган, хәзерге көндә дә бөтендөнья күләмендә сөйләшер өчен уңай ун-унбиш тел арасында саналган, җәмгыять яшәеше барышын бөтен тулылыгы һәм нечкәлекләре белән чагылдыра алырлык бихисап сүз байлыгы булган Ана телебезнең бүгенгесе ничек тә, киләчәге ничегрәк булырга ошый? Сораулар катлаулы һәм авыр. Әнә шул билгесез авырлык каләм алырга мәҗбүр итә дә инде. Телнең бөеклеге, байлыгы, үлемсезлеге, бердәнберлеге, көч-кодрәте, тылсымы турында абстракт фәлсәфә, рәхәт оета торган вәгазьләр чоры үтте. Әгәр телне милли үзаңны билгеләүче бер төп күрсәткеч дип саныйбыз икән, безнең хәлләр бүгенгә мактанырлык түгел. Халкың тулысы белән үз телендә сөйләшә икән, ул—тулы милләт, яртысы сөйләшә икән—ярым-йорты милләт, ә биштән бере сөйләшсә... Безгә хәзер чаң сугып, «Уян, татар!» дип кенә түгел, «Тел сагына бас, Татар» дияр чак җитте. Телебез аңлаута, ярдәмгә, яклаута мохтаҗ.

Көелә утларда,
сандалларда таптала.

ярыла сәяси тегермән-ташларда...
Имгәнә, сызлана, көрәшә,
яңгырый алыр хокук өчен.

Хакыйкатьнең күзенә карау җиңел түгел. Күп нәрсәләрне танып, тәкрарлау авыр булса да, моннан күп еллар элек бер студент шәриктәшемә хатта әйткәндәй «Ирләр булыйк!», реалист булыйк, дөресен әйтик. Дөньялыкта глобаль процесслар бара. Кеше дигән зат, Бөек Табигатькә зыян салып, яшәү сутын җимереп (иң аянычы—бер аңда яралган адәми кардәшләрен үтереп), экологик фаҗигагә—ахырзаманга барса—анологик процесс Рух Дөньясында бигрәк тә кызу бара. Гамьсез, ваемсыз җаннарыбыз әлегә артык сизми аны, яки сизмәмешкә салыша. Сер түгел: үзләрен дөнья тоткасы санаган илләр, аз санлы халыклар телен үз «тегерменнәре» аша («мы на русской мельнице перемололи заезжий татарский язык») үткәреп, бөтенләй таптап, бетереп бара. Кайбер «табышка» әверелгән фактларны (үзебезгә инъекция рәвешендә!) искәртеп үтик: ана телебезнең бөтен нечкәлекләрен тойган, кабатланмас аваз аһәңе белән ләззәтләнгән укучылар катламы бик югарды; чын әдәби китапларны (китап рәвешендә дөнья күргән чүп-чарны әйтмим) укучылар нык кимеде: милләттәшләребез күпләп яшәгән төбәкләрдән әдәбият-сәнгатебезгә килгән яшь талантлар ифрат сирәгәйде...

Үткән егерменче гасыр, тел җәһәтеннән (бөтентатар җәһәтеннән түгел микән?) безнең файдага булмады. Элегрәк заманнарны никадәр генә караңгы итеп күрергә тырышмыйк, кайтып булса да таныйк: милли тамырлар ул чак ныграк, саурак булган (Ерак Көнчыгыш, Кытай, Япон илләрендә яки Төркестан, Кавказ якларында үзенең икътисади базасы, мәдәни учагы, басма китабы, театры, мәхәлләсе булган тулы канлы татар даирәсен күреп буламы соң хәзер?). Татар Конгрессларында, төрле милли җыеннарда берәм-сәрәм шытым-«курпылар» күренгәләп, чыгышлар ясаштыргаласалар да, чынында, тамыр-зәмин, нигездә, корыган... Гомумтатар әдәби теленең барлык этник төбәкләрдәге үзенчелекләрен бар тирәнлеге һәм байлыгы белән Идел-Урал, Казан төбәге тирәсендә генә саклау кыен... Соңгы елларда, бар булган дәрман белән Казаннан читтә яшәүче кардәшләребезгә игътибар (шәмдәлләргә соңгы май тамызу булмаса ла!) артты артуын. Әмма бу бөек миссиягә тартым хәрәкәт мәгълүм бер кампания уңаеннан гына булып, даими, эзлекле гамәл булмаса, уңай нәтиҗәләр бик булмас.

Йодрык—төен. Ул язылса—
аерылыр бармаклары...
Өчпочмаклар булып калыр—
өзсәң йолдыз канатларын.
...Булсаң бишкә бер халыкны
аннан—исем калыр бары...

Ананың балага биргән иң зур бүләге—тел. Шуңа да ул—байлык, хәзинә санала. Ә бүләкне, байлыкны, хәзинәне кадерләп саклый алу, күбәйтә-ишәйтә алу үзе бер батырлык сорый. Файдасын күреп яши белмәгәндә, тиз исраф итү, югалту бик җиңел аны. Телнең үз-үзен саклау «инстинкты» көчле көчлесен (диннәр алышынганда да тел калган!), әмма... Кояш астында һәр халык үзенә үзенчә урын даулый. Җир йөзендәге көрәш-тартышларның, орыш-сугышларның бер нигез сәбәбе, төптәнрәк уйлап карасаң, әнә шул тел дә бит инде! Һәр халык үз тарихын, үз рухын, җыр-моңын, матурлык өлгесен сакламакчы, үзенең яңа токымнарына тапшырмакчы. «Теле барлар—халык булган, теле юклар—балык булган» дигән сүзләр юктан тумаган. Әлбәттә, иҗтимагый күренеш буларак, тел объектив кануннарга буйсынып яши. Субъектив факторның, хәтта бик теләгәндә дә, роле ул хәтле зур була алмый. Әгәр тел сау-сәламәт икән, ул телдә җәмгыятьнең бөтен

катламнары сөйләшә: ил башы да, бомж да, сырхау кеше дә, мәхбүс тә, шагыйрь дә... Тел үзенең иҗтимагый функциясен тулы кимәлдә башкара алганда гына мөмкин хәл бу. Әгәр тел кешенең тормыш ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерә алмый икән, ул аны кирәксенми, яхшы дигәндә дә, аңа битараф кала. (Аяныч булса да, искә төшерик: авылдан шәһәргә килгән сәләтле күпме татар яшьләре тел «казасы» аркасында югары уку йортларына керә алмый калды заманында!) Рухи байлык (бу очракта тел) матди байлык тупларга булышырга тиеш булып чыга. Бу процесс тормышта шул хәтле бер-берсенә керешеп беткән ки, кайчак кайсысының беренчел икәнлеге дә онытылып китә. Бу очракның мисалы шул: яһүдләр кешелек матди байлыгының иң күп өлешен үз кулларына җыйгач, онытылып бетә язган «үле тел»не—ивритны тергезә алдылар, егерменче гасырга аны дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрделәр. Үзаң дигән төшенчәне аңлар өчен бик тә гыйбрәтле хәл бу.

Тел—диңгез. Бер ясканып кына аның тирәнлегенә төшеп, киңлекләрен иңләп бетереп булмас. Көнелдә сызланып йөргән уй-зарларны бер читкәрәк куеп, «ниләр эшләргә, ни гамәлләр кылып була» дигән сорауларга җавап эзләп карау дөресрәк булыр. Телебез халәтенә дөрес диагноз куярга сәләтле без бүген. Димәк, аны савыктыру өчен дәвасын да бергәләп табу ихтималыбыз бар. Фикри һәм гамәли хәрәкәтләр фарыз. Әлбәттә, уй-фикернең иң беренчесе һәм зурысы—Дәүләтчелек идеясеннән баш тартмыйча, республика статусын саклап калу. Тел язмышы шушы статуска бәйләнгән. Моның шулай икәнен үткән егерменче гасырның соңгы ун елындагы милли күтәрелеш бик ачык күрсәтте. Кыска гына вакыт эчендә тарихи геннар яңарып, байтак күркәм гамәлләр кылынды. Шул исәптән тел үсеше ягыннан да. Милли идеянең максаты һәм асылы булган Дәүләтчелекнең ышанычлы нигезе ул, шиксез, мәгариф системасы. «Мәгърифәт»—азатлык юлында беренче адым» дип тикмәгә әйтмәгән бөек әдибебез Гаяз Исхакый. Мәгърифәт—киләчәккә күпер ул, дип өстәргә генә кала. Мәгърифәт белән һәрчак бергә үрелеп баручы дин тәгълиматыбыз да бар бит әле. Дин—гомер бакый әхлакны һәм телне саклап килде. Соңгы вакытта диннең көчәюе, һичшиксез, телебез үсешенә дә уңай йогынты ясый ала. Мәгърифәт, гомумән, тәрбия турында сөйләгәндә халкыбыз тарихында төп рухи роль уйнаган китап—Галиҗәнаб Китап турында аерым әйтеп китү кирәк. Мең еллар буена безнең рухны китап яшәтеп килгән (күпләр өчен заман үрнәге саналган, тарихы нибары ике йөз ел исәпләнгән, җирле халыкны кылыч һәм туп белән кырган Америка җәмгыяте өчен китап нинди роль уйнагандыр, әйтү кыен—гәрчә бөек язучыларын таныган хәлдә дә—алар инде тарихи мәгънәдәге китаптан җиңел генә ваз да кичеп киләләр шикелле). Китапта безнең тарих, безнең тел, безнең язмыш. Китап—татар өчен яшәү символы ул! Тел хәзинәсе сагында торган язучыларыбыз моны яхшы аңлыйлар. Халык язучысы Нурихан Фәттах болай язган: «Әгәр тиздән минем телем бетә икән, озакламый тамырым корый икән, бу дөньяда ник яшәргә дә, нигә яратырга, балалар тудырырга, чәчәкләр үстерергә? Нигә җырлар, китаплар язарга?.. Икенең берсе—йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә! Мин көрәшергә булдым.» Мондый хис әдипләрдә генә түгел, үзен татар дип санаган һәр кешедә булырга тиеш.

Киләчәкнең башы бүгенгедә.
Нинди шатлык картлык көнендә—
оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә,
матур итеп туган телеңдә!

Равил ФӘЙЗУЛЛИН,
Татарстанның халык шагыйре.
Декабрь, 2002 ел.

Илдар Юзеев

КӘККҮККӘ ГОМЕРЛӘР ЮРЫЙМЫН

Әче җил. Күкри, дөберди
Түбәдә өй калае.
Йоклый алмый газаплана
Шәһри Казан малае.
Хәлләремне аңлагандай,
Өйгә килә төн җиле:
«Юк әниең, юк әтиең,
Син—бер Казан ятиме...»
Янда гына Иделсуның
Ярсулы гөрелтесе:
Бар җиһанда кызу агыш,
Йоклама, дигән төсле.
Алкын дулкыннар чакыра
Еракка—дингезләргә:
«Әйдә, Алып бабаңнарның
Йөргән юлын эзләргә!
Кыргый кыпчак даласында
Уйнаган ком бураны...
Чыгар башыңны юрганнан,
Алтын Урда торыны!»
Йөрәкне кага дулкыннар,
Тәрәзәне җил кага:
«Аһ, кызганыч, үзең түгел,
Уйларың гына ага.
Уяныгыз, йокламагыз,
Әй, Казан ятимнәре,
Бабагыз язган язмышның
Булыгыз хакимнәре!»

Килдем кырык чакрым ерактан...

Явыз Иван гаскәрләре Казанны яулап алгач, татарларга Иделдән кырык чакрым ераклыкта гына яшәргә рөхсәт ителә.

Адәм үтәлмәслек сукмаклардан
Төнге карурманнан ат менеп,
Иделкәем.
Күрешергә килдем атлыгып.
Тыныч агышымны будылар,
Кырык чакрым читкә кудылар.

Кара йөрәк патша синнән аерып
Кырык якка сибеп таратты.
Иделкәем.
Акчарлагың—сынар канатлы.
Килдем кырык чакрым ерактан.
Иделкәем ага йөрәктән.

Безне дә бер тирбәтерсең әле,
Агышларың калмас тукталып.
Иделкәем
Аңлагандай ага уфтанып.
Гел-гел кара еллар булмаслар,
Безнең агышларны бумаслар...

Кайчандыр әбиләр-бабайлар
Казансу—көзгегә караган.
Тын елга янына утырып,
Сылулар толымын тараган.
Тылсымлы ул нурлы көзгене
Илбасар залимнәр ватканнар,
Кырганнар, асканнар, атканнар,
Су булып ал каннар акканнар.
Казансу өсләре ал-кызыл,
Талларда җемелди алсу чык.
Татарның язмышы шикелле
Су тулы—кыйпылчык-кыйпылчык.
Шул ватык көзгене бергәләп,
Бер булып җыясы иде дә...
Көзгедә бәхетле елмаеп
Яшисе иде үз илеңдә.

Базар эчендә—баянчы

Базар эчендә—баянчы.
Кайчандыр булган моряк.
Җырлый ярсып, кызгандырып:
«Врагу не сдается наш гордый «Варяг!».
Кайберәүләр үз хәлләрен
Аңлагандай үтәләр.
Салган икәнен дә белеп,
Акча салып китәләр.

Ертык тельняшка. Алдында
Бескозыркасы ята.
Россия дигән крейсер
Жырлап, исереп... бата.
Базарда—шашкан музыка.
Ишетелә матәм кебек.
Шул крейсерга эләккән
Үзем дә—батам кебек...

Сизәләрдер...

Синең татлы-баллы иканеңне
Шөпшәләр дә, ахры, беләләр.
Әллә нигә мине ят итәләр,
Бик яратып сиңа киләләр.
Чәчәкләрдән чәчәкләргә күчеп,
Тәмле иренеңә куналар.
Иң ләззәтле гүзәл гөлчәчәкнең
Син иканен белә шул алар.
Сизәләрдер шәраб ачыларын,
Берни юктыр миндә—әчәрлек.
Берсе, каһәр, шундый чагып китте.—
Хәл калмады сине кочарлык...

Булгандыр инде...

Булгандыр инде мине дә
Үпкәләткән чакларың.
... Кызып китеп авыр-авыр
Сүзләр әйткән чакларым.
Булгандыр инде, булгандыр
Соңга калып кайтканым...
«Дусларың белән яшә!» дип,
Ишегеңне япканың.
Хәзер инде бер-беребезне
«Рәхмәт» әйтеп кочарлык.
Мәхәббәтне саклап калган
Икебезнең усаллык.

❦

Ялгышлар да, хаталар да булды.
Тик дөньяга юктыр бер кинә.
Үзем генә беләм: йөрәгемдә
Авырттырып йөри бер энә.
Гомерлеккә, ахры, кадалгандыр.
Мин бәхеткә лаек җан ласа...
Их, шул энә, җан табибы булып,
Йөрәк яраларын ямаса...

Кызлар уйный

Ике кызый гыйнвар урамында
Бер-беренә уйнап кар ата.
Минем дә бит уйнак табигатем
Йомшак җылы кышны ярата.
Җирнең өсте ап-ак болын төсле,
Яланаяк йөгереп китәсе,
Кар-чәчәктән такыялар үреп,
Шул кызларга бүләк итәсе!
Шушы көннән башлап күңелләргә
Гүя кара керләр кунмастыр,
Бер-берсенә пычрак атучылар,
Пычак атучылар булмастыр...
Язмыш җиле кая алып китәр
Табигатьнең ике аккошын?
Елый-елый сагынмаска язсын
Яшьлек болынының саф кышын.
Җирнең өсте ап-ак болын төсле,
Яланаяк йөгереп китәсе,
Кар-чәчәктән такыялар үреп,
Шул кызларга бүләк итәсе!..

Соңгы сорау

Туры юлда йөреп бөкерәйдем,
Турайта алмады «Бәкер»е.
Сез аңларсыз, инде тындым диеп,
Яткан җирем булса бөкере.
Сорау билгесенә охшап китәм,
Соңгы сорау белән багамын:
Бөкерәйми-кәкерәйми генә
Табарсызмы бирәр җавабын?..

❦

Җимерүче мәлгуньнәргә каршы
Сүзләр язган чакта, каһәрең...
Җимергәнмен нәни оныгымның
Бик тырышып корган шәһәрен...

❦

Торыннарым мине укысалар,
Әйтә алсын иде: «Кол Юзи...»
Кол Галиләр, Кол Шәрифләр кебек,
Изгелекләр генә кыл, Юзи,
Кол Җәлилдәй—кыю бул, Юзи!

Таң кошларын юлдаш итәрмен

Иртә таңда мине уяталар
Табигатьнең серле көчләре.
Кәккүк булып үзенә чакыралар
Әкияти урман әчләре.

Озын-озын гомер юрый-юрый,
Кәккүкләре рәхәт алдыйлар,
Аңлыйм инде, гомерең бигрәк кыска,
Мәңгелектә яшәп кал, диләр.
Урман әчләренә керермен дә
Таң кошларын юлдаш итәрмен.
Корган агачларны терелтерлек
Тылсымлы җыр җырлап үтәрмен.

Җитәрлек яшәдем, гомерем
Заяга үтте дип еламыйм.
Комсыз да түгелмен, яңадан
Шул кадәр яшәүне сорамыйм.
Берничә ел өстә, кәккүгем,
Җыр табыйм урманнар тыңларлык,
Бик иртә китте дип, чишмәләр,
Былбыллар сагынып җырларлык.
Үзем дә кәккүктәй моңаеп
Карурман эчендә йөримен.
Табигать шагыйре кәккүккә
Мәңгелек гомерләр юраймын.

Җитмеш яшьтә шаяру

Яшьлегем минем—бер түгел,
Яшьлегем минем—җитмеш...
Картлыкка сәлам бирмичә,
Сиксәнгә таба китмеш.
Миңа һаман килми диеп,
Картлыгым көтә торсын.
Үзе килә күрмәсен дип,
Яшьлегем киртә корсын.
Йоклап яткан картлыгымны
Тибеп уятмый булмас.
Әҗәл алдында уңайсыз,
Чәчне буятмый булмас.
«Әҗәл белән шаярмыйлар»,—
Икәнне күптән беләм.
Мин шаярмыйм, Әҗәл үзе
Уйный бит минем белән...
Яшьлегем минем—бер түгел,
Яшьлегем минем—җитмеш,
Картаеп яткан Әҗәлнең
Хәлен белергә китмеш...

2000–2002

Çəçmə əsərlər
Чәчмә әсәрләр

Марат Әмирханов

ТОЯК ЭЗЕ

РОМАН

Сират кичкән татар бар.
Шигырьдән.

Кинәт кенә күк капусы урталай ярылды. Анда монарчы берәүнең дә күзе күрмәгән коточкыч кара бушлык хасил булды. Ул шундый котсыз, шундый шомлы иде ки, адәмнәр куркышып җиргә ауды. Тирә-як зир-зәбәр килә, җир камыр кебек сузылып, эчендә саклаган барча нәрсәсен атып чыгарырга тотынды. Ә ул нәрсәләр берсе аргыннан берсе көлгә әйләнә барды.

Аһ, кайда син шәфкатьле вә мәрхәмәтле Кояшыбыз? Төнне көн кебек яктыртучы нурлы Аебыз? Энҗе бөртекләре сибелгән йолдызлы Күгебез? Ястыктай йомшак Җиребез?

Җир белән күк бергә тоташты, көн белән төн буталды, ут суга, су утка әйләнде. Җиһан унын-сулын югалтты.

—Кыямәт!—дип өзгәләнде кавем.

Кәшшаф чытырдатып күзләрен йомган хәлдә капшангалап карады, әмма тотынып нәрсә тапмады, куллары янә салынып төште. Гәүдә-сыны да очып йөри кебек. Әллә инде җаны тәненнән аерылган? Алай дияр идең, уе бар. Бу инде яшәү дигән сүз.

Яшәү! Яшәгәндә үткәнең дә, киләчәгең дә җуелмый, күзәнәкләребезгә сенеп, хәтердә саклана. Алар тоташ. Вакыт, Чор, Заман төшенчәсе шул рәвешчә барлыкка килә. "Яшәгән халыкның гына үз тормышы—үз вакыты бар",—дип язып чыккан иде мәртәбәле журналыбызда бер галимә ханым. Хәйран калган иде аның фикер байлыгына, мәгълүматына. "Идегәй" дастанының бөеклеген әлеге ханым шикелле тирән итеп дәлилләгән башка берәүне дә белми Кәшшаф. "Әгәр син исән икән, иртәгәсе көнең дә бар, киләчәгең дә бар. Вакыт яшәүнең берданбер үлчәме".

Марат ӘМИРХАНОВ *(1933)—прозаик; «Безнең лауреатлар», «Таш һәйкәл», «Чулманның ак йолдызы», «Сөн моңы» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

—Әй, миһербанлы бәндәләр, юл табарга булышсагыз иде, адаштык,— дип оран салды бер бичара адәм.

—Сез кем буласыз?—дигән сөаль яңгырады.

—Гыйлем ияләре, елъязма язучы хикмәтле кешеләр.

Кәшшаф сискәнеп китте. Бу соң институт директоры Галимовның тавышы лабаса! Зил-зиләбә аны да бөтереп алган икән. Шулай, Вакыт Галиҗәнаплары алдында без һәммәбез дә тигез, ул син түрә, син академик дип тормый, барчабызны бер тарак белән тарый.

—Татар тарихы бик буталган. Без сезгә ике юл күрсәттек, беренчесе— Хаклык юлы, чытырманлы юл; икенчесе—Яраклашу юлы, такыр юл. Сез кайсын сайладыгыз?

Бу көтелмәгән сөальдән елъязмачылар шүрләп калдылар ахры— ләм-мим. Шунда колакларны чыңлатып күк күкрәп алды, дөнья тынлыкка чумды, жиргә ап-ак томан төште, күзгә төртсәң дә күренерлек түгел. Шул карангылык эченнән ду галәмәт булып яу килгәне ишетелде. Әйтерсең лә, йөзләгән, меңләгән барабанны берьюлы кагалар: дөп-дөп-дөп.

Ниһаять, яу томанны ерып чыкты. Җә, хода, манзара дисәң дә манзара! Алда да атлар төркеме, артта, уңда, сулда да... Дәрья! Бер мизгелдә тояклар туфракка орынып ала, икенчесендә—кош канатларыдай өскә ыргыла: дөп, дөп, дөп! Дәррәү бер сулыш, дәррәү бер очыш. Җайдакларның кулларында уракка охшаш кәкре кылыч.

Чын-чын иткән чын йөгән.
Чыңлатканда караган,
Токымы толпар яралган.
Тимгел чуар ат бирәм,
Ул чуарны мен,—диде,—
Җил карамый жил,—диде.

Татар килә!

Әйе, ат өстендә татар гына үзен шулай горур, җинел, кылтыкланып тота белә. Татар гына атны бар хәзинәләрдән дә өстен күрә. Фәкать татар гына башын аямыйча яуга баса.

Толпарның эзе бетмәс, тоягы китмәс.

Муеннарын алга сузып атлар чаба. Колак төбендә тояк тавышы. Бу тавыш күңелгә ашкынулы моң булып ята. Татар моңының, татар җыруының чишмә башы, мөгаен, болыннарда уртлап йөргән тайлар кешнәвенә, чабышкыларның тояк чынына, сызгыра-сызгыра ат эчергән егет-җиләннең күңел кылларына барып тоташадыр. Юкка гына, ат—ир кешенең юлдашы да, мондашы да, димәгәннәрдер борынгылар.

Атлар чаба. Очы да, кырые да күренми. Кем явы булыр бу? Бату ханныкымы? Бәркә ханныкымы? Туктамышныкымы? Әллә Аксак Тимер фетнәсеме?

Кәшшафның күз алдына кинодагы сурәтләр шикелле Ибн Гарәбшаһның “Могҗизалар” әсәрендә тасвирланган бер вакыйга килеп басты.

Туктамыш белән Тимер Сәйхун һәм Җәйхун елгалары арасында очраштылар. Сугыш тегермәне әйләнеп, Тимер гаскәрен тарттырып бетерде. Шулвакыт җайдакларның сәет Бәркә исемлесе Тимер янына килеп туктады.

—Әй, мөхтәрәм сәетем, минем гаскәр тар-мар ителде!—дип ыңгырашты.

Тимер аны:

—Курыкма!—дип тынычландырды.

Шуннан соң сәет атыннан төшеп, учына эре ком алды һәм чуар атына атланып, эре комны дошман ягына ыргытты вә көчле тавыш белән:

—Ягы качды!—дип кычкырды.

Тимер дә, батыр шәехка ияреп, шул ук сүзләрне кычкырып әйтте. Нәкъ сусаган дөяләрне чакырып: “Җәүт, җәүт”,—дип кычкыручының тавышына тәнгәл иде Тимер тавышы. Атлар колыннары янына кайткан

кебек, Тимер гаскәре дә кайтып, янадан дошманга каршы сугышырга тотынды. Гаскәрнен яше дә, карты да: “Ягы качды!”—дип оран салды.

Туктамыш гаскәре чигенде, Тимер гаскәре боларга үлем шәрабен эчертте, мал-мөлкәтен талады, әсир итте.

—Әй, Туктамыш, Аксак Тимер таркала башлаган татар дәүләтен ныгыту өчен жан атып йөрде, сине хан итте, остазына ник яу чаптын?—дип сорады Кәшшаф. Соравы гына жавапсыз иде.

Атлар килә. Күз иярми. Дәверләр, гасырлар аша сикереп кенә узалар. Алтын Урданын да өч йөз еллык гомерен өч минутта артта калдырдылар.

Өерле ат аксагын белдермәс. Әмма ханнар атларга караганда акылсызрак булган. Тынышмаганнар, бер-берсен ашашканнар, талаганнар, үтерешкәннәр. Кәшшафнын аеруча Кырым ханы Минлегәрәйгә үпкәсе зур. Алтын Урданы ахыргача пыран-заран китереп, талап, жимереп бетерә.

Тарихлары бай булса да татар дәүләтләренен гомерләре кыска булган. Казан ханлыгы да 115 ел гына яшәп калган. Кырым ханлыгы, Әстерхан, Себер ханлыгы да. Шул ук хыянәт, нәфес, ызгыш-талаш, тыкшыну.

Аяусыз, шәфкатьсез, миһербансыз тарих!

Алтын Урданын Бәркә хан вафатыннан сон бәрәкәте китә. Бәркә татарларны мөселман өммәтенә керткән бөек зат. Ул патшалык иткән дәвердә Алтын Урда азан тавышына күмелә. Аны Мисыр солтаны да, башка Ислам мәмләкәтләре падишаһлары да бик ихтирам итә. Бүләкләр алышып, дустанә яшиләр. Халык та “Бәркә хан” дип, үлеп тора.

Бәркә хан бу фани дөнья белән хушлашкач, кыпчакка, татарга, төньяк илләргә, Тимер Капуга һәм аларга барып тоташкан жиргә хөкемдарлык итү Мәнгүтимер кулына күчә. Аларнын бит әле һәркайсынын үз ханы, үз патшасы да бар. Татар ханы Абага баш бирмәскә маташа. Житмәсә, урыс кызына өйләнгән. Бу хәл мөселманнарнын ачуын кабарта. Мисыр солтанынын сүзе кыска: “Бездә Абагага карата тик кылыч кына бар”,—ди. Алай да тегенен кылын тартып караудан йөз чөермиләр үзләре. Солтан да, Мәнгүтимер дә илчеләрен жибәрәләр. Илчеләр Абага катына үткәнче агу, бозу, сихердән саклану өчен ике ут арасыннан узалар. Ышан син, кяфергә, бер хыянәт иткән кеше икенче, өченче тапкыр да хилаф гамәлдән баш тартмас.

Абага башта илчеләргә сырт йонын кабарта, янәсе, сөттән ак булып кылансагыз да, сезнен үзегездә дә кер житәрлек. Бу анын мәрхүм Бәркә ханга төрттерүе иде. Чөнки Бәркәнен улы, үзен авыр сырхаудан терелткәне өчен, христианнар ягына авыша, Петр Ордынский дигән титул ала.

—Солтан белән Мәнгүтимер сина сәлам юллый,—ди баш илче. Аннан сон эре генә итеп кисәтеп куя: “Солтан атлары баскан жирләр—Солтанныкы, Мәнгүтимер атлары баскан жирләр Мәнгүтимернеке булыр”.

Акылга утырталар Абаганы. Тик ни генә әйтмә, Бәркә хан барыбер Алтын Урданын бәхетен үзе белән гүргә алып китә. Бу биниһая зур дәүләттән тора-бара онытылмас ядкәр булып канатлы толпарларнын тояк эзе генә сакланып кала.

Күрәсен, дагасыз атлар бәхет китерми.

* * *

Кәшшафнын уянганына байтактан инде. Бу күзаллаулар пәйгамбәр төшенен уяу халәттәге дәвамы гына. Ул шактый вакыт укыган-белгәннәрен хәтерендә янартып, хозурланып ятты. Өнендәге—төшендә, ди.

Төшендә ботка күргән Мокыт,
Янадан яткан ди, кашыгын тотып.

Хәер, мона гажәпләнәсе дә юк. Итекчегә—итек, читекчегә—читек дигәндәй, гомерлек шөгыле итеп тарих фәнен сайлаган кешенен төшенә жен-пәриләр кермәс ич инде. Алай дисән, тарихнын корсагы жандар биясенеке кебек зур бит анын, анда күп нәрсә сыя.

Төшне аны юрый белергә кирәк. Әнә, диссертациясе дә кабат төгәлләнеп килә. Ихтимал, шуңа ишарәдер болар. Бу юлы, бәлкем, гаделлек җөмһүриятебезнең үзендә үк табылыр.

Тик ничә әйтсәң дә, Алтын Урда тарихына караган тема—каргалган тема инде ул. Анда әлегә кадәр гафләт йокысы хөкем сөрә. Демократия җилләре дә урап узды аны. Аеры-чөере килү һаман дәвам итә. Тик Кәшшафны хәзер бу юлдан тайчындырып булмастыр инде, мөгаен.

Яшьтән үк "иске-москы"га мөкиббән иде ул. Әбисеннән гарәпчә укырга-язарга өйрәнде. Затлы челтәрдәй үрелгән гүзәл гарәп хәрефләре бик ошый иде аңа. Күпме гыйлем, күпме сер, күпме тылсым яшеренгән ул бизәкләр арасына?!

Авылдагы бик күп кешеләрнең чормаларын чистартты Кәшшаф, күңеленә хуш килердәй матур-матур китапларга да юлыкты. Тора-бара шул китапларның аерым битләренә кулдан өстәп язылган язмаларга игътибар итә башлады. Кем кайчан туган, кемнең сыеры кайчан бозаулаган, кем кайсы вакытта вафат булган, кемне башлы-күзле иткәннәр—барысы-барысы да төп-төгәл итеп теркәлгән. Җил-давылы да, гарасаты, янгыры, корылыгы да—берсе дә читтә калмаган. Тарих шулай тернәкләнгән.

Бервакыт Пугач явы чорына мөнәсәбәтле бер кечкенә язма күзенә чалынды. "Бүген өйләдән соң Галимулла хәзрәт Пүгәч әфисәренә ияреп авылыбыздан чыгып китте",—диелгән иде ул язмада. Кәшшаф университетта укыганда шушы бер җөмләгә нигезләнеп реферат та язган иде. Дөрес, Пугачевка теләктәшлек күрсәткән хәзрәтне доцент Галимов өнәп житкермәде, бу сыйнфый көрәш кануннарына туры килми диде. Кәшшаф килешмәде, бәхәскә керде. Эш деканатка кадәр барып житте.

Әлбәттә, кеше тормышындагы һәр вакыйгага тарих мөһере суга алмыйсың. Кәшшаф исә бүгенге тәржемәи хәлен нәкъ менә шушы вакыйгадан башланды дип саный. Чөнки шушыннан соңгы һәр адымы көрәш, каршылыкларны җиңү бәрабәренә башкарылды, һәрберсе юлда уелып калган тояк эзедәй күңел хөҗрәсенә үз хатирәләрен өстәп барды.

* * *

Су, кем әйтмешли, май кебек иде. Шәһәрнең тынчу, бөркү, исле һавасыннан әлсерәгән тән гүя эреп китте. Тизрәк чумасы, йөзәсе, хозурланасы килә. Ләкин гыйшык үзенекен итмичә кала диме соң? Менә Кәшшаф учы белән Заһидәгә су чәчрәтте. Тегесе бәхетле хатын-кызларга гына хас наз һәм кылану белән чыелдап җибәрде:

—Кәшшаф кирәкми, Кәшшаф дим...

Яр буенда кулларын бөерләренә таянып басып торучы ике ханым бер-берсенә карашып алдылар. Хатын-кыз үз ишләренең бәхетен күтәрә алмый бит ул. Көнләшүдән йөзләре янып чыкты.

Тик гашыйкларның кешедә гаме юк. Һәр минутлары кадерле. Урлашып яратышуның ләззәте шунда ич инде аның. Ләкин бу юлы мәхәббәт ашына кара таракан төште. Урман эченнән кемнеңдер тавыш көчәйткеч аша: "62-72 нче номерлы автомобиль хуҗасы, машинагыз янына килегез!"—дигән әмере яңгырады.

—Мин хәзер,—диде Кәшшаф Заһидәгә,—син коена тор.

—Юк, мин синең үзенне генә җибәрмим, бергә барабыз,—дип каршы төште хатын. Аның кәефе кырылган иде инде.

Көнче ханымнарның йөзенә канәгать елмаю йөгерде. Янәсе, ай йөгәнле тай түгел, аны гел үзенчә генә йөртеп булмый.

Машина янында карачкы сыман ике милиционер басып тора иде. Берсе сержант, икенчесе ефрейтор.

Сержант урмандагы ак чыршыдай төз, озын. Ефрейтор түмәр кебек төптән юан, өстәвенә камыт аяклы. Заһидә килә-килешкә Кәшшафның артына посты.

Милиционерлар усал эт шикелле ачулы иде, текәлеп бактылар.

—Типтерәбезме?—диде ефрейтор мыскыллы елмаю белән. Күрәсең, мондый хәлләргә беренче генә тапкыр юлыгуы түгел иде.

Кәшшафның җан ачуы чыкты. Аның Заһидә алдында һич тә хурга каласы килми иде.

—Кешенең шәхси тормышына тыкшынырга хакыгыз юк,—диде ул дорфа гына.—Хәзер демократия заманы.

—Ә нәрсә, демократия дип, без һәр ачыгавызның артын ялап йөрергә тиешме әллә?

Бу сүзләрне сержант әйтте. Аның буш капчыктай салынып төшкән аскы ирене тырпаеп алга бәреп чыкты, күзләре чекрәйде.

—Минем сезгә андый үтенеч белән мөрәҗәгать иткәнем юк,—дип әтәчләнүендә булды Кәшшаф.

—Алай бик эре сөйләшмәгез, без вазифа башкаручы рәсми кешеләр,—диде сержант.—Документларыгызны күрсәтегез, шуннан соң барысы да ачыкланыр.

—Рәхим итегез, алар минем һәрвакыт тәртиптә.

Кәшшаф трусик кесәсеннән кульяулыгына төрелгән ачкычын алды да, машинасы янына килде. Документлары, киемнәре багажникта иде. Ә багажник шыр ачык. Кикриге шиңде Кәшшафның, мескенләнеп калды.

—Җә, егетләр, бераз кызып кителде, гафу, ким-хур итмәм...

Ул милиционерлар юри шаярталар дип уйлый иде.

—Киемнәрем!—дип Заһидә дә яшеренгән җиреннән алга чыкты.

—Син әле безгә взятка тәкъдим итәсеңмени?

Ефрейтор Кәшшафка чын-чынлап бәйләнмәкче иде, сержант әллә иптәшен аңлап житкермәде, әллә бу гамәлен килештермәде: "Урман эчендә кем машина калдыра инде, җә?"—дип хәтта Кәшшафның хәленә дә кергәндәй итте. Тегесе дә кайтып төште.

—Хәзер акт төзибез, ихтимал, документларыгыз да, әйберләрегез дә табылыр әле,—диде.—Ризадыр бит?

Кәшшаф башын какты. Бәлки, чыннан да, бурның эзенә төшәрләр? Костюмы да, туфлиләре дә өр-яңа иде. Ә Заһидәнең киемнәре аныкыннан да затлырак. Модасына китереп киенә белә ул. Сумкасын үзе бүләк иткән иде. Нәфис күннән эшләнгән кыйммәтле француз сумкасы. Акча, төрле кәгазь-язулар. Машина документлары, гомумән, бәһасез. Күпме мәшәкать көтә аны, уйласаң чәчләрең үрә торырлык.

Соңыннан Кәшшаф акт төзеткәненә бик нык үкенде.

Әлеге минутта аны бөтенләй башка нәрсә борчый иде. Су коенган киемнәрдән генә калдылар ич?! Ничек кайтырлар? Өстәвенә, өйдә әле җавап тотасы да бар. Ул костюмны хатыны Польшадан алып кайткан иде. Эш анда гына да түгел. Иртән киенеп-ясанып чыгып кит тә, кичен ялангач кайт, имеш. Моңа нинди сәбәп уйлап тапмак кирәк?

Милиционерлар эшләрен төгәлләделәр дә китеп бардылар. Кәшшаф белән Заһидә караңгы төшкәнен көтеп утырдылар. Эсселек тә, тынычлык та онытылды. Су коену да, яратышу да. Заһидә сыгылып төшеп, мышык-мышык елый иде.

* * *

Кәшшафның тормышына Заһидә көтмәгәндә килеп керде. Институт коридорында күзгә-күз килеп очрашкач, матурлыгына исе китеп, аның җыя алмый торган иде.

—Шәп, чукынмыш, ә?—дип Әлтаф искәртмәстән кулын аның җилкәсенә китереп салды. Мыштым гына читтән дустын күзәткән, күрәсең.

Кәшшаф хәрам гамәлдә тотылган кеше шикелле дерт итеп китте.

Алар бер бүлмәдә утыралар. Әлтаф—фольклорчы. Бик шаян, бик мут кеше. Институтта ул борының тыкмаган бер тишек тә юктыр, мөгаен. Һәммәсен күрә, һәммәсен белә, чит итәкләрне дә игътибарсыз үткәрми.

—Дөрес әйткәнменме?—дип сорады ул күзләрен майландырып.

—Нәрсәне?—дип белмәмешкә салышты Кәшшаф.

—Нәрсә, нәрсә:

Бишмәтенә теккән биш төймәнең
Бишесе дә Бохар көмеше;
Йөзкәйләрең гөлйөзем жимеше,
Буйкайларың Идел камышы.

—Әй, синең шул инде.

Ул әле һаман илле-мәлле тора. Хәлбуки, Әлтаф аңа өченче көнне үк инде бу яңалыкны житкергән иде, институтка бер чәчби алганнар, тауары базарлы күренә, дигән иде. Кәшшаф үзе хатын-кыз мәсьәләсендә үшәнрәк зат, аны кузгату авыррак. Яшьрәк чакта да мактанырлыгы булмады. Оялчан ул. Еш кына аңа тегe яки бу сорау белән кызлар мөрәжәгать итә. Уку алдынгысы бит! Билгеле инде, авызлары ерык, чырык та чырык көлешәләр. Кәшшаф үзеннән көләләр дип уйлый. Шуңа күрә суга салынган борчак шикелле бүртенеп чыга. Ык-мык килә башлый, белгәнен дә юньләп аңлата алмый.

Күңеленә охшаган кызлар белән житәкләшеп йөрү тәтемәде Кәшшафка. Батырлыгы, кыюлыгы житмәде. Алар, әлбәттә, аның кыюланганын көтеп тормадылар, университетны бетерер-бетермәс тәгәрәшеп күршедәге хәрби училищены тәмамлаган яшь лейтенантларга кияүгә чыгып беттеләр. Ул чакта хәрбиләрнең абруе зур иде.

Кәшшаф жаны тартмаган калдык-постык кызлар белән киноларга, бию кичәләренә йөрде. Шулар белән кочышты, шулар белән үбеште. Утсыз-ялкынсыз үбешүләр иде ул. Аспирантурада укыганда кызлар кайгысы булмады. Хәзер инде ул өйләнгән кеше. Чит-митләр турында баш вата торган чагы түгел.

Шулай да Заһидә белән очрашу аның жиде кат йозак эченә яшеренгән хисләрен уятып жибәрде. Хис учагы сиздерми генә пыскып яткан булган икән. Әнә, ничек талпынып-талпынып сулкылдый йөрәге. Ниндидер ләззәтле, ашкынулы сулкылдау. Мондый халәтне әле аның бервакытта да кичергәне юк иде. Анда ярату да, соклану да, гажәпләнү дә, әсәрләнү дә бар иде.

Уйлана торгач, Кәшшаф шундый ачыш ясады: Заһидәне күптәннән белә икән ләбаса! Төшенә кергән иде ул. Исеме генә башка иде. Йолдыз иде ул аның төшенә кергәндә.

Кемдер шигырь яза, кемнедер моң тарта, бәгъзеләр сәнгатькә мөкиббән, Кәшшаф исә тарих колы. Унынчы класста укыганда ук жәяүләп Болгарга сәяхәт кылды. Изге ядкәрләребезнең шулай ташландык хәлենә калуына бик рәнжеп кайткан иде. Университетта офыклар киңәйде. Башта Александр Македонский белән мавыгып алды, аннан соң жентекләп Мөхәммәд пәйгамбәрнең тәржемәи хәлен өйрәнде. Ә бервакыт ул Изетдан Әбүл Хәсән Гали-әл Жәзири елъязмаларына тап булды. Шушы әсәр аны Алтын Урда чытырманлыкларына алып керде. Бигрәк тә Бату хан үзенә жәлеп итте. Аның турында язылган тарихи әдәбият, төрледән-төрле риваятьләр белән танышты.

Заһидә Кәшшафның күңелендә сакланган әлеге риваятьләрнең берсен янә жанландырып жибәрде.

"Бөек гаскәрибаш серле һәм аз сүзле булырга тиеш. Көченне күрсәтү өчен үзенне сер белән чорнап алырга, һәр жирдә тәвәккәллек белән үз юлыңны салырга һәм дошманнарыңны аяусыз рәвештә кырып бетерергә кирәк".

Күренекле акыл иясе хәким Хажи Рәхим Бату ханга ошбу фикерне һаман тукып торды. Сүбәдәй баһадир да аңа гарәпнең әлеге сүзләренә колак салырга киңәш итте. "Бөтен өмет синдә, мин инде картайдым. Бөек боеручыбыз яу чабуны сиңа хәер-фатиха итә",—диде. Бу сүзләрне әйткәндә хәтта, гомер булмаганны, кырыс баһадурның исән калган таза күзенә яшь тә килгәндәй булды.

—Галиҗәнап Чыңгыз хан нәселендәге унбер шаһзадә дә Харәземгә килде, яуга әзерләр. Һәм һәрберсенең җиһангир буласы килә.

Бату хан шаркылдап көлеп җибәрде.

—Аурупага үлем шәрабен мин эчерәчәкмен, баһадур! Ә ул син әйткән шаһзадәләр минем олтаныма да тормый.

Сүбәдәйнең тырма чөедәй эре сары тешләре иреннәрен ярып чыкты. Күренеп тора, бу сүзләр аның йөрәгенә сары май булып ятты.

—Минем даирәдән бер адым да читкә тайпыласы булма, Бату хан! Колагыңа киртлә, сиңа куркыныч Аурупа ягыннан түгел, туган-тумачан ягыннан яный. Көнчел кеше—минчел кеше. Чабышкыны камчы чаптырмый, хөсетлек чаптыра.

Бату ханның калын кашлары бергә кушылды, авызы кыйшайды.

—Гарык инде мин алардан!—диде ул камчысын шартлатып.

Хаҗи Рәхим язып куйды: "Гаскәр көнбатышка кузгалды. Утыз өч төмән. Һәрберсендә ун мең атлы гаскәр. Алар утыз өч юл буйлап шундый киң ташкын булып баралар ки, аның сул канатыннан уң канатына барып ирешү өчен өч көнлек юл үтәргә кирәк булыр иде".

Бату ханның мәшһүр меңлегендә иң чыдам һәм иң житез унбиш дөядән торган кәрван да бар. Бу кәрванда Бату ханның "җиде йолдыз"ы. Монда аларны шулай дип йөртәләр. Бу йолдызларны Батуның кырык хатыны арасыннан әнкәсе Ори Фуҗин үзе сайлап алды. Улы тешетырнагы белән каршы иде.

—Искәндәр Икемөгез[1] бервакытта да яуга хатыннарын алып йөрмәгән, уенда сугыш, җиңү генә булган,—дип киреләнде.

—Искәндәрнең ничек үлгәнен беләсеңме син?—дип ана улына текәлде. Аннан соң җиргә орынган ат тоягыдай һәр сүзгә басым ясап әйтте—Персияне буйсындыргач, шундагы патша кызына өйләнә ул. Шул хатын бөек гаскәрибашны агулап үтерә. Чит мөслимәләргә ышаныч юк, хан, янында үзеңнекеләр, сыналганнар булырга тиеш.

—Ярый, анакай, ризамын. Тик җиде йолдыздан берсе жария булсын, һәм аны үземә сайларга ирек бир. Әлбәттә, синең фатихаң белән.

Иртәгәсен Сүбәдәй баһадур Йолдыз исемле берничә кызны эзләтеп таптырды. Бату хан аларны күзеннән кичерде дә арадан берсенә бармак төртеп күрсәтте. Шуннан соң өстенә ефәк япкыч ябып, кызны Ори Фуҗин катына керттеләр. Ханбикә кызга чишенергә кушты. Тегесе анадан тума калды. Ори аның бөтен тәнен капшап чыкты.

Йолдыз күрер күзгә ябыграк тоелса да өлгергән йөзем җимешедәй тулган иде инде. Гәүдәсе ыспай, күкрәкләре тыгыз. Ә йөзе тулган ай шикелле. Нәфис иягенең нәкъ уртасында мәхәббәт чокыры да бар. Чәч толымнары калын, озын. Оялуыннан кулларын кая куярга белми.

—Нинди һөнәрләрең бар?—дип сорады ханбикә.

—Минме, мин сыер сава беләм—диде кыз тотлыга-тотлыга.

—Тагын?

—Тагын үзебезнең кыпчак җырларын җырлый беләм, әкиятләр сөйли беләм.

Йолдыз әлеге "җиде йолдыз"ның иң яктысы иде.

Кәшшаф үзенең төш алиһәсе Йолдызга гашыйк иде. Хәзер менә бу алиһә образ булудан туктады. Заһидә кыяфәтендә реаль шәхескә әверелде. Әле алар авыз ачып бер сүз әйтешмәделәр. Ихтимал, Заһидә дә Йолдыз шикелле хыялый образ гына булып калыр? Ул, гомумән, билгесезлек йолдызы тамгасы астында дөньяга килгән ахры. Нинди генә гамәлгә алынмасын, телиме-теләмиме, очсыз-кырыйсыз караңгы дәрьяга килеп төртелә. Әйтерсең лә, шушы билгесезлекләрне җибәреп, Ходай аның әхлакый ныклыгын сынап карый. Диссертация темасын сайлаганда да ниндидер өстен көчнең йогынтысын сизеп торды, гүя кулыннан тотып яздырдылар. "Татар халкын оештыруда Алтын Урда дәүләтенең роле"

---

[1] Александр Македонский

дигән теманы ишетүгә кафедрадагыларның да колаклары үрә торды. Чөнки ул вакытта олуг милләт шовинизмына корылган коммунистик идеология милли тарихның совет чорын гына кабул итә, тирәнгә керүне, чокчынуны өнәми иде. Ә Алтын Урда— бу инде үз-үзенне бәйләп коега салу белән бер. Иң сасык тема. Чөнки тарих инде күптәннән сәясәт белән, идеология белән бергә йөри. Татарның милли тарих фәне исә акрынлап татар-монголлардан бөтенләй ваз кичә башлады, янәсе, хәзерге татарларның аларга берниндиі катнашы да юк.

Кәшшаф нигәдер теше-тырнагы белән шул темага ябышты. Дуслары бу "хаталы" юлдан тайпылдырырга да омтылып карадылар, үтемлерәк тема беткәнмени, юк белән башыңны әйләндермә, дип киңәш иттеләр. Ә ул, кире чабата, шундый ук тискәре зат, остазы мәрхүм профессор Ашказарскийның сүзләрен тукылдады: "Бүредән курыккан урманга йөрмәс".

Ашказарский уклау йоткандай төзгә каткан, чандыр йөзле, ак чәчле кеше иде. Йөреше, үз-үзен тотышыннан ук аның зыялылыгы сизелеп тора иде. Иреннәре юка, күзләре зәңгәр. Балтыйк буе морзаларыннан, дип әйтә иде үзенең нәсел-нәсәбе хакында сүз чыкканда. Ул туры сүзлелеге белән дан тота иде. Кемнең кем булуына карамастан, уйлаганын чәпи дә куя. Шуна күрә аннан шүрлиләр иде. Вакытында бик кыйналган. Бер-бер артлы эшеннән дә куганнар. Авыр чакта Мәскәүгә барып егылган. Сабакташлары, ил күләмендә танылган галимнәр, аңа һәрвакыт ярдәм кулын сузганнар.

—Безнең иң зур таянычыбыз Мәскәү,—дип кисәтә иде ул Кәшшафны,—Мәскәү булмаса, татарлар бер-берсен ашап бетерерләр иде.

Сәер караш. Явыз Иван; Казан ханлыгын тар-мар итү; татарларны чукындыру һәм "таяныч". Шулай инде, тормышта барысы да чуалышып беткән. Бер карыйсың—дошман, икенче карыйсың—таяныч.

Ашказарский вафатыннан соң Кәшшаф үзе дә, диссертациясе дә ятим калды. Сәясәткә туры килеп бетмәсә дә, темасы искиткеч кызыклы, мавыктыргыч иде. Әйтик, татар тарихының XIII-XV йөзләргә караган өлеше Совет чорында бөтенләй өйрәнелмәде. Бу Болгар дәүләтенең яулап алынуыннан башлап, Казан ханлыгы оешкан чор. Әйтерсең лә, ул бөтенләй булмаган. Шул чор эчендә болгарлар да татарга әйләнеп куйганнар.

Кәшшаф, әлбәттә, саклану чараларын да күрде. Остазы киңәше буенча, диссертациясендә Алтын Урда сүзен еш кулланмаска тырышты, исемен дә шуңа яраклаштырып үзгәрәтте. Хәер, бу алар уйлап тапкан яңалык түгел иде. Олуг галимебез Шиһабетдин Мәрҗани үзенең хезмәтләрендә Алтын Урда дәүләтен "Дәшти кыпчак", "Җуҗи улусы", "Бату йорты", "Бәрриятел Бәрәкәт", "Үзбәк иле", "Сарай дәүләте", "Ак урда" исемнәре белән атый. Бу, билгеле, галимнең үз белдеклеге белән күктән алган атамалар түгел. Алар шул чор тарихи зилзиләләрнең табигый чагылышы.

Диссертация язу йөз мәшәкать булса, Казан шартларында аны рәсмиләштерү, яклау мең мәшәкать. Мондый четерекле темаларны гына түгел, берниндиі бәхәс уятмый торганнарын да, артында көчле терәген юк икән, үткәрүләре, ай-һай авыр. Казан телдә фән үзәге дип йөртелсә дә, аның хокукы үксез бала хокукыннан да кимрәк иде. Гуманитар фәннәр буенча диссертация яклау советы да булмаган шәһәр нинди фән үзәге булсын ди инде ул? Татар теленең кушма җөмләләр төзелеше буенча язылган докторлык диссертациянне син Алма-Атага яки Бакуга барып якларга тиешсең.

Кәшшаф та бик күп ишекләрне кагып, бик күп бусагаларны таптады. Йөри торгач, СССР Фәннәр академиясе Тарих институтының кафедра мөдире профессор Дмитрий Олегович Волчек тарафына барып ирешә. Ашказарскийның абруе булышты.

Кабинеты зур түгел. Җиһазлары да гадәти. Гап-гади өстәл-урындыклар. Диваны таушалып беткән, шыгыр-шыгыр килә, күптәнге, күрәсең. Аның урынына китаплар бихисап. Инглиз, француз телендәгеләр дә шактый. Берничәсе ачык килеш өстәл өстендә ята. Бүлмә хуҗасы, димәк

ки, алардан да файдалана. Без үз ана телебезнен тарихын да юньлебашлы белмибез, дип офтанып куйды Кәшшаф.

Волчекның гәүдә-сынын килешле дип әйтеп булмый иде. Ул туч иттән генә тора. Сөйләшкәндә көмәчтәй кабарынкы калын иреннәре дерелдәк шикелле дерелли, кайбер сүзләренен мәгънәсенә тора-тора гына төшенәсең.

—Что, батюшка, Махмут Имамутдинович не успел, да?—дип, профессор кысык күзләре белән Кәшшафка текәлде. Кәшшафка әлеге сүзләр "не умер, да?" дип ишетелде. Ни әйтергә белми аптырап калды. Ә кабатлап сорарга кыймады. Волчек үзе ярдәмгә килде.

—Царство ему небесное, прекрасный был человек.

—Житешә алмадык Дмитрий Олегович, көтелмәгәндә булды бит.

Профессор аны тыңламый иде инде. Саргылт керфекләрен җилпеп алды да, күзләрен йомды. Шул халәтендә мәрткә киткән кеше кебек кәнәфиендә хәрәкәтсез калды. Кәшшаф тын алырга да кыймый. Шулай шактый гына вакыт үткәч, ниһаять, Волчек үзенен исән-сау икәнен белдереп, иреннәрен ялмап куйды. Һәм берни булмагандай көр тавыш белән сөйләп китте:

—Сез, атакай, вак милләт вәкилләре, бөеклек чире белән чирлисез. Әйе, әйе. Шуны раслау өчен әллә нинди каганатлар, әллә нинди империяләр уйлап табасыз. Янәсе, сез кайчандыр зур халык булгансыз, дәүләтегезнең чикләре океаннан океанга, диңгездән диңгезгә сузылган булган. Әйтегез әле мина, атакай, ул океаннан океанга сузылган дәүләтләрне кайсыгызга гына житкерергә соң? Җир шары камыр түгел бит ул, атакай, сузылмый да, җәелми дә. Таш гасырдан ук бабаларыгызны эзләп азапланасыз. Синен шикелле бик үҗәт башкорт галиме палеолит чоры кешесенен башкорт милләтеннән икәнен исбатларга алынган. Милли тарих ул, атакай, язма истәлекләр, дәүләтләр барлыкка килгән, конкрет бер халык конкрет җирлектә оешкан чордан башлана. Аннан алдагысы да тарих, әлбәттә, ләкин ул гомуми тарих.

Профессор графиннан су эчте дә сүзен дәвам итте.

—"Халыклар күчеше" дә, атакай, сезнең ул купшы теорияләрегезне челпәрәмә китереп ташлый. Чөнки бу процесс туктаусыз дәвам итә. Бүген дә. Ышаныгыз, озакламый, кемнең нинди милләттән икәнен аерып та булмаячак. Вак милләтләр йотылачак, шул исәптән французлар да, немецлар да...

—Ә руслар?—дип үз соравын кыстырырга җөрьәт итте Кәшшаф. Хәер, ул монда лекция тыңларга килмәде. Өстәвенә, картның фикерләре дә үзе кебек үк буталчык икән.

Волчекның йөзе чытылды, әмма ризасызлыгын тышка чыгармады, иреннәрен бөрештереп Кәшшафка сөзеп бер карады да:

—Руслармы, руслар чырыш халык,—диде. Янә вәгазен ялгап китте. —Тарих фәне гадел, принципиаль булырга тиеш. Бәйсез. Соңгысы иң мөһиме. Яраклашу—иң зур фаҗига. Алтын Урда сазлыгында да бик күпләр ятып калды. Сак бул. Эзоп теле белән фикерләренне, атамаларны башка төргәккә төрергә тырышсаң да, диссертациянда Алтын Урда менә мин дип чәчрәп тора.

Тагын да бер киңәшем: һәр халыкның тарихы дөнья тарихы белән аерылгысыз рәвештә бәйләнгән. Аны бүлгәләргә ярамый. Милли тарих шунын бер бик кечкенә генә өлеше. Сез милли үзәнны үстерәбез дип аны абсолют дәрәҗәсенә күтәрергә омтыласыз. Үз тиресендә генә чокынган тавык хәленә калырга ярамый, бу сукырлыкка китерә. Киңлек, масштаб зарур, атакай, масштаб!

Волчек "лекция"сен ничек капылт кына башлаган булса, шулай ук капылт кына тәгәлләде дә. Муены белән тоташкан башын янә күкрәгенә салып, күзләрен йомып ял итеп алды. Аннан соң:

—Җә, җә, беләм ич инде, бүләккә бүрек алып килгәнсең, утка чыдам пыяла чәйнек...

—Дмитрий Олегович... мин... ни... кунакханәдә әле...

Кәшшаф үз ялганыннан тотлыгып калды.

—Шаяртам гына, атакай, миндә алар болай да бер букча, дип мыгырданды профессор.

Үпкәләттем дип коты качты Кәшшафның. Күчән баш, үзеннең акылына килмәсә, сораштырырга була иде ләбаса! Аяк чалмагае, кәефе кырылды бугай. Дөрес, диссертация әле тикшерү стадиясендә генә. Бер кирегә киткән эш шулай инде ул. Бәлки әле, борчылырга урын да юктыр. Сынап каравы гына булгандыр. Белмәгән-нитмәгән кешегә бүләк төртү үзе үк куркыныч гамәл. Әгәр кире какса, дау куптарса? Капканны ябып куярга да күп сорамаслар.

Кәшшаф соңыннан ачыклады, чыннан да, казанлылар Мәскәүгә бүрек, профессор әйткән әлеге утка чыдам пыяла чәйнекләрне ташыйлар икән. Чиновниклар мона күнгән икән инде.

Бер ике-өч ай үткәч, ул үзе дә шул традицион Казан бирнәләрен култык астына кыстырып янә башкалага чыгып китте.

Волчек аны көттермичә кабул итте. Дустанә күренә. Кәшшафның эченә жылы йөгерде. Димәк, мәсьәлә уңай хәл ителгән! Бу минутта аңа бу ит бүкәне чибәр егет кебек тоелды. Озын-озакка сузмыйча тәжрибәле дуслары кинәшен тотып, төргәкләрен шифоньер эченә куйды. Профессор аның бу гамәлен дәшми генә күзәтеп торды. Каршы килмәде, монысын да яхшыга юрады Кәшшаф.

Волчек, ниһаять, өстәл тартмасыннан аның папкасын тартып чыгарды. Кызыл тышлы папка ул. Урта бер жиренә диссертациянен темасы, Кәшшафның исеме-фамилиясе, адресы язылган ак кисемтә беркетелгән. Ул аны дөм карангыда да таныр иде.

Профессор зур итләч учларын папка өстенә салды. Папка күренмәс булды.

—Теге вакытта гаделлек, бәйсезлек, принципиальлек дип сафсата сатканы өчен гафу ит бу картлачны, атакай,—диде күтәрелеп карамыйча гына,—диссертациянне үткәрә алмадым. Казаннан безнең хуҗа исеменә шикаять жибәргәннәр. Хәмитовның хезмәтен планга кертсәгез, Үзәк Комитетка, ВАКка язачакбыз дип янаганнар. Менә шул, Алтын Урданың сәгате сукмаган әле, күрәсең.

Кәшшаф коелып төште, тоемлау хисен югалтты, әйтерсең лә, аны бозлы бәкегә чумдырып алдылар. Нидер әйтәсе килә, теле әйләнми, чыгып китәр иде аяклары йөрми. Бу хәлдән аны телефон чылтыравы арындырды. Волчек сөйләшкән арада ул акрын гына бүлмәдән чыгып шылды. Ә кичке якта профессорның секретаре бүләк төргәкләрен кунакханәгә китереп китте.

Ялгышкан остазы, Мәскәү дә сайлап кына ярдәм итә икән шул.

Кәшшаф бу фажигане авыр кичерде. Күзенә бер кеше күренми, берсе белән дә сөйләшәсе килми. Барысы да аннан көлә, мыскыл итә кебек. Шуңа күрә таныш табибы аша бюллетень юнәтеп, сукыр тычкандай үз оясына кереп посты. Ул бервакытта да хәмер белән дус булмады. Эчсә дә буена сеңдерә белә иде. Аптыраган аракы эчәр, үтә аптыраган коега төшәр дигәннәре хак булса кирәк. Кәшшаф та шушы Иблис төкрегенә башын салды. Бикләнеп эчте. Баксаң, хәмер дөньясы бөтенләй башка икән ич. Ул бу мәшәкатьле, көйсез тормышка бөтенләй ошамаган. Үзенне чәчәктән чәчәккә кунып очучы күбәләк сыман хис итәсең. Җинел, рәхәт, күнелле. Уйлар да жинел. Жә, ярар, диссертация үтмәде ди. Шуннан нәрсә? Баш ярылып, күз чыкканмы әллә? Юк. Әнә, Жир шары да элеккечә үз күчәре тирәсендә әйләнә, кояш та вакытында чыгып, вакытында байый. Тарих! Нигә кирәк ул тарих? Иске-москы арасында әвәләнүнен кемгә файдасы бар? Алтын Урдаларның инде көле күккә очкан. Бүгенге көн турында кайгыртырга кирәк. Ә ул аны хәл итеп куйды инде. Авылга китәчәк Кәшшаф. Шагыйрь әйтмешли, яшәсеннәр үзләре калаларында. Төкерә ул Казанына да, институтына да, диссертация-

сенә дә! Нигә ул монарчы шушы рәхәтлекне белмичә яшәде икән? Бер дә кирәкмәгәнгә күпме гомерен тирес корты кебек чүп-чар арасында казынып үткәрде бит, ә?

Һәрнәрсәнең чиге бар. Өч көннән соң Кәшшафның тамагына хәмер үтми башлады. Тырышып-тырышып йотуы була, косып җибәрүе була. Интекте. Башы чатный, тәне калтырана, күнелендә шом. Менә-менә йөрәге туктар шикелле. Ул урамга чыгып, институтка шылтыратты:

—Әлтаф, мин үләм, тизрәк килеп җит,—диде.

Дусты озак көттермәде. Кәшшаф аңынчы бүлмәсен җыештырырга чамалап караган иде дә хәле китеп ятагына ауды.

—Махмыр бит синдә, кәтәнә,—диде Әлтаф дустының иске чүпрәк кебек асылынган-салынган кыяфәтен күздән кичергәннән соң.—Күр инде, Батый явы үткәнмени? Ярар, миннән күр яхшылык, рәтлим мин сине.

Әлтаф Кәшшафка кайнар чәй эчерде, дару бирде. Ә кичен мунчага алып китте.

* * *

Институтның конференциягә хәзерләнгән көннәре иде. Ул татар халкының килеп чыгышы темасына багышлана. Бик мөһим конференция. Чит мәмләкәтләрдән дә кунаклар көтелә. Татар милли тарихына кагылышлы беренче зур җыен. Шуңа күрә барысы да дулкынлана.

Галимовның бүлмәсе хәрби штабны хәтерләтә иде. Берсе керә, берсе чыга, көтеп утыручылар да күп. Директор кәнәфиендә Галимов күптәннән утыра. Оештыру сәләте зур, бик эшлекле җитәкче. Булдыклы. Ләкин ул фәндә рәсмилек киртәсен үтеп чыгарга җөрьәт итмәде. Аның өчен һәрвакыт җитәкче даирәләрнең сүзе сүз булды. Билгеле инде, Алтын Урда дәүләтен ул хәзерге татарларның дәүләте дип санамый. Шуңа күрә Кәшшафка да мөнәсәбәте үзгә. Аның өчен ул күзгә кергән кылчык.

Мәскәүгә шикаять язуда да Галимовның кулы уйнамады микән дип шикләнә Кәшшаф. Һәрхәлдә, бу татар халкының килеп чыгышы мәсьәләсендә Болгар теориясе тарафдарларының казынуына охшаган. Галимов исә әлеге агымның иң күренекле, иң абруйлы вәкиле, лидеры. Әлбәттә, директор башы белән үз хезмәткәре өстеннән шикаятьләр язып ятмас, аның кулында батыруның башка ысуллары да күп. Ялагай эт шикелле күзенә генә карап торучы куштаннары бихисап. Фәнни эшләр буенча урынбасары Тәфкилев шуларның иң турылыклысы. Хобәй белән Гобәй шикелле һаман бергә йөриләр. Югыйсә, Тәфкилев Галимовка тиң кеше дә түгел. Гыйльми егәрлеге бик чамалы. Кайчандыр директорның шоферы булып эшләгән. Күрәсең, шул вакытта бик якынлашып калганнар. Хуҗасы өчен утка-суга керергә әзер. Директор да аны шуның өчен тота булыр.

Тәфкилевтән теләсә-нинди этлекне дә көтәргә мөмкин. Хуҗасы өстерсен генә. Кәшшафка ул болай да өрми үтми. Мөнәсәбәтен хәтта яшерүне дә кирәк санамый. Кәшшаф бервакыт аның үзенә дә күзләренә туп-туры карап: "Сез генә батырдыгыз мине",—дигән иде. Тәфкилевнең бу сүзләргә кәефе генә килде.

—Хикмәт шикаятьтә түгел, Хәмитов, хикмәт эшеннең зарурлыгында,—дип тешләрен ыржайтты.

Галимов, кагыйдә буларак, һәр докладчы, һәр чыгыш ясаучы белән аерым-аерым сөйләшеп чыкты. Чират, ниһаять, Кәшшафка да җитте. Директор аны ишекле-түрле йөргән хәлдә кабул итте.

—Сезнең докладны пленар утырышның көн тәртибеннән алырга туры килә,—дип, Галимов бер мәлгә аның янында туктап калды. Берберсенә карашып тордылар.—Оештыру комиссиясе докладыгыз тенденциоз дигән нәтиҗәгә килде. Аннан соң, сезнең гыйльми дәрәҗәгез дә юк бит әле. Ә конференция бик мәртәбәле булачак, академиклар, членкорлар катнашачак.

—Компетентсыз димәкче буласыз инде,—диде Кәшшаф ачуын

күрсәтмәскә тырышып.—Оештыру комиссиясе сез үзегез ич инде ул. Докладка килгәндә, борчылмагыз, мин аны ишәйтеп, конференциядә катнашучыларга үзем таратачакмын. Фәндә барлык юнәлешләр дә яшәүгә хаклы.

—Фән, имеш, юнәлеш, имеш. Сезнең соң диссертациягезне яклауга да кабул итмәделәр ич.

Кәшшафның эч-бавырлары бөрешеп бугазына менде. Күр, ачыктан-ачык мыскыл итә бит. Ләкин дорфалыкка дорфалык белән җавап бирергә ярамый. Тешне кысып булса да түзәргә кирәк.

—Яңалык авырлык белән юл яра инде ул, Сәубән Сәубәнович,—диде Кәшшаф,—без болгарларга да каршы түгел, әмма татар халкының чын тарихы Алтын Урдадан башлана. Аннан соң, минем диссертация сәяси сәбәпләр нәтиҗәсендә кире кагылды. Шөкер, соңгы ике-өч ел эчендә аның актуальлеге артты гына. Югыйсә, сез минем белән болай сөйләшеп тә тормас идегез.

—Миңа нотация укымагыз,—дип бүлде аны Галимов.—Белегез шуны, үзем исән чакта милли тарихка ревизия ясарга ирек бирмәячәкмен!

Кәшшафның мондый янауларны беренче мәртәбә генә ишетүе түгел. Галимов, һичшиксез, төрле сәбәпләр табып, аны институттан да куа алыр иде. Ләкин заманалар үзгәреп китте. Демократия җилләре сүздә генә булса да институт эченә дә үтеп керде. Директорның да үзен демократ итеп күрсәтәсе килә. Шуңа күрә әлеге чеметүле төртмә сүзләрне ул кеше арасында әйтми, ачуын икәүдән-икәү калгач кына чыгара. Ул татар тарихының бердәнбер хуҗасы булудан туктады. Университетта, әнә, гыйльми совет оешты. Хәзер диссертацияләрне Казанның үзендә дә яклап була. Һәрхәлдә, мөмкинлекләр артты. Ләкин Кәшшафны элекке хезмәтләре канәгатьләндерми инде. Ул өр-яңа монографиясен язып бетерде. Хәзер менә шуны җәмәгатьчелеккә җиткерергә кирәк. Шул хакта баш ватуы.

Директорның да эше муеннан. Көн аралаш киңәшмә уздыра, һәр мәсьәләне җентекләп ачыклый. Киләчәк кунакларның, делегатларның тәрҗемәи хәлләренә кадәр бөртекләп өйрәнә. Кемне кайда, кем белән урнаштыру, культура хезмәте күрсәтү, экскурсияләр, банкет—барысы да аның вак иләге аша уза. Конференциядән шаккатып китәрлек булсын, күргән-белгәннәрен башкаларга сөйләсеннәр. Таралсын институтның даны!

Гыйльми эшләрдән тыш һәркемгә яңа вазифалар да өстәделәр. Кәшшаф, мәсәлән, конференция уңае белән чыгарыла торган басма әсбаплар өчен җаваплы иде.

Кәшшаф Заһидәне икенче мәртәбә шул мәшәкатьләр артыннан йөргәндә очратты. Өстендә ап-ак кофта иде, тал чыбыгыдай нәфис гәүдәсенә сыланып торган кара итәк, аякларында биек үкчәле түфли. Чибәр. Әлтаф әйтмешли, борынга бөтереп тыгарлык. Бу сылубикәгә кем кул салырга батырчылык итә икән, дип уйлады Кәшшаф.

—Мин галимнәр әллә яшелчә базасында гына өлгерлек күрсәтәләрме дип йөри идем, бик һәйбәт йөкче дә икәнсез ич әле сез,—диде Заһидә көлә-көлә. Сүзне кеше кесәсеннән эзли торганнардан түгел икән. Ә тавышы! Диктор Камал Саттарованыкы шикелле бизәкле, аһәнле тавыш.

Төнлә белән дә шул гөлдер тавыш колагына керде Кәшшафның. Нindидер ләззәтле халәттә уянып китте. Моннан күп еллар элек булган бер вакыйга хәтеренә төшеп, күңелен уеп алды. Унынчы класста укыганда Сәмига исемле бер укытучы кызга үлеп гашыйк булган иде. Көндезләрен артыннан күзәтеп йөри, төннәрен исә хыял дингезендә йөзә. Чик-чамасыз хыял. Сөйгәнен әле янгын ялмап алган йорттан күтәреп алып чыга, әле бозлы суга кереп коткара. Ул да булмый, бәйләнчек адәмнәрне пыран-заран китереп ташлый. Кыз, билгеле инде, аның кыюлыгын, тәвәккәллеген бәяли, куенына сыена

Яшерен сөю—кысыр сөю. Сәмига бу хакта үзе белмәде. Белсә дә, көләр генә иде, мөгаен. Бәлки, юктыр да. Үзен яратканны яратмаган хатын-кыз буламыни?

Мәңгегә килгән сыман тоелса да, акрынлап бу тормышка ашмас

хис сүнде. Ләкин янә кабынырга сүнгән булган икән. Һәм тагын кысыр сөю. Киракcез, мәгънәсез. Йөраккә дә, күнелгә дә артык йөк.

Кәшшаф сукыр чебен шикелле ябышкан бу хисне куарга, битараф калырга тырышты. Тик йөрәк үзе белән шаярганны өнәми бит ул. Бер француз чибәре әйткән, имеш: "Минем өчен һәр яна ярату беренче мәхәббәт кебек" дигән. Бу, ихтимал, мәхәббәткә карата чыгарылган иң дөрес бәяләмәдер.

Ходай шаһит, Кәшшаф ана чын күнеленнән карышты, чәбәләнде. Тик бер институтта эшләгәч, очрашмый-күрешми дә булмый.

Язганны күрерсең, чәчкәнне урырсың, ди, көннәрдән бер көнне бүлмәсенә Заһидә үзе килеп кермәсенме. Аларнын танышлыгы да ташкаулчим генә иде ич әле. Идарә бүлмәсендә әйтешкән бер-ике сүздән ары узганнары юк иде.

Кәшшаф генералны хөрмәтләгән хәрби шикелле үрә катты.

—Кәшшаф абый, мине алыгыз әле, зинһар,—диде дә Заһидә көлеп җибәрде. Аннан соң гына сүзләренә ачыклык кертте.—Профессор Каюмов сезгә мөрәҗәгать итәргә кушкан иде. Мин быел университетны тәмамлыйм бит, диплом эше язам. Җитәкче кирәк иде.

Кәшшаф, чыннан да, университет белән яхшы элемтәдә тора, дипломчылар алгалый. Ничә әйтсән дә, азмы-күпме акчасы килә. Менә бу чибәр ханымга да кирәге чыкты.

—Белмим шул,—диде ул икеләнгәндәй.

—Хатын-кыз үзе алыгыз дип тора... Ә сез?

Заһидә каш астыннан гына күз сирпеп алды: әллә шаяртуны аңламады инде?..

Кәшшаф акланырга ашыкты.

—Мин сезне институтка диссертация яклау унае белән килгәнсез дип уйлаган идем... күпләр шулай эшли бит хәзер...

—Әле укуны төгәллисе бар.

—Ә... нишләп...

—Нишләп сонардыгыз димәкчесез, шулаймы?

—Әйе.

—Анысы башка тема, Кәшшаф абый. Бу хакта дипломны югәнда сөйләшербез.

* * *

Кәшшафнын куен дәфтәренә Акмулланын бик гыйбрәтле икеюллыгы теркәлгән.

> Имгәнеп коры юкка азап чикмә,
> Бакыр чыкмас урыннан алтын казып.

Юк, ул тәрәзәдән кергән ай яктысына ябышып, күккә менә торган хыялый затлардан түгел. Сәләте дә бар, тырышлыгы да җитәрлек. Тик Ходай шулай яраткандыр инде, әбе килсә, җәбе килми, җәбе килсә, әбе килми. Анын бер гамәле дә кешенеке кебек булмады. Гаилә коруын гына ал. Әнисе мескенем күпме тырышты, "йөрмә болай адәм мәсхәрәсе шикелле, башлы-күзле булырга вакыт", дип авыз суларын корытып ялвар-ды. Димләп тә карадылар. Кәшшаф исә: "Мина кызлар карамый",—дип җүләр кеше сыман авызын гына ерды. Ә үзе һич көтмәгәндә бер төн эчендә өйләнде дә куйды.

Бу хәл Беренче май көнне булды. Әлтаф аны бәйрәм мәҗлесенә чакырды.

—Китап тузанынннан чехотка эләктергәләгәнче җимереп гөләйт итеп калырга кинәш итәм, минем бер танышларымда аулак, гармунынны култык астына кыстыр да сәгать алтыга килеп җит,—диде.—Ләкин кисәтеп куям, хуҗа кызга нәфсенне сузасы булма. Ул инде тамгалы, үземә ниятләп торам.

Кәшшафны бөтенләй башка нәрсә борчый иде. Кыз турысындагы сүз колагына да кереп чыкмады.

—Минем уенга, ай-һай, кем биер икән?

—Һи, исең китмәсен, чыланып алгач, тукмак та сикерә,—дип үзенекен тукыды Әлтаф.

Кәшшаф кечкенәдән гармунга мөкиббән иде. Тик ныклап уйнарга гына өйрәнә алмады. Хәер, гармуны да юк иде ич. Алай дисәң, авылның оста уйнаучылары да башта клуб гармунында бармак яздылар бит. Берсендә Кәрим исемлесе карангы мунчага алып кереп, Кәшшафның бармакларын үз бармакларына бәйләп тә өйрәтеп карады. Өйрәтүнең шундый алымы да булган, күрәсең. Тик аңа карап барыбер осталыгы артмады. Шул чакта, үсеп җитеп, кулга акча кергә, гармун сатып алам, дип үз-үзенә сүз биргән иде. Вәгъдәсендә торды.

Университетка укуга кергә, бүлмәдәшләренә ияреп, Идел буена көнлекле эшкә йөри башлады. Гәүдәгә таза егетне эләктереп кенә алдылар. Өстәвенә, авыл баласы чырыш та була. Шуңа күрә студент—эшчеләр арасында бик тиз үз урынын тапты. Һәм беренче эшләп алган акчасына комиссион кибеттән ике рәтле хромка гармуны сатып алды. Шуннан бирле күнеле үрсәләнгән шатлыклы вакытларында да, моңсу вакытларында да кулына гармун ала. Ул фәкать үзе өчен генә уйный. Ә Әлтаф мәҗлес дип аһ ора. Барыбер үз дигәнен итте, Кәшшафны ризалаштырды.

Аулак өйнең хуҗабикәсе Дәрига исемле кыз иде. Тимер юл вокзалы янында үз йортларында яшиләр икән. Әти-әнисе каядыр чит шәһәргә кунакка киткән ди.

Көн чалт аяз иде. Әмма салкынча. Шуңа күрә кояш та җансыз, кысыр елмаю белән елмая. Шәһәргә Идел ягыннан искән котсыз җил хуҗа. Таш диварларны, бормалы урамнарны шыксыз кочагына кыскан. Тик ничек кенә тузынмасын, усал җилбикә бәйрәм күтәренкелегенә йогынты ясый алмады. Халык гөж килә. Шәһәр кызыл комачка, кәгазь чәчәккә төренгән. Җыр, музыка, уен-көлке.

Кәшшаф колхоз базары тукталышында троллейбустан төшеп калды да сәүдә павильонына узды. Хуҗабикә бик затлы кыз, чәчәксез килә күрмә, дип кисәтеп куйган иде аны Әлтаф. Ә базарга, гүя Кавказны күчереп утырткаңнар. Ат башыдай зур, тулы йөзле, ыргак борынлы, бияләй кебек калын кашлы дәү-дәү абзыйлар шау-гөр килеп җиләк-җимеш, чәчәк саталар. Барысының да башында вертолет төшеп кунарлык бинһаһая зур канатлы чем кара кепка. Һәрберсе үзенә өнди.

—Дарагой, сэ-мый ывкусный бинаград. Язык праглатиш.

—Не прахади мима, на прубый, нигде нэт такой яблыкы.

—Их, какой ысветок, эвсе дэвушки тваи будут, бери дарым отдаю.

Казанлылар бәйрәм итәләр, кавказлылар акча эшли.

Кәшшаф кайсы сатучы янына барып төртелергә белмичә берара тирә-якны күзәтеп торды. Кече фәнни хезмәткәрнең акчасы күке төкреге генә, әллә ни җәелеп китә алмыйсын. Әле бит, эчемлек тә, ризык әйберләре дә аласы бар. Буш кул белән барып булмый.

Аның игътибарын олырак яшьтәге бер сатучы җәлеп итте. Башкалар шикелле тузынмый, тыныч кына басып тора. Чәчәкләре купшы, чибәр. Әйтерсең лә, түтәлдән генә өзеп алганнар.

—Минем чәчәкләр кыйммәт,—диде ул Кәшшафның хәленә кергәндәй,—кичә генә самолет белән китерделәр.

Сатучының түбәнсетеп каравы Кәшшафка ошамады.

—Миңа иң яхшы өч канәфер чәчәге сайлагыз,—диде эре генә.

—Берсе-берсе өч тәңкә!

—Әйттем ич инде, сайлагыз дидем!

Кәшшаф кызуы белән грузинның кайтарып биргән акчасын санап тормыйча гына бөгәрләп кесәсенә шудырды. Инде кибеткә сугылырга кирәк. Рәте ничегрәк икән? Ул читкәрәк китеп, акчасын барлап алды. Бер кат, ике... Ә акча нишләптер кимемәгән, киресенчә, арткан! Грузин

ялгышкан, күрәсең. Нишләргә? Кире илтеп бирергәме? Бәлки, үзе саташадыр? Алдатырсың грузинны. Спекулянт ич ул. Хәрәм оясы.

Шул рәвешле исәп-хисап итеп уйланып торганданиндидер тавышка сискәнеп китте. Борылып караса, теге ике иякле грузин! Итләч беләкләрен буташтыра-буташтыра базар тутырып кычкыра:

—Вай-вай, таладылар... милиция, милиция!..

Кәшшаф шыр җибәрде. Чөнки тота-нитә калсалар, аны бур итәчәкләр, аклана алмаячак. Шуна күрә бу нахак акчадан котылуның башка берәр чарасын уйлап табарга кирәк. Шунда ул сәләмә киемле бер карчыкны күреп алды. Аркасына биштәр аскан, кулында таяк. Бик авыр атлый. Кәшшаф карчыкның каршысына йөгереп барды да: "Әбекәй, мә хәер, дога кылып ал",—дип әлеге акчаны ана тоттырды.

Карчык каушавыннан сүз дә әйтә алмый калды.

Дәригаларның йорты бакча түрендә утыра. Кая карама, җимеш агачлары. Каралты-кура буяулы. Шуна күрә курчак дөньясына охшап тора. Агач-куакларның күбесе инде яфракланган. Алмагачларның гына бөреләре ачылып җитмәгән, җылы көннәрне көтеп утырулары.

Кәшшаф бераз вакыт капка янында таптанып торды. Чөнки коймага: "Сак булыгыз, усал эт бар",—дип язылган такта эленгән иде. Ә аның сөймәгәне эт.

Эзләнә торгач, электр кыңгыравының төймәсен күреп алды. Төймәгә басуга сукмакта Әлтаф пәйдә булды.

—Ялындырып кына йөрисең, малай, ә?—диде үзенә хас шаярту белән,—көтә-көтә абыстайлар кабарып бетте анда.

—Эт бәйдәме?—дип сорады Кәшшаф койманың теге ягыннан.

—Мин ана кызлар турында тукыйм, ә анда эт кайгысы.

—Соң.

—Бәйдә-бәйдә, тыныч бул, әйдә, уз.

Ул арада буылып-буылып эт өрә башлады. Чит кешенең исен әллә кайдан сизеп ала, каһәр. Котырыныпмы-котырына, чылбырыннан ычкынса, ботарлап ук ташлар иде, мөгаен.

Тавыш-гауганы ишетеп булса кирәк, болдырда бөдрә чәчле бер кыз күренде.

—Босс, урыныңа!—дип әмер бирде ул.

Эт шунда ук оясына кереп посты. Кара, күз дә буа белә икән бу, дип уйлап куйды Кәшшаф кыз турында.

—Таныш бул, безнең бәйрәмнең йолдызы вә хуҗабикәсе Дәрига туташ,—дип таныштырды Әлтәф.

—Бәйрәм белән котлыйм,—диде Кәшшаф һәм кызга әлеге мажаралы чәчәк бәйләмен сузды. Дәригага чәчәкләр бик ошады булса кирәк, бер тын йөзенә терәп хозурланып торды.

—Рәхмәт сезгә, шатландырдыгыз.

Дәрига терекөмеш шикелле тиктормас зат икән. Җилдәй очып кына йөри. Кич буе күләгәсе күмелеп тормады. Кәшшаф үзе авыррак аяклы. Шуңа күрә хуҗабикәне кызыгып та, гаҗәпсенеп тә күзәтеп утырды. Ыспай, төзү. Барысы да үз урынында, барысы да үлчәп ясалган кебек, артыгы да, ким җире дә юк. Тик барыбер нидер җитми кебек. Кәшшаф шул хакта баш ватты. Уйлана торгач, аңлады тәки, җылылык, мөлаемлык җитми икән ләбаса кызда.

Әлтаф, гадәтенчә, мәҗлеснең дилбегәсен үз кулына алды. Сүзгә бик маһир егет ул, теле тегермән шикелле, бертуктаусыз тарттыра да, тарттыра. Әле дә сайраргә тотынды:

Юмартны утырттым югары,
Саранны утырттым сәкегә;
Юашны утырттым янга,
Гаделне утырттым алга;
Яхшыны утырттым унга,

Яманны утырттым сулга;
Усалны утырттым ушага,
Оятсызга ярар бусага.

—Читтә калган кеше юкмы, булса, кулыгызны күтәрегез. Юк, димәк ки, куллар күтәрелмәде. Мәҗлесне башлап җибәрәбез. Шушы унайдан бер табышмак тәкъдим итәм. Каршылар юкмы? Юк, әлбәттә. Булуы да мөмкин түгел.

—Сафсата сатма, табышмагыңны әйт,—диде кемдер.

—Сабыр, җәмәгать, сабыр, кем икәнемне беләсез, саруымны кайнатмагыз.

—Сузма инде.

—Хуш, бик хуш. Инде күз алдыгызга китерегез. Чүл. Тирә-якта ком, ком, ком. Кояш кыздыра. Һич чыдар әмәл юк. Шул утлы табада ике мосафир, берсе хатын-кыз, икенчесе ир-ат. Каядыр барулары.

Син күр дә, мин күр, тегеләрнең алдында бинибая зур сандык пәйда булмасынмы. Сорау: ир-ат мосафирның башына нинди уй килә дә, хатын-кыз мосафирның башына нинди уй килә? Беренче сүз егетләргә.

—Бу сандык эчендә сулы савыт юкмы икән?

—Сандык өстенә утырып ял итеп алыргамы әллә?..

Әлтаф ике бармагын тырпайтты.

—Житте, булды, егетләр, сезнең өчен миңа оят, ир-атларның абруен гына төшерәсез бу килде-китте җавапларыгыз белән.

—Ә дөресе ничек?

—Шөрепләре исән егетнең башына үзеннән-үзе шундый сөаль килергә тиеш иде: каян килеп чыккан бу сандык монда?

—Инде, кызлар—чәчәкләр, чират сезгә килеп житте. Җә?

—Җиңүчегә нинди дә булса бүләк булачакмы соң?—дип белеште Дәрига.

—Әлбәттә! Татарның булачак бөек профессоры Кәшшаф әфәнде җиңүчегә үзенең кайнар иреннәрен бүләк итәчәк.

—Ура!

—Бүләк дисәң дә бүләк!

Кызлар чәүкә көтүе сыман чыр-чу килеп алдылар.

Кәшшафның исә бу көтелмәгән хәбәрдән зиһене чуалды, чөгендер кебек кызарып чыкты. Ничек инде, вәйт дуамал, дип эченнән генә Әлтафны сүкте.

—Кемгә беренче итеп сүз бирәбез?—диде Әлтаф дустына илтифат та итмичә.

—Мин,—диде Дәрига.—Моның җавабы гап-гади: Җир шарындагы теләсә-нинди хатын-кызның башында бу очракта фәкать бердәнбер сорау гына туа ала: бу сандык эчендә нәрсә бар икән, дип уйлый ул.

—Афәрин!

—Ай-да, молодец!

Кәшшаф сыгылып төште. Чөнки Дәрига тигез ак тешләрен балкытып аның янына килеп баскан иде.

—Күрсәт егетлегеңне, галим-әкә,—дип гөрләде Әлтаф,—вә ләкин онытылып китмә...

Кәшшафның иреннәре кызның иреннәренә кадәр барып житә алмады, ияк очында тукталып калды.

Кичә уен-көлке, жыр-бию белән бергә үрелеп барды. Кәшшафның гармун тарткалавы да ярап куйды. Дәрига бик оста бии икән. Гәүдәсе гүя сөяксез, әллә ничекләр итеп сыгыла, бөгелә, урала. Үзе һаман Кәшшаф янында кайнашты. Савыт-саба жыйганда да, аш-су чыгарганда да аңа мөрәҗәгать итә, булышуын үтенә. Тора-бара табын икесенең жилкәсендә калды. Әлтаф кунаклар янында, һәммәсенең күңелен күрергә тырыша.

* * *

Кәшшаф уянгач озак кына күзләрен ачарга кыймыйча ятты. Чөнки эчке бер сиземләү белән күкрәгендә шәрә кул ятканын тоеп алган иде. Хатын-кыз кулы. Димәк, мәҗлестән соң куна калган. Һәм...

Ул кичә булган хәлләрне хәтерендә янартырга чамалап карады. Ләкин ахырына кадәр житәргә жөрьәт итмәде. Күкрәгендә яткан кулга жинелчә генә бармагы белән орынып алды. Шик юк, бу Дәрига кулы. Кәшшаф бер күзенен кырыен гына ачып карады. Урын-жир Дәриганын пумаладай чуалып беткән чәчләре белән тулган иде. Рәхәткә чыккан, тәмле итеп йоклый.

Нишләдем мин, дигән уй Кәшшафнын йөрәген кисеп узды. Әлтафка ни дип жавап бирер? Ул мокыты нәрсә карап торган соң? Нәфсенне сузма, имеш. Үзе сөйгәнен кеше куенына керткән. Шулай итеп, эшләр зурга китте булып чыга микәнни өйләнергә туры килер микәнни инде? Кырык эше кырык якта таралып ята. Әйбәт фатиры юк, диссертациясе тар-мар килде. Кесәсе тап-такыр. Хатын тотарлыкмы соң анын хәле?

Ихтимал, бу болай гынадыр, борчылырлык бернәрсә дә юктыр? Әлбәттә инде, исерек иде ич ул, ятып кына торганнардыр?

Дәрига күпчелек шәһәр кызлары кебек тапкыр, тәвәккәл, үзсүзле иде. Әйтәсен әйтә, эшлисен эшли. Әле педагогия институтын бетереп, Арча урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты фәнен укыткан чагы. Казанда гына эшләр иде дә соң, жибәрмиләр, институттан соң өч ел эшләргә кирәк диләр. Законы шундый икән. Бу вакытны кыскартунын бердәнбер юлы Казан егетенә кияүгә чыгу. Билгеле, Арчада анын артыннан йөрүчеләр хәттин ашкан. Тик анын авыл килене булып, мал-туар арасында чуаласы, абзар исе жыясы килми. Ә менә Казанда яшәүче авыл егете белән чәчне чәчкә бәйләргә ике куллап риза. Ник дисән, авыл егетләре эшчән, сау-сәламәт, тел-тешсез, тынлаучан һәм үҗәт булалар. Аларны кайсы якка кирәк, шул якка боргалый да аласын.

Әлтаф та авыл егете анысы. Күптәннән сүз кушып йөри. Әмма ул алтынга мансалар да Әлтафнын куенына керә алмас иде. Арыш капчыгы шикелле жәелгән буй-сынын да килештерми. Үзе күп сүзле. Хатыншак ир-егетләрне өнәми ул. Ә Кәшшафны бер күрүдә ошатты. Һәм хатын-кызларга хас ышаныч белән, бу егет минеке булырга тиеш, дип күнеленә беркетеп куйды. Гомере анын китапта казынып үтәчәк. Хатын эшенә тыкшынмаячак. Шәһәр ялкавы вакчыл булу өстенә, итәк артыннан да чаба бит әле ул. Кыскасы, Дәрига тәвәккәлләргә ният калды.

Төн урталарында мәжлес дилбегәдән ычкынды. Исерәселәр исерде, танышасылар таныштьı. Акрынлап таралыша башладылар. Әлтаф та шактый йомшарган иде.

—Мин дусларны гына озатып керәм, кыбырсынмыйча гына көтеп тор,—дип Кәшшафны жыенган жиреннән туктатты.

—Нигә мин сине монда көтәргә тиеш, мин артык кашык...

—Әйткәнне тынла!

Ул арада янына Дәрига килеп басты.

—Әйдәле, Кәшшаф, аулакта рәхәтләнеп бер биик әле,—диде. Шушы тәкъдимне генә көткәндәй Кәшшаф аны биленнән эләктереп алды. Алар араларына кыл да сыймаслык булып укмаштылар. Егетнен куллары үзләреннән-үзләре кофта эченә шуды. Кыз каршылык күрсәтмәде.

—Мин сина бер күрүдә гашыйк булдым, Кәшшаф,—дип пышылдады Дәрига.

—Мин дә,—диде Кәшшаф. Ул тулысы белән кыз карамагында иде.

Дәрига бер жаен китереп утны сүндерде. Хәлләре беткәнче үбештеләр. Хәмердән, хатын-кыз назыннан Кәшшаф тәмам әлсерәде. Әлтаф та, анын кисәтүләре дә—барысы да, барысы да онытылды. Ул үз-үзенә хисап бирер дәрәжәдә түгел иде.

—Дәрига, чык мина кияүгә, гомерлеккә синен белән бергә буласым килә,—дип Кәшшаф кызнын алдына тезләнде.

Дәрига бу көтелгән тансык сүзнең кичәдә үк әйтелүенә өмет тә тотмый иде. Шулай да куанычына ташып чыгарга ирек бирмәде.

—Кәшшаф, бу бик житди тәкъдим, ашыгып әйтмисенме, без бит әле бер-беребезне белмибез дә диярлек.

—Беләсенме, Дәрига, гыйшык турында бер аксакал нәрсә дигән?

—Юк, белмим.

Дәрига егеткә тагын да елыша төште.

—Ул әйткән, ир-егеткә үзенең гашыйкмы-түгелме икәнлеген белү өчен нибары жиде секунд вакыт житә дигән. Ә безнең бергә булган вакытны секундларга салып исәпләсәң, о-о, миллионга житәдер. Гомумән, мәхәббәт ул жә бар, жә юк. Ә минем эчем-тышым мәхәббәт. Менә дәлиле!

Кәшшаф пычак очы белән бармак битен уеп алды да, саркып чыккан канны башта үзе ялады, аннан Дәригага ялатты.

Кәшшаф бу гамәлләрне аерымачык хәтерләмәсә дә, бөтен мәсьәләләрнең дә төн эчендә хәл ителүен чамалый иде. Шуна күрә хәзер үкенүдән файда юк. Булганы булган. Ир-егетнең сүзе бер булырга тиеш. Ул ипләп кенә юрган астыннан чыкты да чәй табыны хәзерләде, Дәриганы уятты. Дәрига оялмады да, унайсызланмады да, үзен Кәшшафның хатыны итеп сизә иде инде.

* * *

Ниһаять, кояш шырпыдай төз наратлар очыннан төшеп, куаклар өстенә кунаклады. Анда да озын-озак юанмады, кызарып-бүртенеп, таулар арасына кереп югалды. Тиздән күл өстен жемелдәтеп торган ал нурлар да сүнде, тирә-якка аксыл томан булып эңгер-меңгер таралды. Чык жиле исеп китте.

—Кузгалыйк булмаса,—диде Кәшшаф,—без олы юлга чыккалаганчы ут алыр вакыт та житәр.

Заһидә дәшмәде, үзенә генә карап куйды. Ул Кәшшафның машина ремонтлаганда кия торган кара сатин халатына уралган иде.

—Кайсы сараегызга боерасыз?—дип шаяртмакчы итте Кәшшаф. Ләкин аның бу урынсыз шаяртуы Заһидәгә ошамады.

—Булдыклы егетләр кергәнче чыгу юлын тәгаенләп куялар,—дип төрттерде.

—Булдыклы булып тумаганмын бит, нишлим соң?—дип үпкәсен белдерде Кәшшаф. Үзе эченнән генә: "Житәрдер ахры, чик куярга кирәк бу уенга",—дип уйлады.

Юл буе бер кәлимә сүз сөйләшмәделәр. Кәшшаф машинасын юри дөн-дын итеп, сикәлтәләрне саный-саный алып кайтты. Борылмалардан тәгәрмәчләрне сызгыртып, выжылдап кына үттеләр. Тормозларга басканда машина янтаеп-янтаеп китә, саклану каешлары кысып тормаса, маңгайларына шеш утырыр иде, шәт. Алай да исән-имин Заһидәләр йортына килеп життеләр. Ул Киров урамындагы зур ишек аллы ике катлы агач йортта яши. Өч гаиләле коммуналь фатир. Ана ничек тә кухнядагыларга күренмичә бүлмәсенә үтәргә кирәк. Кәшшаф машинадан чыга алмый, ул трусиктан гына.

Заһидә төнге жанвар сыман сак-сак кына атлап, баскычтан икенче катка үрмәләде. Монда куркыныч янамый, чөнки бинаның башка өлешеннән ул такта стена белән бүлеп алынган. Өй ишеге бикләнмәгән иде. Эчтә быдыр-быдыр сөйләшәләр. Димәк, гадәттәгечә, кухняда хатын-кызлар ләчтит сата. Монысы яхшы. Андый вакытта аларның күзенә ак-кара күренми, бәлки, хәвефсез генә яннарыннан үтеп китә алыр?

Заһидә бусагадан атлап керде дә кухня белән бүлмә арасын аяк очларында гына йөгереп узды. Кабаланганда син дигәнчә буламыни ул, аягы нindидер савытка килеп орынды. Савыт дөбер-шатыр килеп идән буенча тәгәрәде.

—Кем ул, ни жимерәсен анда?

Тавыш иясе лас-лос атлап ишек катына сөйрәлде.

Заһидә идән ярыгына төшеп кысылырдай булып бөрешеп бетте. Бәхетенә, йозагы ачкыч тыгуга ачылды. Бүлмәсенә керде дә киселгән агач шикелле диванга ауды. Берара хәл җыеп, селкенмичә дә ятып торды. Шуннан соң гына Кәшшафның пижамасын чыгарып бирде.

Кәшшафның хәле Заһидәнекеннән күпкә четереклерәк, күпкә катлаулырак иде. Чөнки ул шушы таланган килеш хатыны каршысына басарга тиеш. Ана Дәриганы ышандырырлык ниндидер бик саллы дәлилләр табарга кирәк. Бу сират күперен үтү белән бер булыр, мөгаен. Дөрес, әлегә кадәр араларында башка хатын-кызга кагылышлы аңлашылмаучылыкның булганы юк иде. Шөкер, мона кадәр бизмән белән гер кебек яшәделәр. Кәшшаф язмышын кабул итте. Ә мәхәббәт килмәде. Ихтимал, килмәс тә. Ләкин гаилә өчен мәхәббәт зарур түгел икән, аны цементлап тоту өчен бала да җитә икән. Бала барысын да бәйләп тора.

Дәрига унган хатын. Анарда ир-ат характеры, вакланып җанны кыймый. Үзе теләгәнчә яши бирә. Хәзер, әнә, укытучылыкны ташлап, бизнеска кереп китте, алыш-биреш кәсебе белән шөгыльләнә.

Дала елгасы кебек дымык кына булып аккан тыныч тормышка Бату ханның Йолдызыдай Заһидә килеп керде. Кәшшафның алга таба язмышы нинди юлдан китәр, анысы билгесез, әмма аның үз тормышын әлегә һич тә бозасы килми. Ул акрын кеше, кискен адымнар ясарга үзен әзер түгел дип саный. Моны акылы да кабул итмәс иде. Тик хис бар бит әле. Хис! Ул йөгәнсез тай һич нәрсә белән исәпләшми, үзенекен итә.

Ирен бу хәлендә күргәч, Дәрига үзен ничек тотар, ни әйтер? Ул сугып алсаң чыгымчылый, сыйпап алсаң йөри, сөеп алсаң юрта, үбеп алсаң чабып китә торганнардан түгел. Уйлана торгач, Кәшшаф күл буендагы хәлне Әлтафка якмакчы булды. Янәсе, анда аны ул кодалаган. Һәм көтмәгәндә хулиганнарга тап булганнар

Кәшшаф кайтып җиткәндә төн иде инде. Подъезда кеше-фәлән очрамады. Күнеле күтәрелеп киткәндәй булды. Ләкин ачкычын йозакка керткәч, аяклары хәлсезләнеп, ишек янагына килеп сөялде. Ничек килеп чыкты соң әле бу? Барысы да әйбәт иде, кайгы-хәсрәте юк иде, күнеле тыныч иде. Юк, ул мәхәббәт өчен яратылмаган. Кирәкми! Кирәкми ана ярату. Афәт икән ул мәхәббәт. Аны һәркем дә күтәрә алмый. Бу ярсу дәрья аны харап кына итәчәк, йотачак.

Әгәр бу бәладән тавыш-гаугасыз гына котылса, ни эшләргә белер иде белүен. Гаиләле иргә болай азып-тузып йөрү бер дә килешә торган нәрсә түгел.

Түбәнге катта ниндидер дөп-дөп иткән тавыш ишетелде. Бу ыгы-зыгы Кәшшафны ишекне ачарга мәҗбүр итте.

Фатир эче дөм-караңгы иде. Залда да, йокы бүлмәсендә дә, кухняда да ут күренми. Дәрига кая икән? Улы Кәрим дәү әниләрендә иде, аны алырга киткән ахры. Кәшшаф җинел сулап куйды. Җә, Хода! Үтте. Ин каты бәрелешү—беренче бәрелешү. Ә ул булмыйча калды. Бәхете җиңде. Калганын ничек тә ерып чыгар.

Кәшшафның җилкәләре тураеп китте, гүя өстенә басып торган авыр йөкне алып ташладылар. Өстендәге пижамасын салып идәнгә бәрде дә, залга кереп, стаканга мөлдерәмә итеп шәраб агызды. Аны бер күтәрүдә эчеп бетерде. Шунда гына өстәл өстендәге язуны күреп алды. Анда түбәндәгеләр язылган иде:

"Кәшшаф! Мин бик ашыгыч рәвештә Польшага киттем. Бригада шулай хәл итте. Анда товарның арзан чагы икән. Бер атнадан кайтам. Кәрим әниләрдә торсын. Барып хәлен генә белештереп йөр.

Син эшендә юк иден. Кара аны?!

Үбеп Дәриган".

Кәшшаф шатланып та өлгермәде, телефон шалтырады.

—Тыңлыйм,—диде Кәшшаф битараф кына.

Трубкада тавыш-мазар ишетелмәде.

—Тынлыйм,—дип кабатлады Кәшшаф. Хәмер җанына рәхәтлек, күнеленә тынычлык биреп, тәненә, бөтен күзәнәкләренә таралды.

—Синең белән сөйләшергә буламы?

Ниһаять, телефон чыбыгының аргы очындагы кеше дә телгә килде.

—Заһидә!

—Чү! Ул кадәр кычкырма, ишетерләр!

—Ишетсәләр соң?

—Өйдә үзең генәме әллә?

—Моның нинди әһәмияте бар соң?

—Мактанчык.

—Ә без кемнән ким?

—Мин сиңа бая катырак бәрелдем ахры, гафу ит, нервылар какшаган,—диде Заһидә. Аннан соң борчулы тавыш белән өстәде.—Берәр үчле кеше сагалап тормады микән дип тә шикләнәм әле мин.

—Безнең су коенырга барганны берәү дә белмәде ич.

—Аптыраганнан инде.

—Иртәгә куна киләм,—диде Кәшшаф,—шунда барысын да сөйләшербез.

—Белмим-белмим...

—Әйткән сүз, аткан ук.

Куркулары да, шик-шөбһәләре дә, сөйгәне белән араны өзү турында үз-үзенә әле генә биргән вәгъдәләре дә Кәшшафның башыннан чыгып очкан иде инде. Аның бөтен барлыгын янә Заһидә биләп алды.

* * *

Иген иккәнгә, рәхәт михнәт чиккәнгә, ди халык мәкале. Заһидәнең дә шатлык кичергән вакыты иде. Шулай инде ул, һәр кичнең бер көндезе була. Бу араларда кояшның нурын, көннең яктысын, күкнең зәңгәрлеген бүген генә күргәндәй мөкиббән китеп әсәрләнеп йөри. Аның өчен дөньяның офыклары киңәйгән чак. Әнә, университетта өзелеп торган укуын ялгап җибәрде, Казанга килеп эшкә урнашты, фатир тапты. Хәер, боларның берсе булмаган хәлдә дә, яшәү үзе зур бәхет ләбасы! Һәр көн йокыдан сызланударсыз, күтәренке күңел белән уяну өчен генә дә әллә ниләр бирерсең. Шуңа күрә аның урамда очраган һәркемне кочаклап аласы, хәлен беләсе, ярдәм итәсе килә. Күрмәгән-белмәгән кешеләргә елмаеп, исәнләшеп узуына кешеләр сәерсенеп карап калалар.

Соңгы бер ел эчендә ниләр генә кичермәде Заһидә. Ходай дошманына да күрсәтмәсен. Җимертеп йөргән җиреңнән урын өстендә кал әле. Бер сәбәпсез. Егерме дүрт яшьлек алма кебек хатынның нинди сырхавы булсын икән?!

Чүпрәледән кайтып, үз төбәкләрендә, Апас районында эшли башлаганнар иде. Ире Гаффар мәктәп директоры. Үзе—укытучы. Берни белмичә, бернәрсә күрмичә, матурлыгы аркасында унынчыны бетерүгә кияүгә чыкты ул. Дөресрәге, әтисе сүзен тыңлады. «Үзем исән вакытта урнаштырып калыйм, кешесе әйбәт"—дип бик өзгәләнгән иде мәрхүм.

Чыннан да, Гаффар инде үз урынын тапкан төпле егет иде. Югары белемле. Нык, таза гаиләдән. Яшь аермасы да куркытмады. Ул, гомумән, өлкәнрәкләрне хуп күрә иде. Алар өйләнешкәч, Гаффарны икенче бер авылга мәктәп директоры итеп күчерделәр. Тормышлары матур гына көйләнеп китте. Тагын бер елдан Заһидә читтән торып университетка укырга керде.

Бер ел яшиләр, ике, өченче елга китте. Ә ул һаман көмәнгә узмый да узмый. Ике як та хафага төште. Тора-бара Гаффарныкылар: "Кысыр хатыннан күкәй салган тавык яхшы",—дип мыскыл итә башладылар. Арага сүз керде. Заһидә елап бетте, иренә тикшерелергә барыйк, дип ялынды. Ләкин Гаффар хастаханәгә аны да җибәрмәде, үзе дә бармады.

Шуна күрә ул вакытта кем «гаепле"икәнне ачыклап булмады. Ә ирдән узып йөрергә кыймады, чөнки гаилә эше, уртак эш. Шул ук вакытта Гаффар Заһидәне яклап туганнарына ник бер сүз әйтсен?! Шунын белән гайбәтләргә дә юл ачты.

Дөресен генә әйткәндә, Заһидә ул гайбәтләргә башта колак та салмады. Чөнки әлеге чыш-пышлар башлыча үзләренең туган авылы урамнарында йөрде, эшләгән җирләренә килеп ирешмәде.

Ә туксан дүртенче елның язында ул авыруга сабышты. Тиктомалдан хәле бетә башлады. Аз гына кыймылдауга да кара тиргә бата. Тамагыннан калды. Үзенең исә, күнелендәге шомны исәпкә алмаганда, тәгаен гына авырткан җире дә юк сыман.

"Шомырт чәчәк атканда тигән салкын җәй буе бара ул,—дип юатты апасы,—үтәр, Аллаһы боерса, тешенне кысып булса да түз, гайбәткә җим салмыйк". Ләкин чирнең чигенергә исәбендә дә юк иде. Гаффар хатынын хастаханәгә илтеп салырга мәҗбүр булды.

Туктаусыз укол кададылар, учлап-учлап дару эчерделәр. Файдасы гына тимәде. Төннәрен керфек тә какмый үткәрде. Инде, әнә, йөрәге кадый башлады. Чирен исә һаман тапмыйлар. Күзгә күренеп сулды Заһидә. Йөзендә борыны гына утырып тора. Озакламый аны республика хастаханәсенә җибәрергә карар иттеләр.

Казанга алып китәргә бер көн алдан кич-кырын анын янына Хәлимә исемле өлкән яшьтәге табибә кереп утырды. Дежур да икән. Ул үзе гинеколог. Әмма ана башка төр сырхаулар да мөрәҗәгать итә. Чөнки күпне күргән, тәҗрибәсе зур.

—Сенлем, мине дөрес анла,—диде ул Заһидәнең хәленә керергә тырышып,—врач кешегә бу сүзләрне әйтү, ихтимал, ярап та бетми торгандыр. Ләкин әйтмичә дә булдыра алмыйм. Язгы боз шикелле көннән-көн сызасың бит, шуңа бик тә сызланам. Һаман күз алдымда торасын. Сине бозганнар, сенлем. Мари бозуы белән бозганнар. Нык бозганнар. Дару организмыңа зыян гына сала. Сиңа бик әйбәт имче табарга кирәк. Казанда, әнә, Маһинур исемле имчене бик гыйлемле диләр. Әллә тәвәккәллисенме, сенлем?

—Минем бер дошманым да юк бит, апа, нигә бозсыннар икән?

—Ныклабрак уйлап кара әле, сенлем, дошманнан курыкма, дустан курык, диләрме әле? Хәтта туганнар да кайчак үч юлына баса...

Йокысыз төнен Заһидә шул хакта уйланып үткәрде. Уйлана торгач, бу Суфия апа эше дигән нәтиҗәгә килде.

Суфия Гаффарның бертуган апасы. Ул, ни бирнәсе, ни абруе дип, башта ук аларның никахына каршы төшкән иде. Әлбәттә, унынчы классны әле генә бетергән кыз баланың нинди байлыгы булсын сон? Хәзинәсе—яшьлеге дә, пакьлеге. Авылда Кифая исемле шәфкать туташы эшли иде. Бай кыз, үткен кыз. Энесенә шуны алдырмакчы иде Суфия. Югыйсә, йөрешеп тә алганнар иде. Өйләнешер чак житкәч кенә нигәдер кәҗәләнде Гаффар.

Заһидәнең гайбәтен дә тырышып-тырышып шул Суфия апасы тарата лабаса! "Аертам, безгә кысыр килен кирәкми",—дип әйткәнен ул үз колаклары белән ишетеп торды.

Заһидә бала хакында үзе дә бик нык борчыла, билгеле. Бигрәк тә кеше арасында хурлана иде.

Чирләп, урын өстенә аугач кына бәби кайгылары китте, хәзер аның бердәнбер теләге—терелеп аякка басу. Мона кадәр им-том, бозу-чыру турында уйланганы булмады. Фән, гыйлем заманы ич. Мәктәптә дә ун ел буе шушы хакыйкатьне тукыдылар. Хәзер менә чарасызга калды, барысын да янабаштан уйлап корырга кирәк. Берәүнен дә вакытсыз гүргә керәсе килми. Имчегә түгел, шайтанга барырсын.

Гаффар аны хастаханәдән авылга ат белән килеп алды. Ара ерак түгел. Көн матур, бераз саф һава сулап, табигать белән хозурланып кайтсын, бәлки файдасы тияр дип уйлады, күрәсен.

Июнь ае иде. Тирә-як яшеллеккә күмелгән. Әйтерсең лә, җир өстенә хәтфә палас җәеп куйганнар. Аяз. Күк—зәп-зәңгәр. Шул зәңгәрлек эчендә кояш балкый, йомшак нурлары белән җирне иркәли.

Урман авызында күкеләр тавыш сала.

Зәһидәнең хәлсез иреннәре: "Күке, күке, әйтче, миңа тагын ничә ел яшисе калды?"—дип пышылдады.

Күкеләрнең туй вакыты, алар көне-төне кычкырырга да әзер. Зәһидә саный-саный чутын югалтты. Бу аның кәефен күтәреп җибәрде. Тик үзенең җеп өзәрлек тә хәле юк иде. Әлеге матурлыкны күзе күрә, күңеле туймый. Бер кечкенә авылны үткәндә чиләк-көянтә аскан ике хатын аларны суга барган җирләреннән туктап, күзәтеп калды.

—Әстәгъфирулла, әллә мәет алып кайта инде бу кеше,—дип куркынып сөйләнде озынрак буйлысы.

—Шушындый җәмле вакытта , бер-бер чирләшкә карчык булгандыр инде.

Авыл читендәге чишмә буенда Гаффар атын эчерде, хатынының урынын җайлаштырыбрак куйды.

—Су эчәсем килә,—диде Зәһидә.

—Салкын булмасмы?—дигән шиген белдерде Гаффар.

—Тимәс, минем тамагым төзәк бит.

* * *

Мәһинур бар кылган дәва-гамәлләрен дини тышчага төреп тәкъдим итә. Шуңа күрә үзен абыстай дип йөртә иде. Диагнозы да бар кеше өчен дә уртак: бозыклык! Талымсыз. Бар кешене дә кабул итә. Ара-тирә, үзенең исемен, дәрәҗәсен күтәрү өчен генә бәгъзеләрне кире дә боргалый. Бу терелмәслекләре күрер күзгә үк күренеп торган бәхетсезләргә кагыла. Зәһидәгә дә абыстай башта якты чырай күрсәтмәде. Чөнки яшь хатынның килеш-килбәте һич тә ышаныч уятырлык түгел иде.

—Абыстай апа, бөтен өметем сездә, зинһар, хәлемә керегез,—дип ялынды Зәһидә.—Башка барыр урыным юк, врачлар сезне тәкъдим итте...

Мәһинур түгәрәк йөзле, мул гәүдәле алтмыш яшьләр тирәсендәге хатын иде. Йөзендә ник бер җыерчык булсын. Өс-башы зиннәтле. Бармакларында затлы балдаклар, барысы да кашлы. Авызы тулы алтын теш.

—Алданрак килергә булмый идемени, табибларда каңгырап йөрисез-йөрисез дә, эш узгач миңа килеп егыласыз. Мин барыгызның да сырхавын үземә алырга тиеш. Минем дә яшисем килә әле бу якты дөньяда,—дип сукранды Мәһинур.

—Абыстай апа, гомер бакыена рәхмәтле булыр идем, абыстай апа, зинһар, мин яшь бит әле...

Имче янында тән сакчысы шикелле кукраеп басып торган какча гәүдәле хатынга нидер әйтте. Тегесе муенын сузып, колагын аның авызына ук китереп терәде. Нәрсәдер пышылдаштылар. Бераздан хатын Зәһидәне күрше бүлмәгә алып керде.

—Фу, бозыклыгыннан күзләр ачыта,—диде ул йөзен чытып,—үзен ничек түзеп йөрисендер. Абыстайның да башына тиде. Печтек кенә ятып хәл алам диде.

Ходаем, шул кадәрләр дә хәерсез бәндә икән, дип офтанып куйды Зәһидә. Суфия апа эше инде бу. Хәлен белергә сырхауханәгә дә аяк басмады, кайткач та ачылып сөйләшмәде...

Зәһидә арыган иде, кыенсынып кына диван кырыена чүмәште.

Ябык хатын Мөслимә исемле иде. Соңыннан әле алар якынаячаклар. Зәһидә дә аның шикелле үк Мәһинур абыстайның иярчен-булышчысына әвереләчәк. Үзенә фанатикларча бирелгән сырхауларны якынлаштыра белә иде имче. Ул өйдә кыл да кыймылдатмый. Бөтен эшен шушы мөслимәләр башкара. Арада ир-атлар да бар. Тик алар басынкы, мәхлук затлар. Утыз яшьләр тирәсендәге Трофим исемле рус егетенә абыстай

төннәрен үз ятагында урын да бирә иде. Гомумән, бу дөнья бөтенләй башка дөнья. Чирлеләр, гарип-гораба, исәр-мисәрләр дөньясы. Аларның яшәеш кануннары гадәти кешеләрнекенә туры килми. Заһидә моны сырхаудан күзе ачылгач кына аңлады.

—Иртәгә бер кило йөзем җимеше, бер кило кара җимеш, мөселман кешесе суйган сыерның үпкәсен, бер кап тоз, ике литр чишмә суы, өйдә салынган бер арыш ипие алып кил,—диде Мөслимә,—абыстай сине дәвалап карамакчы булды.

И, Заһидәнең сөенгәнлеге! Сырхавы да, чире дә онытылды, яландагы колын шикелле ваемсыз, йөгерек бер затка әйләнде. Шулай инде, кайчакта кешене чарасызлыктан арындыру өчен вакытында әйтелгән бер сүз дә җитә. Имчеләр моннан бик оста файдалана беләләр. Кызганыч, кайбер табиблар сүзнең могҗизалы көчен, тылсымын хәтта инкарь итәләр.

Заһидә иртән иртүк бик күп күчтәнәчләр төяп, имченең ишек төбенә килеп басты. Бүген ул беренче иде. Беренче булып керде дә. Маһинур күчтәнәчләрне ошатты. Эш ялы аерым. Анысын Мөслимә җыя. Монда андый чыгым белән чутлашып торучы юк. Файдасы гына тисен!

Имче бүген якты көн шикелле ачык иде. Көлеп-елмаеп кына сөйләшә. Теле татлы.

—Утыр әле, кошчыгым, яныма, сөйлә әле барысын да түкмичәчми. Бер нәрсәне дә яшермә. Мин үзем аларның барысын да белеп торам. Сөйләү үзең өчен кирәк. Күңелең бушап калыр. Шунсыз бозыклыкны кайтару миңа да авырга туры килә.

Заһидә бәйнә-бәйнә үз тормышының сәхифәләрен ачты. Елыйелый, үкси-үкси хикәят кылды. Маһинур аны итләч кулы белән аркасыннан кага-кага бүлдермичә тыңлады. Заһидә үзе дә тынычланып калды.

—Бәхетең, миңа килгәнсең, кошчыгым, гүр иясе итәсе булганнар сине,—диде Маһинур,—бу куркыныч сиңа янамый инде хәзер, хафаланма. Син сөйләгәндә мин фәрештәләр белән элемтәгә кереп, аларның хәерфатихасын алдым. Мин әйткәннәрне үтәсәң, Алланың рәхмәте белән, чирләреңнән котылырсың, шөт.

Бозыклыкны куу имче кулыннан үткән ризыклар белән туклану һәм көнгә бер мәртәбә өстенә өшкерүдән гыйбарәт иде. Заһидәнең ашау ягы коты иде әле. Укшып интекте. Косты. Фатир хуҗасы берсендә куркуыннан аның үзенә әйтми генә күршедә яшәүче табибны да чакырып кертте.

—Анализларсыз бернәрсә дә әйтә алмыйм, хаста үт куыгында булырга охшаган. Больницага салырга кирәк,—диде табиб.

—Мине больницада шушы хәлгә төшерделәр дә инде,—дип каршы төште ана Заһидә.

Имче сөенде генә.

—Түз, кошчыгым, бозыклык шулай бик авырлык белән генә чыга инде ул, аны шайтаннар тотып тора,—дип юатты.—Дөресен әйтим, кузгатып булырмы икән дип үзем дә бик борчылып тора идем әле. Шөкер, кузгалган.

Чыннан да, көннәрдән бер көнне Заһидә косудан тукталды. Йокыдан ул манма су булып уянды. Әмма тәне искиткеч җиңел иде. Күкрәк эчен өзлексез яндырып торган кайнар төен дә юкка чыккан.

Имче янына атлап түгел, очып барды.

—Маһинур абыстай, мин терелдем,—дип аның аякларын, кулларын үбәргә тотынды.—Бер җирем авыртмый, абыстай апа, космадым да бүген. Мең-мең рәхмәт, мин сезнең алда гомерлек бурычлы.

—Иншалла, Ходай теләкләремне кабул итте, тереләсеңне бүген таң алдыннан миңа җиткергәннәр иде инде,—дип гадәттәге тылсымлы сүзен әйтте, дога кылды Маһинур.

Заһидәнең хисләре тулып ашкан иде, үзенең дә имчегә ниндидер яхшылык эшлисе килде. Тик нинди яхшылык эшли ала соң ул дөньяның иң мәрхәмәтле, иң гыйлем бу кешесенә?!

—Абыстай апа, сезгә "әни" дип дәшергә рөхсәт итегезче,—диде ул кыяр-кыймас кына.—Сез минем әнием урынында.

Маһинурның күзләре төймәдәй түгәрәкләнде, бит тамырлары тартышып-тартышып куйды, бермәл ни әйтергә белми аптырап торды. Чак елап җибәрмәде.

Үз гомерендә ул кешеләргә яхшылыклар да эшләде, рәнҗеткән вакытлары да булгандыр, мөгаен. Алдашу, урлашу да аннан читтә йөрмәде. Үзен дә тормыш күп талкыды. Яшьли ирдән калды. Янадан чыкканыннан уңмады. Иң матур чакларын төзелештә интегеп үткәрде. Төзелеш эшендә хатын-кыз тупаслана, иржәмәйгә әверелә: эчә, тарта, сүгенә.

Хәзер менә имче. Бу сәләте Ходайдан бирелгән булырга тиеш. Югыйсә, ничек кереп китәр иде ул әлеге шөгыльгә? Кемнәрдер файдасын күрәләр, кайсылары хәрәм гамәл кылып, кеше алдап ятасың диләр.

Дөресен генә әйткәндә, ул үзе дә берни аңламый. Кайвакыт үзе сөйләгәннәргә үзе шакката. Минме соң бу, дип аңышмый тора, гүя аның белән нииндидер югары көч идарә итә. Тик әлегәчә берәүнең дә ана "әни" дигәне юк иде.

—Үз әнием дөньяга тудырган, сез мине тормышка кайтардыгыз,— диде Заһидә үтенечен шәрехләп.

—Ризамын, кошчыгым, ризамын,—диде Маһинур.

* * *

Вакыт уза. Һавага, әнә, көз исе керде. Авылга да кайтыр вакыт житте. Тиздән мәктәптә укулар башланачак. Ә аңа эшкә чыгасы.

Ничек яшәп китәрләр алар Гаффар белән? Бу сорау Заһидәнең башыннан чыгып тормый. Бизде инде ул аннан. Ире Казанга хәл белешергә килгәндә дә ул ана якты чырай күрсәтмәде.

Хатының белән рәхәтләнеп сөешмәгәч тә нинди тормыш була ди инде ул?

Ир-атка Ходай мондый түземлелекне бирмәгән. Гаффар берара унга-сунга бәргәләнеп йөрде дә, элекке мәгъшукасы акушер Кифая белән якынлашты.

Заһидә үзен терелдем дип исәпләсә дә, чынлыкта тирән төшенкелектә иде әле. Әйе, тәне авыртмый, йокысы да кайтты кебек. Әмма җан чире аны әле һаман йозакта тота. Кыргыйланды. Берәүне дә якын җибәрми, һәммә кешедән шикләнә. Үзе пешергән, үзе хәзерләгән ризыкны гына ашый. Бернәрсә дә аны кызыксындырмый, битарафның битарафы. Шат күнелле, уенчак һәм көләч Заһидәдән шәүлә генә утырып калды. "Ирен кеше белән чуала бит, ник оеп утырасың син",—дип килеп-килеп әйткәләделәр, ә ул, минем анда ни эшем бар дигәндәй, жилкәсен генә жыерып куя иде.

Йозак көтелмәгәндә ачылды. Сентябрь азаклары иде. Көзнең алтын төскә манчылган саф-чиста чагы. Җир өстенә сап-сары яфраклар түшәлгән. Күк—очсыз-кырыйсыз. Аның шулай икәнен бөтен күңелен белән сизеп торасың. Бигрәк тә кичләрен, җиһан энгер-менгер пәрдәсенә төренгән мизгелләр серле тоела. Хәтта эт өргән, шыгырдап ачылган капка тавышлары да матур моң булып янгырый.

Шушындый илаһи кичләрнең берсендә нииндидер көч Заһидәне урамга тартып чыгарды. Иртәдән бирле күңеле урынында түгел иде аның. Әллә ничек, йөрәге бер җилкенеп ала, бер шомлана, әйтерсең лә, бик мөһим вакыйга булачак.

Заһидә Инеш буена төште дә, мал сукмагы буйлап болынлыкка таба юнәлде. Монда юеш иде. Аяклар таеп-таеп китә. Салкынча. Ләкин ул боларның берсен дә сизми, баруы-бару.

Шулвакыт тал-тирәкләрне шыбырдатып йөгерек жил исеп узды. Чак-чак кына Заһидәнең башындагы яулыгын очыртып алып китмәде. Шуннан соң дөнья тынып калды. Тик озакка булмаган икән. Яулыгын ябып та өлгермәде, жил янә калыкты. Болытларны пыран-заран китерә башлады, әллә нинди рәвешләргә кертте, укмаштырды, таратты, талкыды.

Баш очына житкәч исә иң зурысы бөтенләй кеше сурәтенә охшап калды. Ап-ак чәч, ап-ак сакал, ап-ак жилән. Үзе туктаусыз кулын изи.

—Ак бабай!

Давыл тынды, ак бабай күздән югалды. Заһидә дә тылсымлы чишмәгә чумдырып алгандай жинеләеп калды. Гүя болыт аның шомборчуларын да үзе белән алып киткән иде. Әйтерсең лә, берни булмаган, сырхау да, күңел буталулары да. Уйлары да гадәти. Кара, нишләп мин караңгы төндә япа-ялгыз болынлыкта йөрим соң әле, дип бермәл аптырап торды. Күр инде, оеклары лычма су, бөтен жире пычранып беткән. Кешегә күренерлеге калмаган ич. Ә Гаффар кая?

Бу сорауларга әлегә җавап юк иде. Әмма шунысы ачык, ана хәзер кире борылырга кирәк. Җүләр түгел лә ул саташып йөрергә?

Заһидә кайта-кайтышка туры мунчага китте. Киемнәрен алмаштырып, чистартасын чистартып, юасын юып кермәкче иде өйгә.

Тик мунча ишеген ачуга тагын зиһене чуалды. Ялгыштым ахры дип, тиз генә ишекне ябып та куйды. Ләкин куллары янә ишек тоткасына үрелде. Чөнки идәндә әүмәкләшүче парның берсе аның ире Гаффар иде.

Күзләре дүрт булды тегеләрнең. Мәгъшука хатын бала мендәредәй олы имиләрен учлары белән каплап, Гаффарның артына посты.

Ә Гаффар һични булмагандай:

—Әй, син, исәр баш, үкчәңне күтәр моннан,—дип кычкырды.

Ул хатынын чын тилегә саный башлаган иде инде. Шуңа күрә саклану чараларын күрүне дә кирәк санамады. Ләкин аның каршында элекке Заһидә түгел иде. Әллә ишетте иренең сүзләрен, әллә юк, утыргыч өстендәге ашамлыкларны, эчемлекләрне берәм-берәм тибеп очырырга тотынды. Аннан соң ләүкәдәге чиләкне алып, өсләренә су тондырды. Гаффар сикереп тормакчы иде дә таеп егылды. Ул лаякыл исерек иде.

—Кабахәтләр, фәхишләр...

Заһидә уйнашчыларның өстеннән бикләп куйды да, әйберләрен төйнәп, мәктәпнең тулай торагына күченеп китте.

Гаффар икенче көнне, инде айнып алгач, хатыны янында койрыгын өзгән кигәвен кебек бөтерелде, антлар бирде.

—Кеше алдында мыскылга калдырма, мин бит мәктәп директоры, эшемнән алдырма,—дип ялварды. Заһидәгә аның белән сөйләшү дә җирәнгеч иде. Зәһәрен бер сүзгә сыйдырды:

—Шакшы!

Ә тагын ике көннән ул районга барып, Гаффардан рәсми төстә аерылып кайтты. Әтисе Идрис картның ышанычы акланмады. Никах гаилә бәхете алып килмәде.

Ак бабай гына аны мәрхәмәтеннән аермады. Алар тагын очраштылар. Поездга утырып Казанга барышы иде. Төнгә каршы булгангадыр, мөгаен, пассажирлар күп түгел, бармак белән генә санарлык. Ишек катында бер егет белән бер кыз сөешә, керүгә үбешергә тотынганнар иде, әле дә туктаганнары юк. Калганнары борын сызгырта. Тора-бара Заһидәнең үзен дә йокы басты. Бервакыт сискәнеп уянып киткән иде, син күр дә, мин күр, каршыдагы эскәмиядә Ак бабай утырып тора.

—Исән-сау гынамы, кызым, исән-имин генә йөрисеңме?—дип кызыксынды ул.

Заһидә аның нурлы карашыннан эреп китә язды. Эчен-тышын сүз белән аңлатып булмый торган күтәренкелек биләп алды.

—Аллага шөкер әле, бабай.

Бабайның алдына ятып, елый-елый эчен бушатасы килде. Тик урыныннан гына кузгала алмады, аны нидер тота иде.

—Мин уйларыңны белеп торам, кызым,—диде бабай,—күңелең изгелектә синең, күп авырлыклар да күргәнсең икән.

—Минем дә сезне мона кадәр дә күргәнем бар иде,—диде Заһидә.

—Мин бит мөсафир, кызым, табигать илчесе, күп йөрим, күп очрашам, күп күрәм. Мохтаж бәндәләр ишәйде хәзер, ваемсызлык,

битарафлык басты дөньяны, упкынга тәгәри җәмгыять. Менә шулар борчый мине...

Заһидә сихерләнгән шикелле күршесеннән күзен алалмый иде. Шундый да мөлаем булыр икән!

Ул арада Ак бабай юкка да чыкты. Күз сирпеп алганчы эскәмия буш иде инде.

Поезд тәгәрмәчләрен рельс араларына бәргәли-бәргәли алга чаба. Ишек катындагы егет белән кыз үбешеп арыганнар иде, күрәсең, инде бер-берсенең кочагына кереп, йокыга талганнар. Аларга карагач, Заһидә елмаеп җибәрде. Үзен бик әйбәт хис итә иде ул. "Ак бабай миңа тагын күтәренке күңел бүләк итте",—дип шатланды.

Казанда яшәүче Фирая апасы да аны шушы күтәренке хәлендә күреп, бик сөенде. Гаффар белән аерылышуын да әйткәч:

—Шул бүән белән болай да яшьлегеңне харап иттең, бигрәкләр дә әйбәт булган,—дип сеңлесенең гамәлен хуплады.

—Уку елы төгәлләнүгә Казанга үрмәләргә дип торам, апай, син ни диярсең икән?—диде Заһидә.

—Ә нигә уку елы беткәнен көтеп торырга? Илдә чыпчык үлмәс, сеңлем. Ничек тә җае табылыр. Тимерне кызуында сугу хәерле.

Уйланган эш—беткән эш, ди. Заһидә тиздән Казанга күченеп килде. Фирая бер почта бүлегенең башлыгы булып эшли иде. Таныш-белешләре күп. Сеңлесенә фатир да табып бирде.

Заһидәнең калага күченеп килүен Маһинур да бик ошатты. Заһидә хәзер бөтен буш вакытын аның янында үткәрә башлады. Кешеләрне каршы ала, бүләкләрен кабул итә, исемлеккә терки. Кирәк икән, ашарына пешерә, фатирны җыештыра.

Тән таза вакытта эш нәрсә ул, рәхәтләнеп эшләде. Имченең генә нәфесе балыкчы карчыгыныкы шикелле күперә барды. Беркөнне ул аны бүлмәсенә чакырып кертте. Трофимның алдында утырып тора иде. Заһидә кергәч тә төшмәде. Аңласын диде бугай, аклангандай әйтеп куйды:

—Бозыклык күп керә, стрессны мин шулай куам.

Заһидә бу хәлгә бик гаҗәпләнсә дә, йөзенә чыгармады. Абыстай аның өчен фәрештә дәрәҗәсендәге изге зат иде: ул хилаф гамәл кылмас!

—Әни, берәр йомышың бармы әллә?—дип сорады ул, гадәттәгечә, йомшак, буйсынулы тавыш белән. Маһинурга Заһидәнең ялагайлыгы, ярарга тырышуы да ошый иде, билгеле. Трофимның тезләреннән төшеп, Заһидәнең аркасыннан кагып куйды. Трофим да авызын ерып, аңа баштан-аяк йотылып карап торды.

—Бар, житәр, ата мәче шикелле күзләреңне майландырып утырма монда,—дип Маһинур аны бүлмәдән куып чыгаргандай чыгарып җибәрде.

—Кызым, сиңа сүзем бар иде,—диде Маһинур,—утыр әле каршыма.

Тавышы күгәрченнеке кебек гөрелдәп чыкса да, карашы өттергеч иде имченең. Заһидәнең тәне эсселе-суыклы булып китте. Маһинур аны берара күз әсирлегендә тотты.

—Син минем бусагама килеп егылганда ярты үлгән идең, шулаймы?

—Әйе, әни, шулай.

—Мин синең бозыклыкларыңны куып савыктырдыммы?

—Савыктырдың, әни.

—Син үзеңне минем алда бурычлы дип саныйсыңмы?

—Бу хакта сүз дә булырга мөмкин түгел, әни.

Маһинур канәгать иде. Кулларын җәеп киерелеп алды да әйтте:

—Бүген фәрештәләр хозурыннан бер хәбәр алдым...

—Әйе, әни...

—Менә шул, кызым, бүгеннән башлап минем ярдәмчем-йомышчым булырсың. Өстән шулай әйттеләр. Трофимнан кала, бу туксан тугызларның барысын да җилгәрәм. Алар минем абруйны гына төшерәләр. Шуңа күрә килүчеләр саекты. Син яшь, чибәр. Игътибарны җәлеп итәрдәй.

—Мин болай да сезнең ярдәмчегез инде, әни.

Мәһинур янә карашы белән өттереп алды.

—Эшеннән чыгасың, минем янга күчеп киләсең.

—Ярар, әни...

Заһидә үзе бик тиз генә ризалык бирсә дә, апасы Фираяның җен ачулары чыкты.

—Ул убырлының арт сабагын укытып кайтырга да күп сорамам,— диде зәһәрләнеп,—кара, тапкан хезмәтче.

—Апа...

—Сарык бәрәне булма,—дип бүлде Заһидәне Фирая,—гамәленә күрә хакын бирдек ич инде. Инде ялчы кирәк булган, ә?

—Апа...

—Ишетсең колагың, ике аягыңның берсен дә атламыйсың!

Заһидә ике ут арасында калды. Кемне тыңларга? Апасының сүзләре якынрак та, аңлаешлырак та. Шул ук вакытта Мәһинурны да тыңламыйча ярамый. Яхшылыкка таш атмыйлар.

Их, Ак бабай килеп чыксын иде дә, бер-бер киңәшен бирсен иде. Бик мәрхәмәтле җан бит ул. Мәһинур аның сырхавын куса, Ак бабай рухын кайтарды, күзләрен ачты.

Дөресен генә әйткәндә, Ак бабайның җиһан затымы-түгелме икәнен Заһидә тәгаен гына белми дә. Күңеле иләс-миләс килгән бер мизгелдә пәйда була да, шундук юкка да чыга. Ихтимал, ул хыял җимеше генәдер? Тик ничек кенә булмасын, андый чакта үзен-үзе белешми Заһидә, чәчәктән чәчәккә куна-куна очып йөргән май күбәләгедәй җиңеләя, җаны-тәне үзенә бер ашкынулы хис белән тула.

Аның җилкенүле чагы түгел иде әле. Шулай да Ак бабай аны эзләп тапты. Беркөнне, эш сәгате тәмамланыр алдыннан идарәгә яшь кенә хатын килеп керде. Йомышын йомышлап Заһидә яныннан узганда, өстәл кырыена орынды булса кирәк, ханымның сумкасындагы әйберләре идәнгә чәчелде. Ул әйберләр арасында ниндидер китап та бар икән. Китап тышлыгыннан Заһидәгә таныш бабай карап тора иде. Үзе кар өстендә, яланаяк. Озын ак чәче җилкәсенә кадәр салынып төшкән.

—Ак бабай!

Заһидә үрелеп китапны кулына алды.

—Бу Остаз,—диде ханым,—Порфирий Корнеевич Иванов. Бездә аның клубы бар. Шимбә көннәрдә җыйналабыз. Зәңгәр күлгә бергәләп су коенырга барабыз. Кышын да, җәен дә. Килегез. Үкенмәссез.

Татьяна исемле бу ханым инженер. Авиация заводында эшли икән.

—Мин аны ике мәртәбә күрдем, соңгысында сөйләшеп тә утырдык әле,—диде Заһидә.—Ул миңа бик зур ярдәм күрсәтте.

—Сез бәхетле кеше, Остаз сезне үз иткән,—дип, Татьяна Заһидәне кочаклап ук алды.

—Тик мин, бу саташу гына булмадымы икән дип, икеләнәм.

—Борчылмагыз да, икеләнмәгез дә. Остазның рухы, җаны мәңгелек,—диде Татьяна. Теләсә, ул элекке рәвешенә дә кайта ала. Аны космоста да очраталар. Беләм, минем бу сүзләремә ышануы авырдыр да. Моның өчен махсус хәзерлек зарур. Сез әлеге ачышка кемгә караганда да тизрәк киләчәксез, чөнки ул сезне үз канаты астына алган инде. Менә күрерсез.

Әлеге очрашу Заһидәнең тормышын бөтенләй икенче юнәлешкә борып җибәрде. Өч-дүрт ай эчендә Мәһинурдан читләшеп, Иванов тәгълиматы ягына авышты. Моңа Мәһинур үзе дә гаепле. Ул аны бер нигезсез Трофимнан көнли башлады. Берсендә җәнҗал куптарды, Заһидәне "фәхишә" дип мыскыл итте. Ивановлылар клубында исә мөнәсәбәтләр бөтенләй үзгә, елмаеп-көлеп каршы алалар, һәрберсе ярдәм кулы сузарга әзер. Хәзер ул Остазның "Детка" принцибы буенча яши. Һәр көнне иртән урамда өстенә чиләкләп салкын су бөрки, атна саен ураза тота. Кышын кар өстендә ялан тәпи йөри. Зәңгәр күлдә су коена.

Болары физиологик гамәлләр. Рухи камиллеккә караганнары да бик мәгънәле. "Кешеләргә ярдәм ит, бигрәк тә мохтаҗларга, сырхауларга.

Моны шатланып башкар... Кешеләргә ышан. Комсыз булма, икейөзләнмә, гаделлекне сакла. Кеше сөйләмә. Башынны чир, үлем турындагы уйлардан арындыр..."

Остазнын бу теләкләре Заһидәнең халәтенә бик тә туры килә иде. Гүя әлеге системаны Порфирий Корнеевич аның өчен уйлап тапкан.

Бәхетле булу өчен өч нәрсә кирәк диләр. Беренчесе—тән тазалыгы, икенчесе—фикер саулыгы, өченчесе—күнел пакьлеге. Заһидә бу сыйфатларны үзендә бар дип саный. Димәк, ул бәхетле. Кәшшаф аның тормышына шушы шаукымда килеп керде.

Ир-ат белән хатын-кыз арасындагы мөнәсәбәтләрнең серен әлегә берәүнең дә ача алганы юк. Хис, дияр кайберәүләр. Әйе, хис—беренче урында. Тик хис кабынсын өчен ин әүвәл табышырга кирәк бит әле. Гашыйклар ничек табыша, ничек таныша? Нинди сихри көч, нинди тылсым этәрә аларны бер-берсенә?

Әйтик, Заһидә Кәшшафны беренче тапкыр коридорда гәпләшеп торган чагында күреп алды. Алар берничә иде. Ә анын күзе Кәшшафка төште. Костюмын ошатмады. Карасу-яшькелт төс абзар төсен хәтерләтә сыман тоелды. Әллә чулак та инде, дип уфтанды. Чөнки Кәшшафның бер терсәген салындырыбрак йөри торган гадәте бар иде.

Шушы мизгелдә танда янгыраган гармун моңыдай Заһидәнең күнелен ниндидер кайнар дулкын ярып узды. Сагыш дисән, сагыш түгел, юксынуга да охшамаган. Бу—сусау иде. Ләззәтле сусау. Хатын-кыз күнеленең ашкынуы. Чөнки табигать аны сөю, сөелү өчен яраткан. Хатын-кызнын ходай биргән асылы шуннан гыйбарәт.

Заһидә күрмәгән-белмәгән, әле бер авыз сүз катышмаган әллә нинди чит кешене үз итте. Диплом эше дә, башкалары да ул уйлап тапкан, акрынлап ул көйгә китергән хәйләләр иде. Шулай да чын-чынлап якынаю, аңлашу шактый озакка сузылды.

Бервакыт Кәшшаф аны ресторанга чакырды.

—Юк, Кәшшаф абый, мин бит тәкъва зат, рестораннарда йөрү мина гөнаһ,—дип көлде Заһидә. Ләкин бу тәкъдимне кире кагу түгел иде. Бүлмәдә генә чәйләргә килештеләр.

Кәшшаф Заһидәнең чибәрлеген, яшьлеген өстәл аша гына күзәтеп, сокланып утырды. Гүя тәти уенчык. Кул сузса, уалыр сыман. Бу тыйнаклыгы Заһидә алдында анын абруен тагын да үстереп җибәрде. Әле хисләрнең чәчәк атасы, җимешләнәсе бар ич.

Заһидә Яшел Үзән шәһәрендәге апасынын хәлен белмәкче икән. Якшәмбе көнне Кәшшаф аны барып алырга вәгъдә итте.

Яшел Үзәннән кайтканда Кәшшаф беренче мәртәбә сөйгәненен кулларына үрелде. Боз кебек салкын иде Заһидәнең куллары. Ул аларны җылытмакчы булган иде дә, Заһидә ирек бирмәде.

Кәефе юк иде Заһидәнен. Ул килгәндә апасы авырып егылган иде, ул киткәндә дә тора алмады. Шуна борчулы иде. Кәшшафка бу хакта әйтергә кыенсынды.

Ә Кәшшаф бу сәяхәткә зур өметләр баглаган иде. Төн йокламыйча шул хакта хыялланып, планнар корып яткан иде. Ләкин өмете акланмады. Заһидә ник бер елмаеп карасын. Сүзләрен дә теш арасыннан тартып чыгарырга кирәк. Ана карап, Кәшшаф үзе дә сөйләшмәс булды. Радио кабызды да юл буе шуны тынлап кайттылар.

—Тагын кайчан күрешәбез?—дип, сорады ул саубуллашканда.

—Башка очрашмабыз инде, Кәшшаф абый,—диде Заһидә ана күтәрелеп карамыйча гына.—Килеп алуыгызга рәхмәт. Борчуым өчен гафу итәрсез дип уйлыйм.

Кәшшаф китеп баргач, Заһидәнен күнеле талпынып куйды да куюын, ләкин соң иде инде. Үзе бит, югыйсә, Кәшшафны чәйгә чакырырмын дип, күнеленә беркеткән иде, тәм-том да хәзерләп куйган иде. Нигәдер киреләнде. Шулай ул, вакыт-вакыт үзеннән-үзе кәефе төшә, эче поша, бер дә юкка киреләнә башлый.

Бүлмәсендә дә үзенә урын таба алмыйча үрсәләнеп йөрде. Бераздан мендәргә капланып еларга ук кереште. Шул ятуыннан тормады, йокыга талды.

Төшендә нииндидер бер биек тау башында басып тора, имеш. Баш очында болытлар йөзә. Аста—кара-кучкыллы дәрья. Ак башлы бинһаяя зур дулкыннар шаулый-шаулый кыяларга килеп сугылалар да кире чигенәләр. Тау уйнаклап-уйнаклап куя. Зәһидәне курку басты, бер-бер чарасын күрмәсә, аны бу ярсу дулкыннар йомып алачак ич. Әнә, инде күз дә бәйләнеп килә. Нишләргә, кемнән ярдәм сорарга? Тукта-тукта, аның сон Ак бабасы бар ләбаса!

—Ак бабай! Ак ба-а-ба-ай...

Күп тә үтмәде, болытлар арасыннан бер нур кысылып чыкты да зурая-зурая җиһанны якты кочагына алды. Тора-бара ул Ак бабай рәвешенә керде. Баш очыннан бармак янап очып үтте.

Кәшшафны үпкәләткәнне ошатмаган, дигән нәтиҗә чыгарды Зәһидә уянгач.

Кәшшаф, дөрестән дә, борчуда иде. Китек күнелне кимсетү ансат бит ул. Зәһидәнен кинәт кенә үзгәрүен һич тә анламый иде. Сәбәбе нидә икән? Әллә бер-бер хата җибәрдемме, дип үрсәләнде. Әмма хатасын тапмады. Шулай да, уйлана торгач, акылы белән ул Зәһидәнен киреләнүен хуплады да. Зәһидә чибәр, ялгыз, яшь. Ана үзе шикелле күренекле пар кирәк. Кәшшаф тин яр түгел. Шулай булгач, өмет тотунын фәтвәсе дә юк. Өзәргә, онытырга!

Ләкин мәхәббәтнен күзе сукыр шул анын. Ул бернинди кануннарга да буйсынмый, анын үз туксаны туксан. Гашыйкка Бохара да ерак түгел дигәннәр бит. Матурмы, ямьсезме, өлкәнме, кечеме, озынмы, кыскамы— гыйшкы төшкән кешегә боларнын берсе дә киртә була алмый.

Зәһидә дә төннен яртысын әйләнеп-тулганып үткәрде. Күз алдыннан Кәшшафнын боек йөзе бер генә минутка да китеп тормады. Әллә ниләр уйлап бетерде, бар нәрсәдә үзен гаепләде. Ит яхшылык, көт яманлык, ди. Алай кырын торырлык булгач, китертмәскә генә иде. Тәкъдимен башта ук кире каксан, җәфаланып йөрмәгән дә булыр иде. Ул бит әле рульдәге кеше. Бер-бер хәл килеп чыкса нишләрсен?

Зәһидә эшкә бер сәгать алдан барып утырды. Кәшшаф кына күренмәде. Әллә китапханәдә эшли торган көне микән дип, аны да белешеп карады. Эшкә килә диделәр. Юк йомышын бар итеп, шул тирәдә әйләнде. Тик һәрберсендә дә бикле ишеккә төртелде.

Минем аркада авариягә эләккән икән дип, бөтенләй хафага калды яшь хатын. Ә үзе коридорнын аргы очында Кәшшафнын гәүдәсе шәйләнүгә, тиз генә бүлмәсенә кереп шылды.

—Зәһидә Идрисовна, сез бүген нигәдер бик тынычсызланасыз, берәр хәл булмагандыр бит?—дип сорады идарә башлыгы.

Зәһидә ни ялганнарга да белмәде—дөресен әйтә алмый ич инде. Аннан сон: "Хәмитов белән хәл итеп бетерәсе мәсьәләләр бар иде",— дип Кәшшаф бүлмәсенә ашыкты.

Кәшшаф шкаф пыяласындагы шәүләсенә карап, учларына төкеренә-төкеренә чәчен рәткә китерү белән мәшгуль иде. Зәһидәне күргәч, калтыранып китте, йөрәге лепер-лепер килеп алды. Шулай да каушавын күрсәтмәскә тырышты. Чөнки гыйшык-мыйшык мәсьәләсен үзенчә хәл итеп куйган иде ич инде. Ялынуга калгач, булмый инде ул. Бер акыл иясе әйткән бит, кем дә кем хатын-кызны көчләп үзенә каратырга тели, ул кеше, һичшиксез, аны югалтачак, дигән. Һәм дөрес. Ялыну-ялвару бервакытта да үзенә бәрабәр нәтиҗә бирми. Ялыну—көчсезлек билгесе. Ә ул яшь-җилкенчәк түгел инде, хатыны бар, улы бар. Шуна күрә шайтан котыртуына бирешергә тиеш түгел. Бу дөньяда кем яратышып өйләнгән сон? Җете кызыл тиз уна ди, андый гаиләләр бәхетсез була.

Тик алдан уйланган бу уйларны Зәһидә бер күз сирпеп караудa челпәрәмә китереп ташлады.

* * *

Конференциягә хәзерлек унаеннан Галимовны министр Сабиров кабул итте. Ул үзе президент белән очрашуга өмет тоткан иде, шул максаттан шактый гына чараларын да күреп куйган иде. Соңгы сәгатьтә генә барысы да җимерелде. Президент Америкага җыена, имеш.

Идарәче даирәләр милли мәсьәләдән өрәктән курыккандай куркалар. Совет чорында да шулай иде, хәзер дә хәл күпкә үзгәрмәде. Татар теле, милли матбугат, тарих, гореф-гадәтләр турында сүз чыкса, кашлары җимерелә. Татар тарихы болай да сәясәт белән бер ызанда, аның койрыгына тагылып йөрде. Сабиров та шул камырдан изелгән кеше иде, карашлары ВКП(б) ҮКның 1944 ел 9 август карары концепцияләреннән әллә ни аерылмый иде.

Галимов күренүгә аның зур биек өстәл артында агач төбедәй калкып торган башы ишек катына таба тәгәрәде. Өстәл читенә җиткәч кенә сыны пәйда булды. Алар икесе дә өтек гәүдәле иде. Аерма шунда—Галимов төп шикелле кыска юан, ә Сабиров кипкән балык сыман коры сөяк.

—Әйдүк, әйдүк, Сәүбән Сәүбәнович, күптән күзгә-башка күренгәнегез юк иде,—диде ул чәрелдегрәк, әмма көр тавыш белән.

—Мәшәкатьләр күп бит, Ильяс Хәбирович, үзегез белеп торасыз, чаба-чаба аяк табаннары тузып бетте инде монда.

Галимов үз сүзләренә үзе кәефе килеп, эре сирәк тешләрен күрсәтеп, кеткелдәгәндәй итте.

—Сезнең тәҗрибәгез зур, Сәүбән Сәүбәнович, конференциянең уңышлы үтәчәгенә бөртек тә шикләнмибез.

—Рәхмәт ышанычыгызга, Ильяс Хәбирович. Төркиядән, Румыниядән, Финляндиядән, Германиядән, Америкадан җаваплар килде инде. Кытайдан да ризалык биреп торалар. Менә шулай иплән-иплән милләтебезне үз асылына кайтарырбыз дип уйлыйм.

Сабиров сызгырырга әзерләнгәндәй иреннәрен бөрештерде.

—Чыннан да, безнең татар-монголларга бернинди мөнәсәбәтебез дә юкмы?—дип сорады.

—Бернинди дә! Без җирле халык. Безнең ата-бабаларыбыз башка җирле халыклар белән гомер-гомергә шушы төбәктә яшәгәннәр. Килмешәкләргә катнашмаганнар да, бирешмәгәннәр дә.

—Яхшы, бик яхшы. Бу республиканың тоткан мәсләгенә дә туры килә. Безгә рәсми сәясәттә дә шушы юнәлештән тайпылмаска кирәк. Барыннан да элек, күпмилләтле республика шартларында тотрыклылык зарури. Милләтләрнең берсен дә өстен куярга ярамый. Татармы, русмы, чувашмы—барысы да тигез хокуклы булырга тиеш.

—Борчылмагыз, Ильяс Хәбирович, берәүгә дә болганчык суда балык тотарга ирек куймабыз.

Шушы очрашудан соң күп тә үтми Галимовның бер калын журналда болгар-татар тарихына багышланган зур күләмле мәкаләсе басылып чыкты. Татар милли тарихының нинди юнәлештә үсәргә тиешлеге ассызыкланган иде анда. Дөрес, автор татар халкының этногенезы мәсьәләсендә бердәнбер хәлиткеч компонент теориясенә генә ябышып ятмый. Әлеге мәкаләсендә ул, мәсәлән, Идел буе татарлары халык буларак, нииндидер ырунын сан ягыннан үсеше исәбенә түгел, ә башка халыклар кебек үк, Урта Идел буенда яшәгән төрле халыкларның берләшүе юлы белән формалашкан. Менә болгарларның, мишәрләр, бортаслар, башкортлар, удмуртларның да өлеше кергән, дип тәкрарлый.

Бу исемлектә Алтын Урда татарлары гына юк. Булуы да мөмкин түгел! Ник дисәң, алар басып алучы, баскын, Болгарны туздыручы. Ә әлеге "татар" дигән яңа милләт үз исеменнән хурланып, мыскыллы гомер кичергән. Күренекле рус тарихчысы Худяков әйткәнчә, Урдадан чыккан татарлар хан тирәлегенең хәрби аристократиягә караган бик кечкенә катламын тәшкил иткәндер, мөгаен. Рус елъязмаларында да

Казан ханлыгы халкын татарлар дип түгел, казанлылар дип атыйлар.

Күренә ки, татардан Галимовка кадәр үк ваз кичкәннәр икән ләбаса!

Әлеге мәкаләне Кәшшафның өстәленә Әлтаф китереп салды.

—Син хәзер бик популяр кешегә әйләндең, шушы гәжиткә имзаңны сырла әле,—диде шаяртып,—киләчәк буыннарга бер ядкәрең булыр.

—Нәрсә, Тәфкилев тагын бер-бер мөгез чыгарганмы әллә?—дип сорады Кәшшаф илтифатсыз гына.

—Тәфкилев кенә булса, бер хәл иде. Башта күз йөртеп чык әле, гәп соңыннан.

Кәшшафның күзләре иң беренче булып үз исеменә төртелде. Чөнки Әлтаф аның фамилиясе астына кызыл карандаш белән сызып куйган иде. Тагын өч-дүрт фамилия бар. Галимов аларны "узгынчы татарлар" дип атаган. Күрәсең, ул үзен кемнәргәдер исем тагарга вәкаләтле кеше итеп саный иде.

Кәшшаф, әлеге мәкаләгә җавап сыйфатында, Әлтафка автограф итеп, Мәрҗанинен татар турындагы сүзләрен язып бирде: "Болгар мәмләкәте халкының, аларга иярүче һәм аларга күрше булган мөселманнарның күпчелеге соңга таба татарлар тарафыннан җинелделәр, һәммәсенә дә "татар" исеме бирелде, иске исемнәр беттеләр, югалып калдылар".

—Бүгенге тел белән әйткәндә, болгарлар татарлар тарафыннан ассимиляцияләнәләр, йотылалар. Син ни өчен Исхакыйның "Инкыйразы"нда болгарларның иң соңгы вәкиле Җәгъфәр җан тәслим кыла дип уйлыйсың?—дип сорады Кәшшаф. Һәм үзе үк җавабын да бирде.—Чөнки юк ул болгар, беткән, тамыры корыган.

—Шаяртма, дустым. Җәгъфәр үлмәде, Җәгъфәр ул мин! Без әле үрчиячәкбез, Алтын Урда татарларының арт сабагын укытачакбыз,—диде Әлтаф ясалма бер кылану белән.

—Әйдә, барысына да төкереп, сыра эчеп киләбез. Галимов мәкаләсе тамакны корытып тора әле монда,—дип көтелмәгән тәкъдим кертте Кәшшаф,—кичә буфетка бик яхшы сыра китергәннәр иде.

—Әллә кайчан шулай диләр аны, буш сүз сөйләп күпме вакытны әрәм иттек.

Дуслар бүлмәдән чыгып китәргә өлгермәделәр, сәркәтип кыз кереп, Кәшшафка бер конверт тоттырды.

—Милициядән,—диде ул кызыл иреннәрен мыскыллы кыйшайтып.

Кәшшаф кабалана-кабалана конвертның очын тешләп икегә аерды. Конверт эченнән дүрткә бөкләнгән саргылт кәгазь килеп төште. Тез буыннары калтыранып китте Кәшшафның.

—Аккош күле буендагы мәрәкә буенча чакыралар,—диде,—тапканнар вакыт.

—Бер рәхәтнең, бер михнәте, дустым

—Ярар, син дә ярага тоз салып торма әле. Сүз берләшкәндәй бөтен дөньясы миңа каршы.

—Мине ул исәпкә кертмә, дустым. Әйдә, киттек, бу юлы үзем сыйлыйм, сыра белән генә чикләнмәбездер ахрысы.

* * *

Шушы яшенә житеп, Кәшшафның суд-тикшерү әһелләре алдына беренче мәртәбә басуы иде. Бер-бер җинаять кылган кешедәй ишекне кыяр-кыймас кына ачты. Каушавыннан исәнләшергә дә онытты шикелле. Аңысына янә бер оялды.

—Мин Хәмитов, чакыру буенча килдем.

—Бик яхшы, узыгыз, утырыгыз, Кәшшаф Газизович.

Бүлмә хуҗасының көр тавышы, исем-фамилиясе белән мөрәҗәгать итүе генә аны бу халәтеннән арындырды. Ул батырчылык итеп, тирә-якка күз йөртеп чыкты. Куыш чаклы гына кечкенә бүлмә. Шунда ике

өстәл сыйдырганнар. Почмакта Казан трамвайлары шикелле кыршылып беткән шкаф. Өстәл өсләрендә, шкаф башларында, тәрәзә төпләрендә катыргы папкалар аунап ята.

Бу шапшаклыкка исе китте Кәшшафның. Ул милициядә тәртип корабтагыдан да катгыйрактыр дип уйлап йөри иде.

Тикшерүче аны Аккош күле буенда милиционерлар төзегән акт белән таныштырды.

—Имзагыз үзегезнекеме?—дип сорады.

—Үземнеке, дәгъвам юк.

Актта Заһидәнең дә кулы бар иде. Димәк, аны да чакыртачаклар. Ул шунда гына зур хата җибәргәнен аңлады. Заһидәне актларга кертеп бутыйсы калмаган да соң? Нишлисең, тәҗрибәсезлек. Шулай да Кәшшаф милициянең машина документларын табып бирүенә өмет тота иде. Тикшерүче исә нигәдер әңгәмәне документлардан түгел, ир белән хатын мөнәсәбәтләрен ачыклаудан башлады.

—Минем гаилә хәлләренең әлеге вакыйгага нинди катнашы бар соң?—дип ризасызлыгын белдертте Кәшшаф.

—Алайса сорауны конкретрак бирәм: Бәширова сезнең кемегез ул?

—Хезмәттәшем.

—Сез барлык хезмәттәш хатын-кызларыгыз белән дә шулай су коенырга йөрисезме?

Кәшшафның йөзенә кып-кызыл тимгелләр бәреп чыкты. Бермәл кулларын кая куярга белмичә аптырап торды, әле өстәл өстен сыйпаштырды, әле тезләрен капшады. Аннан соң гына:

—Юк,—дип җавап бирде.

—Димәк, Бәширова сезнең гади хезмәттәшегез генә түгел?

—Василий Андреевич, зинһар өчен аны чакыртмагыз инде, бар сорауларыгызга да үзем җавап бирермен. Үтенеп сорыйм!

Кәшшаф сөяк өмет итеп иясенә баккан ач эт шикелле тикшерүчегә текәлде. Тегесе ана күтәрелеп карамыйча гына язу машинасында теркелдәвен белде. Ул әңгәмәне үзе теркәп бара иде.

—Аның да әйберләре урланган бит,—диде ул, ниһаять,—актта да имзасы бар.

—Үтенеп сорыйм, Василий Андреевич

—Эш кузгатылган, Кәшшаф Газизович, мин аны үз белдеклегем белән туктата алмыйм.

Беренче әңгәмә шуның белән тәгәлләнде. Өстәвенә, янә дә шикшөбһәгә төшереп, бармак сырларының сурәтен дә алдылар. Бу эшне башкаручы сержант ул чыгып киткәндә ярдәмчесенә әйтте:

—Бу кеше шизик ахры, куллары калтырана,—диде. Моны Кәшшаф үзе дә ишетте. Шизик кына түгел, әллә кем булырсың, минем хәлгә төшеп карагыз әле, дип уйлады күнеленнән.

Аның беркемне дә күрәсе килми иде, Заһидәгә дә шалтыратып тормады. Туры фатирына юл тотты. Ярый әле, өйдә кеше юк, дип үзенүзе тынычландырды. Дәрига товар артыннан китте, алыш-биреш артыннан йөри, мал кайгырта. Кәрим—әбиләрендә.

Фатирның ишек төбендә ул колакларын торгызып, туктап калды. Чөнки эчтә кемнәрнеңдер сөйләшкән тавышы ишетелә иде. Әллә Кәрим инде? Димәк, Дәрига кайткан. Соң әле ул атна ахырында гына көтәргә кушкан иде ич.

Кәшшаф чын борчылу белән ишекне ачты. Саклап кына торган диярсең, шул мизгелдә үк Кәрим муенына килеп асылынды.

—Әтием, күр, әнием мина нинди матур куртка алып кайткан,—дип мактанды.

Кәшшафның борчуларын ишек җиле үзе белән урамга алып чыгып китте. Ул улын күтәреп алып, күкрәгенә кысты, битен аның битенә тигезде.

—Улым...

—Әтием, ул кадәр кысма, яна курткам бөгәрләнә бит,—диде Кәрим.

Ул арада кухнядан биленә кәкит алъяпкычын буган Дәрига чыкты.

—Ирне менә шулай сыныйлар аны,—дип алтын тешләрен күрсәтеп елмайды.—Вакытында кайттың, молодец. Ә Кәрим янына ешрак барырга иде. Югыйсә, мине "апа", сине "абый" дип әйтүгә дә ерак калмас.

—Минем үземне дә нәкъ шул нәрсә борчый,—диде Кәшшаф.

Дәрига плитә янында кайнаша иде булса кирәк, йөзе алсу төскә кергән, күзләре янып тора. Бик сөйкемле иде ул бу минутта. Кәшшаф Кәримне кулыннан төшермичә генә хатынын да кочагына кертте.

Тинтәк мин, аңгыра бәрән, дип үзен-үзе орышты, шушындый улым, алма кебек хатыным була торып, читтә тәм табып йөрим бит, ә? Каян килеп чыкты соң бу Заһидә?

—Әтием, курткамны кара инде,—дип Кәрим анын кочагыннан шуып төште.

Кәшшаф улын бер урында әйләндерә-әйләндерә куртканы энәсеннән жебенә кадәр тикшереп чыкты.

—Син нәрсә, әтием, мин әллә бөтерчекме?—дип четер-четер көлде Кәрим.

—Мондый куртка бер малайда да юктыр әле, Кәрим.

—Унике кесәле, әтием, ышанмасаң санап кара. Менә бер, ике, өч...

Кәрим әнисе шикелле тапкыр сүзле. Әбисе әле дә көлә-көлә сөйли. Узган көз мактанасы килептер, мөгаен, өстәл өстенә яна гына өзеп алган кып-кызыл помидорлар, суты сытылып чыгардай булып тулган алмалар тезеп куйган да оныгыннан:

—Кәрим, бәбкәем, әйт әле, алма тәмлерәкме, помидормы?—дип сораган.

Тегесе бераз башын кашып уйланып торган да әйтеп салган:

—Банан!

—Исем-акылым китте шунда Кәримнең зиһененә,—дип сөйли әбисе,—нишлим, кибеткә чыгып банан алып керергә туры килде.

—Әниең дә бик матур шул синең,—диде Кәшшаф һичнинди ялгансыз.

—Беркатлы хатын-кыз гына ирләрнең ант-вәгъдәләренә, тәжрибәлеләре комплиментларына ышана,—дип көлде Дәрига,—мин үземне тәжрибәлеләр рәтендә йөртәм. Шулай да комплиментларыңны берниндн икеләнүсез кабул итәм. Мактыйсыңны алдан белеп, бер бүләк тә алып кайттым үзеңә.

Дәрига Кәшшафның жилкәсенә каз мамыгыдай жинел кара төстәге бик ыспай пинжәк китереп салды.

Аккош күле буендагы мажаралы вакыйга шаукымыннан Кәшшаф теге вакытта бик жинел котылып калган иде. Дәрига аның сүзләрен шик астына куймады. Чөнки әлегә кадәр Кәшшафның моңарчы бер мәртәбә дә гаеп өстендә тотылганы булмады. "Эсселеккә түзә алмыйча, иптәшләр белән су коенырга барган идек, талаганнар",—дип котылган иде ул чакта. Хатыны: "Кемнәр иде соң ул иптәшләрең?"—дип кайтарып сорауны да кирәк тапмады хәтта.

Дәрига алыш-биреш эшенә бик маһир булып чыкты. Башта Польшага йөрделәр, хәзер Төркияне айкыйлар. Кәшшаф үзе дә хатынының эшенә тыгылмый. Нәрсә ала, нәрсә сата, дуслары кем—төпченгәне юк. Соңгы вакытта тормышлары күзгә күренеп яхшырды. Өй жиһазлары яңарды, кием-салым үзгәрде. Кәшшафның барлы-юклы акчасына боларның берсен дә майтарып булмас иде, әлбәттә.

Бу "тигезсезлек" Кәшшафның мин-минлегенә сукмый калмый, билгеле. Мөселман ире жәмгатенең өстенлеген күтәрә алмый бит ул. Ләкин нишлисең. Үзеңнең кулыңнан килмәгәч, тешеңне кысып булса да түзәргә туры килә инде. Шуңа костюмны да риясыз кабул итте.

Телефон шылтырады.

—Мине сорасалар, кайтмады әле, дип әйт,—диде ул Дәригага.—Өйдә дә тынгы бирмиләр...

—Өчпочмакларым көя, үзең җайла,—дип хатыны кухняга кереп югалды. Кәрим һаман күзгә каршында бөтерелә, курткасыннан арына алмый.

—Тыңлыйм,—диде Кәшшаф битараф тавыш белән.

—Мин әле бу—Заһидә.

Кәшшаф Заһидәнең тавышы читкә чыкмасын дип телефон трубкасын бар көченә колагына басты.

Заһидә үпкәле иде.

—Мин үземне кая куярга белми өзгәләнәм, синең исеңдә дә юк. Хәлеңне әйтеп шылтыратырга була иде бит. Шулай шәфкатьсез булырга ярамый ич инде.

Кәшшаф Заһидәнең күз яшьләре тамганын сизеп-тоеп торды. Ләкин ачыктан-ачык сөйләшә алмый иде.

Кухня ишегеннән Дәрига башын тыкты.

—Ярар, калганын иртәгә эшкә килгәч сөйләшеп бетерербез. Доклад нигездә әзер инде,—диде Кәшшаф бик эшлекле кыяфәттә. Ә үзе бу сүзләрне әйткәнче үк телефонның төймәсенә басып куйган иде инде.

—Табын әзер,—диде Дәрига.

Кәшшаф Заһидә кабат шылтыратмасын дип хатынына күрсәтми генә телефонның чыбыгын өзеп куйды.

Озаклап, иркенләп кичке ашны ашадылар. Күчтәнәч коньяк та гайрәтле иде. Кәримне яткыргач, Дәрига юкка чыгып торды. Кәшшаф диванга кырын ятып, телевизорга текәлде.

—Җә, ничек?

Кәшшаф башын калкытты да, шаккатып калды. Дәрига, әйтерсең лә, журнал тышлыгыннан гына төшкән. Чын мадонна! Яңа гына яуган кар шикелле ап-ак төстәге йөзү костюмыннан иде ул. Аяклары яшь болан аякларыныкы шикелле төз, зифа. Биек үкчәле түфлиләр аны тагын да күркәмләтеп күрсәтә иде.

Кәшшаф хатынын кочаклап алганын сизми дә калды.

* * *

Сәүдә үзенә бер үзгә дөнья. Аның үз фәлсәфәсе, үз кануннары бар. Юнан фәйләсүфләре, мәсәлән, шул җөмләдән Аристотель дә, сәүдә вә кул һөнәрләре белән шөгыльләнүчеләрне түбән һәм ким кәсепчеләрдән чутлаганнар. Платон хәтта андыйларның мәдәни хокуклардан мәхрүм булырга тиешлеген тәкрарлый. Рим җөмһүриятендә исә алыш-биреш белән читләр генә шөгыльләнгән.

Хак бәясен биреп, сәүдә кәсебен абруйлы хезмәт дәрәҗәсенә күтәргән зат Рәсулулла хәзрәтләре. “Иман сәүдәгәрләр шәһидләр белән бәрабәр савапларга тиң”,—дигән.

Болгар, Казан ханлыклары чорында да сәүдә башка халыклар белән икътисади, мәдәни, рухи багланышлар урнаштыруда искиткеч зур роль уйнаган. Рус патшалары да аны кысмаган. Чөнки сәүдә казнага зур файда китергән. Сәүдәгәрлеккә тоталитар режим чик куйды. Җәмгыять янә Юнан дәверенә әйләнеп кайтты. Кәсепчеләргә “спекулянт” дигән тамга сuктылар.

Демократик үзгәрешләр чорында сәүдә шушы хәрабәләр арасыннан башын күтәрде. Традицияләр инде онытылган, максатлар да бүтән. Беренче урында—акча! Саф акчамы ул, күз яше хисабына алынганмы, анысы әһәмиятле түгел. Фәкать кесәгә генә керсен!

Бу инде бәйдән ычкынган кыргый базар иде.

Дәрига башы-аягы белән менә шушы упкынга чумды. Базар аны бөтереп алды. Елатты, бәргәләде, суккалады. Шунда үзе дә нығыды, хәйләләргә, алдарга, сүгенергә өйрәнде.

Польшага тәүге тапкыр баруы хәтеренә төшкәндә хәзер дә тәннәре калтыранып китә. Ул вакытта таныш-белешләре дә, таяныр кешесе дә юк иде әле. Үзе шикелле бер укытучы белән тәвәккәлләгәннәр иде. Поезд чумаклар (челноклар) белән шыгрым тулы, барысы да товарга бара. Баксаң,

Россиянен бөтен Европа өлеше йөри икән Польшага.

Варшавага төнгә каршы килеп төштеләр. Ә анда мәхшәр! Борын тыгар урын юк. Кая барып бәрелергә дә белмисең. Шулай кем артыннан иярергә белмичә ан-сан итеп карангалап торганда алар янына мәһабәт гәүдәле бер поляк туктады. Башында модалы эшләпә, өстендә затлы плащ.

—Проше, пани, сезгә ярдәм кирәкмиме?—дип бармак очлары белән генә башыннан эшләпәсен калкытып куйды.—Таныш булыйк, пан Пильсудский.

Аллдана күрмәгез, анда Шомбайлар күп дип кисәткәннәр иде Дәриганы. Шуна күрә ул бу озын буйлы чибәр кешегә ачык йөз күрсәтмәде.

—Рәхмәт, безгә берниндии дә ярдәм кирәкми,—дип читкә борылып басты. Ләкин кая бәрелергә, транспорт йөрүдән туктаган, танышлары юк. Шуңа күрә вокзалның аулаграк жиренә барып кунакладылар. Тик монда да тынгылык бирмәделәр. Бу юлы юлпыч корсагы тезенә кадәр асылынып төшкән бер юан адәм бәйләнә башлады. Үзләренчә сөйләшсә дә, аның бинокль сораганы аерымачык аңлашыла иде. "Бинокль, бинокль",—дип учларын йомарлап күзләренә куеп-куеп ала.

Бу Дәриганы гажәпләндермәде. Чөнки Польшага килгән һәр татарстанлы Казан бинокле, Чистай сәгатьләре юнәтеп килә. Ул әйберләр аларда да бар, әлбәттә. Ләкин караңгы почмакта бу хакта сүз кузгату зур ахмаклык булыр иде.

—Юк, бездә берниндии дә бинокль юк,—диде Дәрига.

Ул арада тагын бер кеше пәйда булды. Анысы яңый ук башлады.

Чит ил, чит шәһәр. Кемнән ярдәм сорарга? Дусты мышык-мышык еларга ук тотынды. Җебегән. Үзенен дә жаны табан астына төште. Ни дип шушы караңгы урынга килеп урнаштылар сон әле алар? Монда полиция дә бардыр ич инде. Әллә тавыш күтәрергәме? Бәлкем, ишетеп ярдәмгә килерләр.

Ният итеп авызын ачарга да өлгермәде, жир астыннан калыккандай каршыларына теге фырт кеше килеп басты.

—Хәзер үк күземнән югалыгыз!—дип кычкырды ул тегеләргә.—Паниларга бәйләнергә ярамый. Алар безнен кунакларыбыз. И, мәнсезләр.

Юлпыч корсакның иреннәре чалшайды. Ләкин Эшләпә дә куркаклардан түгел икән, кул таягы белән тегенә нык кына кизәнеп тә алды, теленнән "полиция" сүзе дә ычкынды кебек. Тайдылар. Пильсудский да: "Мин хәзер урап киләм",—дип каядыр китеп барды. Үзе шундук әйләнеп тә килде. Ике кулында ике катыргы стакан. Аларда кайнар кофе иде.

—Рәхим итегез!

Бик хикмәтле кофе булды бу, арыган тәннәренә көч кереп, күнелләре күтәрелеп китте. Әйбәт кешеләр бар ул. Күр инде бу полякны, йөрәген ярып бирергә әзер тора бит. Дәрига үзе болай булдыра алмас иде. Бәгыре каты анын. Әнисе дә, кемгә охшап шулай булып тугансыңдыр дип, орыша үзен.

Пильсудский аларны вокзалга якынрак алып барып урнаштырды.

—Җә, ярар, панилар, хушыгыз,—дип, кавалерларча башын иеп саубуллашты.—Мин китим инде. Карагыз аны, сак булыгыз!

Хатын-кызның башына нәфесе житә диләр. Хәерче шикелле, ямаулык күрсәтсән, күлмәклек сорый башлый ул. Соңгы мизгелдә генә Дәриганың да шушы бозык каны уйнаклап алмасынмы.

—Пан Пильсудский, бер генә минутка мөмкинме?—дип полякны киткән жиреннән туктатты.

—Тыңлыйм, пани!

—Ул биноклырләр бездә, чыннан да, бар бит. Аларны урнаштырасы иде. Без әле монда беренче тапкыр гына...

—Самими кеше икәнлегегезне мин бер күрүдә абайлап алдым,—диде Пильсудский,—шуна да хәлегезгә керәсем килгән иде.

—Тагын бер яхшылык эшләгез инде.

—Мин үзем андый алыш-биреш белән шөгыльләнмим шул, пани. Мин сәнгать әһеле, артист. Еш кына халык арасына менә шулай образ,

типаж эзләргә чыгыштырам. Анлыйсызмы? Ләкин дә, ничегрәк итеп булышырга соң әле сезгә? Бер-бер әмәлен табарга иде бит.

Пильсудский кашларын җыерып, күн перчаткаларын бер-берсенә бәргәләп алды. Башын чөеп бераз уйланыбрак торды. Аннан соң: "Көтегез, ярты сәгатьтән килеп җитәм",—дип халык арасына кереп югалды.

—Бу кеше сине сихерләде,—дип көлде Дәриганың иптәш хатыны.

—Ир-ат беркатлы мәхлук бит ул, чит итәк күрсә, акылын җуя. Типаж эзлим ди бит. Без типаж түгелме әллә?

Күп тә үтми Пильсудский үзе дә күренде. Янында йомгак шикелле бер кеше тәгәри.

—Пан Йозеф,—дип таныштырды Пильсудский.—Йокысыннан уятып алып килдем.

—Мин фәкать затлы импорт джинсылары белән генә эш йөртәм шул,—диде ул гафу үтенгәндәй,—бинокль, сәгать ише әйберләрегезне товарга гына алыштыра алам. Өстәү белән, билгеле.

Йозеф русчаны су шикелле эчә иде.

—Бик яхшы, без риза,—диде Дәрига эчке бер куану белән.

Алар читкәрәк киттеләр. Йозеф товарын күрсәтте. Джинсылар, дөрестән дә, затлы иде. Американың үзендә эшләгәннәр, чын джинсылар. Фирма! Дәриганың күзләре янды. Болар бик кыйммәткә китәчәк дип, күнеленнән исәп-хисап та ясап алды. Артист сатулашуда катнашмады, читтәрәк кенә басып торды.

Дәрига Йозефтан дүрт ирләр чалбары, ике пар балалар костюмы алды. Барысы да зәвыклы итеп пакетка төрелгән. Карап торулары күңелле.

Курку белән башланган эш хәерле була ди, тора-бара эшләре пеште бит тәки. Иртән базарда вак-төяк юнәтәсе генә калды. Поезд кичке якта кузгала. Анысы җайлы. Ана кадәр бәлкем өстән-өстән генә булса да шәһәр белән дә танышырга булыр. Варшава—гүзәл шәһәр.

Алдануларын алар иртә белән генә белделәр. Янә дә куанычлары килеп, пакетларын ачып караганнар иде, икесе тиң бөгелеп төште. Ялтырап торган матур пакетларга иске-москы чүпрәк тутырылган иде. Күрсәткән пакетларын бирмәгәннәр, икенчеләрен төрткәннәр.

Дәриганың кулдашы башка базар ягына әйләнеп тә карамады. Үзе исә, киресенчә, алыш-бирешкә үҗәтләнеп, теше-тырнагы белән ябышты.

Алыш-биреш дөньясы шәфкатьсез, аяусыз, әрсез, үчле, астыртын дөнья. Ул дөньяда син ялгызың гына бернәрсә дә майтара алмыйсың. Дөнья—базар, базарда күп йөргән азар, дип бик белеп әйткән борынгылар.

Базар күпләр өчен сөтле сыер ролен үти. Сәүдәгәр сатып алучыны имсә, аның үзен имәргә тырышучылар да бихисап. Милиция, салым әһелләре, базар хуҗалары, санитария хезмәткәрләре, янгынчылар, мэрия вәкилләре... Көнгә икешәр-өчәр тикшерү. Гаеп табу бернигә тормый. Ә бәхилләтү өчен майларга кирәк. Акт төзесәләр, эш тирәнгә китә, чыгымы да арта. Болары әле аның алай ук куркыныч түгел, ни бирсәң, шуна риза. Иң зур афәт—"түбә" дигәне. Аларны тыгындырып кына бетерермен димә. Таш яуса да үз дигәннәрен итәләр, качып та котыла алмыйсың. Ахыр чиктә алтатар теленә күчәләр. Милиция дә алар белән каршылыкка кермәскә тырыша.

Дәрига аерым урын алган көнне иртүк тигәнәк кебек кадалды берсе. Әйберләрен тезеп, эләселәрен элеп, сатуга әзерләнгән генә иде, янында көрәш батырыдай таза гәүдәле бер егет пәйда булды. Авызында сагыз, сыер шикелле бертуктаусыз күши. Дәрига аны сатып алучы дип белде. И, тотынды сайрарга, и, тотынды. Чөнки мондый тәти егетләр акча кызганмый, сатулашып та тормыйлар.

—Мин сезгә Мисыр патшасы мәшһүр Клеопатра рецептлары буенча ясалган кершәннәр тәкъдим итә алам. Гүзәлегезне сөендерү өчен моннан да затлырак кершән таба алмассыз. Алар фәкать миндә генә. Әле сорап-сорап киләләр...

—Такылдама, түтәй, колакны тондырасың,—дип егет сагызын җиргә төкерде дә, янасын капты.

—Мин разведчик.

Яна клиентларны "регистрация"гә алучыларны алар үзара "разведчик" дип йөртәләр икән.

—Нинди разведчик?—дип аптырап калды Дәрига.

—Булды, түтәй, житте. Бу безнен биләмә. Бүгеннән ясак түли башлаячаксын. Кичкә бер "курчак" хәзерләп куй. Керү взносы.

—Әле сата да башламадым, каян алыйм мин ул каләр акча?—дип кызып китте Дәрига.—Мина бернинди дә "түбә" кирәкми. Сакларлык малларым юк.

—Мин әйттем, түтәй.

Егет тук аю кебек алпан-тилпән атлап, будкалар арасына кереп китте. Дәрига шом эчендә калды. Ул, әлбәттә, бу хәлләрдән хәбардар иде. Алардан котылу чарасы юк диләр. Күршеләре дә шуны тәкрарлый. Ләкин берсенең дә күпме түләп торулары турында ачылып сөйләшәсе килми, соравынны ишетмәмешкә генә салышалар.

Дәриганың да белмәгән-күрмәгән кешеләргә кан бәрабәренә табылган акчасын алай тиз генә чыгарып саласы килми шул. Кемнән саклыйлар соң алар аны? Үзләре кебек башкисәрләрдәнме? Ә милиция нәрсә карый?

Ул бу сорауларның очына чыга алмады. Кичен теге егет тагын пәйда булды.

—Кая, бир!—диде.

—Акчам юк,—диде Дәрига.

Егет аңа баштан-аяк сөзеп карады да, сагызын төкереп китеп барды.

Икенче көнне сатуга дип килсә, аһ итте Дәрига. Киоскның ишек-тәрәзәсе бер җирдә, түбәсе икенче җирдә аунап ята иде. Көне шуны эшләтеп үтте. Эше төгәлләнер алдыннан янә "разведчик" килеп басты.

—Түтәй, мин килдем,—диде, әйтерсен лә, калерле кунак. Аңынчы күршеләре Дәриганы мөнәсәбәтләрне катлауландырма, көн күрсәтмәячәкләр, дип кисәткәннәр иде инде. Ул сүзсез генә егетнең кин учына алдан хәзерләп куйган төргәген салды. Тегенең иреннәре кыйшайды.

—Окей, түтәй, гуд бай.

Бу сүзләр әллә кайчан шулай кирәк иде дигән мәгънәне аңлата иде бугай.

Бер ел эчендә башыннан әллә ниләр кичерде Дәрига. Инде ул үзе дә төркемдә. Пильсудский кебекләр аның ягына карарга да базмый. Дөрес, хәзер алар Төркия юлын таптыйлар. Анда хәл үзгәрәк. Бу илдә ин арзан, иң үтемле товарга ябырылучы Русия кәсепчеләрен кочак җәеп каршы алалар.

Очсыз чалбар төпсез була. Күпме доллар шунда утырып кала. Югыйсә, ул әйберләрне үз илендә дә житештерергә мөмкин ләбаса! Хәер, бусы Русиянең гомер-гомергә килгән булдыксызлыгы. Ул һәрвакыт бай хәерче булды. Һәм шулай булып калырдыр да, мөгаен.

Барысына да ияләште Дәрига. Бервакыт шулай, төргәк-төргәк әйбер төяп, фатирына кайтып ауды. Утырып чәй эчте, черем итеп алды. Шуннан соң гына әйберләрен урнаштырырга тотынды. Тик ник бер төргәген урыныннан кузгата алсын?

—Таш төягәнсен, ахры,—дип көлде Кәшшаф.

Ул бит әлеге төргәкләрне Төркиядән алып кайтты. Ничәмә-ничә автобус, самолет. Дүртенче катка ялгызы ташыды.

Белеп әйткәннәр, дәрманы килгәндә адәм баласы дию пәриен дә егып сала.

Тик шулай да, төркемдәгеләр аны мыскыллап "абыстай" дип йөртәләр. Ул әлегә берәүне дә үзенә якын җибәрмәде. Иргә карап яту хәзерге заманда җүләрлек, типтереп яшәргә, дөньяның бар ләззәтен татып калырга кирәк, дип ничек кенә кодаласалар да, беркемне дә тыңламады. Аны үзенеке итәргә теләүчеләр әле дә шактый. Дәриганың нык торуы, тотанаклылыгы аларны тагын да үҗәтләндерә, ахры. Бер алдына, биш артына төшәләр, ярарга тырышалар. Ихтирам итүләрен дә тоеп йөри. Ир-ат җилбәзәк хатыннар янында кайнаша. Әмма күнеле белән тугрылыклыларга тартыла. Инглиз джентельменнары шикелле. Алар да блондинкаларны охшаталар, брюнеткаларга өйләнәләр ди.

* * *

Дәрига кеше бөкресенә атланып оҗмакка керә торган затлардан түгел. Ул һәрвакыт үз кояшын, үз учагын булдырырга омтылды. Кылган гамәлләренең хаклыгына чын күнеленнән ышанып яши иде. Кәшшафка кияүгә чыгам диде—чыкты. Ир бала тудырам диде—тудырды. Бизнеска керәм диде—керде. Күнеле тыныч иде. Чөнки барысы да аныңча иде. Киләчәктә дә шулай булачагына да шикләнми иде.

Һәм уйламаганда, көтмәгәндә—хыянәт! Мәңге бозылмас шикелле тоелган тормыш таш тигән көзгедәй чатнады да китте.

Дәрига да тикшерүче янына ире шикелле шик-шөбһәле уйлар белән барды. Чакыру кәгазен күрүгә, чакканнар икән, дигән уй кисеп узды. Кем булыр бу? Югыйсә, чын-чынлап ачуланышкан кешесе дә юк шикелле. Кешеләр белән уртак тел таба белә ул, каршылыкка керергә тырышмый. Шуның белән бергә, алыш-биреш, сату итү белән шөгыльләнгән кеше гел туры юлдан гына йөрми, аңардан һәрвакыт гаеп табарга мөмкин. Ләкин Дәриганың зурдан кубып закон бозганы юк. Моңарчы хокук саклау органнарының күзенә чалынганы булмады.

Тикшерүченең ни өчен чакырганын белгәч, исе-акылы китеп торды. Аннан соң теленә килгән беренче сүзне әйтте:

—Ялган!

Тикшерүче мондый кыланышларга күнгән иде инде, стаканга су агызып, Дәриганың калтыранган кулларына тоттырды. Тегесе аны капылт кына бушатып та куйды.

—Минем ирем галим кеше,—диде Дәрига.

Тикшерүче аны юатырга ашыкты.

—Гафу итегез, Дәрига Хәсәновна, мин һич тә сезнең гаилә мөнәсәбәтләрегезгә тыкшынырга теләмим. Бу сезнең шәхси эшегез. Минем фәкать Кәшшаф Газизовичның машинага кагылышлы документлары турында гына белешәсем килгән иде. Бәлкем, алар элегрәк югалгандыр? Ихтимал, фатирыгызның берәр аулак почмагында аунап ятадыр әле. Галим кешеләрне үзегез беләсез сәеррәк халык, онытучан.

—Ул алдаша торган кеше түгел.

Дәрига төртелеп калды. Читкә борылып, кульяулыгы белән тиз генә яшьләрен корытып алды.

—Алай ук бетерешмәгез әле, Дәрига Хәсәновна, хезмәттәшләр белән аралашу һич тә гаеп нәрсә түгел инде ул.

—Мин сезгә бернинди дә мәгълүмат бирә алмыйм, өйдә юк идем,—диде Дәрига.

—Беләм, Кәшшаф Газизович әйткән иде.

Белми торган булса, бәлкем, әйбәтрәк тә булган булыр иде. Хәзер, әнә, йөрәгенә мәңге төзәлмәс яра алды.

Алдакчы! Фәхиш! Дуслар белән су коенганда таладылар дигән булды бит. Мокыт кына димәссең. Тәтәйләр белән типтерә икән бераү. Ул аны томанага чутлап йөрде. Җүләр. Иделгә таянма, ирләргә ышанма, ди. Утыз яшенә кадәр кыз куенына керә алмаган утын пүләне чакларын оныткан, күрәсең. Мәҗлестә исертеп, үзе янына яткырмаган булса, әле һаман саламторхан булып калган булыр иде.

Дәрига нindидер бик мөһим нәрсә исенә килгәндәй барган җиреннән туктап калды. Юк, монда хикмәт Кәшшафта гына түгел. Сөйрәлчеге башын әйләндергән. Ихтыярсыз бәндә ич ул. Фәненнән башканы белми. Аны кулга төшерү төкерек кенә. Үзе дә шулай эшләде ич. Тегесе, димәк ки, өмет баглый, тартып алмакчы. Юк, тәти кош, Кәшшаф сиңа тәтемәячәк. Кара көл итәм мин сине. Җилегенә төшәм. Күпме көч сарыф итеп корган гаиләсен, дөньясын таркатырга ирек бирергә исәр түгел лә ул. Кәрим хакы да бар әле монда. Ана кеше беренче чиратта баласы турында кайгыртырга бурычлы. Шуңа күрә ул бүген Кәшшаф белән очрашырга тиеш түгел.

Очрашса, барысы да челпәрәмә киләчәк. Үзен тота алмаячак. Ниятен оянны саклау икән, ордым-бәрдемгә барырга ярамый.

Акылы белән үзен тыярга тырышса да, ачуы барыбер аны үз йөгәнендә тота иде. Аяк атлаулары ук үзгәрде. Күзенә ак-кара күренми, элдертә генә. Әледән-әле үткән-сүткән кешеләргә килеп орына. Тегеләре сәерсенеп юл саба. Берзаман абынып китте дә йөзтүбән мәтәлеп төште.

—Аһ...

Аны бер ир кеше күтәреп торгызды.

—Сез авырыйсыз, ахры, ашыгыч ярдәм машинасы чакыртмыйкмы?—дип сорады тирән борчылу белән.

Дәриганың күзләре акайды. Әлеге кеше кайсы ягы беләндер Кәшшафны хәтерләтә иде. Аның юл буе кайнап килгән ачуы бер секундка бүселеп тышка бәреп чыкты.

—Фәхиш! Күземнән югал!

Ярдәмчедән жилләр исте. Дәриганың акылы янә ачылып китте. Юк, болай ярамый, үз-үзенне кулга алырга кирәк, дип уйлады ул. Иң мөһиме, хәзер ачуын басу. Ачуны басуның бердәнбер юлы—эниләренә кайту.

* * *

Дәрига иң элек Зәһидәдән үч алырга ниятләде. Ният бер нәрсә, әмма аны ничек итеп тормышка ашырырга? Нинди жәза уйлап табарга? Дөрес, аның классик алымнары бар-барын, ихтимал, мөгез чыгарып азапланмаска да кирәктер? Әйтик, урамда очрашып, чәченнән сөйрәп йөрергә булыр иде. Дәрига моны ике дә уйламый булдыра алыр иде. Көче дә, үҗәтлеге дә, усаллыгы да житәрлек. Кемдер көндәшенең йөзенә кислота сибә, киемнәрен тураклый. Тик болар борынгы заман гамәлләре. Дәриганың шул сөйрәлчек аркасында кеше арасында хурга каласы килми. Бу көчсезлек булыр иде. Шундый нәрсә уйлап табарга кирәк ки, ул еланнан да яманрак чаксын, рухын, жанын кыйсын. Ә үзе коры калсын, исеменә тап төшмәсен.

Ике-өч көн баш ватканнан соң, ниһаять, эзләгәнен тапты кебек. Йөзендә зәһәр елмаю кабынып алды. Иреннәре исә: “Котырган нәфесенне бастырам әле мин синең”,—дип ысылдады.

Дәрига институтка страхагент сыйфатында килде. Страхагентларның ишек ачык булмаса, тәрәзә ватып кер торган гаять дәрәҗәдә әрсез бәндәләр икәне һәркемгә мәгълүм. Шуңа күрә аларга каршылык та күрсәтеп тормыйлар. Дәрига чәчәннәрчә сүзнең балын агызып сөйли белә. Юмаларга да бик оста. Ике-өч жөмләдән институт хатын-кызларын авызына каратты да куйды. Әллә нинди дөньяда булмаган югары процентлар вәгъдә итте. Имеш, бу тәжрибә рәвешендә генә үткәрелә торган зур яңалык икән, Казанда әлеге экспериментны бернича белгечкә генә ышанып тапшырганнар. Әлбәттә, кемнең инде акчаны көрәп аласы килмәсен ди?

—Кызлар, полисларны тутырып бирегез, мин тикшереп кенә чыгармын, взносларыгызны соңыннан түләрсез,—диде Дәрига. Үзе бур мәче шикелле ялт-йолт каранды. Бу чибәр ханымнарның кайсысы Кәшшафның сөйрәлчеге икән?

Дәрига полисларны жыеп алды, барысын да жентекләп күздән кичереп чыкты. Ләкин арада Зәһидә Бәшированыкы юк иде. Әллә бүлмәне буташтырдым микән, дип уйлап алды Дәрига. Югыйсә, барысы да туры килә иде кебек. Институтта канцелярия бирәү генә, ул 18 нче бүлмәдә урнашкан, диделәр ана.

—Кызлар, бер буш өстәлегез дә күренә, үпкәләштән булмасын, аның иясенә дә полис калдырам,—дип, Дәрига янә бер кармак салып карады.

—Зәһидә Идрисовна нәшриятка киткән иде шул,—диде өлкәнрәк яшьтәге ханым,—озакламастыр, мөгаен.

Шул вакыт ишек ачылып китте.

—Гомере озын икән, менә кайтып та житте,—дип каңгылдашты хатын-кызлар.

Дәриганың эченә ут капты, түбә чәчләре үрә торды. Хәтта конспирация дигән нәрсә дә онытылып торды. Кул тиресен чеметеп алгач кына аек акылы өстенлек алды. Юк, сугышып ир бүлешергә килмәде ул монда, аның планы күпкә отышлырак.

Дәрига ачуын йотып, көндәшен баштанаяк карап чыкты. Шунда ук бәясен дә чыгарып куйды: "Торна. Кытай курчагы". Бу Заһидәнең озын аякларына, сөрмә тарткан кашларына ишарә иде, билгеле.

—Сезгә бер тәкъдимем бар иде,—дип, калтырануын басарга тырышып, Заһидәгә гозерен аңлатты Дәрига. Тегесе каршы килмәде, полисны тутырды. Ниһаять, кирәкле адрес кесәдә.

Кичке якта институт бакчасында дию пәриедәй зур гәүдәле бер егет белән Заһидәне көтеп утыралар иде инде алар. Эш сәгате тулып килә, озакламаска тиешләр. Чыннан да, аллеяда Заһидә пәйда булды. Каләм йоткандай турыга каткан. Биек үкчәләрен ташка бәрә-бәрә тып-тып атлап килә.

—Менә шушы мәткә инде ул,—дип пышылдады Дәрига шәрә башлы таза егеткә. Егетнең кирпечтәй калын йөзе тартышып алды.

—Матур курчак икән ич бу, түтәй.

—Дөрес әйтәсең, курчак. Кытай курчагы!

—Миңа барыбер. Кытайныкымы, Японныкымы сәмәне генә булсын.

—Анысы килешкәнчә. Яртысы хәзер, яртысы...

—Беләм,—дип кырт кисте Такыр баш,—кабатламасаң да була.

Заһидә горур кыяфәт белән кырт-кырт басып узып китте. Дәрига аның артыннан сүгенү сүзләре яудырды.

—Сука, блин.

—Син борынгы заман кешесе икән, түтәй,—дип көлде Такыр баш,—хыянәт түгел, хыянәт итмәү гаеп хәзер.

Дәрига җавап кайтармады. Әлбәттә, хәзерге буынның бу фәлсәфәсе аңа яхшы таныш. Яшьләрнең күпчелеге шул рәвешле яши дә. Ә ул гаилә мәсьәләсендә кадими караштa тора. Үз оясы, үз кагыйдәләре. Иң мөһиме, тотрыклылык. Заһидә аның менә шушы кыйбласын тар-мар итеп ташлады, таяныч ноктасын какшатты. Хәзер Дәрига котырынган диңгез уртасында кулдан киткән кораб хәлендә. Ихтимал, түзәр дә иде, характеры нык аның. Әмма кичерә алмый. Инде нияте көндәшен дә шушы чарасызлыкка дучар итү. Моның берданбер юлы, хатын-кыз буларак, Заһидәнең дәрәҗәсен төшерү, абруен пычрату, мәсхәрәгә калдыру.

* * *

Такыр баш Заһидәне өч көн андыды. Кая бара, кайсы юлдан йөрибарысын да ачыклады.

Заһидәнең иң яраткан урыны Киров бакчасы иде. Юлы ничек кенә урау булмасын, шушы бакчага кермичә калмый иде ул. Эштән кайтышлый озаклап күгәрченнәр белән булыша. Ашата, эчертә. Кошлар да аңа күнегеп беттеләр инде, сырып алалар. Кайбер тәвәккәлрәкләре җилкәсенә үк килеп кунаклый. Көйли-көйли сыйлый ул аларны.

Күгәрченнәр ояда ла,
Оялары пыяла.
Күгәрчен кебек гөрләшеп,
Күк күгәрчен, сандугачым,
Торсаң икән дөньяда.

Ә ишек алдында аны мәчеләр өере сагалап тора. Алары күпкә әрсезрәк, ризык бирмәсәң, өскә сикерергә әзерләр. Баласыз хатын шулай инде ул, кош-корт, киек-җанвар белән юана. Бу хәл тирә-юньдәгеләргә ошамый, билгеле, орышалар, алай бик яраткач, өеңдә асра диләр.

Киров бакчасында Заһидәгә якын килә алмыйсың. Анда төннәрен дә кеше мыж килеп тора. Милиция дә тыз да быз йөри. Иң унайлы урын ишек алды дигән нәтиҗәгә килде Такыр баш.

Ишек алды, дөрестән дә, аулак иде. Ул таш койма белән әйләндереп

алынган. Аргы очында сарайлар тезелешеп киткән. Туалет. Шунда гына чүп савытлары, утын өемнәре. Карангы. Капка башына эленгән электр фонаренын соры яктылыгы анда барып житми. Нәкъ убыр оясы. Сагалап торсан, бер жае чыкмый калмас.

Чыннан да, бер көнне Заһидә Иванов жәмгыяте клубында шактый тоткарланды. Ул инде хәтсездән Остаз тәгълиматы буенча яши, акрынлап имче Маһинур йогынтысыннан арынып бетте. "Ничек итеп мин ана әни дип дәштем икән",—дип, хәзер үз-үзенә шакката.

Заһидәнен бүлмәсендә ут юк иде. Димәк, әле кайтмаган. Егет кулларын угалап куйды. Ниндидер эчке сиземләү белән, ниһаять, бүген теләгенә ирешәчәген тоеп алды. Тизрәк араны өзәргә кирәк, болай да озак юанды. Ул, гомумән, беркайчан да мондый "пычрак" эшләр белән шөгыльләнмәде. Дәрига өчен генә алынды. Дөресрәге, шеф кушты. Абыстайга күз салган булса кирәк. Шулай, һәркемнен үз мәнфәгате.

Такыр баш Заһидәне шундук танып алды, анын йөрүен беркемнеке белән дә бутап булмый. Кавказ хатын-кызларынын биюенә охшаш йөрү: атламый, йөзә.

Такыр баш кулындагы мәче баласынын койрыгын кысты.

—Ми-яу, ми-яу,—дип чыелдады тегесе.

Заһидә мондый ялварулы мескен тавыш янынан тыныч кына үтеп китә димени, адымнарын акрынайтты. Егетнен мәкере шуннан гыйбарәт иде дә инде. Ул янә койрыкны борды.

—Ми-яу, ми-яу.

Такыр баш мәче баласын утын өеменә орды да, Заһидәне эләктереп алды.

—Кисәтеп куям, түтәй, кычкыра-нитә калсан, муенынны өзәм,—дип пычагын Заһидәнен бугазына китереп терәде.

Бу шулкадәр тиз булды ки, Заһидә аһ та итә алмады. Шулай да үзенен нинди капкынга килеп капканын бик тиз төшенеп алды. Мондый чакта карышу бик куркыныч нәрсә дигән сүз колагына кереп калган булган икән. Шул хәтерен бораулап алды.

—Чишен!—дип боерды егет.

Карышунын куркыныч нәрсә икәнен акылы белән анласа да, Заһидә кыл да кыймылдатмады. Такыр башнын көтәргә вакыты юк иде. Шуна күрә үзе эшкә тотынды. Ин элек корбанынын кофтасын умырып алды, аннан сон итәген аерып төшерде... Ул аны мозахистларча ин арзан фәхишәләрдән дә түбәнрәк итеп мыскылларга тиеш иде.

Егетнен куллары Заһидәнен күкрәк алмаларына орынып китте. Кайнар иде алар, тыгыз... Электр тогы сыман күзәнәкләренә кан бәрде. Дәрига да, шеф та, көчләү тыела дигән кисәтүләр дә онытылды. Хайвани теләк барысын да йотты. Куллары чалбар каешына үрелде.

Заһидә егетнен бу каушавыннан бик оста файдаланды, бар көчен жыеп читкә ыргылды.

* * *

Иванов жәмгыяте рәисе Мефодий югары белемле табиб. Чуваш милләтеннән. Үз даирәсендә бик абруйлы кеше. Мөритләрен авызына гына каратып тора. Күптән инде гамәли медицина белән шөгыльләнми. Үзен Остазнын шәкерте, рухани зат дип саный. Чын аскет. Гаиләсе дә, фатиры да, балалары да юк.

Заһидәнен хәтеренә төште, ул аны элек тә күргәне булган икән. Нинди сәер карт бу дип артыннан гажәпләнеп карап калган иде. Кешеләр инде кышкы киемгә күчкән, ә ул лаштыр-лоштыр карлы суны ярып, яланаяк атлый. Изүе ачык. Сакыл-мыегы, ачуым килмәгәе, биленә житкән. Куе төк баскан йөзендә куздагы күмердәй күзләре генә янып тора.

—Абау, тиләләр йортыннан качкандыр бу адәм,—дип сөйләнде бер хатын,—килеп ябышса, аллам сакласын.

Жүләр дигәнебез ниндидер үзенә бер үзгә тавыш белән башын иеп:

"Исәнмесез, сау-сәламәт булыгыз",—дип, изге теләкләр теләп узып китте.

—Әйттем бит, тиләләр йортыннан качкан бәндә бу дип. Кем инде шәһәрдә белмәгән-күрмәгән кеше белән исәнләшеп йөрсен.

Шушы кырык яшьлек "карт" Заһидәнең рухи атасына, иң якын кешесенә әверелер дип кем уйлаган? Хәзер Заһидә үзе дә Казан урамнарында кешеләргә сәлам биреп уза. Тиле диючеләргә җавабын да белә. Остаз әйткән: "Исәнлек теләү гыйлемлек түгел, ә кешенең гамәле. Бу—мәхәббәт, кешеләр арасындагы дуслык. Сезнең бурыч хәл белешү, кабул итәләрме-юкмы—монысы башка мәсьәлә",—дигән.

Ишек алдындагы һөҗүм турында да Заһидә иң беренче Мефодийга чиште. Тегесе йөнтәс кашларын борын өстенә җыеп, озак кына дәшми утырды. Ул киңәш-табыш биргәндә һәр сүзен пәйгамбәрләрчә төптән уйлап, аңа тирән мәгънә салып әйтергә күнеккән.

—Остазның сынавы бу, Заһидә ханым. Хак шулай. Хәтереңә төшереп кара әле, элегрәк синең белән элемтәгә керергә омтылып карамадымы?

—Миңа калса, бу аерылган ирем ягыннан килә,—диде Заһидә.—Теге вакытта бозымлауларын кайтаргач, Суфия исемле апасы чистый үчләнде бит. Өстемә яллап велосипедчы да җибәреп карадылар инде алар. Хәзер башым катты, ни дип юрарга да белмим.

—Ләкин ниятләре тар-мар килде, шулаймы? Чөнки сиңа Остаз ярдәмгә килә.

—Мин үлемнән куркам мине һаман сагалыйлар,—диде Заһидә яшь аралаш.

—Менә монысы гөнаһ инде, Заһидә ханым,—диде Мефодий төкрекләрен чәчә-чәчә.—Остаз үлемне бөтенләй танымый.

—Беләм,—диде Заһидә,—Порфирий Корнеевичның "Мин бернәрсәдән дә курыкмыйм, үлемне гомумән кабул итмим. Чөнки табигатьтә үлем дигән нәрсә юк", дигән сүзләрен куен дәфтәремә дә язып куйдым.

—Әйе, кеше—мәңгелек. Һәм ул дөньяга төрле сурәттә килергә мөмкин. Хәтта хайван, җанвар рәвешен алуы да ихтимал. Тән генә үлә, җан үлми...

—Алары шулаен шулай, тик бу сынауларның да бер ахыры булырга тиештер ләбаса инде,—дип Заһидә үзенекен сукалады,—ялыктым инде мин ул сынаулардан.

Мефодийның җирән сакалы арасыннан ак тешләре күренеп алды.

—Остаз да күп сынаулар үткәргән, төрмәләрдә утырган, психушкаларга ябылган, Заһидә ханым. Андый чакларда ул нишләгән?—дип сорады Мефодий шәкертеннән имтихан алган мөгаллимдәй.

—Гимн җырлаган.

—Дөрес. "Гимнда хәзер барысы да бар. Мин гимнны минут саен җырлыйм",—дип көндәлегенә язып куйган Остазыбыз. Әйдә, без дә җырлыйк әле шушы тылсымлы гимнны, Заһидә ханым.

Мефодий опера артисты сыман көчле калын тавышы белән җырлап та җибәрде. Ана Заһидә дә кушылды.

Люди Господу верили как Богу,
А он сам к нам на землю пришел.
Смерть как таковую изгонит,
А жизнь во славу введет.

—Күнелем сизенә, Заһидә ханым,—диде Мефодий самими бер эчкерсезлек белән,—Остаз сине бу борчуларың белән япа-ялгыз калдырмас.

Әйе, моңа кадәр һәр очрашу Заһидәгә яхшылык кына алып килде. Беренчесендә сырхау томалаган аңын ачып, зиһенен айнытып киткән иде. Ире булып ире аны тиләләр рәтенә кертә башлаган иде бит. Мунчада сөяркәсе белән тоткач, ике дә уйламый Заһидә судка аерылышу турында гариза илтте. Ул чакта Остазны белми иде әле. Аның өчен ул Ак бабай иде. Шәфкатьле, миһербанлы Ак бабай! Ул аннан бервакытта да курыкмады. Киресенчә, очрашуны көтеп ала иде.

Такыр башның төнге һөҗүме Ак бабайның килүен тизләтте, ахры. Заһидәнең өянәге кузгалды. Беркөнне Кәшшаф: "Җимешем, мин сине бик

сагындым",—дип кочып алмакчы иде, аны ачу белән этеп җибәрде:

—Кит әле, күземә кылчык шикелле кадалма сана!

Заһидә бераздан кайтып төште. Кәшшафны нахакка рәнҗетүен үзе дә аңлады. Хәер, анын үзен дә гаепләп булмый. Ник дисән, бу тискәрелеге, кирелеге ихтыярыннан тыш кузгала ич.

Кичен тагын башы әйләнеп китте. Кәнәфидә журналлар караштырып утыра иде. Тереза-Ананын зәгыйфь акыллы балалар шифаханәсендәге сурәтен күргәч, башта күз аллары әлҗе-мәлҗе килеп алды, аннан сон үзен-үзе белешмичә сикереп торды да тумбочкадагы лампаны идәнгә бәреп төшерде. (Бу затлы бәллүр лампаны узган ел 8 нче мартта Кәшшаф бүләк иткән иде.) Тотынды таптарга, тотынды таптарга, плафон пыяласы онга әйләнде.

Ә бераздан үзенең гамәлен күреп, артына авып китә язды. Утырып елады. Тик бер-ике сәгать уздымы-юкмы, янә өянәге кузгалды. Авылдан кучтәнәч итеп хәтсез ит җибәргәннәр иде, шуны трамвай юлына чыгарып ташлады. Аш салам дип итне кулына гына алган иде, укшырга тотынды. Шул секундта ук: "Бозым!"—дигән уй башын мингерәйтте.

Төне дә тынычсыз үтте. Күзләре йомылуга саташу баса. Мона каләр дә керә иде ана хафалы төшләр. Ләкин ахыры Һиндстан кинофильмнарындагы шикелле әйбәт тәмамлана иде. Упкынга төшкәндә кыяга тотынып кала, дәрьяда бүрәнәгә ябыша, тормозлары ычкынган машинадан да ниндидер могҗиза белән исән-имин сикереп котыла иде. Соңгы вакытта ул әлеге хәтәр хәлләрдән фәкать уянып кына арына.

Бу юлы Заһидә биниһая зур аждаһа белән тартышты. Килбәтсездер үзе, тәненнән әллә нинди кәкре-бөкре ботаклар чыгып тора. Инде күлдән чыгып җиттем генә дигәндә, теге саз гыйбрәте аны эләктереп ала да әчкә ата, эләктереп ала да әчкә ата. Хәлдән тайды. "Бетүем шушы икән",—дип офтанды Заһидә.

Курку аны йокысыннан уятты. Шыбыр тиргә баткан, тәне калтырана, йөрәге еш-еш тибә иде.

Ул урыныннан сикереп торды да, тиз-тиз генә киенеп, урамга чыкты, Киров бакчасына кереп, ин аргы почмактагы эскәмиягә барып кунаклады. Авыз эченнән генә Гимнны көйли башлады:

Люди господу верили как Богу

Төн дә Заһидәнең күңеле шикелле үк тотрыксыз иде. Шыксыз. Җил бер котырынып ала, бер тына. Якында гына элмәгеннән ычкынган яктырткыч шак та шок килеп баганага бәреп уйный. Ара-тирә үгез үкергән тавыш чыгарып төнге троллейбуслар узып киткәли. Боларның һәрберсе Заһидәнең миендә ниндидер җәрәхәтле эз калдыра.

Җил агач ябалдашларын шаулата-шаулата тагын кузгалып алды. Монсында калай яктырткычны кубарып алып, асфальт юлга ора-бәрә тәгәрәтеп үк алып китте. Шуннан соң барысы да тынып калды, бу җилнең соңгы талпынуы иде булса кирәк. Заһидәнең дә сулышы җиңеләеп китте, гүя башын кысып торган кыршауны кемдер кисеп төшерде.

Шушы хозур халәттә күпме утыргандыр, берзаман күзен ачып караса, янында филдәй зур бер эт басып тора. Колаклары гына да әрекмән яфрагы чаклы. Үзе шундый мәхәббәтле, шундый матур, ипле.

Заһидә ирексездән этнең башыннан сыйпады. "Килденме, мин сине бик көттем",—диде. Эт анын кулын ялап алды.

—Мин синен ярдәменә бик мохтаж.

Эт беләм дигәндәй, башын селкеде.

—Бу араларда йөрәгем бәргәләнде, мине бик нык кимсеттеләр.

Маэмай акыллы күзләре белән Заһидәгә яратып карап торды.

—Рәхмәт.

Эт Заһидәнен бу сүзләрен ишетмәде, ул юкка чыккан иде инде. Заһидә дә урыныннан кузгалды. Күктә кояш балкый. Бакчада балалар чырчу килә, күгәрченнәр гөрелдәшә. Урамда тормыш кайный.

Заһидә оча гына. Аяк-гәүдәләре генә түгел, җаны оча иде.

Кәшшаф аны шушы халәтендә очратты. Алдан урынын, вакытын белгә-

ләп куйганнар иде диярсең. Заһидә Кәшшафның муенына килеп асылынды.

—Мин сине бик көттем.

—Көткәнгә шулай качып йөрисеңме?

—Чәнечкеле сүзләр әйтмә миңа бүген, Кәшшаф, син мине ярат кына...

Кәшшаф Заһидәнең очкынланып янган күзләренә карады. Алардан дәрт, кайнарлык, сөю бөркелә. Ул ышанырга да, ышанмаска да белмәде. "Күземә кылчык шикелле кадалма сана",—дигән Заһидә түгел иде бу.

Кияүгә чыкканда мыскалга салынмаган ак ефәк иде Заһидә. Ләкин Гаффар моның белән исәпләшеп тормады. Зөфаф кичендә салмыш килеш яшь кәләшен ит чабучыдай ботарлап ташлады. Заһидә ике-өч көн аңына килә алмыйча йөрде. Шуннан соң бик күпләргә ләззәт коесы булып тоелган якынлык аның өчен җәфалы гамәлгә әверелде. Ир-атны күрәлмас булды.

Бүген ул беренче мәртәбә үзен хатын-кыз итеп тойды. Тәнең, җанын фәкать күңел генә тоемлый ала торган татлы хис биләп алды.

—Кәшшаф, кочакла мине, нык-нык итеп, кысып-кысып кочакла.

—Син болай да минем кочакта, җимешем.

—Минем синең кочагыңда эреп китәсем килә.

—Әйдә, өйгә керик, бу бит урам.

Көнне яратышып үткәрделәр. Хәлләре беткәнче сөешәләр дә, бераз тынып торалар. Аннан соң тагын. Тагын, тагын...

—Син минем ирем,—диде Заһидә.

Шул сүзне әйтте дә аптырап калды. Чөнки аның моңа кадәр Кәшшаф белән булган мөнәсәбәтләренең язмышы турында да, үзенең чын хәле турында да уйланганы булмады. Ул Кәшшафны ошатты. Бу аз сүзле, эре сөякле, олы авызлы кеше аны ниндидер ягы белән үзенә караткан иде. Мәхәббәт идеме бу? Бәлкем, сырхаудан арынган кешенең үзен сынап карыйсы гына килгәндер? Хисләре корымаганмы, ир-атка карата мәрхәмәте югалмаганмы, үзен яраттыра аламы?

Менә шулай бернинди максатсыз, ишарәсез дә яратып була микәнни соң ул? Чынында Заһидә Кәшшафны Кәшшаф булганы өчен генә ярата. Хатынлымы, балалымы—бу хакта башына уй кергәне булмады. Дәгъвасыз сөю. Һәрхәлдә, моңа кадәр шулай булды.

—Ирем,—дип кабатлады Заһидә. Һәм тагын уйга калды. Аннары:

—Син миңа өйләнә алыр идеңме?—дип сорады.

Давыллы, ләззәтле яратышу Кәшшафны тәмам әлсерәткән иде. Шушындый җитди фани дөнья елгасына аяк тыга торган чакмы? Ул Заһидәне кочагына кысты. Заһидә назны кабул итмәде.

—Нәрсә инде, мин җавап көтәм, ә син?

Хатынның иреннәре турсайды.

Кәшшаф та Заһидә белән танышканда бу мөнәсәбәтләрнең артын-алдын уйлап тормады. Хәер, уйлап эш иткән булса, ихтимал, бервакытта да Заһидә белән якынлаша да алмас иде. Ул табигате белән йомыкый, аек акыл белән эш итә торган кеше. Әмма мәхәббәт хис гамәле, акылны санга сукмый. Ул зилзиләгә тиң. Аңа бернинди көч тә каршы тора алмый. Кыра, җимерә, вата—барыбер үзенекен итә. Яшь мәхәббәт келәт ватар, карт мәхәббәт пулат ватар, ди. Һич көтмәгәндә башы-аягы белән чумды шул дәрьяга Кәшшаф. Тик бу җиһанда бернәрсә дә гомерлек түгел. Мәңге сүрелмәс кебек булып тоелган ярату хисе дә шундый язмышка дучар. Ни эшләсәң, шуның әҗерен аласың, черки үтерсәң, битеңә чабасың шул ул. Кәшшаф ике ут арасында иде. Әлеге утның бер ягында Заһидә, икенче ягында—Дәрига. Икесе дә аның өчен якын, икесе дә аның сөекләләре. Кайсына өстенлек бирергә дә белми. Ихтимал, ул моны беркайчан да булдыра алмас. Бармагыңның кайсысын киссәң дә авырта, шуның кебек инде бу.

Дәрига белән аңлаштылар, шөкер. Дөресрәге, хатыны аны гафу итте. Гафу итсә дә ирен бик нык кисәтте: "Алдымда ашымны ашап, артымда башымны ашый торган булсаң, юлларыбыз аерылыр,—диде.—Мин барысына да түзә алам, әмма ләкин кат-кат хыянәтне кичермәячәкмен".

Дәригага бу һич тә җиңел бирелмәде. Уйлана-уйлана эченнән сөреме чыкты, күзләрен бәйләп качар хәлгә җитте. Тик шулай да дуамал хисләренә

тузынырга ирек бирмәде. Ирен тартып алганнар икән дисәләр, гарьлеге ни тора? Дәриганың горур жаны бу кимсетелүгә юл куя аламы соң? Нинди дер гадәттән тыш хәл килеп чыккан нәүбәттә дә, соңгы сүзне ул әйтергә тиеш. Шулай булмаганда, үзен-үзе ихтирам итүдән туктар иде.

Кәшшаф, чыннан да үзгәрде, берара хатыны алдында песи булып кына йөрде.

Беркөнне сөйләштеләр-киңәштеләр дә әнисе янына авылга кайтып киттеләр.

Басу-кырлар инде бушап калган. Быелгы көз коры булды. Шуңа күрә эшне тиз тоттылар. Рәт-рәт тезелешеп киткән салам эскертләре бу бушлыкка ниндидер моңсулык өсти. Игенченең елы тәмам. Ул, гадәти еллардан аермалы буларак, көздән көзгә кадәр дәвам итә. Ә һәр тәмамланган нәрсә үзе белән күңел тотрыклыгын, күңел тулылыгын да алып килә.

Кыр эшләренең хәвеф-хәтәрсез төгәлләнүе, ашлыкның вакытында келәтләргә кертелүе, көзнең менә шулай якты, матур килүе авыл халкы өчен зур шатлык иде. Бәхет өстенә бәхет, менә Кәшшафлар кайтып төште. Әнисе куанычыннан кая басарга белми. Өч бала үстереп ялгызы яшәп ята мескенем. "Кышны гына булса да бездә үткәр",—диләр үзенә. Юк, ризалашмый. Кунакка килгәндә дә атнадан артык тормый. Жә, казының утырыр вакыты житә, жә тавыкларының чаты ачылыр чак. Сәбәбен таба инде. Ә жәен балаларын, оныкларын көтеп үткәрә. Чисталык мәсьәләсендә ифрат та талымлы инде мәгәр. Бу хакта авылда мәзәк сүзләр дә йөри. Кәшшафның сеңлесен сорарга килгәч, әнисе булачак кодагыеның артыннан калмый сулы савыт тотып йөри, имеш. Кодагый исә, бу бер-бер йола ахры, дип суны авыз итмәкче, ди. "Кодагый, мин касәсез эчә алмыйм, касә бир",—ди икән.

—Эржинкәләрең бик пычырак, кодагый, касә суы белән генә чистарырлык түгел, әйдә, ишек алдына чыгыйк, шунда юарсың,—дип әйткән ди әнисе.

Булса да булгандыр, коры көннәрдә дә капка төбендә сулы ләгәне торыр. Теләсән-теләмәсән дә, ул суга кул тыкмый булмый. Хәер, авылнылар инде күнгән, капка төбендә аяк киемнәрен салып кына калдыралар. Чөнки ишек алды ямь-яшел, инглиз чирәменнән һич тә ким түгел.

Әнисенең тагын бер өстен ягы бар: аш-суга бик оста. Төплекәй дигән бик матур исемле таба ашын аның әнисе кебек авылда берәү дә пешерә белми. Иң дөресе, аны бары ул гына пешерә. Тирә-якта инде күптәннән бу милли ризыкның хәтта исемен дә хәтерләмиләр. Өчпочмак, гөбәдия, төш, бавырсак, бәлеш, чәкчәк, коймак, тәбикмәк—боларга һәр өйдә тап буласың. Төплекәй белән менә бары Мәмдүдә әбидә генә сыйланырга була. Югыйсә, катлаулы да түгел. Эремчеккә күкәй туглап, боламык ясыйсың да, күзикмәккә сылап, йөзе килгәнче кайнар мичкә тыгып аласың. Канат белән майлаганнан соң, әнисе аларны өстен каплап, мендәр астында да тота. Шуңа күрә авызда эреп китәрлек булып йомшаралар.

Юл тузаннарын кагып, машинадан күчтәнәчләрне алып кергәндә әнисенең табыны әзер иде инде. Кәшшаф коймакларны кулына тотып, майларын тамыза-тамыза ашый башлады.

—Кыланып утырма инде, зинһар,—дип Дәрига йөзен чытты.

—Тимә, килен, балачактан шулай иде ул,—дип әнисе Кәшшафны якларга ашыкты.

—Шәһәр кешесе ризыкның тәмен белми ул, әни, ашарга тотынуга ук пычак белән кискәләп котын очыра,—дип көлде Кәшшаф.

Ишекне киереп ачып, күршеләре Хәмит килеп керде. Һәм: "Миннән каз, синнән шурпа",—дип, өстәлгә какланган каз китереп куйды. Хәмит ел саен Кәшшафка шушы затлы ризыкны әзерләп куя. Кышка күркә жибәрә. Иң зурысын, иң симезен. Кәшшафлар әмерикәннәр шикелле Яңа елны күркәле табын белән каршы алалар. Хәмит ялгызы яши, буйдак. Хатынын өченче баласын күтәргәндә машина таптады. Башка өйләнмәде. Эчүгә сабышыр дигәннәр иде—эчүгә дә сабышмады.

Алар үскәндә бер мәлне кар базы басу гадәткә кереп киткән иде.

Яшьләр кичке уеннан соң бөтен авылга сибеләләр. Суыткычлар юк иде ул вакытта. Кеше сөтен-каймагын кар базында саклый. Яшь чак—дуамал чак. Дингез тубыктан. Сөт өстен чүлмәгеннән генә күтәреп эчәләр иде.

Берсендә шулай, Морзакай исемле картнын кар базына төшәргә сүз куештылар. Үч алырга иде исәпләре. Ник дисән, Морзакай карт басу каравылчысы булып эшли. Авылда сыртына анын камчысы төшмәгән малай-шалай юктыр, мөгаен. Усаллыгы өчен Урыс Морзакае дип йөртәләр үзен. Басуга кергән бозауларны куып алып кайта да колхоз абзарына яба. Авыл Советыннан штраф салдырмыйча берсен дә чыгармый. Нигә шунда ач килеш ике-өч көн кычкырышып ятмыйлар.

Шалкан басуыннан Кәшшаф белән Хәмитне дә ярып алып кайткан иде. Инде менә үсеп җиттеләр, үчне дә кайтарырга була. Морзакайдан өркә торган чаклары узды, янәсе.

Базны юри дөбер-шатыр китереп ачтылар, капкачын бәрәңге бакчасына тондырдылар. Хәмит базга төшеп китте. Дөм караңгыда әйбер табуы җиңел түгел. Анда сөт-катыктан башка да күп нәрсә саклана. Шактый капшанырга туры килде. Ниһаять, чүлмәкне өскә сузды.

—Мә, сосың Морзакай бабаңның каймагын.

Хәмитне кемдер каты куллары белән җилкәсеннән умырып алды.

—Состырырмын мин сиңа малай актыгы!

Бу Морзакай үзе иде. Саклап торган, күрәсең. Утлы табага бастырды мәгәр Хәмитне.

Хәтер янартырлык вакыйгалар күп анысы. Шуларны искә төшерә-төшерә шактый вакыт юанып утырдылар. Ә иртәгәсен Кәшшафның колакларына ниндидер сихри аваз иңде. Ул аны шундук таныды. Бу Заһидә иде. Ул хәзер радиода эшли. Тавышы матур. Микрофоннан бигрәк тә тылсымлы яңгырый. Аны әйбәт җыр тыңлагандай тыңлыйсың. Сүзләре күңелнең иң яшерен төпкелләренә кадәр барып җитә.

Заһидәнең тавышы бүген аеруча аһәнле, аеруча тәэсирле иде. Ирексездән, их, янымда булсаң иде, дип уйлап куйды Кәшшаф. Аннан соң үзен сүгеп ташлады. Чөнки ул Заһидәне онытырга йөри ләбаса. Авылга да шул максат белән кайтты ич.

Заһидә радиога эшкә күчкәч, сөенеп бетә алмады. Күрми торсам, тизрәк күңелдән китәр дип уйлады. Баштарак ул шулай булды да. Хатыны белән татулашу Заһидәне читкә этәрде.

Юк, этәрмәгән икән. Ярата ул Заһидәне, ярата!

Кәшшаф тиз-тиз генә киенеп ишек алдына чыкты. Әнисе, гадәттәгечә, чистарту-җыештыру эшләре белән мәшгуль иде.

—Тордыңмы, улым, хәзер самаурымны янартып җибәрәм,—диде мамыктай йомшак тавышы белән.

—Әни, без бүген төштән соң китәбез,—диде Кәшшаф.

Мәмдүдәнең йөзенә шәүлә ятты.

—Берәр атна торабыз дигән идең ич әле,—диде ана үпкәсен яшермичә.—Хәмиткә балык тотарга барабыз дип ышандырдың. Ул инде кереп чыкты, синең өчен бригадирдан сорап эштән калган. Кичтән бер сүз, иртән икенче сүз. Килен белән үпкәләшмәгәнсездер бит? Кәримемне дә алып кайтмагансыз.

Әнисе ана күзләрен тутырып карап торды. Кәшшаф бу карашны күтәрә алмады, башын читкә борды. Оят иде аңа.

—Эш күп бит, әни, конференциягә хәзерләнәбез,—дип ялганлады.

—Ярар, ярар, үзең беләсеңдер инде, бер кичкә расхутланып кайтып йөрмәсәгез дә була иде, дип әйтүем генә.

Мәмдүдәнең кулыннан эш төште. Ул чын-чынлап үпкәләгән иде. Аннан соң, авыл хәмер базына әверелде, калса эчеп китәр җә, дип үзен-үзе юатып алды.

Дәвамы киләсе санда

Şiğriət
Шигърият

Айдар Хәлим

КИЧКЕ ҖАЙДАК

Ат чаба. Дүрт тоягыннан
Дүрт давыл күтәрелә.
Давылларда йолдызланып
Яна күзләре генә.

Аргамакның колаклары
Тырпаешкан чук сыман.
Ялына сыланган җайдак
Җәядән чыгар ук сыман.

Дүрт давылдан дүрт арканга
Уралып алып җайдак,
Камчылый атын һәм үзен—
Һич кенә тормый сайлап.

Ат керфегеннән тәгәри
Ямь-яшел күз яшьләре.
Тояктан оча очкынның
Тәлгәшле миләшләре...

Төнгә каршы кем ашыга?
Нигә ашыга икән?
Дуслары каршылар микән?
Дошман камчылар микән?

Шундый мизгел, йөрәк сизгер!
Көндез, йә төнлә түгел,
Кичке шәфәкътә шартларга
Җилкенә гашыйк күңел.

Гөлемгә—үргә чаба ул,
Түбәннән—Кәркәледән.
Йөрәге тарихка керә—
Чак-чак түзә әлегә.

Аргамак канатларында
Хөрмәтле вә гыйззәтле
Йөк бар—ул йөк гыйшык хаты,
Өзә торган үзәкне.

Хатта шул: «Мин хисләремне
Тел белән әйтә алмыйм.
Мин синсез ятим, Хәмдиям,
Мин синсез яши алмыйм.
Бүген миңа йөрәк әйтте:
Барып кил аңа, диде.

Аның да һушы сәламәт,
Йөрәге яна, диде.
Өйләнә калсаң, аңардан
Башканы алма, диде.
Эшкә—калсаң кал, сөюдә
Син соңга калма, диде...»

... Дүрт давылдан дүрт арканга
Уралып алып җайдак,
Камчылап чаба...
Таулардан
Ай чыгып килә җайлап...

Айдар ХӘЛИМ (1942) — шагыйрь, прозаик, публицист; күпсанлы китаплар («Милли шигырьләр», «Татар вакыты», «Яңа Сагыш китабы» һ. б.) авторы. Чаллыда яши.

Васыять

Илсөяр, Зөлфия, Кадрия кызларыма

Минем язмыш гаҗәп булып чыкты:
Өчегез өч анадан тудыгыз.
Өч сеңлекәш!—
Гүя бер анадан
Туган кебек туган булдыгыз.

Әнә,
Әниләрнең ак яулыгы—
Ак болытлар күкне биләгән.
Ходай бирәү. Әмма Бер Ходай да
Газизә бер була димәгән.

Сөю бирәү—
Ул тормышны сөю!—
Газизәләр унау булса да.
Балаларга
Ата
Йолдызлыкта
Тез очларын ертып юл саба...

Мин рәхмәтле
Сезгә биргән өчен
Бертуганлык дигән сәнгатьне,—
Аналарыгызга—
Кан ертылган
Тезем чәнчеп әйтәм рәхмәтне...
Хатын-кыз ул—Бөек мәшәкатьче,
Кырмыскадай йөксез йөреми.
Мин аңарга һәйкәл куяр идем,
Һәйкәл
Аннан матур күренми...

Аның хәтта Айга менәр өчен,
Сез беләсез, җиткән баскычы.
Бавында нотадай эленеп тора
Кер каптыра торган кыскычы...

Мин сезләрне сөйдем, шундый сөйдем!
Бәби дип юрганга көч төрдем.
Күкрәгемне чана итеп, сезне
Аркамда өстерәп үстердем.

Мин байлыкны башыма җыйдым.
Сезгә
Калдырмадым лимузин, дачалар.
Җырда сак юк—
Җырлар алар сиңа
Үзләре ишек ачалар...

Васыятым шул:
Яшәсәгез иде,
Бер булып ялкында вә туңда.
Бердәмнәргә җылынырга җитә
Кышкы карурманда бер тун да.

Бер-берегезне сагынып яшәгез,
Булыгыз башкага үрнәкле.

Баш очымда һава тетрәтмәгез,
Берүк шау-шу,
низаг
Кирәкми!

Күктән аерылмагыз. Җирдән өч тиен
Күтәргәндә күккә карагыз.
Мөслимә булыгыз.
Тигез калсын
Җир белән Күктәге арагыз.

Мин ни әйтсәм, шулай кала күрсен.
Ата сүзе—гомер нәзере.
Мин сезләргә Җиһан бүләк итәм,
Белеп тотсагызчы кадерен.

Мәхәббәтне сезгә тигез бүлдем,
Шигырем дә тигез бүленә.
Сезнең хакка шигъри сука тартып,
Җырлап керен киләм үлемгә.

... Мин киткәндә Ай сөрмәле иде.
Җирдә иде сөрмә рәшәсе.
Бер-берегезне ташламагыз, диеп,
Гүремнән дә килә дәшәсем...

Әнкәм каберендә

И, газиз әнкәм, ул синең гәлсәрдәй күз яшьләрең
Нур чәчә күкләрдән гүя ак йолдыз тәлгәшләре.

Хәтта фаҗигаи яшең нур сипкәч төнгә карап,
Биргәнсең мине дөньяга энә күзендә сайлап.

Кайчак бу моңсыз тормышта мин өшим, бозга калам;
Ятсам кабреңә, и, анам, кузыңда кайныйм, янам!

Тыңлыйм кабреңне... Ишетәм: бүген һәм киләчәктә
Җир йөрәге синдә тибә һәм мәңге тибәчәк тә.

Кистем дә тырнакларымны, җылы тынымны өрдем.
Соңгы тапкыр хушлаштым да, кәфен—кәгазьгә төрдем.

Укып дога, тоттым амин, чөеп кул-беләкләрем.
Аерылыр әгъзаларыма теләдем теләкләрем:

Читләрдә дә бер-берегездән аерылмасагыз иде!
Ия—хуҗасыз каралып, каерылмасагыз иде!

Мин сездән риза, сез миннән риза булсагыз иде!
Гәлсәр савытка әйләнеп, гөлгә тулсагыз иде!

Мөнкир-Нәнкир әхирәттә алганда сездән сорау,
Тотыгыз сүзне бик кыска, йөртмәгез артык урау.

—Әһлебез Айдар бин Хәлим бирергә кушты җавап:
«Җирдә залимнәрдән суглып, милләттән алдык савап»...

Оҗмахка, кирәк тәмугъка бергә керсәгез иде!
Чергәндә дә туган якка кайтып черсәгез иде!—

Дип мин хак өлешләремне агыздым агымсуга,
Аннан шул суларга карап, еладым ямансуга.

Тамак ялгый кызлар

«Уңлап кына ла суллап кашым тарта,
Ниләр булыр икән иртәгә?»

«Биеш». Башкорт халык җыры

Кызсыз йортта үсеп, мин кызларның
Ашаганын күргән булмагач,
Күзәтмәкче булдым, печән чабып,
Төшке ашка—ялга туктагач.

Күренделәр, әнә...
Чырык-чырык
Кояшлы табырга[1] керделәр.
Җил уятып, әнә, тырмаларын
Элмә ботагына элделәр;
Аннан—йәнә чырык-чырык килеп,
Бер сәбәпсез йәнә көлешеп,
Чишмәгә төштеләр,
Чайкандылар...
Таңкә-таңкә сулар сибешеп;
Аннан—гөрләп торган акланнарга
Чәчкәләрдәй иple сипләнеп,
Читкә алан-ялан каранмыйча,
(Күрмиләр микән, дип, шикләнеп!),
Кашавар Сруттәй[2]дән, зур казаннан
Итле тукмач ашы бүлдереп,
Апкиттеләр калай тустагъларын
Алъяпкыч астына яшереп;
Аннан—элмәлектә чырык-чырык,
Җәмәгать күзеннән читтәрәк,
Утырыштылар кызлар, ир-егеткә
Арка белән юлны киртәләп...

Йә, илаһым, нәрсә күрдем шул чак!
Алар ашап... ашамый иде!
Без, егетләр сыман, гаптыр-гоптыр,
Ашны ашый башламый иде!..

Алар, гүя чигү чиккән сыман,
Чемтеп кенә кабып, ашыкмый,
Тәмләп, илне ямьләп, ирен бөреп,
Йөрткәлиләр иде кашыкны!..

---

[1]Төшке ашка туктый торган урын табыр дип атала. Аның өчен гадәттә урман эчләрендәге чишмәле яр буйлары, аланнар сайлана.

[2]Пешекче Сорур түти.

Ашамыйлар—тамак ялгыйлар!
Чемтеп капкан саен балкыйлар!

Ашамыйлар—туклык итәләр!
Матур булсын кичләр-иртәләр!

Ашамыйлар—азык ейәләр[1],
Гүя яңа көлмәк кияләр!

Ашамыйлар—сөю көтәләр!
Сөю берлә туклык итәләр!..

Ышаныгыз, кичә генә сугыш
Үткән илнең кыз балаларын
Яшьләренә төелеп күзәтә иде
Акланның бар кузгалаклары...

Ышаныгыз, абага, сарутлар,
Кызгылт-зәңгәр мәтрүшкәләрдән
Зәңгәр күзле бәби карый иде—
Хәтта көрән мәтрүшкәләрдән...

Сорасалар бүген, бу хәлләргә
Ярты гасыр (!!!) тулган көннәрдә:
—Шушы чорда иң изге ни нәрсә
Югалттың?—дип,—туган илләрдә,—
Ике дә уйламый әйтер идем:
—Әлмәлеккә тырмаларын әлгән,
Шатлыгында чырык-чырык көлгән,
Кайгысында тынсыз кала белгән,
Печән өсләрендә кибән койган,
Ир-егеттән читтә табын корган,
Иренен бөреп кенә аш тәмләгән,
Чемтеп кенә кабып, ил ямьләгән,
Ашамаган—тик тамак ялгаган,
Милләтне һич ялгамый калмаган,
Ашамаган—сөю генә көткән,
Сөю белән генә гомер иткән,
Керфек очларыннан нур тараткан,
Тыйнаклыгы дөньяны караткан
Татар кызын, дуслар, югалттым!..
Милләт катламнарын тарайттым!..
Минем шушы Бөек Сырхавымны
XXI гасыр өшкертсен:
Хатын-кызны ир-ат харап иткәч,
Ир-егетне кем соң үстерсен?!

2001

[1]Ейү *(борынгы төрки)*—тамак ялгау, ризыклану.

Çəçmə əsərlər
Чәчмә әсәрләр

Мансур Вәли-Барҗылы

ИДЕЛ ЯРЫ

ЯШЬЛЕККӘ СӘЯХӘТ

Түбән Кама ГЭСын төзү аркасында юкка чыккан туган авылым Барҗыга багышлана.

* * *

–Юк икән, балалар!—диде әти шул чагында ниндидер бер әчке ярсу белән һәм безгә күтәрелеп карамаска тырышыбрак кына.—Үз кулларым белән сүтә алмыйм мин моны!

Бу сүзләрне әйткәндә аның тавышында моңа кадәр ишетеп күнегелмәгән кырыслыкмы, таныш түгел кискенлекме, әллә инде әлегә без аңлап-төшенеп җитмәгән үзгә бер дулкынлануның өзек-өзек авазларымы чагылып үтте... Үзе исә бу минутта нинди хәлдә-халәттә икәнлеген безгә сиздерергә теләмәде, ахрысы, шуңа күрә сүзен әйтеп бетерер-бетермәс кызу гына атлап күрше ихатага таба китеп тә барды.

Ә без—үзебез утырып кайткан зур йөк машинасы янындагы өч ир-ат, әтинең өч малае—бу сүзләрдән соң бермәлгә тукталып, ни дияргә дә белмичә, тәмам аптырап калдык. Иртүк таң белән кузгалып, кайчандыр үзебез яшәгән менә шушы өйне сүтәргә, күчерергә дип кайткан идек ләбаса! Бу әтәйгә кисәк кенә ни булды соң әле?!! Үзе үк безне оештырып-туплап: «Шуның хәтле әйбер су астында калсынмыни инде?!»—дия-дия, айлар-атналар буена безне тәмам тинтерәтә-тинтерәтә, куалап диярлек алып кайтты да—хәзер үзе әнә нәрсә ди!

—Шулай шул... Бөтен җегәрен салып, көчәнә-көчәнә төзеде шул бу өйне әтәй!

Беркавем вакыт үткәч өлкән абыебыз иң башта телгә килә һәм тагын өстәп тә куя:

Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ *(1948)—тәнкыйтьче, прозаик; «Үзәгең өзелгәндә», «Мәхәббәт—мәңгелек», «Күңелнең көткәне», «Гасыр ахырында» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

—Төн йокыларын йокламыйча тырышты бит ул моны салырга! Эшли-эшли коры сөяккә калып бетте бит ул!.. Ә хәзер менә «күчәргә!» диләр...

Әтәйнең хәле, безнең башка сыя алмастай олы кайгысы шунда гына миңа барып җитте! Чыннан да, гомерлеккә диеп үзе төзегән, үзе салган өйне сүтәргә ничек кулы күтәрелсен соң аның?!

Шулай байтак кына вакыт тинтерәп, нишләргә дә белмичә басып торабыз... Ә әтәй үзе каядыр икенче урамга ук юнәлде, ахрысы—бөтенләй күздән дә югалды ул...

—Ярар, нишлисең инде! Бер без генә түгел бит, мир белән бит!—диде дә, абый машина әрҗәсенә менеп китте һәм шап та шоп итеп җиргә эш коралларын: балталарны, кадак суыргычларны, пычкыларны ата башлады... Әтәй кайчандыр зур өметләр баглап салган, без үзебез шушында егет булып өлгергән өйне әнә шулай итеп сүтәргә тотындык...

Кичкә таба өй тәмам туздырылып, аннары тау башындагы күрше авылга ташылып беткәч тә капка һәм койма баганалары белән байтак изаландык әле без! Ул имән баганаларны әтәй шундый да тирән итеп утырткан булып чыкты: ачуым да бер килмәгәе—һәркайсысы метр ярымышар тирәнлектә булыр! Аларны без җирдән көч-хәл белән суырып, тартып ала алдык! Көрәкләр, ломнар белән галәмәт озак газаплангач кына! Әтәй, чыннан да, мәңгелеккә диеп төзегән булган икән шул...

Менә инде кире Казанга да кайтып киләбез...

Ә минем юл биштәремдә бик кадерле ике әйбер. Өй сүткәндә килеп чыктылар алар... Торам-торам да, тагын бер мәртәбә кулга алып карыйм мин аларны... Берсе—саргаеп беткән карточкалардан торган гаилә альбомы ә икенчесе... ә икенчесе—үсмер чагында мин язып барган калын гына дәфтәр.

Өйгә кайтып керүгә юл тузаныннан арыну өчен тиз генә су коенып алам да, җәлт кенә үз бүлмәмә кереп бикләнәм.

Дәфтәремнең беренче битләре үк минем бөтен дөньямны онyттыра, яшьлеккә—үзебезнең гүзәл Кама буйларына—җәйләрен печән чабып, печән җыеп үткәрә торган ямьле Аръяк болыннарына алып китә. Ул көннәрдән бирле әйтерсең лә утыз елдан артык гомер узмаган, әйтерсең лә мин әнә шул вакыттагыча яшь-яшь егет!

* * *

—Илсу-у-ур!.. Нишләп мине монда алып чыгарга теләмәден си-и-ин?—диеп, үзенә бер төрле матур-ягымлы да һәм бераз гына иркәрәк тә тавыш белән, әз генә үпкәләгән дә кебек итеп эндәшә мина Ләйсирә.—Әллә инде шәһәрдән кайткан хан кызынын укасы коелыр диеп курыктыңмы?

Ә мин ап-ак саплы жинел тырманы бер көйгә әйләндерә-әйләндерә, эндәшмичәрәк торам. Һәм сүзсез генә еракта гы әрәмәне, анын янынннан гына чишмәгә таба сузылып киткән сукмакны күзәтәм. Дөресрәге, күзәткән булып кыланам.

Ләйсирә дөрес әйтә инде: чыннан да, ничек инде аны—Казан хәтле Казандагы институтта, әле анын да чит телләр факультетында укучы чибәр һәм затлы кызны—бирегә, Иделнең аргы ягындагы усал чебен-черки оясына, ай буена куна-төнә ятып печән чабучы колхозчылар янына алып чыгасың ди?!

Ләкин чибәр кызлар үз дигәннәрен эшләтмичә каламы сон инде алар! Ләйсирә дә тәмам авылча киенеп, жиләк жыю өчен кулына кызыл талдан бик матурлап үрелгән зур гына кәрзин тотып, тәки безнең белән Аръякка чыкты бит!.. Без абый-апалар белән көне буе болында кипкән печән жыябыз, ә ул иртән иртүк чыгып китә дә, кәрзинен көчкә күтәреп кичкырын гына кайтып керә.

Карангы төшкәч тә бүтәннәр куышлардан әллә ни ерак китмичә

генә, шул тирәдәрәк кенә кайнаша, ә Ләйсирә иплəп кенә минем янга килә дә:

—Илсу-ур! Идел буенда күнеллерәктер бит анда... Әйдә инде шунда барыйк...—ди үзенең җанны эретердәй ягымлы тавышы белән.

Юк, тавышы гына ягымлы түгел—үзе дә бик чибәр ул безнең Ләйсирә! Мин ана күп чагында тутырып карарга да оялламын, ә инде ниндидер бер эчке кыенсынуымны җиңеп аңа бер текәлеп карыйм икән—ул чагында озак, бик озак күземне ала алмый торам мин аннан. Һәрчак жылы нур сирпүче коңгырттрак күзләре, үзгә бер ягымлылык бөркүче ачык йөзе, артык калын булмаган нәфис иреннәре, йомшак бер юан толым итеп бер якка үреп салынган соргылт чәчләре—боларның барысы-барысы минем күзләрне, минем карашны ни өчендер озак, бик озак үзләренә бәйләп тота.

Буйга да уртача гына Ләйсирә, миннән бер чирек чамасы гына кечерәк кебек ул. Гәүдәсе дә, «иң чибәр кызлар алар менә шундыйрак була» дип бүтәннәргә үрнәк куйган кебек, нәкъ тиешле тулылыкта гына аның...

Әнә шундый бер гүзәл кыз җәйнең ямьле кичендә яныңа килеп басса—кем генә тыныч торып кала алыр икән соң?!

Һәм без аның белән иплəп кенә кузгалып китәбез...

Безнең болыннар Иделдән ике-өч чакрым чамасы эчтәрәк башлана. Ә куышларыбыз бер зур гына күл буйлатып, кечерәк кенә авыл сыман булып урнашкан. Монда хәтта урамнар да бар, аларга исемнәр дә кушылган! Берсе Күл буе урамы булса, икенчесе—Сырт урам... Ерак та түгел бик тәмле сулы чишмәбез дә бар.

Әйе, монда бик күңелле, бик ямьле. Ләкин менә Ләйсирәнең җаны ни өчендер гел дә Идел буена тартып тора... Бүген дә ул мине тәмам сихерләде. Аннары караңгыда кыз баланы ничек итеп үзен генә җибәрәсең инде?!

Инде чынлап та караңгы иңгән... Биек булып үскән үләнне икегә ярып баручы ат юлы аз гына шәйләнә. Без юлдагы вак түмгәкләргә абына-абына алга атлыйбыз... Юл читендә сирәк-мирәк тал куаклары очрый, биек булып үскән ат кузгалаклары кулга тиеп-тиеп кала, төнге ауга чыккан бакаларның безнең алдан гына сикереп үтүләре күзгә чалынып кала...

Ә ул сандугачның өздерүе! Гүяки ул берүзе менә шушы бөтен җиһанга баш булып калган да—гүяки ул менә хәзер берүзе бөтен дөнья өчен ялгызы гына искиткеч концерт бирә! Гүяки ул—дөньядагы бердәнбер һәм иң бөек солист!

Аның илаһи тавышын туктапып, онытылып, хисләнеп тыңлыйсы килә... Аның сихри моңында бөтен фани дөнья уйларын онытып ләззәтләнәсе, эреп бетәсе, күпмедер вакытка бөтенләй югалып ук торасы килә... Аның гүзәл музыкасында җирдәге һәммә затны бәхетле итәрдәй, ана аз гына вакытка булса да күнел тынычлыгы бирердәй көч, сәләт, илһамият барлыгына ышанасы килә... Һәм үзе күзгә күренмәгән әнә шул гүзәл Затка—иҗатчыларның иң зурысы, иң талантлысы, иң бөеге санап—кеше йөрәгендә була алган иң ихлас рәхмәт хисләрен җиткерәсе килә! Ана ирештерәсе килә!

—Илсур...

Сандугач тавышына комачауламаска тырышып кына Ләйсирә дәшә икән.

—Син дә укырга барган булсаң... мина да Казанда күңеллерәк булыр иде...

Әйе шул, бу хакта элегрәк тә сүз катканы булган иде инде аның. Ләкин укыйсы килмәгәч—нишлием соң инде?!

—Җжу-у-ук, малай...—дим мин аңа җавап итеп, үзебезнең яктагыча.—Болай да бик рәхәт бит әле! Мәктәптә ун ел буена хәреф ятлап тәмам туйдым бит инде мин!

Ә болай үзе бөтенләй үк укымаска түгел инде исәп. «Укырга кирәк

булыр» дигән уй бар инде анысы күнел түрендә... Тик бераз ял иткәч. Уку әзрәк сагындыра башлагач...

—Сезнен факультетта уку бик кыендыр инде ул, ә?

—Шулай шул... Авыл баласына бигрәк тә инде! Әле ярый безнең Мәһинур апа монда немец теленең нигезен бик яхшы салган! Гел шуна рәхмәт укыйм!

—Шәһәрнекеләрдән калышмыйсынмы...

—Кайсыберләрен узып та китәм әле! Вәт, беләсеңме апанны!

Ләйсирә рәхәтләнеп көлеп җибәрә һәм минем кулдан тота да:

—Әйдә кызурак!—ди.—Берәр пароход та күрмәбезме әле?!

Ә Идел буенда-а-а... Дөм карангы диярлек анда!

Кап-карангы, кара бушлык булып су җәелгән... Ә бер кырыйгарак озын алтын басма сыман ай шәүләсе төшкән... Әнә шул басма буйлап эчкәре кереп китәсе килә, гәүдәләрнең авырлыгын да тоймыйча вак дулкыннар өстеннән җинел-җинел адымнар белән атлап кына барасы килә... Һәм әнә шул алтын басма өстеннән атлаганда бер кул белән янәшәмнән Ләйсирәне дә җитәкләп барасы килә...

Килеп җиткәч шулай итеп сокланып озак торабыз... Янәшә баскан килеш... Әмма безнең ара бик үк якын түгел. Хәзер инде куллар да бербереннән ычкынган.

Аннары мин шул тирәдән генә коры утын җыя башлыйм. Аны карангыда абына-сөртенә җыям—ләкин үзем бик шат: сукрануише нәрсәнең әсәре дә юк! Әле хәтта авыз эчемнән нindидер бер дәртле көй дә көйлим шикелле...

Онтылмый беренче саф мәхәббәт,
Онтылмый ул Идел сылуы...—

диеп, үзебезнең яраткан җырыбызны әз генә үзгәртебрәк җырлыйм бугай.

Менә учак кабынып китә. Баштарак төтен генә бөркеп яткан учак әкренләп кыюлана, хәл җыя бара, аның ялкыннары да тора-тора зурая, озыная, биегәя төшә—алар инде өелгән утын астында һаман кызурак бии башлый, бераздан алар инде безне урыннан ук кузгатырдай эсселек, кызулык бәрә һәм Ләйсирә белән мина, чыннан да, утырган бүрәнәбезне арткарак күчерергә туры килә.

—Кышны үткәрүе кыен булмадымы соң?—дип, кыенсынган төсле генә сорый миннән Ләйсирә.—Иптәшләр, классташлар булмагач, күнелсез түгелме диюем инде...

Ә минем мона җавап әзер.

—Әй, малай! Мин бит монда кич буена җен кебек чабам!

Шулай диеп әйтеп бетерүем генә була, Ләйсирә тыела алмыйча көлә-көлә, минем кулга килеп ябыша.

—Ни булды?—дип сорыйм мин, бераз аптырый төшеп.—Нигә болай кисәк кенә көлә башладың әле син, кызый?

Ә ул нәрсә дип җавап бирә диген?!

—Соң, «җен кебек» дидең бит! Ә минем әле беркайчан да җенне күргәнем юк... Син әйткәч, уйлап куйдым: әллә мәйтәм, җен дигән нәрсә ул, чыннан да, синең кебек менә шулай: озын буйлы, озын чәчле, озын куллы була микән, дим...

Ләйсирә белән безнең арада үпкәләшү дигән нәрсәнең эзе дә була алмый инде ул—шуна күрә Ләйсирәнең бу бәләкәй шаяртуына «әйе, әйе», «шулайдыр, шулайдыр» дип тиз-тиз генә җавап бирәмен дә (ә чынлыкта ул минем портретымны төп-төгәл әйтеп бирде бит инде!) үзебезнең ниләр майтарганыбызны кызу-кызу сөйли башлыйм. Үткән кышта авылда нинди күнелле кичәләр уздырганбыз, аны оештырып йөргәндә кемнәр белән чәкәләшергә туры килгән, шәп идеяләрнең кайсысы чынга ашмыйча калган—менә хәзер минем күнелдән барысы да чишмә булып агыла, түгелә... Әле болар хакында шулай ихластан беркемгә дә сөйләгәнем юк иде бит!

—Ә быел кышын безнең авылда беләсеңме нинди вакыйга булды?

Мин шулай дип Ләйсирәдән сорагандай итәмен дә, үзем исә аның ни дип җавап биргәнен дә көтеп тормастан, дәртләнә-дәртләнә сөйләп китәм:

—Шагыйрьләр килде быел безнең авылга! Чып-чын шагыйрьләр! Клубта алар менә дигән кичә үткәрде! Ә менә шушы үзебезнең авылда, аның әле бик үк җылынып та җитмәгән клубында шигырьләрне шагыйрьләрнең үз авызыннан ишетү, аларны тыңлау бөтенләй икенче икән ул, малай! Бар дөньямны онытып утырдым мин анда.

Ул кичәдә шагыйрьләргә иң күп сорау бирүче дә мин булдым, ахрысы. Чөнки алар зур дөнья, олы әдәбият вәкилләре иде бит—олы калалардан ерактагы безнең авылга алар «әдәбият» дигән әнә шул көчле агым дулкыннарын алып килде бит!

Әле тагын иң кызыгы шунда: икенче көнне иртән ат җигеп, аларны күрше авылга илтеп кую бәхете дә миңа эләкте бит, малай!

Көне дә, махсус эшләгән шикелле, шундый матур иде аның... Акрын гына кар төшкәләп тора... Кышкы урман юлы биек-биек чыршылар, юан-юан наратлар арасыннан борыла-борыла бара... Атыбыз бер көйгә генә юырта, чанабызга күп итеп печән түшәлгән. Ә Казан шагыйрьләре иплəп кенә авыл тормышы, минем үземнең хәлләр белән кызыксына, үзләренең кала яңалыкларына да кереп-кереп алалар...

Унике чакрым ара сизелмичә дә калды—шагыйрь абыйлар китеп барды, ә минем күңелгә әнә шул чагында ниндидер бер талпыну, омтылу хисе кереп оялады. Зур дөньяга, калага таба тартылу тойгысы димме... Кичен клубта шагыйрьләрнең әсәрләрен авыз ачып тыңлау, икенче көнне атта алар белән аз гына аралашу—ничектер, миңа, бер көчле, зур дәрьяның дулкыннары сыман тәэсир итте... Тарта башлады.

—Ә миңа авылда икебез оештырган Чайковский кичәсе бик ошаган иде.—Ләйсирә шулай дип минем сүзне дәвам итеп китә кебек.—Казанда шуны күз алдына китерәм дә, бер үзем хисләнеп утырамын кайчак тулай торак бүлмәсендә... Кайчагында җылап та җибәрәм... Әй лә, бусын әйтмәм дигән идем бит инде!

Мин аның бу сүзләренә бик гаҗәпләнәм. Авылда чагында ул мондый түгел иде бит! Нәрсәдер булганмы соң әллә аңа?.. Ә менә «әй лә!» диеп куюы—бер мәзәк гадәте инде аның—шактый еш әйтә Ләйсирә бу сүзне. Мәктәптә чагында без аны шулай дип үрти дә идек әле—үзе үпкәләми иде тагын, елмая гына иде... Ә менә хәзер калада елап утыруы—гаҗәп! Ни булды икән соң?!

* * *

—Их син!—димен шунда мин үз-үземә, укып барган дәфтәремнән аерылып.—Ул чагында син шуны да сизмәгәнсең, тоймагансың икән бит! Туфрагыннан куптарылган гөлләр беренче мәлләрдә ничек саргайсалар, ни рәвешле авырсалар—адәм баласы да күченүне, бүтән җирдә, бүтән мохиттә яши башлауны әнә шулай авыр кичерә бит ул!

Әнә: үзебезнең туып-үскән авылны күчерер алдыннан да, күчерә башлагач та, авыл халкы шушы фаҗигане ң ачылыгыннан, йөрәкләрне тетрәндергеч катылыгыннан ни эшләргә дә белмәде ич!

Ә авыл зиратын күчерү фаҗигасе?!!

Ул көн гомергә онытылмаслык булып минем хәтергә сеңеп калды—иң зур, иң тетрәндергеч фаҗига булып!

Колакка бәреп кергән яман ачы авааздан башланды ул:

—Үтерәлә-ә-әр!

Иртәнге тын авыл урамын күтелмәгән шом һәм курку белән сискәндереп, әнә шундый ачы аваз яңгырады ул көнне. Бер-ике минут узып өлгердеме-юкмы, тагын да куәтлерәк булып һәм аз гына якындарак ишетелде әлеге тавыш:

—Үтерәләр!—дим бит! Нигә берәү дә юк—нигә ишетмисез?!

Алма бакчасында китап укып утыруымнан бүленгән идем инде, әлеге иләмсез тавыш икенче мәртәбә ишетелгәч, урексездән торып, урамга чыгарга мәҗбүр булдым. Ләкин безнең тирәдә беркем дә юк бит... Шулай булса да, хәзер күңелгә борчу керде, тынычлык качты—аптырап, шыкаеп, якындагы борылмага таба киттем. Бераздан адымнарымны кызулата да төшәм: «утерәләр!» дигән тавыш килә ич! Уен эшмени!

Ә борылмадан узар-узмас шушындый күренешкә тап булам—урамның теге очыннан кулларын кызу-кызу болгый-болгый, тоташ кара кием киенгән бер карчык килә, үзе барган көйгә ямьсез тавыш белән кычкыра... Капка төбенә чыгып баскан әби-апа барысы да аңа текәлгән...

Тукта! Бу бит, теге, зират очындагы Кара Әсма, өендә бер ялгызы гына яшәп ятучы, әзрәк «тегендәйрәк» дигән даны да чыккан әби түгелме соң?!

Әйе, әйе—шул карчык бит бу! Нәкъ үзе!

Нәрсә булды икән соң?! Нигә ул шуның кадәр борчылып кычкыра икән?! Кемнәрдер капка төбеннән кузгалып, Кара Әсманың каршысына китә... Мин дә түзеп тора алмыйм, аларга кушылам.

Ә Әсма әбинең чынлап та күзе-башы тонган, ул тәмам иләсләнгән, башындагы кара яулыгы чүт кенә эләгеп тора, ә үзе һаман әлеге иләмсез сүзне тәкрарлый:

—Үтерәләр дим бит! Нигә барып карамыйсыз? Нигә коткармыйсыз?!!

Апалар тәмам аптырап, Әсмадан сорашалар:

—Кая, нәрсә булды соң? Ник аңлатып әйтмисең, Әсма?!!

Моңа каршы Кара Әсма бер сүз дә әйтми—тегеләрне әйдәкли бирә:

—Әйдәгез, әйдә! Анда баргач күрерсез!

Без ни дияргә дә белмибез, әмма һәммәбез дә аның артыннан ияра. Ул, килгәндәгедәй кызу-кызу атлап, безне зират очына таба алып китә.

Ә анда барып җитсәк! Анда... Анда иң яман, иң куркыныч төшеңдә дә күрмәстәй бер хәл! Зур-зур тракторлар иләмсез дию пәриләренә охшап, ахырзаман галәмәте ясап—безнең зиратны актара! Авылның иң изге, иң кадерле саналган урынын туздыра! Ара-тирә ят телдә сөйләшкән авазлар да шәйләнеп ала...Әллә урысча инде?

Йа Хода, ни соң бу?!! Нинди яман төш бу?!!

Бераздан минем исемә төшкәндәй була—«зиратны күчерәчәкләр икән...» дигән шомлы хәбәр ишетелгән иде шул элегрәк... Ләкин ул хәл булса да әле тиз генә эшләнмәс кебек иде бит—авыл кешеләренең күз алдында кылынмаска тиеш иде бит инде мондый вәхшилек!

Шул чагында телгә иң усал, тегеләргә иң зур каргыш булырдай сүзләр килә. Ул сүзләрне безнең зират эчендә йөрүче ят ир-атларның йөзләренә бәреп әйтәсе, бөтен тимер аждаһалары-ниләре белән куып чыгарып, аларны иң әшәке сүзләр белән сүгәсе килә... Әнә шундый газаплы, әрнеткеч уйларга чыдый алмыйча тешләр шыгырдый, иреннәр кысыла, йодрыклар нык итеп йомарлана!

Ә авылдашларым... алар зиратның әлегә исән калган бер як коймасы янына тезелешеп басканнар... Алар да минем хәлдә, минем халәттәдер инде...

Мин аларны әнә шул чагында фашист концлагерында тилмерүче әсирләргә, тоткыннарга охшатып куям. Шуларга бик тә ошаш ич безнең хәлебез, боларның хәле: эчтә ачу кайный, тешләр кысыла—әмма үзебез менә берни дә эшли алмыйча, гаҗиз булып басып торабыз! Шушы фаҗигагә каршы берни кыла, бернинди киртә куя алмыйча! Әсирләр димичә, ни дисең инде безне...

Бары тик Әсма әби генә тракторлар үкерүен җиңәргә тырыша-тырыша, бүтән урам кешеләрен тупларга дип, ахрысы, ары таба китеп бара:

—Үтерәлә-ә-әр!—дип кычкыра ул.—Үтерәләр!

...Авылда бераз гына «тегеләй»рәк дип йөртелгән Әсма әбинең узып киткән җәйдә инәлеп кычкырган бу сүзе гүяки менә хәзер генә чынлап торып минем зиһенемә барып җитә! Дөрестән дә, безнең җирләрне су астында калдырып—безне бетерергә, юкка чыгарырга теләү бит бу! Безнең яшәү җирлегебезне тартып алу, тамырыбызны кису ич бу! Халык өчен, милләт өчен иң зур фаҗига лабаса бу хәл!

Безгә карата эшләнгән әнә шул иң зур кабахәтлекнең, иң олы

дошманлыкның-золымның бөтен мәгънәсе, асылы Әсма әбинең бер сүзенә—«утерәләр» дигән инәлү авазына сыеп беткән түгелме соң?!!

...Ә Ләйсирә белән Идел буенда йөргәндә без әле алда торган мондый кара көннәрне белмәгәнбез дә, сизмәгәнбез дә икән... Әнә ич—Ләйсирәне ничек җиңел генә тынычландырырга теләгәнмен мин ул вакытта!

* * *

—Менә хәзер, авылда ял итеп киткәч, сагынуың бетәр инде...—дим мин Ләйсирәне тынычландырырга теләп. Аннары, аз гына туктап, уйланып торгандай итәм дә, тагын болай диеп тә өстәүне кирәк табам:

—Тора-бара кала тормышына да ияләнерсең әле...

Ләкин телем белән әнә шул сүзләрне әйткәч үземә ни өчендер күңелсез дә булып китә. Күңел түрендә, йөрәкнең бик эчкәреге бер ноктасында нииндидер бер ризасызлык, нәрсә беләндер канәгать булмау, килешергә теләмәү хисе туа. Хәтта аны, ул йомшак, исемсез тойгыны үпкә диеп тә әйтергә мөмкиндер сыман... Тик кемгә, нәрсә өчен ул үпкә? Үз-үземә ачу тотып утырам дисән—мин авылда чыннан да үз теләгем белән калдым ич! Бары тик бүтән укыйсы килмәгәнгә күрә калдым! Шуңа күрә беркая да барып, укырга керергә омтылып та карамадым! Шулай булгачтын монда нинди үпкә турында әйтергә мөмкин ди инде...

Анысы шулай шулайлыкка...

—Институтның комсомол комитетына да сайламакчылар иде дә... «Әле миңа бик күп укырга кирәк—авылдан килгән кыз ич мин!»—диеп аңлаткач кына тындылар бераз... Әй лә, сиңа мактаныйм әле, әйеме, Илсур!

—Каян белгәннәр диген...—Шулай дип мин үзебезнең авылда, мәктәптә бергә йөрүләрне искә төшермәкче булам. Миңа хәзер әнә шул хакта сөйләшү, үзебезнең үткән көннәребезне озайту, аларга яңа гомер, яшәү бирү күңеллерәк тоела. Җай чыккан саен, әңгәмәбез арасында мөмкинлек туган саен мин шулай итәргә тырышам.

—Мәктәптән бирелгән характеристикага язганнар иде бит!

Ләйсирә моның серен миңа шулай дип аңлата.

Аннары тагын тын калабыз... Ә учагыбыз инде хәзер тәмам көчәйде. Ул хәзер әллә кая, күккә ашам дигән сыман ук яна башлады. Яз көне әле генә араннан чыккан яхшы айгыр менә шулай кылана бит: ул сикерә, ярсый, авызлыгын чәйни, йөгәнен өзмәкче була; әле бу якка, әле теге тарафка тартыла! Безнең менә бу учак та нәкъ әнә шул язгы айгыр инде! Аңа карап торуы күңелле дә һәм куркыныч та, рәхәт тә һәм бераз гына ямансу да...

—Ә син хәтерлисеңме: без үзебезнең Текә ярда, язларын менә шулай учак ягып утыра идек... Бозлар акканын карый-карый...

Бу сүзләр белән мин Ләйсирәне тагын үз авылыбызга, аңа терәлеп кенә аккан Зур Су буена алып кайтмакчы булам... Аның язгы дымлы дәртле кичләренә... Сер, тылсым тулы кичләренә!

Ә ул кинәт бөтенләй икенче нәрсәне искә төшерде.

—Унынчыда чагында мине якларга теләвең кызык кебек...

Аның бу сүзе мине кызарта... Үземнең яшүсмер чакның бер дуамаллыгы белән очраштыра...

Әйе, авылга кала артистлары килгәч булды бит әле ул хәл...

Башка кызлар белән бергә Ләйсирә дә билет алган алуын (ә бәлки аңа әнисенең билеты гына эләккән булгандыр әле!), ләкин моның урыны алгы рәткәрәк туры килгән. Һәм, гөнаһ шомлыгы диген: бер укытучыбызның клубка спектакльгә килгән ире үзенә урын таба алмыйча арткы рәтләргә китәргә мәҗбүр булган ул кичне. Ләйсирә исә үз урынында утырып театр караган...

Икенче көнне менә шушы хәл мәктәптә зур гына гауга чыгарды.

Безнең сыйныф Ләйсирәне яклап бара, «ул хәзер уналты яшьлек кыз бала, аның үз билеты белән спектакль карарга хакы бар бит»—дибез. Ә укытучылар исә безгә: «олы кешегә урын бирергә кирәк иде!»—диләр. Шуның өчен битәрлиләр!

Ул көнне мин үз сыйныфыбыздагы һәркемнән кул куйдырып укытучыларга бер кискен хат кертеп бирдем... Җүләрлек инде, билгеле! Ләйсирәнең менә хәзер учак янында утырганда шуны искә төшерүе ничектер мине оялтып җибәрде, сүзсез дә калдырды.

—Илсур... Син менә хәзер ул көн өчен үкенәсеңме?

Аның бу соравыннан башта рәхәтләнеп көлдем әле. Чөнки бу эшнең дулкыннары басылган бит инде. Сүрелгән бугай бит инде алар.

—Ихластан булган инде ул... Беркемгә дә начарлык, явызлык теләп түгел!

—Ә шулай да үкенәсеңме соң?

—Юк! Үкенмим мин аңа!

—Нишләп?

—Чөнки ул чагында «мин» бүтәнчә эшли алмады!

—Шулай дисеңме?

—Әйе, шулай дим шул! Чөнки... Чөнки—зур калалардан ерактагы бер караңгы авылда синең белән Чайковский кичәләре оештырып йөргән; тәнәфес вакытларында патефонга тәлинкә куеп классик опералардан өзекләр тыңлаган; авыл егет-кызларына урысның бөек шагыйре Сергей Есенин, эмиграциягә киткән намуслы әдип Иван Бунин турында мавыга-мавыга сөйләгән адәм (ягъни мин) ул чагында да үзе эчендәге әлеге «җен»гә каршы тора алмый иде! Ул чагындагы яшүсмер егетне әйбәт эшләргә рухландырып йөрткән «җен» синең белән булган очракка да тыныч кына кала алмады шул! Бәлки бик үк дөрес тә эшләмәгәндер—ләкин ул үзенчә, ихлас күңеле кушканча эшләде! Теге кышкы кичне, укытучылар рөхсәт итмәсә дә, без сыйныфыбыз белән күрше авылга мәхәббәт турындагы киноны карарга бардык бит әле—менә шуның кебек биредә дә йөрәк үзенең ихлас сүзен әйткәндер инде диеп уйлыйм мин!

—Рәхмәт шуның өчен!

Ләйсирә тиз генә миңа таба борылды да, уң як битемнән генә үбеп тә алды! Ә мин мавыгып сөйләгән җиремнән аңышмый да калдым. «Бу нәрсә булды соң әле?..»—диеп тып-тын тордым хәттә!

* * *

Дәфтәремдәге әнә шул бәхетле елларны укыйм да, күз алдымда шундый да тере булып җанланган ул гүзәл хатирәләр тәэсиренә түзә алмыйча, утырган урынымнан ук торып китәм һәм бүлмә буйлап арлы-бирле йөри башлыйм. Нинди бәхетле чаклар булган бит, ә?! Ләйсирә белән без бергә булганбыз, янәшәбездә генә алкын Идел тирбәлеп яткан, ә Иделнең икенче ярында исә безнең туган авылыбыз ул чагында әле бернинди хәвеф-хәтәр белмичә матур гына, тыныч кына яшәп яткан...

Ә аннары...

Ә аннан соң инде безнең якларда адәми затның башына да сыя алмастай галәмәт куркыныч хәлләр башланды. «Иделне буачаклар икән дә, шунда җыелган су якын-тирәдәге бик күп авылларны басачак икән!» Иң беренче килеп ирешкән шомлы хәбәр әнә шундый иде... Халык моңа ышаныргамы-ышанмаскамы белми торды баштарак. Чөнки, чыннан да, акылга сыймастай хәбәр иде шул ул! Ләкин, ни кызганыч, ул хәбәр дөрес булып чыкты—озакламый безнең авылда яңа йортлар салдырмый башладылар. Күченәсе булачак!

Таралу шуннан башланды—йортлары тузган кешеләр бүтән авылларга, яисә инде ерактагы шәһәр җиренә үк китеп, яңа нигездә дөнья корырга кереште...

Менә инде без дә үзебезнең иң кадерле нигезебезне, оябызны—туып-үскән газиз өебезне үз кулларыбыз белән сүтеп, туздырып атарга мәҗбүр булдык...

Ләкин күңелнең бу якта озакка тукталасы килми—ул артта калган якты көннәргә таба тарта.

* * *

—Әйдә, бераз йөреп килик...—дим мин тагын күпмедер вакыт узганнан соң, кыюсыз гына.—Су кырыена төшеп менәргә була...

Иделнең бу турыннан теге якка көймә белән, паром белән чыгып йөриләр, шуңа күрә аның яры шактый ук текә булса да, менеп-төшеп йөри торган сукмаклар салынган. Кайсыбер җирендә баскычлар да ясалган. Ләкин хәзер дөм караңгы булгач, аларны ничек итеп тиз генә шәйләп аласың ди инде?!

Яр өстеннән дә әллә ни ерак китү юк—ун-унбиш адымлап атладыкмы-юкмы, яшь тирәклеккә килеп терәлдек. Эченә керерлек түгел, әмма, аның каравы төнлә нинди хуш ис бөркеп утыра бу яшь тирәкләр! Бары тик үзләренә генә хас әчкелтем тәмле ис!

Әкрен генә Ләйсирәнең кулыннан җитәкләп алдым. Шундый да кайнар кул... Ә телгә ни өчендер һаман юк-бар сүз килә.

—Калада мондый кичләр була алмыйдыр инде ул...—дигән булам... Аннары ипләп кенә аны кочагыма да алам. Ул монда карышмый шикелле... Мин бу кыюлыгыма, тәвәккәллегемә ышанырга да, ышанмаска да белмим... Әнә шулай Иделгә таба карап торабыз... Хәзер инде күзгә Идел дә, бүтән нәрсә дә күренми. Әллә караңгы булганга, әллә эчтә хисләр дулаганга...

Байтак кына сүзсез тордык без. Ничектер, бу мизгелдә нинди генә сүз сөйләшсәң дә ул бәхетнең ямен, тәмен, ләззәтен киметер сыман иде. Монда инде бер генә сүз дә кирәкми—бүтән бер генә ым да, ишарә дә! Бары тик бу бәхет эчендә эреп кенә бетәргә кирәк шикелле иде. Иң дөрес, иң мәслихәт эш бары тик әнә шул гына була ала кебек иде ул чагында!

—Пароход түгелме...—Ләйсирәнең пышылдап диярлек кенә әйткән әнә шул сүзе безне дөньяга кайтарды. Мин дә Идел өстенә карадым, бөтен дикъкатемне җигеп пароход утларын эзләдем. Ләкин тиз генә шәйләп ала алмадым.

—Әнә, әнә! Өске яктан, югарыдан килә!

Чыннан да, пароход икән шул! Менә бәхет! Димәк, хәзер аның якынлашканын көтәбез дигән сүз. Шунсыз моннан китмибез инде!

Агым буйлап түбәнгә таба йөзгәч, пароход үзе бик тиз якынлаша тагын. Әнә инде аның аллы-гөлле утлары да аерымачык күренә башлады, өске кат бүлмәләрендәге бүлем-бүлем яктылык та кап-караңгы су кинлегенә үзгә бер ямь бирә. Ул тарафтан талгын гына музыка да ишетелә... Ә бүтән һичнинди аваз юк! Бары тик музыка һәм су өстендәге аллы-гөлле утлар гына! Һәм әнә шул могҗиза акрын гына безгә таба якыная, безнең якка таба килә...

Андый чагында түзеп торып, бер урында гына басып торып буламыни соң ул?! Без дә кузгалып ярга таба киттек, ярның ин-ин читенә, кырыена ук барып бастык. Пароходны мөмкин хәтле якыннанрак, ачыграк итеп күрергә исәп.

Менә ул тагын да якыная. Аның ян-ягындагы түгәрәк ишекләрнең шапы-шопы килеп суга бәрелүе дә ишетелә инде. Иң өске палубадан чыгып торган ап-ак нәзек колгалар да, алар арасына сузылган нечкә чыбыклар, баулар да күренә хәзер.

Ә шулай да иң мөһиме, иң кызыгы—менә шушы ап-ак аллы-гөлле тантана үзе! Төн караңгылыгын акрын гына ерып баручы менә шушы бәләкәй генә бер сарай!

Ә, юк! Нишләп соң әле мин аны бәләкәй диеп әйтәм?! Яннан, якыннан карагач әнә нинди озын, зур икән бит ул! Утлары белән балкып, ымсындырып торган ничәмә-ничә каюта, әллә ничә бүлмә бар бит анда!

Нинди бәхетле кешеләр бара икән бу пароходта?

Мөгаен... Мөгаен, алар барысы да парлыдыр... Һәм аларның, менә хәзер бу пароходта безнең яннан узып баручы кешеләрнең, бер генә кайгылары, исәпләре дә юктыр...

—Нинди ямьле... Мондыйны беренче күрүем әле минем!

Шулай ди дә Ләйсирә минем кулымнан кысыбрак куя ни өчендер...

Ә минем ана таба борылып шундук кочып аласы, аны менә шушы бәхетле мизгелебездә кысып-кысып кочаклыйсым, үбәсем килә... Ләкин кыенсынамын, тартындыра.

—Минем пароходны болай төнлә әле беренче мәртәбә күрүем бит!

Мин бу сүзләргә чып-чыннан гаҗәпкә калам. «Шулай микәнни соң?» диеп шактый ук аптырап торам... Ә бераздан инде үзем үк аның сүзен җөпләп тә куямын: «Булыр да... Минем кебек авыл баласы ич инде ул да... Ә калага китүен ул поезд белән китте бит... Шулай булгач, пароходны кайда күргән булырга тиеш иде соң инде ул?!»

Ләйсирә төнге Идел өстендәге әлеге аллы-гөлле могҗизадан аерыла алмый. Ул бөтен гәүдәсе, бөтен барлыгы белән әнә шул якты тантанага таба омтылган. Гүяки, канат кагып, менә-менә очып китәчәк бер кош баласы!

Минем монарчы да пароход күргәнем бар иде инде. Идел буенда шактый йөрелде ич инде... Ләкин менә шулай төнлә, бөтен дөнья карангылыгын ерып баручы якты пароходны әле очратканым юк иде кебек... Бу төндә аның утлары мина аеруча якты, аеруча тылсымлы булып күренде... Һәм яшерен-батырын түгел: әнә шул чагында күңел түрендә бер бик матур, бик садә хыял да борынлап маташа иде. Нинди хыял диген? «Их, Ләйсирә белән безгә дә менә шушындый яп-якты, ап-ак пароходта барырга иде бит! Кап-карангы ярларга карый-карый, астагы Идел дулкыннарының баш әйләндергеч тибрәнүләрен тоя-тоя... Һәм... Һәм менә шулай кулга-кулны тотышкан көе!»

Әмма... аллы-гөлле ул пароход яр буенда үзенә үтә дә сокланып басып торган безләргә исе дә китмәстән, түбәнге якка таба уза бирде... уза бирде... Бераздан инде ул бөтенләй дә күздән югалды, арттагы утлары гына безгә күз кыса-кыса үртәгән төсле күренә иде. Ул киткән яктан ишетелгән күңелле музыка тавышы да тынды, бары тик өзек-өзек аһәңнәр генә ара-тирә колакка килеп чалына.

* * *

Мин тагын дәфтәремнән аерыламын да:

—Их!—димен.—Шушындый якты, бәхетле минутларның нигә соң гомерен озайта алмый икән адәм баласы?! Нигә соң Ходай аңа мондый минутларны кызганып кына бирә икән?

Безнең туган авылыбызның да гомере ни өчен шулай кинәт кенә өзелде соң? Ничәмә йөз еллар буена сөенә-сөенә бергә яшәгән авылдашлар нишләп соң аерылып җиде ят җирләргә күченеп китәргә мәҗбүр ителде??

Узган елгы Сабан туе, авылыбызның соңгы Сабан туе искә төшә. Күченеп киткән барча авылдашлар бердәм булып кайткан иде бит аңа! Алар бик озак еллар буе очрашмаган, күрешмәгән кешеләр төсле рәхәтләнеп чүкердәштеләр, серләштеләр—йөзләреннән елмаю китмәде аларның! Сагынышып, җирсеп кайткан авылдашларымның чиксез бәхетле сәгатьләре иде бу! Сүзләре дә үз авылыбыз, аның һәммәбезгә гаять кадерле урман-сулары, болын-әрәмәләре турында иде аларның... Менә шул сәгатьләрдә алар гүя туган авылыбызның һавасын да күбрәк, тирәнрәк итеп сулап калырга телиләр сыман иде...

И газиз авыл, и туган авыл?!! Шулай итеп, истәлекләрдә генә калырсыңмыни соң инде син?!

Ә дәфтәр исә мине бәхетлерәк елларга алып китә.

* * *

Шулай итеп Идел өстен тагын караңгылык биләп алды...

Без дә үзебезнең учагыбыз янына кайттык... Ул бераз сүрелә төшкән иде, тиз генә тагын утын алып килдем дә, яңартып җибәрдем. Хәзер инде шундый теләк биләп алды: пароход алып киткән ямьне, яктылыкны, тантананы кайтарып алырга! Аны—әлеге яктылык, нур бәйрәмен—минә шушында ясарга! Үзебез өчен һәм... Һәм үз кулларыбыз белән!

Яр буенда яткан бөтен коры-сарыны җыеп алып килдем! Тагын-тагын чаптым утын эзләп! Һәммәсен дә учакка өсти барам, өя барам... Бертуктамыйча шулай ташый торгач әллә тагы үзем кадәрле биек итеп өйдем инде шунда!

Ә Ләйсирә гүзәл бер учак сакчысы булып шунда матур гына басып тора. Ул да мине дәртләндерә, аны да минеке сыманрак бер хис биләгән ахры... Яисә минем җен аны да кузгаттымы шунда!

Менә берзаман учагыбыз күтәрелеп китмәсенме, мин сиңа әйтим! Әйдә, әйдә!—дия-дия, аны кыстый-кыстый гына кузгаткан идек кузгатуын—бик тиз арада учагыбыз кибән хәтле утка әверелгәч, бер мәлгә куркыбрак та киттек, хәтта! Кырыена, янына барырлык түгел ич! Бөтен яр буен, су өсләрен яп-якты итте... Әнә шул яктылыкта бераз гына читкәрәк бәйләп куелган көймә дә күзгә чалынды... Аны күргәч «әллә бер әйләнеп килик микән соң?» дигән уй килгән иде дә башка, ләкин, ничектер—әлеге якты пароходтан соң, ул калдырган билгесез бәхет тойгысыннан соң—Ләйсирәне, кыз баланы, юеш һәм салкын көймәгә алып керергә, шунда дәшәргә кыймадым... Ләйсирә үзе дә аны-моны әйтмәде ул чагында.

Ә безнең ут котырыныпмы котырына! Югарыга омтылган биек-биек ялкын канатларын болгап-болгап ала... Гүяки бер гаять олы кош күктән җиргә ингән дә, хәзер ул үзе белән безне дә канатларына утыртып янадан өскә менеп китәргә җыена... Гүяки ул безне сүзсез генә үз канатлары өстенә утырырга чакыра...

Әнә шул төннең аллы-гөлле пароходы һәм безне күкләргә чакырып янган биек ялкынлы учагы минем хәтергә мәңгегә кереп калды... Инде үзебезнең куышлар янына кайтып җитәрәк Салихҗан белән Нурия очраган иде, аларга да күренгән икән без яккан учакның ул яктысы.

—Бөтен дөньяны яктырттыгыз, малай!—диде Салихҗан көлә-көлә.—Кая кереп качар урын тапмадык!

Ә минем телгә радиодан ишеткән җыр сүзләре килде:

Без кабызган утлар сүнмәс алар!
Сүнмәс алар хәтәр җилләрдә...

Ләйсирә куна торган куыш янына килеп баскач, пышылдашып кына сөйләшә-сөйләшә тагын шактый гомер торылды бугай әле.

—Барысы өчен дә рәхмәт сиңа, яме!—диде ул бу төнне соңгы сүзе итеп һәм матур гына иелеп куыш караңгылыгына чумды...

«Черкиләр кермәсен» дип, аның куышы ишегенә печән учмаларыннан үреп куелган капкачны да төзәтеп маташтым әле мин аннан соң. Бер әти кеше үз баласын йокларга сала диярсең, валлаһи!

Икенче, өченче кичне дә төштек без аның белән Идел буена. Пароходлар гел очрамады очравын, ләкин барыбер бик тә күңелле булды... Инде кайтып ятканда яктырып, таң беленә башлаган була иде инде...

Ә бер көнне куышта минем белән яши торган егетләр авылга кайтып китте. «Кайткач-кайткач мунча да кереп килербез инде... Кунмыйча булмас!»—диделәр. Тәлгат хәтта шаяртып та маташты әле:

—Кара, Илсур—без югында атны куышлар ашап бетерә күрмәсен, яме!

Әйе, әйе нәкъ әнә шулай диде ул—«куышны атлар ашамасын» түгел, ә «атны куышлар ашамасын».

Моның бер сере бар билгеле. Көлдерә торган сере бар!

Шулай төннәрнең берендә йоклап яткан чагында үзебезнең баш очында гына нәрсәдер кисәк-кисәк кыштырдаганга уянып киттем. Шактый ук каты кыштырдый бу, тычканга гына ошамаган! Әһә, дим, ерак та түгел атлар утлап йөри иде бит—димәк әнә шулар килеп ябышкан безнең куышка! Уйлап бетерүем булды, шул сүзләр авыздан чыгып та очты:

—Тәлгат! Тәлгат! Атны куышлар ашай бит!

Ул төнне егетләр йокыдан уянып житә алдымы, юкмы—анысы бик истә түгел, әмма «атны куышлар ашай» дигән сүз аларның теленә кереп калды. Көненә бер ун мәртәбә шул сүзне әйтеп, миннән көләләр иде егетләр! Сон, гаеп итеп, үпкәләшеп торыш юк инде анысы—кычкырышып, бергә-бергә көләбез! Рәхәтләнеп дигәндәй!

—Ярар, жегетләр! Сез югында атларны куыш ашамас!—дип көлә-көлә озаттым мин аларны авылга.

Көн эш белән үтә, билгеле. Син инде Аръякка чыккач тырай тибеп йөри алмыйсың! Бәләкәй малайлар кипкән печәнне күбә-күбә итеп ат белән тарттырып алып килә тора, без озын агач сәнәкләр белән аны кибән өстенә ыргыта барабыз. Кибән башында Сабир бабай тора, ул безнең эше яшь жилкенчәк оялырдай сүзләр әйтеп, көлдереп тә ала:

—Биткә ояты булса да, тәнгә сихәте бар аның, оланнар!

Ә бераз гына арырак кызлар печән жыя... Алар арасында мин танымаганнары да бар, кунак кызлары, ахрысы... Ул яктан да шаярып сөйләшкән, көлешкән авазлар еш кына ишетелеп китә.

Менә шушы аяз матур көн, якында гына кызларның көлешүе, малайларның йомшак, яшь тавыш белән ат куалаулары, акрын гына югарыга күтәрелә, үсә баручы кибән—боларның һәммәсе миңа бик тә ягымлы, бик тә кадерле булып күренә. Туктап ял иткән чакларда тиреңне сөртәсең дә—ирексездән рәхәтләнеп елмаясың! Менә шушы ямьле болынга, аяз зәңгәр күккә, аның ерак читендә тыныч кына күренеп торган ап-ак болытка, якындагы өем-өем тал куакларына сөенәсең... Алар сиңа бертуганыңдай якын, кадерле булып күренә. Алардан аерылып, алардан читтә ничек итеп яшәргә, көн күрергә мөмкин икән, диеп уйлап аласың... Һәм әнә шундый уйдан соң сиңа Ходай тарафыннан бүләк ителгән бу көннең, бу күренешнең әйтеп, аңлатып бетерелә алмастай олы бәһасе тагын да әчкәрәк үтеп, синең хәтереңә сеңә. Әлеге кояшлы күренеш мәңгелек яктылык булып синең күңелеңә оялый!

Жәй көннәре бик тә озын бит инде ул... Көне буена кояш астында йөрү, биек-биек кибәннәр утыртып кую—арыта да, туйдыра да... Әмма кичке салкын төшеп, эшләр тәмамлануга сине тирән күл суы көтә! Кырыйларыннан башта бата-бата гына атласаң да—эченә бер кереп киткәчтен иллә дә тәмләп, рәхәтләнеп йөзәсең инде анда! Зурлыгын да зур шул ул! Аның теге очы бөтенләй күренми: тал куаклары артыннан борылып китә ул, ә инде каршы як ярына хәтле бер сиксән-йөз адымнар чамасы булыр кебек. Әле житмәсә ул як—тоташ таллык кына! Күлнең суы да кара кучкыл булып тора анда—шомлы булып. Куркыныч булып! Ул якка йөзеп чыгучы да юк диярлек: без күлне буйлап йөзәбез, яисә инде бу яктарак юанабыз.

* * *

Тагын бер мәлгә тукталам. Чөнки ул матур күл үзенең бөтен чынлыгы—тирәсендәге тәбәнәк бөдрә таллары белән, биек-биек үләнле аулак култыклары белән, әчтәрәк йөзеп йөргән төнбоек чәчәкләре белән, хәтта үзенә генә хас булган исе-тәме белән дә менә хәзер минем каршыма килеп яткандай була... Гүя мин хәзер өс киемемне салырмын да, колачны җәеп йөзә-йөзә шуның рәхәтлеге эченә кереп китәрмендер кебек...

Бераз шундый сихри халәттә утырганнан соң кинәт сискәнеп китәм. Тукта, хәзер инде бу күл дә, аның янындагы без печәнен-җыйган җыеп йөргән

болыннар да—болар барысы да тирән су астында калып юкка чыгарга тиеш була бит! Юкка чыгарга...

Аннары үземә-үзем каршы килеп карыйм: ничек инде алай була алсын, дим... Шуның кадәр илаһи гүзәллек ничек итеп юкка чыга алсын ди инде?!. Бу кемгә кирәк булсын ди...

Ләкин... үзебезнең әти бүген нинди кайгыда иде соң әле? Безгә күрсәтмичә генә эчтән җылады, әрни-әрни җылады бит ул! Димәк, әнә шул олы кайгыны безгә караганда тирәнрәк аңлаган инде ул!

Элекке вакытларда туган җирдән читкә чыгып китүчеләр болай дип җырлаган:

Китәсе килеп китмимен,
Туган җирдән кем туйган?!

Ә менә монда безнең туган-үскән җиребезне бөтенләйгә, мәңгелеккә тартып алалар! Безгә нишләргә кала соң???

Күңелемә бераз тынычлану табарга теләп, яңадан бәхетле көннәргә таба атлыйм—укуымны дәвам иттерәм.

* * *

Менә әкрен генә энгер дә инде... Кичке ашлар да ашалды, карлыган яфраклары, мәтрүшкә, җиләк салып пешерелгән чәйләр дә эчелде...

Әрле-бирле сугылып тагын күпмедер вакыт узды...

Һәм бермәлне бөтен болынны яңгыратып гармун сыздырып җибәрде! Безнең оч егете Рәис ул шундый да шәп иттереп, шундый да оста борылмалар ясый-ясый уйнаучы! Быел үзебездә аның кебек шәп гармунчы булгач башка еллардагы шикелле күрше авыл болынчылары янына йөрүләр дә юк—хәзер үзебездә көн саен диярлек бичыр ясыйбыз!

Менә бүген дә куышлар артындагы сырт ягыннан ишетелде Рәиснең гармун тавышы. Аннары ул салмак, моңлы көйгә күчте—«Рамай» ахрысы... Әйе, әйе—нәкъ шул: дөньядагы көйләрнең иң-иң моңлысы, иң тирән сагышлысы! Әлегә гармунга кушылып җырлаучы булмаса да ул көйне ишеткәч күңел, җан, йөрәк үзеннән-үзе моңлана, җылый, тилмереп үкси башлый кебек...

Төнгә каршы берәү моңлы итеп, Рамай,
Аерылышу көен җырлады...

Нинди бәхетсез җан чыгарды икән шушы гаять тирән хисле җыруны? Ишеткән кешеләрнең үзәкләрен өзәрдәй иң-иң нечкә, иң-иң төгәл сүзләрне ул каян таба алды икән? Күрәсең, аның—бу җыруны чыгаручы моңлы җан иясенең дә—сөйгән кешесе белән сыкрана-сыкрана, өзгәләнә-өзгәләнә хушлашу мизгелләре булгандыр инде... Әнә шуңа күрә ул үзе чыгарган бу җыруның иң беренче сүзләре итеп «төнгә каршы...» дигәндер... Үзенең каршында, үзенең алдында кара төн генә күргәндер ул мескен бала... Ул моңлы бала...

Менә шул чагында, авылдашым Рәис гармунда «Рамай» көен уйный-уйный моңланганда, минем күңелгә бик тә кызыклы бер фикер килә!

—Тукта әле! Безнең татар халкының менә шушындый «Рамай» шикелле моңлы көйләре симфонияләргә тиң булырдай моңны сыйдырган түгелме соң үзләренә?! Бөек кичерешләрне, иң тирән хисләрне чагылдыру өчен бәлки безгә музыканың нәкъ менә шушындый рәвеше кулайдыр?! Музыканың эчке ягы, эчтәлек ягы тирән икән, үтә дә житди икән һәм бик тәэсирле икән—ул чагында ни өчен соң без тагын тышкы форманың, тышкы рәвешнең нәкъ менә симфония исемендә булуын таләп итәбез?! Дөньяда бит: «Зур әйбер генә яхшы була, зур күләмле әсәр генә бөек була» дигән канун юк! Минемчә, кайчагында безнең менә шушындый бер көебез дә нindидер бүтән халыкның бер симфониясенә тора ала торгандыр бит... Һәрхәлдә, халыкларның, милләтләрнең үз язмышлары

бик тә төрле булган шикелле, аларның холык-хасиятләре дә нык аерылып тора бер-берсеннән. Димәк, «синдә теге нәрсә юк, бу әйбер күренми» дигән таләпләрне бик тә уйлап, алдын-артын үлчәп кенә әйтергә кирәктер.

...Рәис белән без көндез дә гел бергә эшлибез, шуңа күрә аның ялгыз монаеп утыруына комачаулыйсы итмәдем. «Хәзер җиелырлар синең янга...» диеп уйлап, үзем генә күл буйларын урап киләсе иттем. Ләйсирәләр куышына да сугылып чыгарга исәп бар, билгеле—кеше күзенә бик чалынмыйча гына инде...

Әмма гаҗәп: куышта беркем дә юк иде! Кая соң болар? Озак басып торырга ярамый—ары киттем дә, сөзәк кенә үрдән күлгә таба төшеп киләм... Инде тәмам караңгы дияргә була: түмгәкләр арасындагы сукмак аз гына шәйләнә дә, күл буйлап тезелгән тал куакларын гына аерып була. Әз генә кызурак китсәң түмгәк арасына барып төшүең дә бик мөмкин, әле аның биек булып үскән кыягы да муеннан диярлек бит!

Шулай сак кына барганда алда хатын-кыз тавышы ишетелмәсен-ме! Сөйләшә-сөйләшә кайтып килешләре икән боларның... Көлешеп тә алалар шунда. Тик нәрсәдән көлгәннәрен генә белеп булмый... Тукта, берсе Ләйсирә тавышы түгелме соң монын? Шул шул—аның тавышы бу! Мина да кыюлык кереп китте, адымнарны житезләтә төштем. Ә якынлашкач:

—Су керергә мине дә алмагансыз шунда!—дигән булам, әз генә үпкәләгән тавыш чыгарып. Ләйсирә дә югалып калмый:

—Йә батырырсың диеп курыктык!—ди.

Аның юлдашы Әнисә апа булып чыкты, ул мине тану белән туктап та тормады тагын.

—Мин чәй куя торам, яме!—диде дә кызу-кызу китеп тә барды.

Ләйсирә жинел жәйге халаттан гына. Сөлгесен жилкәсенә салган да, ни әйтеремне көтеп минем алдымда тора. Ә мин сүз әйтердән элек аның су салкынлыгы, су дымы да китмәгән кулыннан тотам да:

—Чынлап та, нигә мине дә ияртмәден?—дим.

Минем бу сүзләремә каршы ул нәрсә ди?!

—Әй лә! Җегетләр барында иркенләп коенып булмый ич ул...

Аның мондый серлерәк сүзләрен аңлыйм да кебек. Шул ук вакытта төшенеп тә житә алмыйм... Әмма озак баш ватып торырга вакыт юк.

—Әйдә, мин дә бер чумып чыгыйм инде—син мина күз-колак булып тор инде!—дим.—Үзем генә керсәм йә батып үләрмен дә, соңгы күрүче кеше син булгач, сиңа минем өчен җавап бирергә туры килер!

—Әй лә, авызыңнан жил алсын!—дип Ләйсирә мине төртеп җибәргәндәй итә дә, үзе күлгә таба борыла. «Әһә, минем белән бара болай булгач!»—дип сөенәм эчтән генә.

Дөресен генә әйткәндә, мин бүген, эштән кайткач та, бер мәртәбә су кергән идем инде. Ә монысы шул, Ләйсирәне аерып алып калу өчен булды аның... Ләкин үзенә әйтеп тору юк—шуңа күрә күл буена килеп житү белән чыннан да су сагынган кыяфәт чыгарып кердем күлгә. Төнге күл ул бөтенләй икенче икән! Суы шундый жылы, шундый йомшак! Ә күзем бары тик Ләйсирә ягында гына—әйтерсең лә мин карап тормасам ул китеп барачак та, мин монда берүзем, бер ялгызым калачак... Шулай да төнге кап-кара су эчендә берүзең йөзеп йөрүе шактый шомлы икән. Ләйсирәгә карап йөзүем дә үз-үземне дәртсендерү өченрәк булды, ахрысы... Теге якка таба баксаң—бөтенләй шомлы ич!

Кайтуын кызу-кызу атлап, йөгереп үк диярлек кайттык без. Яр буенда мине көтә-көтә Ләйсирә дә күшеккән иде кебек, төнге салкынча һава үземне дә тизрәк куалады.

Үзем барам, ә үзем һаман сүз куертам:

—Син кайтуга чәй куеп торалар инде, ә!—дигән булам.

Ләйсирә дә җөпләп куя:

—Шулай шул, апаңны баллы, карлыганлы, мәтрүшкәле чәй көтә!

Ә мин шунда кызу гына кайткан жирдән аны кочаклап алам һәм:

—Мин сине менә шушыннан җибәрмәсәм, нишлисең?!—дим.—Чәеңне эчә алмый каласың бит!

—Ә мин каты итеп: «Әнисә апа-а-ау!..»—диеп кычкырам, ди Ләйсирә—зур матур күзләре белән миңа текәлгән көе, шаян тавыш белән һәм мут елмаеп.

—Миңа да чәй алып керсәң... Чәй алып керсәң...—димен мин аңа якын ук килеп.—Мин сине җибәреп торыр идем кебек беразга...

Ләйсирә тагын да шаянрак төс ала да, башын кырын салып:

—Җегетләргә чәй килешәме соң ул?—дигән була.

Минем телгә дә әллә каян гына мут фикер килә дә, болай дим:

—Беләсеңме, чәйне кызлар күзенә карап эчсәң—күз алдында әллә нинди сихри йолдызлар күренә башлый. Үзеңне әллә ничә йолдызлы коньяк эчеп утыргандай хис итә башлыйсың... Тылсымлы шәраб эчкәндәй тоеласың үзенә! Чын менә! Валлаһи, билләһи!

—Булды, булды! Ышандым, ышандым!—ди Ләйсирә көлә-көлә.

Аннары тагын өстәп куя:

—Алайса бүген сиңа да чәй эчермичә ярамас инде... Йә чирләп китәрсең төнлә су кергәч...

Ул минем кырыйдан узып китмәкче була, ә мин аның бер битеннән тиз генә үбеп алам да:

—Бүген үзем генә калдым әле куышта...—дим.—Әйдә, бездә генә эчик чәйне?

Ләйсирә әкрен генә алга омтыла. Ә мин аны җавабын ишетмичә җибәрмәскә тырышам, ике кулым белән кысып тотам... Һәм ниһаять, аннан шундый сүзләр ишетәм:

—Әнисә апа җибәрсә...—ди ул миңа карамыйча гына. Мин инде бу сүзне нәрсә диеп анларга да белмим... Ләйсирәне ычкындырыргамы-юкмы—анысына да баш җитми... Әмма җибәрмичә чара да юк. Төн буена монда басып тормассың бит инде!

...Менә инде Ләйсирә кызу-кызу атлап китеп тә барды...

Мин аны үземә чакырдым түгелме соң?! Шушы уй минем башка аннары гына, Ләйсирәнең төн караңгылыгын ерып баручы матур гәүдәсенә карап торганда гына килде...

Әйе, әйе—мин аны үземә кунакка чакырдым! Үз куышыбызга чакырдым! Ничек итеп минем моңа кыюлык житте соң әле... Әйтсәм әйтим инде: анарчы юньләп кызлар озатканым да юк иде әле! Шул—бер елны Сабан туена безнең күршегә кунак кызы килгән иде... Аның белән кинодан бергә кайттык... Җәйге жылы төн иде ул... Каушый-каушый гына, үз гомеребездә тәүге мәртәбә үбешкән дә булдык шунда... Беренче мәртәбә кызлар иренено кагылдым мин ул кичне!

Ә икенче көнне ул кунак кызы ап-ак кисея күлмәк киеп безнең тыкрыктан су ташыды. Гәүдәләрен әкәмәт тә матур итеп боргалый-боргалый... Безнең чирәмле сукмагыбызны гомергә күрелмәгәнчә ямьли-ямьли... Койма, читән буйларында үскән чәчәкләргә охшый-охшый...

Хәзер, менә күп вакытлар үткәч, аның белән беренче үбешүебез истә калган да, аның безнең тыкрыктан бик матур итеп су алып кайтуы күз алдына килә.

Ә Ләйсирә белән без һаман бергә укыйбыз кебек... Менә бу җәйге каникуллар үткәч янадан да үзебезнең мәктәбебезгә җыелырбыз шикелле... Елга яры буйлап озын итеп салынган бер катлы агач мәктәп һаман да безгә ямьле-ямьле көннәр, якты, нурлы илһамлы кичләр бүләк итәр сыман... Аның белән бергә дәртләнеп, рухланып йөрүләр әле һаман да дәвам итәр шикелле...

Ләкин шул ук вакытта баш миенең бер почмагында гына булса да «ул хәзер калада инде» дигән уй сакта тора. Хыялларга артык үсеп, үсенеп китәргә юл куймый ул шактый ук кырыс сакчы. Әйтерсең язмыш юлларының аерылуы әнә шуннан башлана да, гүяки әнә шул аерымлык адәм балаларының бөтен-бөтен гомерен хәл итә!

Безнен куыш эче үзе болай байтак кына зур ул. Өчәү яшибез бит... Тик менә әйберләрен генә бик тә туздырып ташлаганнар икән бу Тәлгат белән Фәйзерәхман. Күрәсең, машина китә диеп шулай кабаланганнардыр инде...

Кайтып керү белән ин башта аларнын кием-салымнарын, тәлинкә-кашыкларын җыештырып куйдым. Әйтерсең лә Ләйсирә мина ныклы вәгъдә биргән керәм дип! Бу яшьлекнең нарасый ышануы диген!

Шулай да... Шулай да үзем яшәгән куышны әйбәтрәк итеп күрсәтәсе килә бит инде! Күңел түрендә «керерме, юкмы?» дигән сорау әледән-әле калкып алса да—ике кул һаман ашыга-кабалана «өй» җыештыра мин сина әйтим!

Ул арада кесә фонарен да табып, әзерләп куйдым инде. Баш очындагы бөгелгән тал ботагында фонарь элү өчен көйләнгән урын да бар безнең. Кичләрен, төннәрен куыш эчендә ут кирәк дибез икән—тотабыз да менә шушы фонарьны элеп куябыз өскә! Ярый тагын... Гәжит укырдай ук булмаса да, алда торган савытларны күрерлек кенә яктырта үзе...

Мин куыш эчендә вакытны ничек итеп үткәрергә белмичә аптырыйм, ни уйларга белмичә йөдәп утырам—ә «авыл» башындагы сырттан хәзер инде ду килеп биегән тавышлар килә. Рәис гармуны дәртле көйләр сибә инде... Берсе артыннан берсен алыштырып кына тора! Әйе, бу бичыр бер башлангач озак кына барыр әле... Хәзер бөтен кеше шундадыр инде... Биемәгәннәре карап торадыр. Сабан туе карагандай шунда йөрештерәдер, таптанадыр...Чирәмнәре тапталып, кап-кара җир кала инде анда иртәнгә!

...Менә куышның тышкы ягында аз гына кыштырдау ишетелде дә, ул да булмады—эчкә таба зур гына бер кәрзин шуып керә башлады... Карасам... Карасам—ул кәрзинне тыштан бер кул этә ич! Тукта, ул килгән ич! Ул килгән!

Шатлыктан йөрәк шартлар дәрәҗәгә житте, малай! Әмма беркая да барып булмый! Аның каршысына чыгып та булмый хәтта! Чөнки куыш авызы бик тар—иелеп бер кеше аннан көчкә үтә ала.

Нишлим соң?!

—Ләйсирә синме?—дип сораган булам, нәрсә дә булса әйтер өчен генә.—Синме бу?

Ә тыштан бер тавыш та юк. Бер сүз дә ишетелми.

Аннары гына башыма барып житә: соң ул «мин!» дип кычкыра алмый ич инде! Кыз бала ич инде ул!

Мин кәрзинне, шундый да авырайган кәрзинне, иплэп кенә эчкә аламын да, бер кырыйгарак урнаштырып куям. Аннары Ләйсирәне каршыларга дип башны тыгыйм гына дигән идем, шык итеп башлар бәрелеште безнең! Көлеп тә жибәрдем һәм шундук көлә-көлә артка да утырдым. Ләкин шулай да аның кулын эләктереп өлгердем, эчкә таба житәкләп үк керттем дияргә була.

—Шундый карангы-ы...—ди Ләйсирә пышылдап кына диярлек.

Мин исемә киләм һәм әзерләп куйган жиреннән фонарьны алып кабызам да, югарыга элеп куям. Ләйсирә әле мүкәләп диярлек тора икән, үземнең сырманы жәеп аны шунда утырырга өндим. Аста шундый тәмле, хуш исле печән дә бар, барлыкка—әмма сырма жылырак шул инде ул! Кызларга бигрәк тә уңайлы кирәк бит инде ул...

Ә Ләйсирә ул арада кәрзингә үрелә, андагы әйберләрне алырга тели күрәсең... Тик шундук туктап та кала, мина күтәрелеп карый:

—Берәр нәрсә кирәк иде бит... Боларны куярга!

Менә монысын уйламаганмын икән мин! Арлы-бирле каранам, бер дә жүнле нәрсә күзгә чалынмый шул... Ахыр чиктә күзем бер читтәге фанир тартмага төшә.

—Әһә!—дим әллә нәрсә тапкандай шатланып.—Менә моны бушатам да, каплап куябыз! Вәт була!

Күз ачып йомганчы астын өскә китереп, андагы вак-төякне почмакка

аударам, фонарь яктысына китереп карыйм—аскы ягы тигез дә, шактый чиста да күренә монын. Ник ярамасын ди!

Әмма Ләйсирә ана гына риза түгел, ул минем әйберләр арасыннан бер гәзит тартып чыгара һәм бик хасиятләп шуны җәеп куя. Затлы бер ашъяулык диярсең!

—Әкиятләрдәге тылсымлы ашъяулык кебек булды бу!—дип мактап та алырга телим Ләйсирәне, әмма анын йөзе җитди. Тик менә беркайчан да мөлаемлыгы бетми, югалмый Ләйсирәнең. Аңа, аның йөзенә һәрчак карыйсы гына килеп тора. «Бер битең ай, икенчесе кояш» диеп менә шушындый—менә шушы Ләйсирә шикелле кызларга әйтәләрме икән соң әллә? диеп уйлап куям эчемнән генә хатын-кыз турында, аларның бик тә серле дөньясын бөтенләй дә белмәгән көйгә... Бу хакта ять-яшь, ямь-яшел башым белән...

Ә Ләйсирәнең кәрзиненнән ниләр генә чыкмый, мин сиңа әйтим! Иң башта зу-ур керәч чәйнек менеп утырды безнең бәләкәй өстәл өстенә. Аннары кечерәк банка белән бал, шулай ук бер бәләкәй савыт май... Ап-ак ярты күмәч тә менеп утырды өстәл түренә...

Без, җегетләр, монын ише нәрсәләр белән бик сырланып тормыйбыз шул инде... Ә чын дөресен әйткәндә, өйдә дә мондый тәмтом сирәк була әле. Кая монда алып чыгасың инде аны?! Шул—күбрәк колхоз итенә, колхоз бәрәнгесенә ышанып чыгасың инде ул чагында Арьякка... Монда безгә боткалар да, төрле-төрле ашлар да әйбәт кенә эләгә! Анысын күл буе чирәменә кырын ятып, өерләре белән бөтерелгән черкиләрне куа-куа, өфләп өрә-өрә ашаулары үзе бер зур бәйрәм була инде ул!

—Ә-ә... Юк, юк! Ин зур бәйрәм менә бүген икән! Менә бүген!

Сүрән генә ут яктысында Ләйсирә белән икәү генә тәп-тәмле чәйне иплэп кенә кабып утырабыз, малай, бу бәхеткә ышанырга да ышанмаска да белмичә!

* * *

Әй, ул бәхетле минутлар... Әй, ул чәйнең тәмлелекләре! Әй, ул кичне безнең куышта оҗмах фәрештәсенең кинәнә-кинәнә канат кагынуы! Тирәбездәге һәр нәрсәнең, һәр мизгелнең бер тоташ гүзәл музыкага әверелүе ул кичне... Сөйләп сүзләр генә җиткерерлек түгел иде шул, валлаһи! Мин, инде озак еллардан соң әнә шул минутлар өчен Ходайга чиксез рәхмәтләремне укып утырам.

* * *

Менә бер заман чәйнегебез бушап калды... Ләйсирә җәһәт кенә «өстәлебез» өстен җыештырды, ә мин фанир тартманы бер яккарак алып куйдым... Хәзер инде безне төн үз кочагына чакыра иде. Төнге болын сукмаклары ымсындыра иде!

Әле бит җитмәсә сыртта ду килеп бичыр бара: яшьләрнең уйнап-көлешкәннәре, җинелчә генә кычкырышып та алулары безгә кичке тын һавада дулкын-дулкын булып килеп ирешә.

Әмма Ләйсирә белән минем ул тарафка бер дә барасы килми. Безнең аяк ул якка тартмый... Безгә тынычрак, аулаграк, үзебезнең күңел теләгәнрәк урын кирәк... Һәм мин бүген Идел ягына бара торган юлны түгел, ә күрше авыл куышларына таба илтүче такыр сукмакны сайлыйм. Ул сукмак иплэп кенә сыртка күтәрелә дә, аннары инде тал өемнәрен урап үтә-үтә, еракка сузыла. Ә үзе гел сырт буйлап бара көндезләрен шомарып беткән беләү кебек ялтырап ятучы бу сукмак...

Әзрәк өскәрәк менгән идек, сукмагыбыз да икегә әйләнде, хәзер инде безгә янәшә атларга да була кебек... Алай күнеллерәк ич! Сөйләшергә дә жайлырак.

Чәйдән соң кәеф тагын да күтәрелеп китте әле. Ләйсирә белән сөйләшәсе килеп кенә тора... Нәрсә турында булса да булсын—бары тик бу бәхетле минутларны дәвам гына итәргә! Аны озаккарак кына сузарга!

—Калада авыл сагындырадыр инде...—димен мин, анын ин авырткан жиренә кагылуымны башта уйлап та житкермичә.—Ничек итеп түзәсен сон?

Ләйсирә авыр сулап куя... Шактый гына ара тып-тын бара. Аннары гына минем сүзгә жавабын бирә:

—Әй лә! Бик тә, бик тә сагынсам—әнигә хат язарга утырам... Шул чагында анын белән сөйләшкән шикелле була... Күнел тынычланып китә әнигә хат язганда... Ана сыенган, иркәләнгән кебек буласын.

Минем үземнен әле авылдан бик еракка китеп караган юк, шуна күрә сагыну хәлләрен чамалап та, анлап-төшенеп тә бетерә алмыйм. Шулай да белгән-күргән кеше сыман:

—Ә-ә-ә...—дип куямын.—Алай икән...

Акрын гына атлый бирәбез шулай... Ә якындагы әрәмәлектә шашынып-шашынып сандугач өздерә. Шундый да дәртләнеп сайрый ул—бу вакытта сөйләшүе дә бер-бер гөнаһ булыр шикелле. Ана игътибар бирмичә алга атлау язык эш сыман, ярамаган нәрсә кебек.

—Ә бер көнне кызык булды әле!

Ләйсирә шулай дип жинелчә генә көлеп куйды да, ипләп кенә сөйләп китте.

—Дәресләр иртә беткән иде дә... Тулай торакка кайтасы да килми. Ә безнен янда гына күргәзмәләр залы бар. Бөтен атаклы картиналар шунда инде! «Тукта әле, бер кереп чыгыйм әле!»—дип бусагадан атлавым булды—нәкъ менә үзебезнен як табигатен күреп, баскан жиремдә катып та калдым! Ул көнне, минем бәхеттән, Шишкин картиналарын куйганнар икән! Безнен якташны! Урманнары нәкъ безнеке ич инде—без әби белән жиләккә барган жирләр ич инде ул! «Менә сина, мә!» димен эчемнән генә. Безнен дәреслектәге аклы-каралы рәсемнәр алар бернәрсә дә түгел икән бит! Ә менә болары инде чын картина, чын сәнгать! Алар мине туган якка алып кайтты, туган як һавасын бирде.

Ышанасынмы-юкмы, менә чын дөресен әйтәм: ул көнне күргәзмә залы ябылганчы йөрдем мин анда! Караштырып торучы апалар да хәлемне анладылар, ахрысы—ипләп кенә сөйләштеләр минем белән, аркамнан сыйпаган төсле генә... Әле аннан чыккач та трамвай эченә, халык арасына һич кенә дә керәсе килми иде... Тәки жәяүләп кайттым бит тулай торакка хәтле... Әй лә! Анын каруы әби белән жиләккә барган сыман тоелды ул көн!

Мин ул арада бераз шаяртып алмакчы булам:

—Әллә жиләген дә ашагандай идеме сон?

Ләкин Ләйсирә минем шаяруны кабул итми. Гүя ул мине ишетми дә әле... Күрәсен мин, үземнен читтә яшәп караганым булмаганга күрә, сагыну хәлен анлап житкермәгәнмендер инде ул чакны... Шаяртуым да урынсыз булгандыр бәлкем? Кем белә...

Әмма ул кичне икенче бер атаклы якташыбызны искә төшерү һич тә артык түгел иде. Монысын мин төп-төгәл әйтә алам!

—Әле сина Петр Ильич үзе дә булышыр әле бераздан!—дидем мин Ләйсирәгә чын күнелдән ышанып.—Нигә, чынлап әйтәмен! Анын туган шәһәре Воткински безгә сиксән генә чакрым ич! Димәк ул да—Чайковский да—безнен якташ дигән сүз!

Шул урында Ләйсирә туктап калды. Бик гажәпләнгән сыман иде ул.

—Кара! Мин моны бөтенләй уйламый идем бит әле! Ничектер, бүтән республикада булгач, безгә бик ерактыр шикелле иде ул Воткински?!

Мин исә тагын канатланып киттем:

—Һи! Дүртенче сыйныфта укыганда ук булдым мин ул Воткинскида! Анда безнен туганнар—море!

—Ә матурмы сон ул? Шәһәрен әйтәм.

Биредә инде минем көймәм комга терәлде. Дүртенчедә укыганда ничек шәһәр карап йөрисең дә, аны каян истә калдырасың ди инде?!

—Болай әйбәт кебек инде ул...—димен үз-үземә ышанмаган тавыш белән генә.—Завутлар күп инде анда... Су керергә буалары да бар!

—Ә үзең әйткән Чайковский музеена кердеңме соң?

Авызны ачтым да калдым шунда! «Ә...»—дип тотлыгып. Анда мине кем алып барсын соң инде! Безнең туганнар завутта эшли ич!

Беркавым шулай аптырашып басып торабыз да, тагын ары таба атлый башлыйбыз...

Ә төн шәп! Менә диган! Хәзер инде безгә гармун тавышы да ишетелми. Бөтен дөньясында әйтерсең без икәү генә менә бу минутларда! Бөтен галәменә, җиһанына икәү генә без гүяки! Әй, юк—алдашам икән әле! Тагын бит әле сандугач бар! Безнең тел белән әйтергә базмаган теләк-хисләребезне йөрәкләргә уйдырып-уйдырып салучы әнә шул моңнар патшасын онытырга ярыймы соң инде, җә?!

Менә бу талга кунганы бигрәк тә якын ишетелә. Икебезнең баш очына килеп баскан диярсең, билләһи! Әллә ул безнең йөрәкләрне әнә шул нечкә ефәк җебе белән бергә бәйләмәкче буламы икән? Бер моң, бер хис дулкынына көйләп безне бер-беребезгә ныграк якынайтмакчымы әллә бу сандугач? Безнең күңел кылларын бергә ялгарга телиме соң әллә ул?

Моның чыннан да шулай икәненә ышанасы килә ни өчендер... Ләйсирә белән икебезнең юлларны бер итеп күрәсе килә... Гел-гел бергә бара торган итеп, янәшә итеп!

—Әллә җитәрме соң инде?—Мина таба карап Ләйсирә шулай ди дә, барган җиреннән туктальш кала.

Ә мин инде үзебезнең кайда, кай тарафта икәнне дә оныткан сыман. Мин инде байтактан бирле хыял дингезендә. Юк, алай әйтү дөрес үк түгел бугай: әлеге сандугач моны, менә шушы сихри төн дулкыннары алып килгән тылсымлы дәрья эчендә ахрысы мин.

Ләйсирәгә биргән җавабым да төштәге сыман тонык кына ишетелә:

—Әйдә соң, алайса, борылыйк...

Ә борылсак... Ә анда—нәкъ безнең артыбызда түп-түгәрәк ай озата килә икән ич! Шундый да якты булып тулган ул, үзе безгә шундый да якын кебек—гүяки тагын бераз кулыңны суза төшсәң бармакларың белән аның битенә дә кагылып буладыр сыман... Аны да иркәләп, сөеп буладыр шикелле...

Дәртләнеп китеп карашымны шундук Ләйсирәгә юнәлтәмен. Менә шушындый илаһи төндә ана да кагыласы, аны да иркәлисе, сөясе килә... Шундый да гүзәл бит ул! Бүген бигрәкләр дә чибәр, назлы бит ул! «Тулган айларга охшатам елмаеп көлгәнеңне»—дип менә шушындый кызларга әйтәләрдер инде ул, мөгаен!

Эчемдә хисләр кайный. Әмма кайсыннан башлап, ничек итеп әйтергә белмим... Сүзсез калам һәм... Һәм сак кына аның кулын үз кулыма алам... Ул моңа сүз әйтми. Ә аның кулы кайнар, йомшак һәм шул ук вакытта аннан мина ниндидер бер сихри нурлар агадыр кебек... Ул агымга тәнгәл матур, ягымлы назлы сүзләрне табуы мөмкин дә түгел сыман. Без сөйләшә торган фани дөнья сүзләре—алар башка, ә менә безнең йөрәкләр, күңелләр арасындагы дәрьяны белдерү, аңлату өчен бөтенләй бүтән төрле: гаять тә нечкә, бик тә тирән мәгънәле, аеруча моңлы булган, бай аһәңле булган музыкага тиң сүзләр генә кирәктер шикелле...

Әйе, әйе—кыз белән егет арасындагы хәлләрне бары тик музыка гына әйтеп, аңлатып бирә аладыр! Нәкъ әнә шуна күрә халыкта гаять тә моңлы, гаять тә тирән хисле җырлар туадыр ул! Һәм алар, ул җырлар, үзләренең аһәңе белән йөзләгән китапларга, поэмаларга тиң эчтәлекне бирә ала торгандыр! Шулайдыр!

Кайтырга таба борылгачтын ни өчендер икебезнең дә адымнар

әкренәя төште кебек. Икебезнең дә менә шушылай янәшә бару, янәшә булу вакытын сузасыбыз килә иде шикелле...

Әнә инде безнең куышлар урнашкан инкүлек тә күренә башлады. Тулы ай яктысында күлебез дә гаҗәеп төсләр белән ялтырап ята.

Ә без менә сырттан төшеп киләбез... Әкрен генә атлап үзебезнең куышка таба якынлашабыз. Хәзер минем баш миен бер генә сорау газаплый: «Их, тагын кереп утырасы иде бит безнең куышка!» Шушы сүзне ничек кенә итеп әйтергә соң Ләйсирәгә? Ни дип әйтсәм җайлырак, матуррак килеп чыгар икән?

Сыртның теге башында исә әле һаман бичыр бара, гармун тавышы әле һаман тынмый... Һәм мин «ни булса шул!»—диеп сүземне болай башларга карар иттем:

—Тегеләр әле һаман типтерә бит... Әле йокы да килми... Әйдә, тагын әзрәк утырабыз безгә кереп...

Шулай дим дә Ләйсирәнең кулына үреләм. Минем «үтенеп, үтенеп сорыйм!»—дигән сүземне белдерә инде бу үземчә. Әмма Ләйсирә моны аңлармы? «Булды бит инде!»—дип кырт кына кисмәсме ул? Күңелне корт кимерә, икеләнү газабы җанны өтә...

—Әнисә апа нәрсә дияр микән соң...

Әйе, әйе—үзе дә икеләнгән, шикләнгән тавыш белән Ләйсирә миңа әнә шулай ди! Димәк... Димәк, ул болай каршы түгел, ахрысы... Аны ризалатырга була, ахрысы... «Әй, телем! Әй, зиһен! Әйдәгез, миңа ярдәмгә килегез инде! Кыз бала белән яшүсмер егет арасындагы бик тә куркыныч, бик тә ныклы тоелган койманы атлап үтәргә зинһар ярдәм итегез!»

—Ул сине бичырда диеп беләдер әле...—димен мин аның шикләрен таратырга теләп.—Әнә, һаман уйныйлар бит әле!

—Әһә, шулайдыр!—дип көлә-елмая миңа каршы төшә Ләйсирә.—Чәйнекләр күтәреп чыгып китүемне күрде ич ул!

Аның елмаеп торуы миңа да кыюлык өсти һәм мин тагын болай дип дәвам итәм:

—Ә беләсеңме ул нәрсә диеп уйлый? «Болар чәй эчеп утырганнар да, аннары иптәшләре янына, бичырга киткәннәр»,—диеп уйлый ул! Нәкъ менә шулай уйлый! Валлаһи, билләһи!

Минем мавыга-мавыга сөйләвем, шуның кадәр нык бирелеп аны ризалатырга, килештерергә теләвем Ләйсирәгә, чыннан да, бик әйбәт тәэсир итә, ахрысы, ул рәхәтләнә-рәхәтләнә көлә. Аннары гына миңа болай ди:

—Әй лә, әйдә соң, тагын бераз урап киләбез... Керсәк шуннан соң керербез алайса...

Бу сүзләрдән инде мин кош тоткан сыман булам!

—Әйдә!—дип аны тагын җитәкләп алам.

Хәзер инде без Идел ягына таба кузгалабыз. Ул якка менә дигән ат юлы бара ич! Әлләни бик еракка да китәсе килми инде хәзер—анысы да бар бит әле аның...

Сыртка менеп Иделгә таба борыласың да, шуннан соң тагын бераз атлау белән янәшә үсеп утырган өч тирәк янына килеп җитәсең. Әллә элек авыл булган инде монда? Ничектер, аларның монда үзләре генә үсеп утыруы сәеррәк тә тоела кайчакларда... Ләкин безнең өчен үзенә бер маяк шикелле алар—әллә каян ук күренеп торалар, кай якка барасы икәнен әйтеп торалар. Мондагы тал куаклары арасында үзенә күрә бер падишаһ сыман да тәэсир калдыралар алар... Биекләр, бик тә биекләр чөнки!

—Болар бик карттыр инде...—ди Ләйсирә тирәкләр янына килеп баскач. Аннары үзе үк әйтеп тә куя.—Йөз яшь бармы икән?

Ул сан исә миңа артык зур тоела. Үземнең шигемне әйтәм. Ләкин Ләйсирә бөтенләй бүтән уйларга кереп киткән икән әле.

—Бу тирәкләр яныннан кемнәр генә үтеп китмәгәндер инде... Кемнәр генә басып тормагандыр менә шушы җирдә? Менә шушы

урында?!.. Ә бу тирәкләр аларны хәтерләми дә булыр инде? Ничек кызганыч... Нинди кызганыч! Әйеме?

Мин аның уйларына өметлерәк, яктырак аһәң бирмәкче булып:

—Менә безне исендә калдырыр алар!—дим.—Безне алар һичшиксез хәтердә калдырырга тиеш!

Ләйсирә караңгыда да шундый матур, серле булып күренгән күзләрен зур итеп ачып, нindидер бер олы өмет белән миңа текәлә. Әйтерсең лә бер сабый бала ерак юлдан кайткан сәфәрчедән тәмле күчтәнәч көтә!

—Нишләп алай дисен? Ә нигә алар безне генә истә калдырырга тиеш?

Ә минем моңа җавабым юк ич әле! Болай сүз арасында гына, үзем дә ышанып җитмичә генә әйтелде ич инде ул... Әмма күңелнең үзенең дә әлеге сүзгә ышанасы килә бит! Өметсез шайтан гына дигәндәй...

—Беләсеңме ни өчен безне бигрәк тә хәтердә калдырырга тиеш алар?! Чөнки... Чөнки бүген—менә хәзер—алар янында дөньяның иң чибәр, иң ягымлы кызы басып тора! Менә шуның өчен безне истә калдырырга тиеш алар!

Телдән шундый сүзләргә ычкынуга үзем дә аптырыйм инде... Ләкин дөрес бит бу! Чыннан да, шулай ич инде!

Әмма миңа мондый кыюлык, шушындый тәвәккәллек каян килде диген?! Үземә үзем ышаныргамы, ышанмаскамы белмим, валлаһи...

Әллә тулган ай миңа шулай әйбәт тәэсир итә инде... Укыганым бар иде бит: кайсыбер кешеләргә тулган ай әйбәт тәэсир итә икән, ә менә бер иш адәмнәрне ул, киресенчә, чыгырдан чыгара ди... Бәйләнчек, усал итә, ди...

—Әллә бу тирәкләр кешене тилертә дә микән?..—ди Ләйсирә миңа карамыйча гына... Һәм тавышын ничектер акрынайта төшеп.—Әллә нинди сүзләр башладың бит, Илсур...

Шул арада минем монысына да җавап табылды бит, малай!

—Үзем дә аптырап торам инде менә! Туп-тулы булып тулган ай шулай тилертәме мине, әнә шул ай шикелле бер кызыймы, әллә инде менә шушы тирәкләрме икән—һич кенә дә белә алмыйммын дөрес җавабын!

—Әйдә, алайса, икебез дә тилергәнче китик моннан тизрәк!—дип Ләйсирә минем кулга ябыша... Ни өчендер кызу-кызу атлый-атлый тирәкләр яныннан китеп тә барабыз. Үзебезнең куышка таба.

Ә килеп җиткәч Ләйсирәнең исенә төшергән булып кыланам:

—Синең чәйнекләрең дә бездә бит әле...

Минем сүзне ул да җөпләгәндәй:

—Әйе шул, Әнисә апага иртүк кирәк була бит инде ул!—ди.

Куыш авызына киләмен дә, черкиләр кермәсен диеп томалап куйган япманы ачамын... Үзем шуннан соң аз гына янга тайпылып, Ләйсирәгә үтү өчен ара калдырам... Һәм ул бер сүз дә эндәшмичә ипләп кенә эчкә кереп китә... Аннары инде үзем дә ишек япмасын кулдан җибәрмичә генә, чигенә-чигенә генә, куыш эченә керәмен—тиз генә ишекне томалап та куям!

—Бу черки-дошманнар каян чыга икән шуның хәтле!—дип аларны сүккән булам!

Ә куыш эчендә әле кесә фонаре кабызылмаган. Анда дөм караңгы. Ләйсирәнең кайдалыгын да күрмим... Ләкин әле ул аласы әйберләрен җыештырмый сыман... «Ашыга күрмәсен генә иде инде...» ди күңел ихлас бер үтенеч, ихлас бер ялвару белән кемгәдер мөрәҗәгать итеп.

Ләйсирә тарафыннан бер генә тавыш та юк... Бераздан үземә дә сәер булып китә дә, иплəп кенә сорап куямын:

—Син мондамы соң...

Әллә инде куыш эченә артым белән кергәнгә күрә башым буталып киткән, әллә башка сәбәп бар, ләкин ни өчендер Ләйсирәнең тавышы мин көткән яктан түгел, ә бүтәнрәк тарафтан килә шикелле... Һәм ул серле булып, әллә нинди бер яңа аһәң белән ишетелә сыман...

—Мин мондау-у...

Кеше кадәр кеше табылмагач, әле карангыда күренмәгәчтен дә, билгеле, эзли башлыйсың бит инде. Мин дә шулай эшләдем инде...

—Кая соң син...—дигән булып эзләргә керештем аны, кул белән капшана-капшана.

Ә аның шымы да чыкмый! Әллә юри дәшми бу... Әллә чынлап качкан?

Тукта әле, чын-чынлап аптырашта калдым! Куышны тоташтан айкап чыктым—юк кына бит Ләйсирә! Нәрсә булды бу, жен эшеме әллә?! Тәмам гажәпләндем бу хикмәткә!

Аннары гына Ләйсирә тавыш бирде:

— Исәр... Ятып торамын ич мин...

Ә, менә нәрсәдә икән эш! Мин бит куышны өстән капшыйм икән, минем куллар өстә йөри икән... Ләйсирә исә астарак кала. Шуңа күрә минем кул аңа эләкми, кагылмый икән... Менә хикмәт!

Аңлагачтын үзем дә пырхылдап көлеп җибәрдем! Түзәрлек мени соң шундый мәзәк хәлгә!

Ләйсирә минем авызны капламакчы була:

—Шуның хәтле шаулама инде...

Түр почмакка ук салган икән дә ул минем сырманы, шуңа яны белән яткан икән... Шуңа күрә аның башы да почмакка ук кереп беткән диярлек. Тавышы да ерак кебек ишетелә.

Ипләп кенә мин дә аның янәшәсенә урнашам... Шулай ук ян белән сузылып ятам... Аңа таба карап инде, билгеле... Ә телдә әллә нинди юк-бар сүз шунда:

—Кара әле, безнең куыш эче карангы чагында да матур була ала икән ич!

—Шулай шул... Сезнең куыш зуррак та бугай әле ул...

—Һе... Без үзебез дә өчәү шул! Сезнең шикелле икәү генә түгел!

—Ә аның каруы безнең куышта печән күбрәк, йомшаграк...—Ләйсирә бу сүзләрен елмая биреп әйтте, ахрысы. Аның тавышында шундый ягымлы аһәң ишетелеп алды.

—Ә катырак урында йоклау файдалырак, апаем!—үзебезнең авылдагыча шушындый сүз кыстырып мин аның елмаюын җөпләргә телим. Балаларча әйткән булып аны тагын елмайтасым да килә әзрәк.

Шулай юк-бар сүз байтак кына дәвам итә безнең арада. Әмма монда, бирегә кереп яткач, нишләптер Ләйсирәгә кагылырга да куркам әле. Ничектер, бүтән кешегә әверелгән сыман ул... Үземдә дә әллә нинди бер эчке дулкынлану, кыенсыну, тартыну тоямын. Гүяки тагын кемдер, тагын өченче берәү безгә карап күзәтеп тора. Безне тикшереп, күзәтеп тора. Әнә шул кеше безне куркыта әйтерсең лә, шыкайта ул безне. Без иялэнгән бер кысадан чыгарга рөхсәт бирми әлеге зат.

Сүзебез туктап торган бер арада:

—Син монда туңмыйсыңмы соң?—дигән булып, аз гына аңа кагылып алгандай итәм. Кулым аның биле тирәсенә кагылып китә, шунда аз гына тоткарланып тора—ул моңа бер сүз дә әйтми әйтүен, ләкин озаграк тотарга минем кыюлыгым җитми һәм мин кулымны янадан үземә таба тартып алам.

* * *

Шушы урында тагын бер мәртәбә укудан туктап алам. Ул чагында без нинди оялчан, тыйнак булганбыз икән... Аннары күңелгә мондый уй килеп төшә: бу соң яхшымы, әллә начармы? Әнә бит, хәзер мәктәп яшендә үк кызлар белән егетләрнең интим мөнәсәбәтләре турында өйрәтәләр, секс хакында мәгълүмат бирәләр... Телевизордан да минут саен диярлек шундый күренешләрне күрсәтеп, яшьләрне интим мөнәсәбәткә керергә кызыктырып, кыздырып торалар...

«Ә андый «тәрбия»нең җимешләре нинди соң?»

Нәкъ менә шуңа күрә дә хәзерге яшьләрдә хисси як утә дә саекты түгелме соң инде?! Әнә шуңа күрә бүгенге яшьләр хис һәм тойгы ягыннан үсмәгән килеш—ярлы күңел белән туп-туры «шәрә секс»ка барып керә түгелме соң инде?! Шунлыктан Ходай яраткан ул изге гамәлнең тәме дә, яме дә китеп бара түгелме бүген?!

Ә без менә яшьлекне Идел ярында уздырдык... Һәм бөтен нәрсәдә, бөтен мәсьәләдә ярны, чикне, чаманы белеп дигәндәй...

Хәзер инде әнә ярлар бетеп, югалып бара...

Тукта әле!!! Бу соң нәрсә була инде?!!

Мондый яман галәмәт—кемдер уйлап чыгарган зур афәт—кемгә һәм ни өчен кирәк икән соң?!

Безне туган җирсез—нигезсез һәм тирәксез калдырып, ятим калдырып—Мәскәүдәге кемнәрдер үзләренең астыртын һәм зур сәясәтен үткәрәме икән соң әллә?!! Һәм шул ук вакытта алар, «электр энергиясе» дигән бик үтемле товарны сатып, үзләренең чит ил банкларындагы капиталларын да күбәйтәме??

Ә безнекеләр нигә дәшми икән? Ә без үзебез нигә дәшмибез??

Аh! Идел ярындагы үзебезнең тыйнак мәхәббәтебез әнә нинди тирән катламнарга алып кереп китте.

* * *

Тышта сөйләшкән, шаулашкан тавышлар ишетелә башлый.

—Тегеләр кайтты...—ди Ләйсирә минем колак янында ук пышылдап кына.—Миңа да вакыттыр инде...

—Тукта инде, куышларына кереп китсеннәр.... Аннары чыгарсың.

Шулай итеп шым гына ятабыз. Үзебезнең тын алудан башка һичнинди тавыш юк бездә. Дошман тылына барган разведчиклар диярсең!

Күпмедер яткач тышта җан ияләре сизелми башлады. Ләйсирә дә торып утырды. Ләкин мин аны туктатырга булдым:

—Башта мин башымны тыгып кына карыйм әле, ул-бу кеше юкмы икән?

Шулай итеп аны юк-бар сүздән, гайбәттән сакларга телимен.

Ипләп кенә куыш капкачын ачамын да, тышка күз салам—як-якка карыйм: болай адәм заты күренми анысы... Шуннан соң кире чигенеп кулларым белән генә Ләйсирәне табам, аның кулыннан тотам һәм битенә якын ук килеп:

—Була бугай...—дип пышылдыйм. Бу сүзне әйтүен әйтәм, ләкин үземне ниндидер ризасызлык, канәгатьсезлек корты кимерә. Аны менә хәзер үзебезнең куыштан чыгарып җибәрәсе килми... Әмма шул ук вакытта каршы бер сүз әйтергә дә, кал диеп кыстарга да кыюлык җитми. Андый тәкъдим чамасыз зур әрсезлек, хәтта тупаслык, начарлыктыр кебек тә тоелып китә кайчак. Шуңа күрә сүзсез дә калам. Ике ут уртасында калам.

Ләйсирә башта, аның артыннан мин дә урамга чыгып басам. Ул исә баскан җиреннән китмичә мине көтеп тора. Ян-якны күзәтә... Аннары гына:

—Нинди рәхәт безнең монда!—дип куя.—Гомергә онытa алмаслык төн бит инде бу! Шундый матурлык бит инде бу!

Әйе, төш кебек гүзәл төн иде шул ул төн!

...Аннары инде...

Аннары инде Ләйсирә авылга кайтып китте... Безгә исә печәнчеләр белән бергәләп әле тагын өч атнага якын болында торырга туры килде. Чөнки бер Аръякка чыккансың икән инде—син эшне тәмам ахырга җиткермичә—бөтен чабылган печәнне кибәннәргә куеп бетермичә—кайтып китә алмыйсың! Көзге янгырларга кадәр калмаска тиеш бу эш! Кышын Иделдә боз каткач колхоз тракторлары кипкән хуш исле печәнне малларга ташырга тиеш.

Ә Аръяктан кайтулар үзе бер бәйрәм була инде ул!

Олау-олау булып, арбаларга шактый гына печән төяп, юл буенча

уйнаша-көлешә кайтыла инде ул ай буена яшәп яткан Аръяк болыныннан! Авыл үзе дә нык кына сагындырган була... Рәхәтләнеп, онытылып мунча керүләр китә... Анда кайткач ашау ягы да бераз төрләнеп китә бит инде: авызга кишер-кыяр ише нәрсә дә эләгә башлый... Яшь бәрәңге вакыты да житкән була инде...

Болары анын һәммәсе дә әйбәт—әмма... әмма менә Ләйсирә киткән! Калага киткән инде ул... Кичен клубтан кайтканда алар тирәсендә торучы бер яшүсмер кыз әйтте моны мина.

—Аръяктан кайткачтын озак тормады бугай инде ул монда...—диде әлеге кызый балаларча сузыбрак кына.

Шулай итеп көзгә мин тагын ялгыз гына кердем...

Төрле-төрле мәшәкать тапкан булып, китаплар һәм кинолар, комсомол эшләре белән онытылырга тырышасың тырышуын—ләкин шулай әйбәт кенә йөргәндә Ләйсирә белән икәү Идел ярында яккан учаклар, ул төнге пароходлар искә төшә дә—минем бәгырьләр өзгәләнә инде, малай! Чыдап булырлык түгел! Андый чакларда карангы авыл урамнары буйлап озак-озак йөрисен, су буйларында, Текә яр башларында басып торасын йөрәгенне басырга теләп...

Икенче елны мин дә калага укырга киллем...

Әйе, бирегә укырга диеп килгәч, билгеле, бөтен вакытны китаплар, дәреслекләр, китапханә ала инде. Көнен дә, төнен дә шулар белән мәш киләсең—баш күтәреп дөньяга карарга да жай таба алмыйсын...

Ләкин... Ләкин арада шундый көн дә килеп туа: боларнын һәммәсеннән котылып, барысын да ташлап үзебезнең су буйларына, үзебезнең болыннарга кайтып китәсе килә! Әнә шунда кайтып язын иреккә чыккан яшь колындай чабып, рәхәтләнеп уйнап йөрисе килә! Бер кайгысыз, бер мәшәкатьсез—иректә, бәхетле жан булып!

Андый көнне инде синен күзенә бер генә нәрсә дә күренми, янындагы иптәшеннең бер генә сүзе дә синең жүнләп колагыңа керми! Ул көнне инде синең күнелең, синең жаның бик еракта торып калган газиз авыл белән тоташкан була... Синең күз алдында ямьле су буйлары, андагы куе-куе толымлы өянкеләр, матур-матур тугайлар, әрәмәлекләр тора... Һәм анда иртәләрен-кичләрен сандугачның өздерүләре! Әнә шул гаять дәртле дә һәм бер үк вакытта тирән моңлы да булган кабатланмас аһәң бирегә—ерактагы таш калага ук килеп ишетелә һәм синең таш диварлар арасына килеп кысылган нечкә жаныңны, бәгыреңне һәр дулкыны, һәр яна аһәне белән йөзгә, меңгә телгәли, кискәли!

Андый көннәрне бу калада үз-үзенә урын таба алмый йөдисен.

Кая керер тишек тапмыйсың андый кичләрдә, андый төннәрдә...

Әнә шундый кичләрнең берсендә мин Ләйсирәне эзләп, ул яшәгән тулай торакка барырга булдым.

Октябрь аеның ахырларында гына була торган янгырлы, салкын жилле бер шыксыз кич иде ул... Күрәсең, нәкъ әнә шундый иләмсез һәм кешене эчтән изә, сыта торган көн булганга күрә—чыдый алмаганга күрә—аның янына диеп чыгып киттем бугай инде мин ул көнне үземнең тулай торактан.

Әлләни озак эзләмәдем мин ул яшәгән урамны—күрәсең алдан ук бик яхшылап белешкән, сораштырган булганмындыр инде... Ләкин өстән коеп яңгыр яуганда, агачларны аударырдай булып көзге жил котырынганда—салкын һәм караңгы бер кичтә шәһәр читендәге ят тулай торак ишеген атлап кереп, бусага төбендә үк тукталып калуымны һич тә онытасым юк! Үзебезнекеннән дә усалрак вахтер хатын туктатты мине.

—Кая! Кая барасың!—дип акырды ул миңа урыныннан да тормыйча.—Мөгезсез сыер сыман дәшми-тынмый гына үтеп китмәк кели, ә! Шустрый!

Минем өстәге авылчарак киемнәргә карап, кем икәнемне мең төрле билгедән чамалап алып, шуңа күрә үтә усалланып кычкырды бугай

инде ул хатын. Үз эчендә бик күптән җыелган ачуны чыгарырга җай табылганга сөенә-сөенә җикеренә сыман иде ул.

Ә мин бит әле Ләйсирәнең кайсы бүлмәдә торганын да белмим, ничәнче катта икәнлеген дә әйтә алмыйм. Нинди бүлектә укыганын гына беләм ич мин аның... Бу явыз хатын, мөгаен, мине куып ук чыгарган булыр иде инде—әле ярый шуннан узып баручы бер шәфкатьле кыз табылды. Минем кем янына килүемне шул арада ишетеп алган да:

—Мин аны беләм, хәзер кереп әйтермен!—диде ул ашыга-ашыга икенче катка күтәрелеп барышлый.

Эчкә җан керде, теге ападан да бик үк курыкмыйм кебек хәзер—бирегә тикмәгә килмәгән ич инде мин! Аны алдалап йөрмим ич!

Шул арада тышта котырынган көзге җил дә, салкын яңгыр да онытылды. Хыялымда үзебезнең җәйге болыннар, Идел буйлары яңарды... Менә хәзер без Ләйсирә белән икәүләп шул кадерле, ямьле минутларны искә төшереп утырачакбыз! Теге кичне безнең куышта эчкән сыман тәмләп чәй дә эчәрбез әле, аның белән!

Минем хыял котырынып эшли, күз алдына әллә нинди, берсеннән берсе татлырак күренешләрне китереп бастыра—мин сиңа әйтим! Шулай итеп, юеш киемнән булуым да, ят бер тулай торакның бусага төбендә басып торуым да—болар һәммәсе дә минем исемнән чыга. Мин гүяки янадан үзебезнең якның ямьле болыннарына кайтам... Ләйсирәне дә алып, аның белән бергә кайтамын гүяки!

Каршыма килеп баскан теге кызыйның тавышы мине ушыма китерде.

—Бүлмәләрендә кеше юк аларның!

Ә мин ул әйткән сүзнең мәгънәсен аңлап житмәгән кебек—һаман карап тора бирәм, аның ни әйтергә теләгәнен белергә телим. Кыз моңа бик сәерсенде, аның гаҗәпләнүе йөзенә үк чыкты:

—Ләйсирәне әйтәмен... Бүлмәсендә юк бит ул!

Шулай диде дә, кире йөгереп менеп тә китте теге кыз.

«Миңа нишләргә хәзер?» Аның бит әле сораштырыр кешесе дә юк. Ул катка менеп житеп булса—«кая китте икән?», «белмисезме, кайчан кайтыр икән ул?»—диеп белешеп йөрер идем дә бит... Әмма мине анда хәтле кем үткәрсен соң?!

Тышта салкын көзге яңгыр ява... Монда, ят тулай торак ишегеннән эчкә үтәргә мөмкин түгел... Житмәсә әле, үтеп-сүтеп йөрүчеләр бик күп—алардан кыенсынам, алардан уңайсыз... Вахтер хатын да һаман күзен акайтып карый.

Аптырагач урамга чыгып китәргә мәҗбүр булам. Анда да ишек тирәсендәрәк кенә йөренгәлим инде. Чөнки Ләйсирә менә-менә кайтыр да, мин күрмәгән арада үтеп тә китәр шикелле тоела...

Әнә шулай—ишеккә таба якынлашкан һәркемгә «ул түгелме?»—дип бага-бага ул яңгырлы кичтә мин бик озак таптандым Ләйсирәнен тулай торагы янында.

Тәки көтеп ала алмадым мин аны.

Ул көнне болай да бик начар булган кәефне инде тәмам күтәрәмгә калдырып, әле һаман туктамаган яңгырда янадан бер мәртәбә чылана-чылана, үземнең бүлмәмә кайтып егылдым мин ниһаять... Әллә нинди үкенүле-газаплы бер хис белән.

Әле ярый үзебездә шәпләп чәй эчтек! Югыйсә суык үзәккә үткән иде ул көнне...

Ә аннары инде, бераз эчкә жылы кергәч, кәеф дигән нәрсә дә чүт кенә булса да күтәрелеп киткәндәй иткәч—үзалдыма уйлап ятам: «Ләйсирә быел өченче курска килде бит инде... Шушы гомер эчендә бер жегетсез дә тормас бит инде ул! Авылдан Илсур кайчан килер икән дип кенә утыра алмый ич инде...»

Тагын бераздан үземә үзем каршы төшеп болай дим!

—Бергә укыган классташ буларак күрешергә хакыбыз юкмыни соң

безнен?! Бар ич! ... Шулай икән—ул чагында нигә дип куркып, икеленеп торырга әле?!

Андый икеле-микеле уйлар мине бүтән көннәрне дә ташлап китмәде, «бар!» белән «барма!» дигән сүзләр арасында күңел күп көннәр буена бәрелеп-сугылып йөреде... Талпынды, икегә өзгәләнде һәм үзе дә нык кына талкынды.

Ә бер көнне үзебезнең лекцияләр әзрәк иде, Ләйсирәләр укый торган институт яныннан урап килергә булдым. Янәсе, анда бару белән миңа Ләйсирә очрарга тиеш инде! Әй, ул өмет дигән нәрсәнең беркатлы ышануы диген!

Болак буйлары бик ямьле, бик матур, әлбәттә. Кызлар да бик еш үтә аннан... Әмма үз күңелең көткән зат күренмәгәч дөнья матурлыгы күзгә бик чалынмый икән шул ул! Болак буенда да очрата алмадым мин Ләйсирәне.

Ул арада бу зур калага кыш килде... Мондагы беренче көзнең пычрак, яңгырлы көннәре онытылды. Шәһәрне һәм барча тирә-юньне каплаган ап-ак кар гүяки бу дөньядагы бөтен шикле, икеле-микеле уйларны да аста калдырды. Бар җиһанга ниндидер бер романтик күтәренкелек, сафлык, хәтта ки үзенә бер төрле илһамлы халәт инде... Безнең тулай торак янындагы бушлыкка бу ап-ак кар бигрәк тә күп булып һәм шундый да тигез, саф чиста иркенлек хасил итеп яткан иде ки: төрле як авылларыннан җыйналган менә бу садә күңелле яшь егет-кызларга үз туган якларында, үз авылларында ятып калган керсез-чиста тормышны искә төшерү өчен гүяки махсус шулай эшләгән диярсең күктәге Илаһи Зат.

Чыннан да шулай булгандыр бу!

Әнә шундый яктылык белән балкып торган кичләрне безнең яшь йөрәкләр—авыллар иркенлеген һәм язгы дәрьялар ташкынлыгын үзләре белән бергә алып килгән яшь җаннар—таш диварлар арасындагы кысан бүлмәдә генә утырып тора аламы соң инде алар, йә әйтегез?! Әлбәттә, юк! Әлбәттә, аларга үзләренең яшьлегенә, үз эчләрендәге уй-хыялларның киңлегенә, югарылыгына бәрабәр мәйдан кирәк, яңалык кирәк, дөньяның монарчы таныш булмаган өр-яңа почмакларын күрү, белү кирәк!

Һәм без, чыннан да, үзебезнең күңел тансыклаган урыннарга чабабыз... Әнә анда—шәһәр үзәгендәге Тукай клубында—язучылар, шагыйрьләр белән бик кызыклы очрашулар уздырыла икән... Әнә Камал театры хәзерге яшьләр тормышына багышланган «Эңгер-меңгер» спектаклен чыгарган—бик тә үткен проблема күтәрелә ди анда... Әнә Актерлар Йортында Батулла дигән язучы Шаяннар Тапкырлар Мәҗлесе оештырып җибәргән—аны кыскартып ШТМ гына диеп йөртәләр икән... Бусы бигрәк тә кызык ди, килгән кешеләр залга сыя алмыйлар икән! Әнә атаклы җырчы Илһам Шакиров яшьләр белән әңгәмәләр үткәрә-үткәрә бушлай концертлар куя икән—анысына бигрәк тә эләгергә иде бит инде!

Безнең авылларда торып калган киңлекне, сафлыкны, иркенлекне әнә шушы дөнья алыштырды. Без үзебезгә әнә шул юнәлештә юллар, омтылышлар таптык... Шул дөнья, шул мохит безне үзенә һаман ныграк кызыктыра, тарта, ымсындыра, дәртләндерә барды...

Бер көнне соң гына бүлмәмә кайтып керсәм, бүлмәдәшем Гамир миннән сөенче алмакчы була:

—Анда, аста сиңа дигән бик тә серле бер язу ята...

Ягъни, хатлар бүленеп куела торган тартмаларда дигән сүзе икән инде бу аның. Көне буе йөгереп йөреп байтак кына арылган булса да, ялт кына аска чаптым!

Ап-ак дәфтәр битен бөкләп, эчкә матур итеп язылган мондый сүзләр иде анда: «Илсур! Мин килгән идем дә, син өйдә булмадың... Ләйсирә».

Ул үзенең кыска гына хатын өчпочмаклы итеп төргән, тышына минем исем фамилияне дә куйган... Тартма янына баскан килеш әнә шул бик кыска хатны бер ачып, бер ябып байтак кына тордым мин.

Ничектер, күнелем әле мондагы сүзләрне укып бетермәгән кебек иде... Ничектер, андагы, ул хаттагы мәгънәләр әле минем башыма барып житмәгән шикелле иде... Мин, ни өчендер, анда язылган сүзләрне дә күбрәк һәм эчтәлеклерәк итеп күрәм сыман идем... Ләйсирә дигән исем куеп язылган бу хат минем өчен әллә ниләр, әллә ниләр турында сөйли иде шул. Бу бер исем минем җанда, йөрәктә яшәгән бихисап күп кадерле күренешләрне бер секунд эчендә җанландыра, яктыртып җибәрә иде шул! Күрәсең, ул кичне—беренче катның таш диварына эленгән хатлар тартмасы янында—мин күбрәк әнә шул үз күңелемдәге кайтаваз яктылыкны карап, үткән көннәр матурлыгына сокланып торганмындыр инде...

Әллә кызлардан алынган тәүге хат шулай исерткәнме икән мине ул кичтә? Әле бит мин моңа хәтле бары тик авылдан гына, әнидән генә хат ала идем бит... Менә бусы беренче кызлар хаты булды ич!

Өскә, үзебезнең бүлмәгә менгәч, әлбәттә егетләр сорамый калмый инде.

—Менә хәзер беләбез инде серне!—дип шундук авызын ерды Хәйдәр миңа карап. Бүтәннәре дә миңа текәлделәр.

—Әй, егетләр! Аптырамагыз—минем классташ кыз гына ул!—дидем дә, шуның белән котылдым мин болардан дисәм, Хәйдәр тагын мине ирештереп маташа:

—Хәзер шулай «классташ» диеп аталамыни инде алар?

Ярый, әкрен-әкрен тынды болар шулай да...

Кичен яткач эчтән генә уйлар иркенә биреләм. «Тегe көнне мин килгәнне Ләйсирәгә әйткәннәрдер шул... Шуңа күрә килергә уйлагандыр инде ул... Ә бит мин барганга да байтак гомер үтте бит инде! Нишлисең, дәресләре күптер аның да! Укуы бик кыен дип сөйли иде ич!»

Бераздан күңелгә шундый бер көтелмәгән уй килә дә мине сискәндереп җибәрә: «Кара әле, Ләйсирә белән бер калада яшәп ничәмә ничә ай буена күрешә алма инде, ә! Бу, кала дигәннәре, кара урманнан да зуррак, аңа караганда да адаштыргычрак ахрысы...»

Ә иртән уяну белән тагын җен кебек чаба башлыйсың инде ул! Кичкә хәтле әнә шулай бара. Атна арты атна да уза икән ул әнә шул ашыгулар белән! «Беренче сессия!»—дип тә куркыталар бит әле, ичмасам! Анысы бигрәк тә яман ич әле аның без—авыл малайлары—өчен! Кеше алдында сынатасы, сер бирәсе килми ич инде, үзегез беләсез!

Ә ул «сессия» дигән мәхшәр килеп җиткәчтен кызык иттем әле барысын да! Беренче сессиянең иң тәүге имтиханын философия фәненнән куйганнар иде, көне килеп җитеп имтихан алучының ишек төбенә килеп баскач—группабыздан берәүнең дә иң алдан керәсе килми! Куркабыз чөнки!

—Аллага тапшырдым!—дидем дә, холкымдагы партизанлыкка таянып, кердем дә киттем. Тагын ике егет иярде миңа.

Әллә бәхет эше булды шунда, әллә инде куркудан бик яхшы әзерләнеп ташланылган—тәки тәүге «бишле» миңа эләкте бит! Бу калага килгәч бирелгән беренче имтихандагы беренче бишле иде ул минем! Чыккачтын, әлбәттә, түшәмгә хәтле үк сикерәсең инде! Кемгә килеп кагылырга белмисең ул чагында!

Кыскасы, ул көнне үземнең иң зур шатлыгымны уртаклашырга Ләйсирә янына киттем мин!

Инде энгер төшеп килә, күз алышына башлаган чаклар бу... Шәһәр урамнары иртән яуган кардан балкый, ә минем күңел бу каладагы тәүге җиңүдән нишләргә белми—атлыга, шашына, ярсый, сикерена! Хәтта трамвайга да керәсе килми: ул бик тә акрын барадыр төсле, минем үземнең тизлек хәзер аны әллә кайларда артта калдырып узып китәрлек төсле! Трамвай эчендәге кешеләр дә бик мескен, үтә гади, кырмыска шикелле генә җан ияләре кебек... Ә мин менә иң авыр, иң катлаулы фәннән «бишле» алган кеше! Әле бит бу—авылдан килгән егет шулай—әле бу егет (ягъни мин үзем инде ул) шәһәр мәктәбен тәмамлаган булса нинди башлы

булыр иде бит! Әллә кайларга китәр иде бит ул алай булган булса... Аны бәлки шундук Мәскәү университетына күчергән булырлар иде... Бөтен дөньядан җыелган иң-иң акыллы кешеләр укый торган җиргә!

Бер унса уна бит ул эшләр!

Бу көнне минем бәхеттән Ләйсирә дә өйдә иде. Тулай торак кухнясында ашарга әзерләп йөргән чагы туры килде аның...

Бу хатын-кыз дигән зат аш-су пешереп йөргәндә нишләп бигрәк тә сөйкемле, бигрәк тә матур күренә икән?! Үзенең иң төп шөгылен эшләп йөргәнгә шулаймы? Әллә кухня кызулыгы шулай алсулатамы, безиме аларны? Яисә инде безнең үзебезнең борынга тәмле ризык исе килеп кергәч, дөнья әнә шулай ямьләнеп китәме?

* * *

Баксаң, инде ул хәлләргә утыз ел гомер үткәннән соң, мин яңадан Ләйсирәне күз алдыма китереп, үзалдыма уйланып утырам икән! Һәм, ирексездән диярлек, аны үз өемнең хуҗабикәсе кебегрәк күрәм, имеш. Шуңа күрә мин аңа сокланып та, бер үк вакытта сынабрак-тикшеребрәк тә карыйм шикелле. Ягъни, без көнкүрештә—көн саен бергә яшәсәк ничегрәк булыр иде икән! Безнең даими янәшәлек ничегрәк килеп чыгар иде икән?—дигән сораулар беләнрәк карыйм шикелле мин үземнең бүгенгемнән еракта—утыз еллык вакыт диңгезенең Аръягында калган—Ләйсирәгә...

* * *

... Ул әле мин килгәнне күрми, белми—кухняның ачык ишеге каршысына басып үзен ничек соклана-соклана күзәтүемне дә сизенми әле хәзергә Ләйсирә... Ул әнә ап-ак фонга алсу чәчәк төшерелгән уртача гына зурлыктагы мискәсен газ плитәсенә утыртып куйган да, су краны белән газ плитәсе арасында мәш килеп йөри. Өстендә шулай ук алсу чәчәкләр төшерелгән юка халат аның, ә чәче өскә күтәреп матур итеп өепме, үрепме куелган—бусы да Ләйсирәнең йөзенә-битенә бик килешеп тора, аны тагын да ягымлырак, чибәррәк итә...

Менә бермәлне ул нәрсәдер сизенеп туктап кала һәм ишеккә таба борылып карый... Ә анда авызын ерып мин басып торганны күрә бит инде ул!

—Ой, Илсур!—була аның авызыннан чыккан тәүге сүз.

Икебез генә булгачтын мин дә әллә нәрсә бик кыенсынып тормыйм инде—аның каршысына атлыйм, кухняга ук үтеп керәм. Шулчакны аны бик тә якын итеп кочаклап аласы, нык, каты итеп кочакка кысасы килә! Ләкин мин бит әле өс киеменнән, урамнан гына кергән көе, ә ул көньякның дингез буенда, кайнар комлы пляжда йөри диярсең—пешеп, алсуланып, янып тора! Мин тукталып, үз-үземне тыеп калдым... Бусы да авылча куркаклык, оялчанлык булдымы соң инде аның—кем белсен! Аның каруы Ләйсирәнең кулларын ныгытып, сагынуымны сиздерердәй итеп, ике кулымны берюлы бирел кыстым мин! Һәм әле аларны озак кына үземнән җибәрмичә дә тордым... Шатлыктан, бәхеттән балкый-балкый... Ләйсирәнең якты күзләренә текәлгән килеш!

—Ничек таптың мине? Кем әйтте монда икәнлегемне?

Ләйсирәнең сөенеп тә, гаҗәпләнеп-аптырап та әйткән сүзләре тагын шул булды. Ә мин нәрсә диим инде:

—Бу каладагы иң тәмле аш исен сизеп килдем!—дим.—Безнең урамга хәтле килеп җитте бит инде бу ашның әкәмәт тәмле исе! Шуны исни-исни килдем һәм таптым да, менәтерә!

Ләйсирә әле башта минем шаяртуымны аңламыйчарак тора, миңа аптырабрак карый, ә аннары инде:

—Әй лә! Тел бистәсе!—ди дә, янадан тулган ай сыман балкый, елмая башлый.

—Ну, малай! Бәхетең дә бар икән үзеңнең!—ди тагын бераздан Ләйсирә.—Менә бит: каз ите салып пешергән ашка туры килдең!

Ул арада мин дә сөенечне әйтергә ашыгам:

—Әле имтиханнан кайтыш бит минем...—дим башта, аны азмы-күпме әзерләргә теләп, ләкин ярты юлда туктала алмыйм һәм хәбәремне ахыргача әйтеп тә бетерәм.—Беренче имтиханнан беренче бишле булды бит, малай!

—Менә маладис!—ди Ләйсирә.—Котлы булсын! Зерә дә шәп ич бу! Нәкъ менә синеңчә инде бу!

Анын мактавы минем телне тагын да ныграк чишә, билгеле.

—Әле бит группадан беренче булып та кердем!—дип тә мактанып ташлыйм шунда бер очтан.—«Ни булса булды!»—дидем дә, барып кердем инде... Ярый, белгән билет туры килде инде анысы...

—Һе! Әзерләнеп килгәчтен шулай була инде ул!

Ләйсирә инде бу сүзләрен күпне күргән, күпне белгән кеше сыманрак итеп әйтә... Хәзер инде ул ашына яшел суган салып маташа, шунын белән мәшгуль.

Ә аннары без Ләйсирәнең бүлмәсенә кайтабыз. Анда тагын ике кыз бар. Берсе—Гөлфирә, ә икенчесе Нина исемле икән аларның. Кухняның кайдалыгын Нина өйрәтеп җибәргән иде, шуңа күрә ул безне күргәч тә:

—Әллә табыштыгыз?—дип шаярткан була.

Кыскасы шул: без ул кичне нәкъ авылда гына, нәкъ менә уңган хуҗабикәләрдә генә пешә торган менә дигән аш эчтек! Ләйсирә белән бу калада беренче мәртәбә күрешүне дә, минем кесәгә кергән тәүге «бишле»не дә без әнә шулай итеп билгеләп үттек.

Шуннан соң нишлисең инде—Ләйсирә бераздан мине озата чыкты. Ләкин менә шунда ниндидер бер сәер хәл килеп туды: без анын белән ничектер иркенләп, элеккечә туарылып дигәндәй, үз кешеләрчә сөйләшеп китә алмадык. Әллә Ләйсирәнең дәресләр белән бик тә баш ватып йөрегән чагы булды бу, әллә минем үземнең күнел артык күтәренке булып—аныкы уртада гына торганга күрә (ул чагында шулай тоелды), әллә инде мин сизенмәгән бүтән бер сәбәп бар идеме...

Ул өстенә дә җиңелчәрәк киенгән сыман тоелды, шуңа күрә бераздан мин:

—Син инде трамвайга хәтле үк барып йөрмә! Мин хәзер тиз-тиз генә җилдерәм!—димичә булдыра алмадым.

Ул:

—Тукта, бераз барыйм инде!—дип караган иде, билгеле. Әмма мин аны кызгандым шул ул чагында... Әллә минем әнә шул кызгануымны Ләйсирә үзенчә аңладымы икән? Ашыгу дип, анын яныннан тизрәк китәргә теләү дип... Ә бит күнел түрендә анын белән иркенләп сөйләшеп йөрергә дигән ният бик тә бар иде минем... Бар иде! Бар иде ул матур ният!

* * *

Чыннан да, ул очрашу әле хәзер дә минем күз алдымда тора шул! Бик күп еллар үткән булса да... Мин, дәфтәремнән аерылып, бер мәлгә уйга чумам.

Бу безнең олы каладагы беренче очрашу булды бит инде...

Ә нишләп без көткәнчә, без теләгәнчә, безнең күңелләр омтылганча килеп чыкмады соң ул? Ничектер, бөтенләй икенче кешеләр шикелле сөйләштек без урамга чыккач та... Әллә инде «таш кала ул адәм башларын адаштыра» дигән сүз, чыннан да, дөрес микән?

Ярар, бүлмәсендә чакта иптәш кызлары алдында иркенләп сөйләшү мөмкин түгел иде инде—анысы аңлашыла... Ә урамга чыккач, анда ни-нәрсә тыеп торды соң безне? Нәрсә комачаулады безгә?

Әллә минем үземнең кыюлык җитмәдеме икән ул чагында—анын телен

чишәргә, аны яңадан үзебезнең элеккеге күңел уртаклыгы дигән юлыбызга алып керергә? Уку белән, бик тә авыр дәресләр белән тәмам изаланган, дөньясын оныткан чагы булган ич инде аның ул вакытта...

Әйе, безгә—бөтен ихласлыгы белән укуга чумган авыл балаларына—ул чагында күп нәрсәне онытып торырга туры килде шул... Хәтта дөньяга язлар якынлашуын, язлар килүен дә соңарып кына сиздек бу олы калада. Бер көнне күпер чыкканда трамвай тәрәзәсеннән елгага күз салсам, ни күрим: анда берәм-сәрәм генә бозлар агып ята! Үзләре зур да түгел, калын да түгел—ваканганнар, таркалганнар алар... Көчсезләр, хәлсезләр алар...

Ә бездә... Ә бездә соң язгы ташу, боз китү болай гына буламы соң?!

Котырган үгезләр өере сыман булып, юлларында очраган һәммә нәрсәне сытарлык, изәрлек, юкка чыгарырлык дәһшәтле көч белән киләләр бит ул безнең яктагы язгы бозлар! Алар үкерә-үкерә өскә дә сикерәләр, алагаем зур гәүдәләре кечерәкләренә бәрелеп, аларны тагын да ваклап ташлый, аннары тагын берничә зур боз килеп бәрелешә дә—ул чагында инде бөтен бу мәхшәри агым катып калгандай була, арттагылар туктый алмыйча берсе өстенә берсе менеп китә, шулай итеп бик тиз арада синең күз алдында боз таулары хасил була... Бусы инде боз тыгылу дигән сүз! Киң-киң елгаларда да әнә шулай килеп тыгыла ул боз! Аннары инде ул бозлар өстеннән тегеяк ярга чыгып йөри башлыйсың, шул чакларда аягың таеп китеп, яисә инде янәшә торган бозга хәтле сикерә алмыйча, боз арасындагы суга да килеп-килеп төшәсең...

Тыгылган бозлар өстеннән теге як ярга чыгам дигәндә генә ул бозларның кузгалып киткән вакытлары да була... Ул чагында инде берәр зур бозга кереп урнаша алсаң ярый—үзеңне коткарганчы артык нык борчылмыйча ары таба да агарга була... Ә инде бозың бәләкәйрәк икән—җаның табанга төшә дә куя инде! «Кайчан гына бозлы суга чумармын икән» дип барасың инде бер Ходайга ялвара-ялвара...

Олы калада трамвай тәрәзәсеннән язгы елгага карап бара-бара, мин үзебезнең авылдагы әнә шул ташуларны күз алдына китерә идем.

—Быел мин язгы ташуны, боз китүен күрми калам мыни инде?!!

Күңелемдәге әнә шул ачы үпкә сүзен ул чагында мин хәтта кычкырып ук әйтә идем кебек. Чөнки бик тә, бик тә зур үпкә иде шул ул! Ничектер, әнә шул чагында мин үземне бөтен дөньядан, барча табигатьтән аерып, бер төрле читлеккә ябып куелган җәнлек хәлендә тойдым. Язлар килүен дә, урманнарда бөреләр ачылуын да, карлар эри башлавын да, беренче кошларның өздерә-өздерә сайрарга тотынуын да сизә, тоя, ишетә алмастай бер төрле таш, бетон камера эченә кертеп утыртылганмын мин гүяки! Ләкин әле ул чагында үземнең бу гайре табигый халәтемне мин акыл белән аңлый да, белә дә, төшенә дә алмадым. Миндә ул чагында бары тик томанлы бер тоемлау, сиземләү генә бар иде. Мин әле ул вакытта моның күп кешеләргә кагыла торган бик зур фаҗигага икәнен чамаламый идем.

Әйе, бездән башка гына шаулап бозлар акты...

Бездән башка гына гөлләр чәчәк атты...

* * *

Май ае кергәч, бу сессиядән дә исән-сау гына котылып булса, җәйне ничек үткәрү турында уйлана башладык. Гамир монда бер бакчада каравыл тора иде, ул китмәячәк икән. «Югыйсә, акчалы эш югала бит, малай»—ди. Ә Хәйдәрнең акча кайгысы юк—ул җәй буе рәхәтләнеп авылында ятачак... Ә миңа нәрсә эшләргә? Ничек итеп бераз булса да акча юнәтергә?

Кыскасы, минем бөтен җәем «шабашка»да үтеп китте. Август ахырларында гына авылга кайта алдым. Кулга кергән акчадан иң беренче эш итеп әнигә бүләк юнәттем, үземә дә шактый гына калды... Әмма менә Ләйсирә... Әмма мин кайтканда Ләйсирә авылдан киткән иде инде.

Берәр атна чамасы авылда бәрелеп-сугылып йөрдем дә, мин дә калага китүче пароходка утырдым.

Кала сагындырган икән үзе! Җәй буена эштә булгач, хәзер шәһәр урамнарында иркенләп, ашыкмыйча гына атлау үзе бик зур бәйрәм сыман тоела. Тип-тигез итеп яшь юкәләр утыртылган шома тротуардан баруы, янәшәннән тезелеп киткән биек таш йортларны күзләү, каршыңа килгән кызларга шактый кыю күз салу һәм иң мөһиме... иң мөһиме: кесәндә акча кыштырдаганын сизеп бару, аның «әтәч булып кычкыруын» һәр минутта ишетеп тору—җәй ахырында студент өчен иң зур бәхет әнә шул түгелме соң инде?!

Тагын укулар башланды... Ә озакламый безнең тулай торакта мондый белдерү пәйда булды: «Актлар залында Илһам Шакиров концерты булачак!» Өстәвенә, әле үзе бушлай да икән! Бу хәбәр инде безнең өчен күк капусы ачылу белән бер иде. Бу атаклы җырчыны радиодан гына ишеткәнебез бар бит!

Ләйсирәгә дә барып әйттем. Түзеп буламыни?!

—Әй лә! Монда өч ел яшәп, бер татар концертына да барганым юк бит минем, Илсур!—диде Ләйсирә!.—Син шуңа ышанасыңмы?! Кызлар гел эстрада концертларына гына йөри безнең, мин дә сирәк-мирәк барам. Аларга ияреп.

—Соң, әйдә! Менә шуңа күрә сине чакырам да бит инде!—дим мин моңа тагын да шатланып китеп.

Ләйсирә белән университетның Актлар залына менеп барышыбыз! Ап-ак мәрмәр баскычтан янәшә атлыйбыз... Ә диварда берсеннән берсе бөегрәк затларның портретлары эленгән. Әнә—бөек юлбашчы, әнә—бөек әдип Толстой, әнә—бөек математик Лобачевский! Аларның рәсемнәрен Ләйсирә дә бик игътибар белән карый, туктый-туктый карый...

Шунда мин, исәр кеше шикелле, кычкырып көлеп җибәрәм.

—Ә син беләсеңме соң: монда укыганда Толстойга бер укытучы нуль билгесе куя! «Сиңа берле, икеле әрәм—нуль сиңа!»—ди! Нигәдер бу сүзгә Ләйсирә бер дә көлми, ул миннән бары сорый гына:

—Син моны каян белдең соң? Без бит бөекләрне бөтен яктан да килгән дип беләбез инде...

Шуннан соң мин аңа Мәскәүдән атаклы шагыйрь Евтушенконың килүен, менә шушы Актлар залында үзенең яңа поэмасын укуын, тик минем аңа эләгә алмавым турында сөйлим дә:

—Әмма дә мин барыбер максатыма ирештем—ул икенче көнне Зур Концерт залында укыганда керә алдым!—дим.—Әй, малай, андагы халык, андагы халык! Ә милиция атларга атланып килгән, мин сиңа әйтим! Чит илләрдәге сыман! Әле минем андый милицияне күргән юк иде!

Ләйсирә боларның барысына да бик гаҗәпләнә.

—Нишләптер, без аның килүен ишетми дә калдык...—ди ул гаебе бар кеше сыман.—Шул дәресләр дия-дия, тәмам дөньядан артта калып бетәбез инде без!

Ә залда инде халык хәттин ашкан. Арттагы рәтләрдә генә урын калган. Сәхнәдә зур рояль тора, аның капкачы ниндидер бер илаһи мәгърурлык белән ачып куелган да, безнең—залда утыручыларның кызыксынучан күз карашы әнә шул ачык урынга текәлгән. Гүяки әнә шуннан, нәкъ менә әнә шул урыннан хәзер без моңа кадәр әле беркайчан да, беркайда да ишетмәгән сихри аһәңнәр тын гына, талгын гына агыла башлар... Ул аһәңнәр гүяки Ләйсирә белән безне дә бер тылсымлы агымга салыр, әнә шунын илаһи дулкыннарында тирбәтер, безне бергә килеш әллә кайларга, әллә кайларга алып китәр... Ул аһәңнәр безнең күңелләрне бер-берсенә ныграк якынайтыр, безнең җаннарыбыз арасында әлегә сизелеп торган кыенсыну, тартыну бетәр гүяки, юкка чыгар ул... Әнә шул вакытта, бу сихри музыка дулкынында йөзгәндә без, әйтерсең, бер-беребезне тиреннән тоя, аңлый башларбыз... Бер-беребезне якын күрү, үз күрү дә

гүяки менә шушы—әле без ишетмәгән, ләкин хәзер ишетергә өметләнгән яна, илаһи, тылсымлы музыка тәэсирендә булачак, әйтерсең!

Ләкин без көткәнчә булмады, сәхнәгә кызу-кызу адымнар белән кара костюм һәм галстук, ак күлмәк кигән уртача гына буйлы бер абый чыгып басты. Чыгып басты, әмма үзе әлегә дәшми—иплэп кенә, тын гына залны күзәтә, барлый... Зал та тып-тын диярлек. Бары тик кызларның иреннәре генә, ишетелер-ишетелмәслек итеп:

—Үзе...—дип куя.—Үзе...

Менә шулай итеп берәр минут чамасы тын гына торды да, җырлап та җибәрде бу абый.

Кара ла гынай урман...
Карангы төн...

Аһән, аваз, моң тантана итәргә тотынды залда! Ә без тын да алырга куркабыз, белмичәрәк тын алсак, бу җырчыга бер-бер комачаулык тудырырбыз шикелле. Аңа җыруын сузарга кыенлык ясарбыз сыман...

Бу аһән шуның кадәр хисле, шуның кадәр дә мәгънәле һәм шуның кадәр дә кинаяле, тирән фикерле... Менә хәзер, бу концертта булуыма күп еллар үткәннән соң, мин җырчының кыюлыгына—ул чагында без яшьләргә нинди зур фикер әйтүенә сокланам!

...Ә аннары ул безгә элеккеге шәкертләр җыры «Беренче сәлә»не өйрәтергә тотынды. Әйе, ул көнне безнең сәхнәдә кара такта да бар иде. Аяклы итеп эшләнгән кара такта. Әнә шул тактага акбур белән яза-яза, сүзләрен дә хәтердә калдырырга куша-куша сөйләде дә, җырлады да безгә җырчы абый. Ә сүзләре аның мондый иде:

Уян инде,
Уян инде!
Уяныгга вакыт килде!

Менә бу сүзләрне без ул көнне бөек җырчы белән бергә җырладык—бер тын белән, бер йөрәк булып, җанның бер үк талпынышы белән!

Аһ, ул кичә... Аһ, ул кичнең гүзәллеге! Минем янда утырган Ләйсирәнең җыр моңына бирелеп ничек рухланып, җанланып алуы!

—Авылда без синең белән Чайковский кичәсен үткәргән идек бит әле... Пластинкалар тыңлаган идек... Нигәдер шул кич искә төште минем...—диде Ләйсирә чыгып барган чагында.—Авылны, әниләрне искә төшереп утырдым тагын... Аларны сагынуым бигрәк тә көчәеп китте бит әле! Үзебезнең авыл урамыннан ашыкмыйча гына атлап узасы килеп китте... Һәр өйне, һәрбер талны-тирәкне күздән кичерә-кичерә—сыйпый-сыйпый, иркәли-иркәли... Алар безгә бик кадерле, бик кирәк икән бит!

Ә урамда инде карангы төшеп, октябрь ахырлары торса да—аяк асты коры, һавасы да бик үк суык түгел. Шуңа күрә җәяү генә кайтырга уйладык без.

—Монда укырга килмәгән булсам, шушы бөек җырчыны күрми үләсе икәнмен, тәки!—дип башладым сүземне.—Менә бу җырчы, ә!

Шунда мавыгып китеп Ләйсирәнең кулыннан да тотып алдым әле:

—Шулай бит?! Сина да бик ошады ич!

—Әле ярый син чакырдың!—ди минем сүземә каршы Ләйсирә, барган җиреннән үк тукталып калып һәм шулай күземә караган килеш болай да әйтеп куя:—Тагын бүтән концертларга да чакырырсыңмы икән мине, Илсур?

Бу сүзләрнең бөтен мәгънәсе шундук минем башыма барып җитә—«Ләйсирә очрашкалап йөрергә тели, ахрысы...» дигән уй күңелдән йөгереп уза, ләкин шунда ук, шул ук мизгелдә бер өер шөпшә дә кузгала һәм мин аларын тел белән әйтергә карар кылам:

—Әй, синең вакытың юк ла!—дим үзебезнең авылдагыча шаян

битарафрак тавыш чыгарырга тырышып. Ә үзем аны житәкләгән көе әкрен генә урыннан кузгалам.

Ләйсирә аз гына дәшми тора да:

—Әй лә, гел шулай булды шул...—ди.—Дәресне бик күп, артык күп бирәләр бит, Илсур!.. Ә минем кешедән калышасы килми. Әни дә һәр хатында «йөзгә кызыллык китермә, кара аны!» диеп кенә тора! Аннары, үзең беләсең, без синең белән авыл баласы булгач, кыенрак туры килә ич... Безнең кызлар бигрәк тә көләргә генә тора! Күбесе шәһәрнеке бит аларның! Яшьтән үк, кечкенәдән үк һәммәсен күреп, белеп үскән алар!

Ә мин аңа шактый кызып ук каршы төшәм:

—Без синең белән, барыбер алардан көчлерәк!—димен.—Әйе, бәлки аларның башында информация дигән нәрсә күбрәктер, бәлки аларның сүз байлыклары да безнекеннән мулрактыр... Ләкин алар, барыбер безнең заман уйлап чыгарган робот шикелле генә тоелалар. Алар, чыннан да, әнә шул робот шикелле! Ни өчен дисеңме? Чөнки... Чөнки алар менә бу тормышның, чын яшәүнең, зур тормышның нигезен—табигатьне белмиләр! Алар чын табигый яшәүнең ни икәнен тоймыйлар, моны белмиләр. Алар табигый көч белән, аның бик тә нечкә импульслары белән кечкенәдән үк ялганып, тоташып үсмәгәннәр. Табигый импульслар арасында яшәмәгән алар!

—Син нәрсәне әйтәсең соң «табигый импульслар» дип?

—Без бәләкәйдән тәпи баскан ямь-яшел чирәмле жир ул; әнә шул жирдән адәм баласына килә торган шифалы көч, сихәт ул; үләннәр һәм агачлар арасында йөрегәндә алардан шулай ук безгә күчә торган күзгә күренмәгән шифалы агым ул (моны хәзерге галимнәр «фитонцит» диләр). Без бәләкәй вакытта ук идәндә кәжә, сарык бәрәннәре белән бер булып әүмәкләшеп йөрибез бит әле—менә шул вакытта ук безгә тәэсир итүче биокыр, биохаләт ул. Әз-мәз әти-әни кул арасына керә башлагач түтәлләр утап, бакчалар казып маташкан булабыз ич әле—менә шул чагында безнең тәнебез, безнең организмыбыз үзләштергән иң төп чыганак, эчке ныклык, эчке бәлзәм ул... Һәм, гомумән, авыл тормышы ул—иң чын жир тормышы! Анда бөтен нәрсә, һәр жан иясе кешене, адәм баласын биологик һәм физик яктан да, әхлакый һәм рухи яктан да ныгытырга булыша!—дип уйлыйм мин... Шуңа күрә шәһәр баласы алдында үземне бер дә мескен дип саныйсым килми!

—Кара әле! Син безнең авылдан чыккан философ икән бит, Илсур! Мин сине белми генә йөргән икәнмен...—Ләйсирәнең бу сүзләрен чынга алыргамы, әллә уен гынамы дип кайтканда ул тагын болай дип өстәп куймасынмы миңа каршы:

—Тик менә бүлмәдә сөйләшеп утырганда, алар тегe яки бу турыда әңгәмә корган чагында, «мин—авылныкы, мин сездән шәбрәк!»—диеп утырып булмый бит. Ул чагында үзең белгән кадәр әңгәмәгә катнашырга, кеше арасында үзеңнең барлыгыңны расларга, күрсәтергә дә кирәк ич әле!

Бу хакта үземнең аерым уйлаган юк иде югын, ләкин күңел сизенүе буенчарак чамалап, Ләйсирәгә җавапны тиз таптым:

—Беләсеңме, нәрсә: адәм баласы барыбер бөтен нәрсәне дә белеп бетерә алмый! Бөтен информацияне башына, хәтеренә сеңдерү аның көченнән килми! Һәм кеше моңа омтылмаска да тиеш! Ни өчен, дисеңме?! Чөнки моның өчен роботлар бар! Бу—аларның вазифасы! Аларның эше бу! Ә адәм баласының чын кыйммәте, иң хәзинәсе—күңел матурлыгында, жан яшәвенең нечкә һәм сизгер булуында, анда тойгыларның гүзәл һәм якты булуында, кеше күңеленең бу фани дөньяны һәм рухи яшәешне мөмкин хәтле киңрәк, тирәнрәк, тулырак итеп колачлый алуында! Кеше күңеленең менә бу дөньяны бар катлаулылыгында һәм бөтенлегендә—аны тулы бербөтен итеп—тоя алуында!

«Бик күпкә китте, ахрысы...»—диебрәк уйлап шул урында туктадым. Ә Ләйсирә дәшми генә бара бирә...

—Артык күңелсез нәрсәләргә кереп киттем бугай...—дим бераздан акланган төсле итеп.

—Әй лә, ярый инде...—ди Ләйсирә артык бик исе китмәгән төсле генә.—Ике студент тагын нәрсә турында сөйләшсен соң инде!.. Реферат та, доклад бит инде аның бар белгәне...

Аның бу сүзләрен шаяртуга таба борырга теләп:

—Кара әле, чыннан да шулай шул! Мин үземне философия түгәрәгендә итеп уйлап кайтам икән ич әле... Анда кичә сөйләшкән сүзләрне дәвам итәм икән ич мин... Бөтенләй дә онытылып киткәнмен бит!

—Ә син ул түгәрәккә йөрисеңмени?

Мина кыен булып китә. Ничектер, мактану шикеллерәк килеп чыга түгелме соң? Шуңа күрә тавышны тыя төшебрәк кенә:

—Йөргән булам шунда...—дигән булам.—Аны бит минем адаш абый алып бара: татарның беренче философы! Илсур Габдрахманович!

—Вакыт таба алгач ярый инде...—ди Ләйсирә.—Ә мин менә аның ишегә һич кенә дә вакыт житкерә алмыйм! Аптыраган инде...—Аның тавышы ничектер бик күңелсез төс ала.

—Йә, ярый!—Әйдә, уку турында онытып торыйк әле!—дим дә күңелдән генә бүтән күңеллерәк тема эзләргә тотынам. Шундук табып та алам:

—Алдагы жәйдә дә синең белән күрешеп булмасмы икән инде...

Бу сүзне әйткәч, кулыннан тотып Ләйсирәне туктатам. Аның йөзенә текәлеп карап торамын. Ә ул моңарчы килгән тыныч ягымлылыгын югалтмыйча гына болай ди:

—Быел безнең практика була бит! Балалар белән эшли башларга тиешбез! Мәктәпкә жибәрерләр микән, лагерьга микән?

—Жәен... ял вакытында... ничек инде мәктәпкә?—диеп аптырыйм мин.

—Нигә, анда жәй көне лагерьлар эшли...—дип аңлата мина Ләйсирә тыныч кына.

—Тагын сине күрүләр насыйп булмас микәнни?—димен авыр сулап.—Авылга кайтсам тагын берүзем тилмереп йөрим инде алайса...

—Нигә, анда бит әле Тәлгатьләр, Фәйзрахманнар бар ич!

Безнең классташларны әйтә Ләйсирә, шуларны искә ала...

—Алар белән бик артык күңелле түгел шул...—дим мин аңа яшерепнитеп тормыйча гына.

Ләйсирә шундук мина жавабын да таба:

—Әһә, үзең әле яңа гына авылны, андагы яшәүне мактап кайткан идең түгелме соң?

* * *

Карале, ул чагында Ләйсирә мине әнә ничек оста эләктергән бит, әй! Чыннан да, мин үзем башта авылны, авылча яшәүне мактап йөрдем дә, аннары үзем үк аннан гомерлеккә чыгып сыздым түгелме соң?! Әле хәзер дә, шәһәр жирендә яшәп яткан көенчә, һаман авылны мактыйсың... Ә үзең шәһәрдә торасың—асфальт урамнардан гына эшкә барасың, краннан су агызып кына «мунча» керәсең... Читтән караганда менә болар ничек күренә икән соң?

Дәфтәрдән аерылып, тагын бүгенге мәсьәләләргә кереп кителә. «Бер мин генә түгел бит, Ләйсирә генә дә түгел—бик күпләр китә ич авылдан»,—дип уйлыйм үземне бераз булса да тынычландырырга теләп.

Һәм шул сүзләр белән бергә үк диярлек авылыбыздан иң башта күченеп китеп, яңа төбәктә нигез корган күршеләр күз алдына килә... Әйе, байтагы аяныч язмышка тарыды шул аларның—бик тә аяныч язмышка...

Менә минем кордашым, күршем Миңнәхмәт... Тракторы белән урманга утынга барган жирдә аны агач басып үтерде...

Менә сабакташым Рафаил... Бик тә уңган, сүз тыңлаучан, ярдәмчел зат

иде ул... Күрше авылда электр баганасына менгән җирдә ток сугып үтерде бит бахырны! Шунда, багана башында, кычкырыпплар үлгән диделәр аны...

Менә Зиннур абый... Яңа нигездә тормышын матур корды ул коруын... Һәрхәлдә читтән караганда шулайрак тоелган иде... Әмма, күрәсең, безнең маңгай күзенә күренми торган ниндидер бер эчке тамыры өзелгән булгандыр инде аның—үз теләге белән бу дөньядан китеп барды ул...

Гәрәй абый да яңа нигездә тамыр җибәрә алмады бугай—шулай ук якты дөнья белән хушлашты... Үз теләге белән...

Уйлый китсәң, әле андыйлар тагын бар бит...

Әмма иң кызганычы шул: менә бу фаҗигаләрнең барысына да, һәммәсенә дә кучену сәбәпче булгандыр кебек тоела миңа... Кучену—туган-үскән туфракка бәйләнгән нечкә, әмма иң мөһим тамыр өзелү!

Хәзерге адәм баласы үзен җиргә бәйләгән әнә шул тамырның кадерен, аның яшәеш өчен мөһимлеген ныклап аңлап бетерә алмый, ахрысы... Әле һаман үзен җиргә, туфракка бәйләгән тамырларын—ныклык һәм тотрыклылык тамырларын—өзә бара ул. Ахмакларча!

... Һәм мин, үземне дә туган як, туган туфрак, Идел яры белән бәйләгән нечкә генә җепләрнең тәмам өзелүеннән курыккандай, әнә шуннан сагайган шикелле—ашыга-ашыга яңадан көндәлегемә ябышам: утыз еллык арадан ымсындырып, кызыктырып яткан яшьлегемә ашыгам... Идел ярына—Ләйсирә янына!

* * *

... Ә бер көнне кичен дәрестән кайтып, бүлмәбез ишеген ачып керим дисәм—анда, әчтә Ләйсирә утыра! Төш күрәм дип торам!

—Исәнмесез...—дигән буламын инде юри генә, авызны ера-ера... Чит кеше бүлмәсенә кергән сымаграк иттереп.

Гамир аңа китап биргән дә, шуны укып утырган икән. Мине күрү белән китап шундук ябылды билгеле, әмма кулында калды.

—Кич белән әллә кайларда йөрисен икән син!—ди Ләйсирә миңа.—Авылга кайткач, әниеңә әйтми булмас әле! Тетмәңне тетсен бер бик шәпләп! «Классташ кыз көтеп утырадыр» диеп уйлау да юк, ичмасам...

Мин өстән сала-сала гына булса да Ләйсирәгә карап елмаерга тырышам, үземчә шулай сүзсез генә акланамын инде, янәсе...

—Алай дисән, хәзер тиз генә барып, түгәрәк житәкчебез Илсур Гадрахмановичтан белешмә алып кайтам мин! «Сәгать 8 гә хәтле фәлсәфә түгәрәгендә булды» дигән язуны бирер әле, нигә бирмәсен... Дөресе шулай ич аның! Авылда әнигә дә күрсәтермен шунда...—дигән булам.

Гамир чәй куйган булган икән, өчәү бергә көлә-көлә мәҗлес корып җибәрдек, мин сиңа әйтим! Табыныбыз студентларчарак инде анысы, әллә ни мактанырлык түгел... Ләкин алда куе гына чәй торгач, салырга шикәре дә табылгач, маргарин белән кумәч тә килеп чыккач—тагын ни кирәк инде яшь чагында! Иң мөһиме безгә күңелле, безгә рәхәт... Өчәү бергә булгач, ничектер, сөйләшергә дә җиңелрәк сыман. Һәрхәлдә миңа шулай тоела!

Озата чыккач Ләйсирә үзенең килү сәбәбен дә әйтте.

—Беркөнне безнең тулай торакка килеп билет саттылар бит әле... Шунда кеше ала дип мин дә икене алган идем. Аннары үкендем дә инде әзрәк—һаман шул дәресләр теңкәгә тия бит...

«Сүнгән йолдызлар»га иде Ләйсирәнең билеты...

Әйе, бардык без бу спектакльгә... Ә аның—ул кичнең—хатирәсе булып күңелдә үзәк өзгеч моңга ия шундый бер җыру калды:

Каз канатларын санадым
Тезелеп кагынганда.

Инде кемнәргә карармын
Өзелеп сагынганда...

Ә аннан соң...

Ә аннан соң Ләйсирәне кая да булса чакыру, алып бару—минем өстә иде бит инде. Хәзер инде мин аны бирәр жиргә алып барырга тиеш идем бит! Ләкин, үч иткән шикелле, нәкъ әнә шул чагында мин муеннан эшкә чумдым: философия түгәрәгендә доклад та ясыйсы бар, зачетларга да әзерләнергә кирәк, стена газетасын да чыгару минем өстә...

Әмма, ничек кенә мәшгуль булсам да, Ләйсирә һич кенә дә истән чыкмый. Күрешәсе килә, сөйләшеп йөрисе килә анын белән!

Һәм бер кичне бүлмәдә үзем генә калгач, кинәт кенә күнелсезләнеп киттем дә—кузгалдым мин анын янына! Ә барганда зур-зур хыяллар белән, әллә нинди матур ниятләр корып атлыйм билгеле: имеш менә без Ләйсирә белән киногa чыгып китәбез, имеш без анда кулга-кулны тотынып, карангы залда пышылдаша-пышылдаша (кемнәрнендер кинода шулай утыруларына кайчандыр бик тә кызыгып калган булганмын инде, күрәсен!) утырабыз.

—Өйдә юк шул ул!

Ул кичне мин корган бөтен хыялларны Ләйсирәнең бүлмәдәше Нина әйткән әнә шул кискен сүзләр бер секундта жимерде дә ташлады! Чәлпәрәмә китерде!

«Менә кайтыр, менә кайтыр...»—дия-дия байтак киләп сардым әле мин Ләйсирәнен тулай торагы тирәсендә... Ә дөресрәге, тыштан гына аларның тәрәзәсенә карап. Ул кичне ин нурлы, ин якты тоелган тәрәзәгә багып, хәтта күнелдә шундый юллар да туган иде әле:

Нур балкыган синен тәрәзән—
Минем өчен үзе бер кояш!

Әмма безгә күрешү ул кичне дә насыйп булмады.

Шулай итеп көннәр үтте...

Көннәр генә түгел—атналар, хәтта айлар да уза бирде. Ә мин исә һаман да Ләйсирә белән очраша алмадым... Бер калада яшәп!

Ә... әйе, тагын бер кичне мин анын язуын алдым әле... Ул аны безнең тулай торакнын иң аскы катындагы хәрефләп бүлеп куелган тартмада калдырган иде. «Хәлләрен ничек? Син исән-саумы?» дигән шикеллерәк язу иде ул... Икенче көнне үк булмаса да, баруын бардым мин Ләйсирә яшәгән тулай торакка, әмма хәерчегә жил каршы дигәндәй—ул шушы калада үз өйләре белән торучы дус кызына киткән булып чыкты. «Кайтып йөремәс инде ул бүген...» диделәр бүлмәдәш кызлары.

Бу кичтән соң тагын күпмедер вакыт узды...

Мин һаман үземчә—иртәдән кичкә хәтле үз уй-ниятләремне үтим дип—чаба бирдем, жан-фәрман тырыша бирдем... Ничектер, аскетларчарак яшәү иде инде бу, билгеле. Моны мин акылым белән сизә, анлый идем. Ләкин бүтән егетләрдән дә еш кына ишетелгәли торган бер сүз—«баштагы өч курс бик кыен була инде ул» дигән сүз—мина борчылмаска да куша иде сыман. Синең бәхетең әле алда, ди иде шикелле...

Мин әнә шулай үз-үземне тынычландырып йөргәндә Ләйсирә һич уйламаган жирдә, аудиториядән чыгышлый, тотып алды мине бер көнне.

—Әйдә әле, синең белән кинәшәсе бар иде!—дип кулымнан ук житәкләде. Әле ярый, соңгы лекция иде... Әллә инде Ләйсирә юри әнә шул соңгы лекцияне көтеп алган, кем белә...

Мина бик кызык булып китте. Уйга да калдым. «Ләйсирәгә мин нинди мәсьәләдә кинәшче була алам микән соң?»

Атлыйбыз шулай урам буйлап... Ләйсирә «кинәш» диеп искәртеп куйгач минем башка бүтән уй да керми инде хәзер. «Нәрсә хакында икән?»—диеп барам.

Менә бер бәләкәй генә бакча янына да килеп життек.

—Әйдә шушында кереп сөйләшик әле...—ди Ләйсирә.

—Әйдә...—димен мин дә, ничектер бер серле, ашыкмас көйгә көйләнеп житеп. Күңелемне бер житди сүзгә әзерли-әзерли...

Нечкә генә каеннар монда. Тагын берничә тәбәнәк юкә дә бар. Шулар арасыннан тар гына бер сукмак үтә... Асфальтланган, әлбәттә!

Бакча эченә кереп бераз гына алга атлыйбыз да, туктап калабыз... Дөресрәге, алдан атлаган Ләйсирә туктый. Ә мин аннан ике-өч адым читтәрәк...

—Кара әле, шушы бәләкәй генә бакчага кош оясы да ясап элгәннәр!—дип сүз башламакчы гына идем, Ләйсирә гүя моны бөтенләй ишетмәде дә, ул үзенекен алып китте.

—Минем нинди киңәш сораганны белсәң—егылып китәсең инде син хәзер, Илсур!

—Сон, егылсам, менә эскәмия ерак түгел ич!—дим мин аңа каршы, елмаерга тырышкан булып... Ләйсирә дә үзен шат тотарга тырыша сыман, әмма ни өчендер килеп кенә чыкмый сыман бу анын...

—Миңа димче килде бит әле, Илсур...—ди Ләйсирә бераздан.

«Тукта, нәрсә ди соң әле бу?» Ләйсирә әйткән сүз һич кенә дә барып житми башыма. «Нәрсә дигән сүз соң әле ул «димче»?» Минем дәресләр белән, философия белән тулган башыма бу ят сүз һич кенә дә керми бит. Мин аны аңлый алмыйм бит!

Шулай шактый гомер узды, ахрысы... Аптырагач, Ләйсирә сорап куйды:

—Син минем ни әйткәнне ишеттенме соң?!

Нишлим, дөресен әйттем инде:

—Ишетүен ишеттем дә... Менә аңлап кына житә алмыйм...

Шулай бит инде ул: хатын-кыз, гадәттә, турыга яручанрак була.

—Кияүгә сорарга килгәннәр, дим мин!

Монысын ишеткәч, чыннан да, егылып китә яздым мин ул чакны!

—Кемне? Синеме?!—дидем кычкырып ук диярлек.

Әнә шунда Ләйсирә дә көлеп жибәрде:

—Сон, миңа килгәч—минедер инде!

Әйе, әйе—ул көлә иде... Ул шат иде кебек... Һәрхәлдә ул чагында аның көлүен мин шулай кабул иттем, шулай аңладым!

Ә мин исә ушсыз идем. Шок хәлендә идем! «Ничек инде алай?!» дип баш вата идем кебек эчтән. «Ничек инде шулай була ала?!»

Тагын күпмедер вакыт узгач сорыйсы иттем:

—Кем инде ул димче?..

Ләйсирә монысына кискен генә җавап бирде:

—Әй лә!! Анысы нигә инде аның!!!

Дөрес сорамаганмын икән шул.

—Кемнән дип сорамакчы идем...

—Ә-ә... Аны әйтәсең икән... Әнә, безнең авылга Мәскәүдән бер абый кайтып йөри иде бит әле... Институтта укыта икән ул!

Ни өчендер Ләйсирәгә ачу килеп китте. Теге адәмнең Мәскәүдә яшәве, анда укытучы булуы—Ләйсирәне кызыктыра сыман иде. Тавышында шундый нәрсә сизелеп киткәндәй булды... Ләкин мине башта бүтән әйбер кызыксындырды әле.

—Ул сине каян күргән соң?

—Сон... Җәйләрен авылга кайткалап йөрде бит инде ул...

—Син дә аны күргән идеңме?

—Бер-ике мәртәбә, шунда...

—Кайда инде ул?

—Әй лә! Киногa чыккач шунда...

«Аңлашылды...—димен эчтән генә.—Димәк, теге адәм Ләйсирәне озата кайткан да булырга мөмкин бит әле! Бик мөмкин!» Ләкин минем бу хакта Ләйсирәнең үзенә әйтәсем килми. Мине хәзер үпкә, ачу хисе

биләп ала. Көчле ризасызлык тойгысы тәмам били мине! «Нигә болай?!» дигән ачу кайный миндә!

Ләйсирә минем нинди хәлдә калганны сиздеме, юкмы—әллә инде сизеп тә сизмәмешкә салышты? Озак та үтми сорыйсы итте:

—Нишлим микән соң, Илсур?

Ә миндә үпкә белән ачу кайный бит инде! Әллә каян искә төшкән китап сүзләре белән җавап биргән булам:

—Соң, йөрәккә әмер биреп булмый инде! Үз күнеленә карыйсың!

Ләйсирә аз гына көттереп:

—Анысы шулай инде...—ди... Һәм тынып кала. Нәрсәгәдер боеккан да кебек булып китә... Ә мин исә эчтән генә фикер йөртәм: «Менә син «аны күрә алмыйм»... диеп борчылып йөре авылда! Ә аның озатып куючылары булган икән ич! Ә син йоклап йөргән инде... Йоклап йөргән!»

Бер-беребезгә бер сүз дә әйтми генә кузгалып китәбез...

Һәм инде бераздан, сөйләшер сүзебез беткән сыман, килеп туктаган трамвайга кереп утырабыз. Кала урамнары буйлап дөбер-шатыр чабучы «тимер атка» атланабыз без! Ямьле көннәр, матур кичләр бүләк иткән авыл инде монда тәмам хәтердән чыга... Тәмам онытыла ул авыл биргән бәхетләр!

Шулай итеп бу «тимер ат» безнең тукталышка килеп житте. Ләйсирә белән корырак кына саубуллашып, мин аннан төшеп калдым...

Һәм шуннан соң... Һәм шуннан соң инде мин Ләйсирәне күрә дә алмадым... Безнең юллар аерылды әнә шул көннән соң. Теге хәбәр колакка килеп кагылганнан соң!

Ләкин әле Ләйсирәнең бер хаты булды. Мин аны иң кадерле истәлегем итеп көндәлегемә ябыштырып куйганмын.

Менә хәзер—ул хатны алып укуыма ничәмә-ничә еллар узганнан соң да—аның һәр сүзе, һәр җөмләсе минем күз алдымда тора. Әнә шулай, мәктәпнең тәүге сыйныфына йөри башлагач ятланган беренче шигырьләр озакка, бик озакка хәтергә сеңеп кала бит әле: син ул әсәрне еллар үткәчтен дә кабатлый-кабатлый йөрисең, ул шигырьләр сиңа балачагыңның, яшүсмер вакытыңның иң саф омтылышларын, иң югары хыялларын искә төшерә, синең еллар узу сәбәпле, күп авырлыкларга очрау нәтиҗәсендә алҗый, ара, таушала башлаган канатларыңны ныгытып җибәргәндәй була. Синең азга гына булса да кәефеңне күтәреп җибәрә, күңел офыкларыңны киңәйтә, яши-яши югалта башлаган юлларыңны янадан да шәйләп алырга, искә төшерергә мөмкинлек бирә ул хәтердә калган тәүге шигырьләр... Чөнки алар синең үзеңнең дә беренче талпынышларыңа тәңгәл, шуларга аваздаш була... Еллар узгач сиңа янадан әнә шул матурлыкны искә төшерә торган була алар!

Ләйсирәнең ул хаты минем өчен әнә шундый бер гүзәл шигырь шикелле. Менә ул хат.

«Илсур!

Үзеңнең әллә ничә еллар буе белгән кешеңнән, үзеңнең бер сыйныфта утырып укыган дустыңнан шушындый хат алу бәлки сине бик гаҗәпләндерер дә...—дип, аз гына акланган төслерәк башлана иде ул хат.—Ләкин укый-укый синең бу гаҗәпләнүең бетәр дип уйлыйм... Минем ни өчен мондый адымга баруымны да аңларсың, һәм дөрес итеп аңларсың дип ышанам.

Менә мин хәзер үзем төн уртасында сиңа хат язып утырам, ә үземнән күз алдына синең белән булган соңгы очрашу тора... Нигә соң син ул көнне шуның кадәр... (нәрсә диеп кенә әйтим икән инде, Раббым, синең ул көнге халәтеңне ялгышмыйча, ничек итеп кенә, нинди сүз белән генә белдерим икән?!) Шуның кадәр дә салкын, битараф булдың? Шундый зур, шундый мөһим адым атларга җыенган классташыңның чын хәлен белергә, аңларга тырышу—аз гына күбрәк сөйләшүең, аның күңеле булсын өчен генә булса да теге яки бу сораулар бирүең кирәк иде бит инде ичмасам!

Ә син... Ә син гүя бөтенләй бу җир, бу тормыш кешесе түгел идең ул көнне! Әйе, әйе—нәкъ әнә шундый салкын һәм битараф, җансыз һәм усал кеше

идең син ул кичне! Үзем сораган ихлас киңәшкә син әйткән боздай салкын сүзләрне ишеткәч минем бөтенләй каным катып киткәндәй булды, бөтен тәнемә котып салкынлыгы иңде!

Ә бит... Ә бит ул көнне мин синнән бүтәнрәк сүз ишетермен дип килгән идем! Үземнең моңарчы булган хыялларыма, күңел омтылышларыма ятышлырак, мин теләгәнчәрәк җавап көткән идем мин синнән...

Ә син... Ә син беренче күргән кешегә әйткән сыман, салкын гына итеп кистең дә куйдың! Икебезне ике якка аердың да куйдың бер сүзең белән ул көнне!

Бәлки «син үзең гаепле!»—диярсең.—«Инде тормышта үзенең ныклы урыны булган, акыл утырткан кешегә кияүгә чыгарга үзеңнең теләгең бар иде ич!» диярсең. Ләкин бу алай түгел, Илсур! Һич тә алай түгел!

Әйе, ул мине җәй көне авылда бер-ике мәртәбә озатып куйды... Ул чагында без аның белән җүнләп әллә ни сөйләшмәдек тә инде. Ул миннән укулар турында сорашты, институттагы укытучылар шикелле акыллы гына киңәшләр бирде, укып бетергәч эшкә кая җибәрәчәкләрен дә сорашты бугай җайлап кына...

Ләкин шуннан нәрсә соң? Әнә шул бер-ике сөйләшү генә бөтен язмышны, тулаем кеше гомерен хәл итә аламыни соң?!

Миңа, беләсеңме, ничек тоела, Илсур: әнә шул соңгы көндәге салкынлыгың белән син минем язмышны гына түгел, ә үзеңнең язмышыңны да үзгәрттең сыман... Нindидер, икебез өчен дә үтә кадерле булган бер яшьлек тамырыбызны, уртак тамырыбызны кисеп аттың кебек син ул көнне! Һәм иманым камил: син моны белеп тә бетермичә, ахыргача аңлап та җитмичә эшләдең... Бәлки ашыгычлык беләндер? Ләкин монысын мин ышанып әйтә алмыйм... Монда, күрәсең, «тормыш тәҗрибәсе җитенкерәмәү» дигән сүз дөресрәк буладыр. Болары өчен «бу хәзер миңа акыл өйрәтергә кереште» дип уйлама зинһар. Сиңа эчемдә кайнаган бөтен нәрсәне менә хәзер түгеп, чыгарып каласым килә. Бүтән мондый җай чыкмаячагын да беләм...

Аннары...

Минем күз алдыма менә хәзер бер бик тә матур күренеш килде, Илсур. Шуны языйм әле.

Бик тә бәләкәй вакытта—әле яңа гына мәктәпкә йөри башлаган чак иде бугай инде ул—яз көне, карлар эреп, иң беренче чирәмнәр чыгу белән, без авыл читендәге Коры елга буена кәҗә бәрәннәрен ашатырга алып килә идек... Бик матур, шундый да аяз күкле, ямьле, җылы бер көнне—карыйм: Коры елганың теге як ярында минем чамадагы бер малай шулай ук кәҗә бәтиләрен алып килгән. Ул да акрын гына шул матур малкайлар белән мәш килә, әвәрә килә. Миңа шулчак шундый кызык, шундый да күңелле булып китте—кычкырасым, шатлыгымны кем беләндер уртаклашасым, хәтта рәхәтләнеп көләсем килеп китте—түзеп кенә булырдай түгел иде!

Ә син миңа таба карамыйсың! Һаман үзеңнең шул бәләкәй кәҗә бәрәннәрең тирәсендә уралган буласың! Билгеле алар—ул бәтиләр—шундый күңелләләр, сөйкемлеләр инде. Аларга карап туя торган түгел! Сикереп-сикереп уйнаулары гына да ни тора! Ямь-яшел чирәмдә. Шундый кояшлы язгы көндә!

Бераздан син ары табарак та киттең бугай, нәрсәдер караган, күзәткән булып йөреп тә килдең, ахрысы—ләкин ул көнне миңа бер генә кәлимә дә сүз катмадың! Әллә ояльдың инде...

Менә шул көнге матур күренеш гел күз алдыма килә иде минем. Ләкин икебез ике як ярда булып...

Аннары, хәтерлисеңме: унынчыда укыгандамы икән, безне синең белән икебезне район үзәгенә комсомол конференциясенә җибәрделәр... Кыш көне иде ул. Җыелыш дигәнебез көне буе булды, шуннан соң без трактор чанасына утырып төне буена авылга кайттык. Киң-киң такталар белән биегәйтелгән трактор чанасының бер почмагына кереп чүгәләгән, поскан идек икебез дә! Шулай җылырак та, күңеллерәк тә иде безгә! Сөйләшә-сөйләшә дә кайттык бит әле ул озын төн буена... Җитмеш чакрым юлны үтеп авылга кергәндә инде кышкы төн яктыра да башлаган иде. Без синең белән икәү бер чатта төшеп калдык та, ашыкмыйча гына төнге, кышкы авыл урамы буйлап икәү генә кайттык. Ничектер кешеләрне уятудан курыккан төсле акырын гына

сөйләшкәләп... Әнә шул төнне, үзебезнең капка төбенә кайтып житкәчтен дә, бер генә дә өйгә кереп ятасым килмәде минем ни өчендер! Инде таң атар вакыт житсә дә... төне бик матур иде, безгә бик рәхәт иде ич! Синең дә китәсең килмәгән сыман иде... Аякларыңны көчләп кенә атлатасыңдыр сыман иде миңа.

Ә бер җәйне район үзәгеннән бергә кайтуыбыз! Автобустан төшкәч, авылга хәтле булган унике чакрым араны икебезнең янәшә атлавыбыз... Башта урман юлы буйлап, ә аннары «моннан турырак» дип кәҗә сукмагыннан гына китүебез... Юлыбызның алма бакчасына килеп чыгуы. Безнең шунда аптырап калуыбыз... Чирәмле тау битенә утырып ял итүебез, биштәребездәге кала күчтәнәчләрен әз генә чеметә-чеметә тамак ялгавыбыз...

Менә хәзер үзем сиңа хат язам, ә үземнең күз алдымда әнә шуларның барысы-барысы кино сыман күренеп тора.

Ә Иделнең аргы ягында үткән кич! Безнең икебезнең янәшә басып төнге караңгы Иделдән узып баручы яшелле-кызыллы утлар кабызган серле пароходны карап торуыбыз! Аннары соң—шул утларга алмашка диеп, үзебезнең учагыбызны кабызуыбыз! Аңа багып—сокланып, рәхәтләнеп, очынып утыруыбыз!

Ә синең куышта икебезнең генә чәй эчүләр... Тагын төнге болын сукмагында сөйләшеп йөрүләр...

Менә болар барысы да шулай кинәт өзеләмени соң? Бөтенләйгә бетәмени соң?

Безнең юллар шушы урында бөтенләйгә аерыламыни соң?!

Мин хәзер төн уртасында бер үзем, бер ялгызым әнә шуларны күз алдына китереп, исәр кеше кебек бер үзем иләсләнеп утырам. Һәм дә тагын шулай дип уйлыйм: боларның барысы да синең өчен дә кадерле түгел идемени соң, Илсур?! Ул чагында син дә бик теләп, чын күңелдән, чын ихластан йөри һәм ихластан сөйләшә идең ич! Әгәр дә алар барысы да чын күңелдән булган икән, синең кинәт кенә үзгәрүеңне мин ничек аңларга тиеш булам соң?!

Бәлки син теге кеше турындагы сүземне инде хәл ителгән мәсьәлә дип кабул иткәнсеңдер? Бәлки мин әле үзем чишмәгән нәрсә турында әйтеп, бер зур ялгышлык ясаганмындыр?! Әгәр бу, чыннан да, шуның аркасында килеп чыккан эш икән, менә хәзер сиңа дөресен әйтәмен: мин ул чакта бары тик аның ягыннан димче килүен генә хәбәр иттем бит сиңа! Һәм тагын, әйтсәм әйтим инде, күңелемдә үкенеч булып калмасын—синең тарафтан да шундыйрак адым ясалмасмы дигән өмет тә бар иде күңел түрендә... Әнә шуңа бер ишарә булырга тиеш иде минем ул сүзем, үземчә... Мин сиңа шул хакта хәбәр бирмәкче идем, уйланырга кушмакчы идем. Ләкин ни кызганыч: син бу кинаяне аңламадың! Хәтта, аңламаган көе мине нәкъ киресенә таба этәрдең! Үзеңнән дә этәрдең...

Инде менә әйтәсе сүзем дә бетеп килә бугай. Төн уртасында шулай хисләнеп сиңа хат язуыма да аптырап куям... Бу хат кирәкме соң инде? дип уйлыйм. Ә бәлки, чыннан да, кирәкмидер ул, аны бәлки сиңа җибәрмәскәдер? Менә хәзер яза-яза үзем белән киңәшәм... Нишлим икән?—дим... Шулай иткәч, баштагы уйлар ачыграк беленә кебек... «Нишлим?» дигән сорауга җавап та тизрәк табылыр шикелле шулай эшләгәч—менә шулай язып уйлангачтын...

Ярар! Нәрсә булса да булыр, бу хатны сиңа җибәрергә карар иттем! Чөнки, әгәр мин аны сиңа җибәрмәсәм, синең кайбер нәрсәләрне бөтенләй белми, аңламый калуың мөмкин бит. Минем хакта дип әйтүем!

Сау бул, Илсур!»

—дип зур нокта куелган иде ул хатның ахырына.

Менә шул зур ноктага бик озак итеп кара тордым мин Ләйсирәнең ул хатын укып чыккач. «Безнең арада барысы да беткәнне миңа сиздерү өчен шулай зур итеп куйдымы икән инде моны Ләйсирә?—дип уйладым эчемнән.—Үзе мине гаепләмәкче була ул, ә үзе сөйләгәненең нәкъ киресен эшли тора! Мин ничек аңларга тиеш соң инде аны?!.»

Кыскасы шул: бу хатны алганнан соң мин Ләйсирәне бүтән күрмәдем! Ә укуын мин ул хатны кабат-кабат укыдым. Бүлмәдәш егетләр ятып беткәч, үземнең яшергән җиремнән тартып чыгарып, йокларга

ятыр алдыннан укыла торган изге дога шикелле итеп көн саен диярлек укый идем мин ул хатны! Чыннан да, анда—ул хатта бит безнең иң саф, иң самими, иң ихлас чакларыбызның тәгәл, чиста, дәртле һәм шул ук вакытта ни өчендер моңлы да ишетелә торган тетрәндергеч авазы иде бит! Ләйсирә белән безнең икебезнең иң ямьле, иң матур, ә бәлки бәхетле дә булган якты көннәребез иде ич анда! Әнә шул артта калган көннәрнең бер якты чагылышы, бер моңлы кайтавазы ишетелә иде ул хатта!

Һәм шул ук вакытта Ләйсирә, күрәсең үзе дә акылы белән бик үк аңышып житмичә, безнең киләчәк язмышларга карата булган кинаяне, шактый ук ачык сизелергә тиешле ымны да искә төшерә үзенең бу хатында. Коры елганы... Икебезнең ике як ярда йөрүебезне искә төшерә...

Әйе шул—минем дә бик исемдә ул язгы ямьле көннәр... Чирәмлектә кечкенә кәжә бәтиләрен ашатып йөрүләр. Һәм... Һәм теге як ярда үзем чамасындарак бер кыз бала йөрүен күреп, эчтән генә канатлану да, кыенсыну да, үзенә бер төрле, өр-яңа хисләр кичерү дә...

... Ул хатны алганга инде менә күп, бик күп гомер узды... Ышанырсыз микән, юк микән—белмим: әмма минем Ләйсирәне шуннан бирле бер дә күргәнем юк! Әйе, әйе—үземнең классташ дустымны, авылдашымны бүтән очратканым юк минем гомер юлымда!

Ләкин ни хикмәт диген: ул хат үзе таушалып бетсә дә анда язылган сүзләр кичә генә укыган шикелле тоела.

Күз алдында һаман яктырып, балкып тора ул ялкынлы сүзләр.

Юк, дөресрәге болай, башта әйткәнемчә икән: яшь чагында ятланган иң матур, иң хисле, иң яхшы бер шигырь шикелле ул хат!

Шуңа күрә күпләр үзләре генә калган чагында хәтерләрендәге шигырь юлларын кабатласалар, ә мин исә ялгызлык минутларында әнә шул онытылмас хатның бәгырьгә уелып калган сүзләрен янадан-янадан күңелемнән үткәрәм! Хәзер инде шактый күпне күргән, байтак хәлләрне кичергән күңел түреннән әнә шул ялкынлы сүзләр үткән чагында мин гүяки тагын үземнең яшьлек танына кайтам! Гүяки мин янадан Идел ярында дәртле учак ягып утырам! Әйтерсең мин бары тик Идел буе болыннарының җәйге төннәрендә генә була торган искиткеч тәмле һаваны сулыйм! Гүяки мин әнә шул сихри төннәрнең жаны булган сандугачның төнге тал кочагындагы өздерүләрен тыңлыйм! Һәм әнә шул илаһи минутларда мин бөтен дөньямны онытам, һәммәсен истән чыгарам—бары тик әнә шул моңга гына мөкиббән китәм, бары тик аның иркендә, аның хозурында гына калам!

Әйе, андый бәхетле минутларда мин үземне янадан да Идел ярында итеп тоямын... Һәм... Һәм андый чакларда күңелнең ни өчендер үзен ялгыз гына итеп түгел, ә Ләйсирә белән бергә итеп сизәсе килә...

Әнә шундый чакларда тагын бер хис, бер тойгы бәгырьне телеп үтә: Идел уртасыннан утлары белән балкып баручы пароходларда безгә Ләйсирә белән бергә узарга туры килмәде... Без бары тик Иделнең ярында гына утырдык... Идел уртасыннан бергәләп йөзүчеләргә кызыгып, көнләшеп кенә...

Әйе, әйе—кызыгып кына шул... Кызыгып кына!

* * *

Менә инде дәфтәремнең соңгы бите дә укып чыгылды...

Яшьлекнең бигрәк самими, бигрәк садә хисләре булган икән шул болар! Билгеле, тора-бара без барыбыз да нык кына үзгәрәбез бит инде, гомер юлларының да текә генә үрләрен менәргә, тайгак кына упкыннары яныннан узарга да туры килә... Борылмалары да шактый ук четерекле була аның... Ләйсирә турында да соңгы елларда миңа авыр хәбәрләр ишетелгәләде: аның ире мәрхүм булган икән, ул ике баласы белән тол калган икән... Боларны белгәч мин

аның өчен чын күңелдән борчылдым, кайгырдым. Әмма үзем, ни өчендер, аңа хат язып, яисә бүтән бер юл белән, кайгысын уртаклашуымны әйтергә, хәбәр итәргә кыймадым. Дөресрәге, бу эшнең кирәклегенә ныклап ышанып җитмәдем, үземне шуңа күндерә алмадым!

Ләкин Ләйсирә турында мин еш уйлыйм.

«Ә шулай да... Ә шулай да,—дип уйлыйм хәзерге акылым белән,—ул чагында Ләйсирә белән бергә булсак әйбәтрәк килеп чыгар иде микән соң язмыш? Ничегрәк булыр иде микән соң ул?»

Инде ярты гасырлык гомер чиген узган минем баш озакка, шактый ук озакка уйга тала, бик күп, бик күп «бәлки»ләр урманын уза һәм, барыбер, ахыр чиктә әлеге сорауга уңай җавапны табып ала алмый... Гәрчә яшьлек үзе, аның матур, аның канатлы көннәре, кичләре бик тә кызыктырып, ымсындырып торса да!

Күрәсең... күрәсең «яшәү» дигән хикмәтнең без аңлап җитмәстәй үз кануннары бар һәм ул безнең йөрәкләрдәге хисләр, кичерешләр белән исәпләшергә бик ук яратып та бетерми бугай...

Хәер, Идел ярын үзен дә су басты, су каплады бит инде хәзер!

Ләкин ул мәңге җуелмаслык якты күренеш булып минем күз алдымда тора... Җәйге ямьле кичтә ягылган һәм безнең өчен иң кадерле яктылык булып тоелган илаһи учагы белән... Әнә шул учак янында—Идел ярында—үзе бер серле балкыш булып басып торган гүзәл Ләйсирәсе белән...

Тагын бер кадерле кешем бик еш кына күз алдыма килеп баса...

Үзе гомерлеккә диеп утырткан таза имән баганаларны урыннарыннан куптаруыбызга, кузгатуыбызга рәнҗеш тулы күзләре белән безнең әти сүзсез генә карап тора... Үзе төзегән таза-сау өйне вакытсыз сүтүебезгә чиксез рәнҗеп тора сыман ул...

Әй, бу Идел яры!

Әй син, Идел яры...

ГОМЕРЕНЕҢ ҖӘЙГЕ ЧАГЫ

Шагыйрьләрне гел яшьләрдән—яшьлектән эзләдек. Бу хикмәт баштан ук, электән үк диюем, остазларыбыздан килә сыман. Алар гел яшьләрне—шагыйрьләрне эзләде. Сибгат ага Хәким «Тукайларны эзлим» дип, оран салды. Ул аларны—Равилләрдән (Фәйзуллин), Рәдифләрдән (Гаташ), Рөстәмнәрдән (Мингалим), Гәрәйләрдән (Рәхим), Зөлфәтләрдән (Маликов) эзләде. Алар турында—яратып, тиң күреп мәкаләләр язды. Зурлады, олылады, кирәк урыннарда тәкъдим итте. Үстерер өчен, тәнкыйть тә иткәләде хәтта... Бу—безгә дә өлге, бер үрнәк булып калды ахры. Шуңа да күзгә күренгән өметле яшьләр безнең өчен һәрчак әдәби киләчәк булды—сөенеп каршыладык. Ркаил Зәйдулланы, мәсәлән. Мәктәптән килде. Кызыклы шигырьләр, хәтта поэма белән килде. Һәйбәт шагыйрь булып җиткән иде. Ә ул ... тотты да прозага—чәчмәгә күчте. Әйбәт чәчмә әсәр—«Ил» китабын язды; бу—проза гына түгел, шигъри чәчмә дә...

Заман болганды.

Заман үзгәрде.

Заман акчалы шөгыль сорый башлады. Ркаил моңа әзерлекле иде—һәр жанрда шагыйрьлек ята! Шуңа да ул «Саташкан сандугач» исемле сәхнә әсәре белән Камал театры сәхнәсенә күтәрелде. Әмма мин аны шигырьдән китте дип санамыйм...

Ләбиб Лерон үзенчә юл алды: балалар әдәбияты да кадерле ... бик кадерле.

Ләис Зөлкарнәй—хәзер шигырь язмый шикелле.

Шигырьгә тугры булып, ул буыннан Газинур Морат кына калды...

Әнә шул буын бүленешеп беткәндә шигырьгә ир уртасы яшьләр килеп керде. Шуларның берсе—Мөхәммәт Мирза. Язганнары буенча мин аны зуррак яшьтәдер дип шәйләгән идем. Имән кебек ир-егет икән... Аның белән Рөстәм Мингалим таныштырды.

—Шагыйрь!—диде.

Сүзне аның үзенә дә бирик:

«Без кемгәдер кирәк. Шул сәбәпле дөньяга килгәнбез. Берәүгә дә кирәгебез калмаса, китәрбез. Китә торалар бит әле, без кемнән ким. Мөхәммәт Мирза (Илфак Мирзамөхәммәт улы Ибраһимов) 1952 елда Актаныш районы Чалманарат авылында дөньяга килгән . Үскән. Казан дәүләт культура институтының режиссерлар хәзерләү бүлеген тәмамлаган... Мөхәммәт Мирзаның көтмәгәндә зур әдәбият мәйданына чыклап аяк басуына сөенәм...»

Яшь шагыйрьнең «Кәккүк тавышын санадым» исемле беренче китабына кереш сүзендә шагыйрь әнә шундый юллама бирә. «Турайгыр» исемле икенче китабына карата да әйтә алыр идек бу сүзләрне: Мөхәммәт Мирза безне дә, шигырь сөючеләрне дә гел сөендерә килә. Аның соңгы елларда язган, төрле шәкелләрне иҗади үстергән (бигрәк тә,

кыска шигырьләр, дүртьюллыклар, газәлләр һ. б.) шигырьләре чыннан да сөендерерлек. Эзләнә ул. Язганнарында—туган ягы Актаныш, аның кешеләре, табигате, моң урыннары. Гамил Афзалга хас уйчанлык, фәлсәфи лириканың нигезе—шуннан. Жырга тартылу да... Әле бит ул сәхнә кешесе, шигырь сөйләү остасы да, оештыручы да: районның мәдәният бүлегендә һәм яшьләр белән озак еллар эшләгән шагыйрь «Агыйдел дулкыннары» исемле әдәби иҗат берләшмәсен дә җитәкли, күмәк китаплар төзеп чыгара... Бүген аның Татарстан мәдәният министры урынбасары булып эшләве дә, Нажар ага Нәҗми әйтмешли, «юкка түгел, юкка түгелдер»...

Үзенең бер шигырендә М. Мирза болай яза:

Гомерләрнен күзе түгел,
Жәйге чагы:
Дөнья йөге арбасына
Бәйле чагы.
Үргә менеп, каерылып
бер карагач:
—Сөбханалла, иншалла!—дип
Әйтер чагы...

Илле яшьлек каләмдәшемнең нәкъ шундый чагы. Ә иҗатының мул төсмерләре турында миннән дә тулырак итеп, шигырьләре сөйләр.

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ.

Мөхәммәт Мирза

КИЕК КАЗ ЮЛЫНДА

**Ук алмаслык арада
зәңгәр күк ник карала?
...Кыйгак-кыйгак тавышлары
бар дөньяга тарала.**

**Йөрәгемне телеп-телеп,
уеп-уеп ала ла.
Күкне дерелдәткән тавыш
бар гамәлгә тарала:**

**—Килүләр бар—кыйгак, кыйгак,
китүләр бар—кыйгак, кыйгак.
Калулар юк, калулар юк
дөньяда—кыйгак, кыйгак... кыйгак.**

Ялган сүз

...Яман сүзнең күңелдән һич заты китмәс...

Акмулла.

Ялган сүз—арттан атылган
агулы уктыр.
Зәһәрен йолып алырлык
дәвасы юктыр.

Ялган сүз—җанга кадалган
тутыккан кадак:
тартып алсаң-алмасаң да
эш үткән—харап...

Ялган сүз—оныкларыңа
күчеп барачак
яманат булып, ыруда
мәңге калачак...

Хыянәтне кичермимен, дидең

Туйлар көттек—туйлар булмый калды.
...Язмыш мине синнән тартып алды.
Шәрабенә салып агу бирде:
—Минеке йә һичкемнеке,—диде.

Исердемме, әллә тилердемме,
ихтыярым бетеп, чигендемме?
...Тезгә төшеп, үксеп ялварсам да:
—Хыянәтең кичермимен,—дидең.

Туйлар көттек, туйлар булмый калды.
Гомер буе җаннар газапланды.
—Хыянәтең кичермимен,—дидең.
...Син шул үзеңнән дә горур идең.

Сиңа кайтыр юлым

Сиңа кайтыр юлым ерак—
тауларны бар кичәсе...
Бүген айның ничәсе?

Сиңа кайтыр юлым озак—
үткелләрне үтәсе,
үткәннәрне сүтәсе.

Сиңа кайтыр юлым урау—
карурманнар узасы;
кыры, кылган-курасы...

Сиңа кайтыр юлым диңгез:
яр белән яр арасын
дулкыннардай ярасы...

Сиңа кайтыр юлым—күктә,
хыялым, уйларымда—
киек каз юлларында.

Болыт куерып каралды.
Томан куерып агарды...—
Болытлы томанлы иртә...
Каеннар тора караеп,
Күңелем калды сагаеп,—
Күк, адаштырып, Кояшны
Кайларда йөртә?...

Агыйделне боз томкандыр,
йокыга талгандыр яры...
тал-курасын сызгырткандыр
кышның беренче бураны...
...Ялгызым калган бу төндә,
бәсле тәрәзәмә багып,
уйлап утырам шуларны...

—Шигырь—шөгыленме?—дисең,
Шөгыль бит ул—кул эше.
Шигырь, дустым, Илаһының
Җанга өргән сулышы!
Чиксезлекнең аһәңе ул,
Мәңгелекнең агышы!
—Шигырь—шөгыленме?—дисең,
Бу—гөнаһсыз ялгышың...

Ак болыт кичте Иделне
табанын да чылатмый.
Йомшак җил үтте йөгереп,
бер дулкын да чыгартмый.
Торналар очып үттеләр,
аккошлар, кыр казлары:
Хәтеренә чорный Идел
төсләрен, авазларын...

Кемнән кем туеп ялыккан—
вакыт күрсәтер ачык...
Килер көн: ташлап барысын,
кем китәр кемнән качып?!

Заманына карап туа
Әйтер сүз, җырлар җыры...
«Ни чәчсәң—шуны урырсың!»—
Фәлсәфи агы шулдыр:
Исән чактаниләр кылсаң,
Раббың каршысына басып,
Әйтәсең булыр туры!..

*

Һәр исемдә шигырь бар...
Шигырь—җисем бизмәне:
Кемдер—дөнья бизәге...
Кемдер—дөнья бизгәге...

*

Мине хәзер никтер күкләр тарта,
Күктә әллә күңеллерәкме?

Ф. Яруллин.

Фәрештәләр хозуры бит ул күк,
Ничек анда булсын күңелсез.
Изгеләрне чакырып тора Гарше:
Шунда
Менәлмәслек шәхес түгел Сез...

Ахырзаман

Ана сөте белән керә, диләр,
бала күңеленә иман нуры...
Соңгы чиккә илтеп терәлдекме:
ата—кызны белми, ана—улны...

*

Бизмә, шигырь, ятим итмә колыңны,
Алма җаннан йомшак җылы кулыңны,
Балкыт Илаһыдан килгән нурыңны,
Яктырт мәңгелеккә күчәр юлымны!

*

Мәңгелек—акыл җитмәслек еракта,
Сере җитмеш җиде мең бер йозакта...
Киек каз юлында казлар тавышы...
Кемнәр китә... кемнәр кемне озата?..

*

Үзенә дәште кыйблам—Казаным,
Чакырды гел шигъри азаны...
Тик, Нөркәмдә калып язармын
Гомер китабымның азагын...

*

Сиңа килдем утлар-сулар кичеп,
Өметемне кысып учларыма...
Ялкыныңа сулар сибим ничек,
Ут тергезим ничек учагыңа?!

Көннең кашын сызган кара күмер,
Сөрмәсен дә тарткан карадан.
Көн белән төн арасында—гомер,
Йә, кем чыгалган шул арадан?...

Тәүбә ит, бәндә, бер Ходаң каршында.
Туар көн—җавап тотарсың каршында...
Кылган бар гамәлең, хәтта уйларың
Сурәттә күренер—үз күз каршында...

...Көл, күңел, дөньяның моңы бер безгә генәмени?

Р. Ф.

Көл инде, күңел, көл инде
дөнья ямьсез түгел лә?!
...Бер чеметем куаныч та,
шөкер итсәң җитәр иде
мең тулып түгелергә...

Г. Афзалга ияреп.

Рәсәй һәрчак супер булды,
Тик халкына сукыр булды;
Талап алды бар җирен,
Тиенләп бирде әҗерен...

Ни кадәрле кирәк—шулай чыда,
тик таштай катмасын күңелең...
Таш күзеннән дә яшь бәреп чыга,
төпсез күле тулса түгелеп...

Җилләр исә, тарый еллар толымын,
Буразналы йөздә язмыш корымы...
Алын—ал, гөлен—гөл иткән чак булды:
Һәр мизгеле бер гомергә торырлык!..

Янып бетеп бара гомер—тоямын,
Сүрелгән көлләрен җанның коямын...
...Фатихасын алырмын шат дөньяның:
Дүрт ягын да тигез күрдем мин аның!

Çəçmə əsərlər
Чәчмә әсәрләр

Әхәт Гаффар

ХИКӘЯЛӘР

Җирләгәч

Гомерем буена: «үләсем килә»—дип яшәгән идем. Үлгән чакта гына: «яшисем килә»—дип әйтә алмадым. Ә яшәргә дә, үләргә дә соң иде инде.

Үләчәгемнән соң, мине татар зиратына күмәргә теләмәүчеләр булган икән. Мин—чуаш хатыны Василиса гына шул. Югыйсә, бу татар авылында даным да, шөһрәтем дә бар иде бугай. Мине Василиса Павловна дип йөрттеләр. Ә мина әбиләрнен, бабайларнын, балаларнын—һәммәсенең Вәсилә дип дәшүләре, эндәшүләре үз иде. Мал докторы булсам да. Тик минем хакта ат духтыры дип һичкем әйтмәгән. Берзаманны мине Кәримулла абый чакырткан. Урамыбыздан безнең өебезгә ике генә өй үткәч торалар. Анын үгез бозавы бар иде. Шуны печәр чак житкән. Эшемнән бушагач, авыл көтүе кайтканчы шуларга бардым. Кәримулла агай капка төпләренә тирә-күршедәге тимерчеләрне, пенсиядәге укытучы, Госман абыйны—биш-алты ир-атны жыеп куйган. Әлеге малның аякларын тышаулап, бар көч белән жиргә егып салырга дип инде. Килеп життем дә, жирдәге бауны алып, теге үгезне юмалый- юмалый аякларын урап алгач, бер генә тарттым. Мин кызу эшләргә күнеккән. Шуннан соң абзарга кертеп япкач, утлыктагы үләнне чемченергә дә керешкән. Мин өйгә кайтып киттем, теге ирләр карап калды. Иртәгесен аларның таң атканга хәтле мине сөйләп утырганнарын житкерделәр. Әллә тагын... Белгәнемне, кулымнан килгәнне генә эшләдем. Билгечлегемә укытканнарынча, өйрәткәннәренчә, күнеккәнемчә. Эшләргә гадәтләнеп була инде ул анысы. Яшәргә дә. Үләргә гадәтләнү генә юк бугай. Хәер, бөтен нәрсәгә өйрәтәләр, өйрәнәләр. Сонгы сулышынны ничек сулыйсын гына әйтмиләр. Аны үзең генә аласын. Бусы—беренче дә, сонгы тапкыр гына. Анаң кендегеннән аерылгандагыча. Югыйсә, ана карыныннан

Әхәт ГАФФАР *(1949)—язучы, драматург, публицист; «Әҗәт», «Яшиселәр алда иде», «Богау» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

төшү, кендек киселү, имчәктән аерылу—сизмәвен, белмәвен аркасында жип-жинел ул. Сизә, белә, аңлый торып, туган жиреннән аералар икән, монысына түзәргә ярый. Ин газабы—чит-ят туфракта сине гүргә индерүләре икән. Әби белән бабайны, алар белән бергә буласы әтиемне өй түбәләре такта белән ябылганы өчен чуаш иленнән Себергә сөргәннәр. Әйтерсең лә ул сөрүчеләрнең табутлары, ләхетләре, баш казыклары такта булмаган. Ярый инде, агач яручы ирем мина ниятләнгән ләхет такталарын да жегенжеккә китереп эшләгән. Аның соңгы тапкыр иренемә тидергәннән соң калган бер тамчы су да үтмәслек, сеңмәслек, кермәслек итеп.

Шулайга күрә, рәхмәтем йөзеннән, ахыргы сулышымда мин: «Ләәәә Иләәһә Илләллаһү Мүхәммәдррасүлүллаһ»,—дип калырга өлгердем. Югыйсә, мине күрше урыс авылына илтеп жирләсеннәрмени? Ирем саф мөселман, кызым мөэминә, ә минем чукынганым, тәре тагып йөргәнем юк. Мин—чуаш кызы. Безнең Себердәге авылга ни чиркәү, ни мәчет салдырмаганнар. Кемдер Инжил, кемдер Коръән яшерсә дә, барлыгын һәммәсе белә иде анысы. Баракта торган чагында ирле-хатынлы Исмәгыйль абый белән Мария апа сәкесе астындагы сандыкта шул китаплар аслы-өсле тора иде. Безгә әле бусын, әле тегесен укыдылар. Исмәгыйль абый бөти тагып йөрде. Аны күмәргә алып киткәндә Мария апа аңа үзенең алтын тәресен тагып жибәрде, үзенә шул бөтине киеп калды.

Укыдым инде. Институтта аспирантурага калдырабыз, дигән көннәрдә концертка барган идем. Шунда бер татар егете үз гармунында уйнап, гел мина карап кына жырлады. Өйләнештек. Аның Татариядәге әнисе вафат булгач, шунда кайтып төпләндек. Мин үлгән көнне ул авылдагы бер абзый мине мондагы зиратка жирләргә ярамый дип йөргән. Ә мин яшь кенә муллага: «Ләәәә Иләәһә Илләллаһү»ны әйткән идем инде.

Мин булып мин дә яткан мөэмин-мөселман зираты очсыз-кырыйсыз булыр, Алла боерса.

Монда гүр кысан-кысанын. Тик туфрак авыр түгел.

* * *

—Яшәгәндә күк иркен. Үлгәч йолдызлар да жинеләя,—дигәч, Вәсилә ак яулыгының уң очы белән иң соңгы тамчы күз яшен сөртеп алырга өлгерде.

Әллә кайда ажаган уйнап алды. Тулган ай зәңгәрләгән зират астындагы тугайда карт бия әле генә үз карынынннан төшкән колынын ялый башлады. Себер карурманында табылган бер мәхбүс мәетнең алтын тәресе рухына кадильяның төче төтене инде. Ә Татария авылындагы агач йортның мич авызы каршында күрек элмәгә ычкындырылмаган тальян гармун телләрендә Вәсиләнең ире буыннары каткан бармаклары белән ниндидер көй эзләп интегә иде.

Янындагы ак эткә ул:
—Кушыл, Акбар,—диде.

* * *

Аның миннән соң бүтән берниндн хатын-кызны якын итмәслеген соңгы тамчы суын иренемә тидергәндә дә белә идем инде. Әйтмәдем генә. Ахыргы сүзне әйтмиләр. Үлгәннәрнең әйтми калдырганы тереләрнең төшләренә керә.

2001 ел, 12 ноябрь.

Карачкылар

Зират каеннарына кичкырын кара каргалар килеп кунган иде инде. Әсхап үзләренең яшелчә бакчаларына карачкы ясап куйды. Авыл көтүе кайткан, сыер, бозавы, ике яшьлек үгез абзарга ябылган, сарык,

бәрәннәр урнаштырылган, тавык-чебеш үз урынында, үрдәк бәбкәләре тук, Акбар атлы эт тыныч кына ята, ике мәче кайда йөри икән—йөрсеннәр. Кызлары Хәдичә телевизор карыйдыр инде. Ә уллары Гаденән мотоциклын төзәтте дә... кая барасын үзе чамалыйдыр тагын. Иртәгә аның соңгы имтиханы—унынчыны тәмамлый.

Әсхап шуларны уйлый-уйлый да, уйламыйча да, болай гына—бәрәңге белән карлыган арасындагы сажин аркылыйга, сигез сажин буйлыйга утыртылып хәстәрләнгән яшелчә бакчасын караштыра иде. Болай... тишеләсе әйбәт тишелгән, борнаган, яфрак җибәргән анысы. Тик иртәләрен түтәлләргә үз тавыкларыннан битәр... күршедәге Гөлбаһар тавыклары, өстәп, кара каргалар төшеп актарынмасынга куркытыр өчен әнә нинди карачкы ясап куйды бит әле! Хәйран—тамаша! Нәкъ үзе.

—Бу ни бу?—дигәнгә ул борылып та карамады. Ире инде—Сәгыйт. Кайткан.

Әсхап юеш, балчыклы кулын күлмәк итәгенә сөртеп куйган булды. Белеп инде. Ире кайтканда кулын итәгенә ничек итеп сөртәсен чамалый ул. Редисканың җирдән калыккан кызыл өлеше сыман, кояшка янган сыйракларыннан тез югартын шалкандай ак төшен чак-чак кына күрсәткәндәй итеп.

Сәгыйт үзенең солдат киемен элеп ясалган карачкыга ымлап:

—Бу ни бу?—дип сорады.

—Син,—диде Әсхап.

—Күрәм. Ә бу киемнең эшкә җарарлыгы да барые ич әле.

—Җарар сина, бар! Эретеп җабыштырасың да җабыштырасың. Утында иләк булып беткән ич инде.

—Бетсә сун. Монынчы ул тишекләрдән төшереп калдырган нәрсәм җугые ич әле.

—Тишәргә сина бир инде анысы.

Сәгыйт хатынының күлмәк изүендәге төрән шикелле күгәреп күренгән төшкә кырын гына карап куйды да:

—Анысы ярый инде,—диде.

—Нәрсә анысы? Ни житмәгән?—диде Әсхап.

—Житүе житеп бара бугай инде анысы,—диде Сәгыйт.

Әсхап, күлмәк итәген югарырак күтәреп, кулын сөртте дә:

—Таныдынмы сун?—диде.

—Нәрсәне?—дип сорады Сәгыйт.—Бу ни бу дидем ич!

—Син,—диде Әсхап.

—Минем гвардия сержанты киемемнән башкасын тапмадыңмыни?

—Шушысы әйбәт,—диде Әсхап.

—Сун?

—Син әрмиедән кайткач, мин синнән курыкканыем.

—Сун?—дип кабатлады Сәгыйт.

—Менәтерә, хәзер тавык, каргалар курыксын инде.

—Курыксын?—диде Сәгыйт.—Бәлки алар мине... ни... яратып кунакларлардыр.

—И, и, и!—диде Әсхап.

Сәгыйт түзмәде: су сипкечне мичкәгә чумылдырып алды да, шуннан сарымсак түтәле буйлата сиптереп узгач, кырыс төстә:

—Аш пешкәнме?—дип сорады.

Әсхап тыныч, сабыр, ягымлы гына итеп:

—Мунча да әзер инде,—дип җавап бирде.

Кичке тузан басылган, тулган Ай калыккан, шомырт, чия, алмагачларның ботаклары төнгә каршы турайган иделәр. Сәгытдин, соңгы тапкыр шикелле итеп, сигарет суыра-тарта яшелчә бакчасына чыгып басты. Яланаяклап. Ак күлмәк-ыштанлы килеш. Рәхәт иде. Шомырт, канәфер чәчәге, инеш суы исе килә. Абзардан тирән итеп сыер сулаганы ишетелә. Ә кысыр җирдәге кыргый чиялектә бетеп-бетеп сандугач сайрый. Тын. Тып-тын. Мунчала күлендә бер-берсен бүлдерми генә бакалар сайраганын тыңламасаң. Әйбәт. Әнә, карачкы да ап-ачык шәйләнә. Шәп. Солдат киемле

карачкы. Аныкы. Торсын. Яхшы. Шәлперәек түгел ич. Асылынып, хәлсез-әхвәлсез тормый. Сак тора. Һәрвакыт әзер булып. Мунчала күленә салып казыклаган юкә кабыклары шикелле жебергә, аннан ары таралырга, сүтелергә дигәнмени? Бигрәк тә мунча кереп чыкканнан соң. Әнә ич: ай ничек тулган. Әйе, тын. Улы Галенәннен капка төбендәге мотоцклы сүнгәч бигрәк тә. «Иеме, Ай?»—дип уйлады ул. Ай: «Ие» дисенмени инде?! Ул дәшми. Эндәшми. Тәгәри шунда. Май ае себеркесе белән изеп, таптап, «Аh! Аh!» дидертә-дидертә чапкачыннан сун, Әсхапнен ләүкәдән әллә ишелеп төшүе, әллә күтәрелеп китүе шикелле.

Сәгыйт сигаретын актык мәртәбә суырды да, анда-санда борнаган бәрәнгеләргә таба чиертеп жибәрде. Күрде: утлы төпчек тулган Айга житкән бер мәлне... әйе, күрде: күршесе Вәдүтнен хатыны Гөлбаһар да үзләренен яшелчә бакчаларына карачкы куйган икән. Зәнгәр күлмәк кидертеп. Сәгыйтнен солдат киемен көтеп-көтеп тә киелмәгән, тузмаган-туздырылмаган крепдешин күлмәген.

Тулган Ай нуры шул күлмәктәге түм-түгәрәк ак борчакларга үтәли төште дә эреде дә бетте... Сәгыйтнен кырыс кына саркып чыккан ике бөртек күз яше сыман.

Ул йокларга кереп китте.

* * *

Ай тәмам калыккан, шомырт, чия, канәфер, алмагачларнын ботаклары кояш чыкканчыга хәтле шәлперәйгән иде әле.

Зират каеннарындагы кара каргалар әледән-әле бер-берсен бимазалаштыргалап йоклый да йоклый.

Авылда бер араны сандугач та тынып торды.

Шул чакта солдат киемле карачкы:

—Нихәлләрен бар сун?—дип эндәште.

Зәнгәр крепдешин күлмәкле карачкы:

—Менә, жуып, үтүкләп чыгарганнарые әле,—диде.

—Син һаман әүвәлгечә икәнсен,—диде солдат киемле карачкы.

—Син дә шундый,—диде зәнгәр күлмәкле карачкы.

—Нинди?

—Мин сине өзелеп көткән, ә син кайткан көндәге шикелле.

—Нинди?

—Үпкәләмә инде.

Ике карачкынын бер-берсенә ниһаять якынаюын кочаклашуын тулган Ай гына карап торды.

Жир уянып килә иде инде.

2002 ел, 22 октябрь.

Кылчык

Капка төбенә бер йөк салам китереп аудардылар. Көн авыр, салкынча, болытлы, аяк асты пычрак. Түндырган да иде инде. Аннары жебетте. Алай да рәшәткә буйларында, өй, абзар түбәләренен яссырак төшләрендә, агач араларында кар эреми калган. Ул тагын атна-ун көннәрдән сон—декабрь башларында гына ятар ахрысы. Шуна күрә сугымга да керешмәгәннәр иде әле. Абзар-курада мал-туар, ишегалдында кош-корт. Тан күзеннән алып, энгер-менгер төшкәнче карыйсы, ашатасы, сугарасы. Кул бушамый. Ә жан тыныч—монысы яхшы. Жәй коры килсә дә, янгырлар да куандырып киткән иде. Печән күп, Аллага шөкер. Ике базлагы бәрәнге белән мал чөгендере дә житәрлек. Келәттәге ашлык та шактый мул. Кибет хәлләре генә мөшкел дип... Аллага шөкер, жанын теләгән бар да бар. Уч төпләрен кычыттырырдай акчасы гына артык юмартланып китәргә ирек бирми. Монысы бөтененә тигез инде. Мирдән узып булмый. Тиз көндә жайланыр да шикелле түгел. Телевизор әйтеп торган хәвеф-хәтәрләрне генә күрергә, кичерергә язмасын. Ул кара-каршы атыш, жимерү, кан кою,

жан кыю өннәрне алып бетерде. Ил кырыкмаса-кырыкка таркалды, бүлде. Саулык бирсен дә йорт-жирең бөтен торсын инде. Калганын күз күрер тагын. Хәер, кичермәделәрме соң? Кичерттерделәр!

Менә бүген хуҗалык өстәмә салам бүлде дә бер трактор арбасы кадәрлесен аударып киттеләр ич әле. Анысы печәне тезмәләргә дә шыплап тутырылган, лапаска да өелгән, бер чүмәләсе бәрәңге бакчасы башына да очлап куелган. Иншалла, күз тимәсен. Саламы да әйбәт. Сап-сары, төп буйлары алланып тора, эт эчәгеле, зәңгәр чәчәкле, билчәнле, коры. Берике күтәрәм кадәресен яңгыр каралтканы, салкын катырганы да эләккәнэләгүен. Зыянлы түгел. Маллар астына түшәргә ярап куя ул. Саламсыз тирес була димени.

Йөкчеләр риза-канәгать калды бугай. Саламны бушаткач, өйгә керделәр. Акча-фәлән бирү бетте бит инде. Лотфия апалары итле аш сосканда тамак кырырга да өлгермәделәр, алларына тып итеп кызыл чөгендер белән алсуланылган әче бал банкасы килеп кунды. Аларга тагын ни кирәк? Берике кашык аш кабып куюга, чынаякларын күтәрделәр. Шуннан соң, чүпрәсенә төшеп житкәнче, тозлы кәбестә генә шыгырдаудан туктамады. Сүз өчен шул саламны мактадылар инде. Дөнья хәлләренә кереп тормадылар. Жае ул түгел. Бүтәннәргә дә кайтарасылары бар әле. Әйтмәделәр димәсеннәр өчен генә шикелле, аларның быел язын Әзәрбәйжанда үтерелеп кайтарылган полковник Минзөфәрләрен искә алдылар да кузгалдылар. Болдырда тәмәке кабызып тарткан арада «Лотфия апагыздан яшереп кенә тотылган нәрсә» дигәнне бик аңлаган кыяфәттә бер литрлы банканы кабымлыксыз гына өстәделәр дә тагын кырга чыгып киттеләр.

Сәнәк сабы очын иягенә терәп, Расих салам өеме янында ялгызы басып калды. Бераздан ярдәмгә Лотфиясе чыгып житәр.

Ян бакчаның рәшәткәсе өсли генә атып, саламны чүмәләгә куясы. Куелыр. Кайткан ич әле. Бар. Менә. И, әүвәл! Шуны үзең ашардайга житеп, бер учына тилмергән заманнар! Кар явып торамы, жирдән себертәме—кышкы кичләрдә генә чанада тартып, язгы болытлы төннәрдә генә күтәреп алып кайткан чаклар... Рөхсәтсез генә инде. Йөрәге житеп, сина кем рөхсәт итсен? Богыл төбендә калган карлы-бозлысын бит әле ул. Үз йөрәгеңне төн жәтмәсендә чабак балыгыдай чәбәләндерә-чәбәләндерә урлаудан кала бүтән чарасы юк иде ич анын. Урлау иде микән соң әле ул? Атаң шул бер чаналык, йә күтәрә алганчыдан да авыррак итеп бәйләнгән бер көлтәлек салам хакын да хаклап, сугышта башын салмаганмыни? Айсыз, болытлы төннәрне сайлап кына, жан тирен чыгара-чыгара алып кайтырга яраган ул салам урлаганга санала икән, анын гомере өзелү урлауның иң зурысы булмаганмыни? Атны дилбегә белән тыйгандай, йөрәгеңнен ярсып тибүен арка бавы белән тыя-тыя кайтып кергәннең соңында әнкәң тамак ялгарга тәгәрәткән бәрәңгедән гайре ризык заты тапмый икән, ул әнкәннең шуңа оялуы әлеге урлау оятыннан кечерәк идеме әллә? Сәкедәге ике кызыңның, бишектә яткан улыңның тәмле йокысын тоя-тоя, беләкләрең талганчы, маңгай тиреҥ чишмәдәй ургып чыкканчы хатыныңны яратасы урынга икәүләп әллә кайдагы көртләр баскан салам богылына таба чыгып китәсең икән, синең ул беләк талуыңны, тир тамчыларыңның кайнарлыгын югалтуың кайсы ягы белән бер күтәрәм салам урлаудан кечерәк иде, йә? Әй! Нинди урлау ди инде тагын? Дөньяның өзелеп төшкән керфегенә дә тимичә яшәделәр ләбаса!

Шулай, колхоз авылдан ике чакрым ераклыктагы Ялпы тавы каршындагы салам богылын ташытып бетергән иде. Кул чанасы тартып, Расих белән Лотфия төнлә шуның калдык-постыгына дип киттеләр. Сәнәк сабын тилгән канатыдай талгын гына айкый-айкый, кар баскан туң саламны каерганда Расих нигәдер аркан борылып карады. Әллә ничек—янында хатыны юк шикелле тоелып китте. Ә ул шунда икән. Каерып чыгарган саламны чанага төявеннән туктаган да, төягән кадәресенә аркасын терәп, кинәт аязып киткән кара күктәге айга карап тора. Ә ай тулган, якты иде. Шуның фаш итеренә өркеп киткәнме соң дип уйласа, юк икән, тәмам онытылган, ай нурына йотылган, монда түгел,—әллә кайда. Шунда—айда иде, ахрысы. Расих сәнәген кадады да, төнге авыл урамына кергән чакта карны шыгырдатмый йөрергә күнеккән гадәтенчә, сак кына аңа таба атлады.

Янына житте, ай нуры зәңгәрсу-алтын төскә манчыган йөзенә карады. Күрде, тойды: Лотфиясенең япан кырдай чиксез моң, ниндидер үкенеч, рәнжеш белән тулы битендә, бәләкәй-бәләкәй айлар булып, күз яшьләре ялтыраша иде. Фәкать иң беренчеләре генә ирен почмагында туктаган да мәржәндәй агарып калган. Мыегындагы боз сөңгеләре белән чәнчеләсен дә онытып, ул иренен башта бер, аннары икенче мәржәнгә тидереп-тидереп алды. Әлеге бөртекләрнең тозлы боз салкынын тояр шикелле иде дә—юк, эретелгән ике тамчы кургаш йотып жибәргән сыман булды. Ә аннары... алтынланып яткан саламның салкын кочагында әллә тычкан чыелдады, әллә тыенкы гына итеп Лотфиясе көлеп куйды. Расих үзе моны ишетмәде дә кебек. Ә менә ялгыз ай күргәндер. Бәлки көнләшкәндер үк. Шушы тау итәгендәге түгәрәк күл буенда үсә торган алпут гөлләренең ал чәчәкләре ачылып киттемени! Аның көлүе шулай тоелды... Анысы Лотфиясен аннары соң да шулайрак көлдергәләгәне булгандыр инде ул. Тормыш ич бу. Тик нәкъ шул чактагы ишесен бүтән ишетмәде бугай дисә ничек инде... Ие.

И, дөнья диген! Нечкә генә алтын сабакта тибрәлгән ач башаклы гомер. Юк, юк, ни генә дисән дә,—тук башаклы, тук. Бугай.

Шуларны уйлый-уйлыймы, искә төшерә-төшерә, хисләнә-хисләнәме, хәзер ул капка төбендәге саламның бер күтәрәмен алдына жайлап куйды, ана иплән кенә сәнәгеп батырды. Нәкъ элеп алам да рәшәткә башыннан бакчага атам дигәндә генә ниндидер бер саламның шартлап сынганын ишетеп алды. Әллә сәнәк сабымы? Йөрәгенә башта энә очы тиеме соң, аннары күгәрек кадак килеп кердеме, анысы урынына очында бер тамчы су тамам-тамам дип торган сырлы-сырлы боз сөңгесе кадалдымы...

Күз алмасын башак кылчыгы чәнечкән шикелле генә булды.

Ара

Аерылышканнар иде инде. Жәйге чилләдән соңгы энгер-менгер узып, караңгы төшкәч, бер хатын зират каршындагы өйнең бикләнмәгән капкасын ачып узды да болдыр ишеге төбендә тукталып калды.

Ул һәрвакыттагыча зәһәр итеп:

—Миргазыян!—диде.

Шуны гына көткәндәй, өй ишегенең тупсалары шыгырдады да бер ирнең йомшак тавышы ишетелде:

—Әү, әү... Синме, Зөләйха?

—Мин ием әле.

—Берәр хәл чыкты мәллә?

—Жук.

—Балаларыбыз ни хәлдә?

—Жахшы!

—Суң?

—Ни... мунча жакканыем.

—Әйбәт булган.

—Кайт, кереп чык.

—Мин чыктым инде.

—Каян?

—Мунчадан.

—Кемдә?

—Кемдә булсын—үземдә.

—Жаңгызынмы?

—Жаңгызынмы, дип... Синең белән түгел ич инде.

—Кем белән суң?

—Үзем.

—Әйдә, кайт. Арканны уармын.

—Удылар да.

—Кем?

—Син түгел ич.

—Кем?

—Әйтәм ич—син түгел инде.
—Сабын... мунчала...
—Шәп булды, шәп.
—Чәченне җуарга... кычыткан суы барыемы сон?
—Җук. Ул моны белми әле.
—Кем?
—Син түгел ич инде.
—Кем суң?
—Белмисең әле.
—Кемне, Миргазыян?
—Аны инде. Кемне булсын тагын?
—Кемне?
—Җарар. Ниттем инде... беренчесенә баштанаяк җуындырып чыгардым. Аңынчы шәпләп чабындырдым.
—Мине шикелле мени?
—Сине шикелле шул. Бүтәнчә нишлим суң?
—Әйбәт булдымы?
—Әлбәттә. Әнә, жоклап ята. Эреп. Синең шикелле... Исендәме?
—Исемдә.
—Бар, өйгә кайт инде.
—Кайтмыенча кая барыйм суң?.. Ә син?
—Мин калыйм инде.
—Җалгызыңмы?
—Нигә ялгызым булыйм ди? Әйттем ич: эреп жоклый әнәтерә.
—Кем? Кем?
—Син түгел шул инде, Зөләйха.
—Әй!
—Җахшы, җәме? Бар, өйгә кайт. Балалар көтәдер.
—Алар сине көтә.
—Ярар... җарар, көтмә инде. Булды-бетте, җәме?
Шул чакны өйдән берәүнең:
—Миргазыян,—дигәне бу хатын белән ирнең арасын төнге ярканаттай ярып узды.
—Әнәтерә, дәшә,—диде Миргазыян.
Шуннан соң Зөләйха айлы төнне сагайтып, каршысына өреп чыккан этләргә һичнинди илтифат итмәстән, өенә кайтып керде дә... яккан мунчасына кереп, баштанаяк юынды. Каен себеркесе белән бетенгәнче чабынмакчы иде дә... мунчасының пары сүрелгән икән шул инде. Чүмеч белән селтәп торып су җилпесә дә, мунча ташлары әллә «пыш», әллә «сез» дигән шикелле генә чыжылдады. Ә каен себеркесенең уртасына кушып бәйләнгән зәңгәр мәтрүшкәләрдән аның Миргазыяны исе килә иде шикелле.
—Әй!—дип Зөләйха шул ис белән әллә наз тансыклаган имчәкләрен уды, әллә шунда мунчаның бәләкәй тәрәзәсеннән ургып кергән тулган Айның сары йөзен юды.
Шунда аның Миргазыяны булсамы? Зөләйха:

> Алым җәл түгел сиңа,
> Гөлем җәл түгел сиңа,—

димәс идеме дә, Миргазыяны:

> Әллә ниләр бирер идем
> «Аһ» дигән сүзләренә,—

дип әйтмәс идемени?
Зөләйха бу мәлдә зират турысындагы өй болдырының биек ишеге төбендә тәмәке тартып утырган иргә өй түреннән берәүнең:
—Ни... Нитмә инде... Кил, ят,—дигәненә Миргазыяның:
—Мин нитәм әле... монда гына җатып торыйм булмаса,—дигәнен каян ишетсен соң?
Ерак ич. Дүрт өй аркылы. Яшәү белән зират арасы. Аяк арасы гына түгел.

ШАГЫЙРЬНЕҢ РУХ БИОГРАФИЯСЕ

ФӘРИТ ГАБДЕРӘХИМГӘ 70 ЯШЬ ТУЛУ УҢАЕННАН

Шигырьне шагыйрьнең рух биографиясе диләр. Чөнки шигырьдә аның тормышны тануы, күз алдына китерүе, ничек кабул итүе ачык чагылып тора. Шуңа күрә, гадәттә, шигырьләр аларны иҗат итүченең үзенә охшап торалар сымак. Миңа, Башкортстанда яшәп иҗат иткән шагыйрь Фәрит Габдерәхим белән кырык елга якын аралашып яшәгән кешегә, аның әсәрләре һәрвакыт үзен хәтерләтеп тора. Шигырь һәм поэмаларын укыганда, мин аның үзе белән кара-каршы утырып сөйләшәм кебек тоела. Гүяки, шагыйрь, гадәтенчә, әкрен генә, сабыр гына әңгәмә алып бара, тормышыбызның төрле гыйбрәтле, хәтта фаҗигале хәлләрен бәян итеп, үзенчә ачык һәм үткен нәтиҗә ясап куя сымак. Һәрвакыт сабыр холыклы, тавышын һич тә күтәрмәс, ашыгып-чәпчеп бармас, яңгыравыклы пафоска бирелмәс Ф. Габдерәхимне якыннан белгән кеше аның эчендә нинди дәрт уты дөрләвен, йөрәге нинди хис-тойгылар белән януын, әкрен генә сүзләре, тормыш-көнкүрешнең гади генә тоелган хәл-вакыйгалары һәм детальләре артында никадәр тирән фикерләр, халкыбыз язмышы турында олы хәстәрлек ятуын күрә, аңлый. Әнә шул тирән тойгылары, фикер-карашлары аның шигырьләрендә өстән караганда гади генә итеп, әмма йөрәккә сеңәрдәй итеп әйтеп бирелә.

Фәрит Габдерәхимнең кырык елга сузылган иҗат юлы ике чорга бүленеп тора. Билгеле булуынча, үткән гасырның егерменче еллары азагыннан—утызынчы еллар башыннан татар әдәбияты үсешен Татарстан автономияле республикасы кысаларына кысрыклап сыйдыра башлагач, элек-электән бу әдәбиятның икенче бишеге булып торган Башкортстанда яшәп иҗат итүче әдипләр ике юл чатында торып кала. Күңелендә туган телгә тугрылык тойгысы көчле булганнары Казанга юнәлә, туган туфракка тугрылык тойгысы өстенлек алганнары үз җирендә торып кала һәм әсәрләрен башкорт фонетикасында һәм орфографиясендә бастыра башлый. Тәүге утыз еллык иҗат гомерендә Фәрит Габдерәхимовка да менә шушы ике тойгы аймылышкан заманда, Уфада татар телендә китаплар нәшер итү мөмкин булмаган елларда, үзенең шигырьләрен һәм поэмаларын шул рәвешле дөньяга чыгарырга туры килә.

Ул чакта татар телендә иҗат итүчеләрнең үз укучылары белән сөйләшү чарасы булып, бердәнбер «Кызыл таң» газетасе хезмәт итә. Туган туфрагыннан аерылмаган килеш татар әдибе булып калу омтылышы белән янган Ф. Габдерәхим озак еллар буена шушы газетәнең әдәбият-сәнгать бүлеге белән җитәкчелек итә, республикада татар әдәбияты кузын сүндермәс өчен тырышлык сала.

Шагыйрьнең бу дәвердә язылган әсәрләрен берләштерә торган төп мотив—кеше һәм туган җир, кешенең тормыштагы, үз заманындагы һәм буыннар чылбырындагы урыны

турында уйлану. Кешене, аның җирдәге вазыйфасын шагыйрь күп яктан (гыйльми тел белән әйткәндә, төрле параметрдан) торып карый: ул үз өстенә тарих тарафыннан, кешелек тарафыннан йөкләтелгән вазыйфаны тәгәл һәм туры башкарамы, әлеге көндә яшәүчеләр бәхете өчен гомерләрен корбан иткән атаклы һәм исемсез батырларның, халыкның иң гүзәл сыйфатларын сакларга һәм үстерергә васыять әйтеп калдырган элекке буыннарның әманәтенә тугрылыклы булып кала аламы, киләчәк алдында үзенең җаваплылыгын ничек тоя—менә шулар уйландыра һәм борчый шагыйрьне. Бер әсәрендә ул замандашының зур эшләренә горурлану хисен яңгыратса, икенчеләрендә байтак кына кешеләрнең гадәт-холыклары турында ачынып уйлану, киләчәк буын хакында хәвефләнү дә ишетелеп тора. Җирне фашизм гарасатыннан саклап башын салган билгесез солдат тарафыннан казылган окоп өстендә утырган йортта бүген кемнәр яши, һәм алар әлеге солдат истәлегенә тап төшермиләрме—шул хакта уйлана Ф. Габдерәхим.

Тамырларын онытабыз бугай
Әбиләрдән калган гөлләрнең;
Гамьсез генә таптап үтмибезме
Бабайлардан калган көлләрне?!—

дип борчыла шагыйрь.

Әйтергә кирәк, шундый борчылу-уйланулар Ф. Габдерәхимнең әсәрләрендә күп урын алсалар да, беренче чор иҗатында ак һәм алсу төсләр дә байтак (ул, гомумән, аклыкка гашыйк). Шигырьләренең һәм поэмаларының үзәгендә, нигездә, әйбәт кешеләр, җирне ямьләү өчен килгән шәхесләр тора. Аның лирик герое—актив иҗатчы, тормыш хозурлыгы өчен армый-талмый көрәшүче, хәтта шуның өчен гомерен корбан итүче шәхес. Ул күбесенчә яшәешнең иң авыр, иң кискен мәлләрендә күрсәтелә, шул авырлыкны горур узуы белән биек йолдызларга тиңләштерелә («Карадым да имән башларына...», «Җирдәге йолдызлар», «Сынау» һ. б.). «Кеше булса...» дигән шигырьдән бер детальгә генә игътибар итәсе килә: йөзьяшәр имән, давылга каршы торалмыйча, төбе-тамыры белән куптарылып, гөрселдәп ава. «Кеше булса, кабат торыр иде. Ул имән шул, бары тик имән...» дигән нәтиҗә ясый шагыйрь. Артыгын сөйләп торуның да кирәге юк.

Кешене эше, кылган шөгыльләре аша конкрет гәүдәләндерү, киңәйтелгән шигъри параллель-янәшәлекләр, көтелмәгән кабатланмас үзенчәлекле чагыштырулар куллану, үткер-үткер детальләр табу нәтиҗәсендә шагыйрь үткәннең һәм бүгенгенең әйбәт шәхесләрен дә, тискәре сыйфат ияләрен дә күңелгә сеңдерерлек итеп сынландыра. Ул сурәтләгән шул кешеләрнең иң күркәмнәре, ихтимал, хатын-кызлар, әниләрдер. Әтисе немец фашистларына каршы көрәштә һәлак булгач, әнисе тәрбиясендә һәм аңа ярдәмләшеп үскән Фәрит Габдерәхим ана образын аеруча бер ихтирам белән сурәтли.

Аның әсәрләрендә туган җир темасы шушы горур һәм нык характерлы кешеләр образы белән аерылгысыз бәйле. Бу туган җир турында җырлауда автобиографик моментлар да күп кенә. Ул аның туган авылы Арслан булып та (шагыйрь бүген дә шушы үз авылында көн итә), районы Бүздәк булып та, Кандра күле, Чәрмәсән буйлары булып та гәүдәләнә.

Мәгълүм ки, совет заманында конкрет бер халык, бигрәк тә үз милләтең турында аерып кына язу хуп күрелми иде. Ф. Габдерәхим дә, безнең буынның һәрбер шагыйре шикелле, үз заманының улы булды, чор идеологиясе киртәсен җимереп чыкмады.

Туксанынчы еллар җитеп, илдә һәртөрле үзгәреш-борылышлар башлангач, Ф. Габдерәхимнең дә, шагыйрь буларак, икенче сулышы ачылды. Ул Башкортстан татарларының хокуклары өчен барган милли хәрәкәтнең үзәгендә кайнады, республиканың Язучылар берлегендә татар язучылары секциясен булдыру өчен көрәш алып барды, моңа кискен каршы торучыларга протест йөзеннән Язучылар берлеген ташлап чыкты.

Электән дә шигырьләрендә «Халык, хаклык, көрәш—иманым!» дип язган Ф. Габдерәхим әсәрләрендә хәзер инде халкы конкрет атала: хәзер бу—тарих борылышларында күптөрле фаҗигаләргә юлыккан, әмма барыбер сынмаган, иркен,азат яшәренә өметен өзмәгән татар халкы. Аның «Кичер мине!..» (1995), «Синең белән мин» (2000) дигән җыентыкларында башлыча әнә шул милли азатлык темасына, ә күбрәге—Башкортстан татарлары язмышы мәсьәләсенә багышланган шигырьләре тупланды. Бу әсәрләрдә шигъри образ-детальләр муллыгы публицистик кайнарлык белән кушылды. Шагыйрь бер үк вакытта киная белән сөйләп туры тидерүче хикмәт иясе булып та («Бер ялгызы кайткан сыерчыгым...», «Егерменче гасыр урманы», «Чабак, табан, чуртан», «Эш аты»), әйтер

сүзен чатнатып әйтүче трибун булып та күз алдына баса («Кичер мине, халкым!», «Күңел зинданында», «Булыр микән?», «Тозак», «Ялган», «Үз Тукаен якса...»).

Бүгенге тормышта тулып яткан юньсезлекләр, үз кесәсен генә кайгырткан бәндәләр турында язганда аның әсәрләренә ачы сатира да килеп керә.

Менә шулай, Фәрит Габдерәхимнең иҗаты һаман үсә, төрләнә бара. Әле җитмеш яше тулган көннәрдә дә ул:

Якты көннәр ягына табан
Үз җырымны җырлап атлармын,—

дип белдерә. «Изге юлында арып калмасын, үз җырын җырлаудан тынмасын», дип теләргә генә кала шагыйрьгә...

Суфиян САФУАНОВ,
әдәбият галиме,
Уфа.

Фәрит Габдерәхим

МИЛЛӘТ БУРАСЫНА—БӨРТЕКЛӘРЕМ

Уйга чумдым

Каккалады-суккалады Тормыш,
Җегәрлекне тәмам бетерде.
Уйга чумдым: милләт бурасына
Сала алдым микән күңелемнең
Тик бер генә энҗе бөртеген?!

Каурый каләм

Шатлык җыры язармын дип,
Кулга алдым каурый каләм.
Сырлый каләм башка көйне,
Язган җирдән туктап калам.

Каурый чакта каләмемне
Давыллар каергангамы,
Җырларымда газап чигә
Кимсетелгән халкым җаны.

Сөрем аша

Киң күңелле Кояш: бердәй бага,
Миңлесенә бага, миңсезенә.
Милесенә бага, мисезенә,
Динлегенә бага, динсезенә...
Шат елмаеп бага—иллесенә,
Сөрем аша бага—илсезенә.

Әйтмәсләрме?..

Утызынчы еллар. Авылларны
Тоташ коллективлаштырдылар.
Спартаклар кызганырлык итеп
Өр-яңадан коллаштырдылар.
Киләчәктә, бу сүзләргә өстәп,
Әйтмәсләрме: «Клонлаштырдылар».

Давыл

Купты хәтәр давыл,
Коеп яуды яңгыр.
Юк ла, яңгыр түгел,
Башка уклар яуды.
Иңрәп илем ауды.
Гыйфрит канны сауды.

Кабат купты давыл.
Бусы—кемнәр давы?
Сүтелә гыйфритнең
Бирән җәтмә—авы.
Ял итә чайкалып
Дарның элмәк-бавы...

Ярап тора

Топтыгин исемле Аю ята
Түр башымда. Усал карап тора.
Их, ботарлар иде—яраланган.
Миңа әле бу да ярап тора.

Топтыгинның яраннары уңган:
Яраларын көн-төн ялап тора.
Атларында җилдерәлми әле.
Монысы да миңа ярап тора.

Түбәтәйле җегет казан аскан,
Сумаласы хәтәр кайнап тора.
Топтыгинның исә коты очкан,
Казан тарафына карап тора.
Миңа әле бу да ярап тора.

Бүре мин

Мин төлке дә түгел, эт тә түгел,
Төрки кавем башы—бүре мин.
Ничә гасыр инде аучыларның
Канлы күзләренә күренмим.

Югарыда иде минем урын,
Төрки ту[1] да иде—яшермим.
Инде хәзер дастаннарда гына,
Әкиятләрдә генә яшимен.

Тарих җилләрендә сәлам юллыйм
Аучыларның соңгы туена.
Мин исән бит! Менәчәкмен кабат,
Менәчәкмен төрки туыма.

[1]Ту *(борынгы төркичә)*—байрак.

Ялгышалар

«Татар» диләр безне әүвәлгечә,
Ялгышалар. Татар түгел без.
...Җиде бабабызны беләбезме?
Берсен генә белә күбебез.

«Белсәң—ярый, белмәсәң дә—ярый»,
Хаҗәте юк андый белемнең.
Бөек телле буласылар килә,
Кирәге юк татар теленең.

Рәхәтләнеп хәмер чөмерәбез,
Баш ватмыйбыз уйлап ахырын.
Су койганда чит-ят тегермәнгә,
Тирләп чыгарабыз махмырны.

Мокытлар дип уйламагыз тагын,
Аерабыз актан караны.
Хуҗа әйтмәсә дә, бик беләбез
Нәрсә ярый, нәрсә ярамый.

Хуҗа алдында тезләнергә ярый,
Мескенлеккә ярый түзәргә.
Һич ярамый аяк-куллардагы
Зынҗыр-богауларны өзәргә.

Ә бабайлар ярлык өләшкәннәр...
Без аларга бүген тиңмени?!
«Татар» диләр безне. Ялгышалар.
Татар шундый була димени?!

Чигенмәскә!

Велика Россия, но отступать некуда:
позади—Москва!

Тарих шаһит: куркаклыктан түгел,
Ызгыш-талашлардан җиңелдек.
Җиңелдек тә мал-мөлкәтне төяп
Күрше арбасына җигелдек.

Без бүген дә әле ул йөкләрне
Бушатабыз күрше келәткә.
Чигенәбез иман-денебездән,
Күченәбез чит-ят милләткә.

Азат биләмәдән—кем сатылып,
Ә кем канын түгеп—чигенде.
Телдән чигенәбез: бирмәсләрме
Богауларның, имеш, җиңелен.

Җитте! Чигенмәскә! Аяк терәп
Басарга бар тулы хакыбыз.
Артыбызда бер карыш та җир юк,
Артыбызда Тарих, халкыбыз!

Ә барыбер...

Җүләр сыман һаман мактанабыз,
Хакыйкатьнең карыйк күзенә.
И татарым! Ераккарак китеп,
Ник бакмыйсың икән үзеңә.

Ташланасың утка,
Ләкин син бит
Кыю гына түгел, куркак та.
Бер сызгырса хуҗаң, «баш өсте!» дип,
Юргалыйсың күндәм юртактай.

«Халык таркау!»—дисең,
Ә бит үзең
Кабатлыйсың бабаң хатасын.
Саесканың шыкырдасын өчен,
Милләт сандугачын сатасың.

Үч итеп син беткә, ягасың тун...
Яратырга сине хакым юк.
Ә барыбер сине яратам мин:
Синнән гайре бүтән халкым юк...

Ярап булмый

Кемдер тыңлый каш җыерып кына,
Кемдер хуплап, ихлас кул чаба.
Булмый ярап бөтен кешегә дә,
Бер Ходайга ярап булса да.

Бәхетлерәк

Урман яна. Агачлардан
Кисәү генә калыр тиздән.
Белми алар шушы хакта,
Бәхетлерәк алар бездән.

Китәселәр килә

Куштаннарны, икейөзлеләрне,
Их, яшисе иде күрмичә!
Китәселәр килә бу дөньядан,—
Китеп булса иде... үлмичә.

Drama əsərlərə
Драма әсәрләре

Гөлшат Зәйнашева

НӘРСӘ БУЛДЫ БЕЗГӘ?..

ТРАГЕДИЯ. 2 ПӘРДӘДӘ, 7 КҮРЕНЕШТӘ

Катнашалар:

Сәрия
Рәүф
Энҗе
Ильяс
Сажидә
Әмир
Банат
Шәмсия
Фәһимә
Кәбирә

Беренче пәрдә

Беренче күренеш

Авыл. Күмәк хуҗалык идарәсе. Рәүф кабинеты. Уң якта җиңелчә бүлеп куелган секретарь бүлмәсе, өстәлендә компьютер. Рәүф белән Сәрия керә.

Рәүф. Кайтып життек, Сәрия кызым!.. Безнең авылның Кремле, Ак йорты шушы инде!..

Сәрия. Ак йортыгыз матур!

Рәүф. Быел гына төзеп бетердек. Утыр, ял ит!

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА (1928)—шагыйрә, драматург. «Тыңларсыңмы җырымны», «Без Казан кызлары», «Гөлләр иле», «Мәхәббәт һәм җыр», «Пьесалар» һ. б. китаплар авторы. Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1991). Казанда яши.

Сәрия. Ял итәрлек армадым ла!.. Шундый яхшы машинада очып кына кайттык бит!.. Авылыгыз матур!

Рәүф. *(Өстәл янына чакырып).* Эчәсең килсә, менә шифалы су бар.

Сәрия. Рәхмәт!.. *(Су эчә).* Бик тәмле су. Каян бу?

Рәүф. Хәмдия чишмәсеннән. Безнең авыл чишмәләренең суы әллә кайлардан китергән минераль сулардан шәбрәк! Элек заманда, Хәмдия исемле бик чибәр кыз безнең авылга килен булып төшкән дә, чишмәгез бик ерак дип зарланган. Кайнанасы: «Зарланма, килен! Чишмә ындыр артында гына булмый ул!» дигән. Килен: «Бик тырышып казысаң, ындыр артында да чишмә чыга!» дигән дә, шушы чишмәне казыган. Менә нинди киленнәр төшкән безнең авылга!..

Сәрия. *(Секретарь бүлмәсендәге компьютер янына килеп).* О!.. Нинди яхшы компьютер алгансыз!.. Шәп!.. Шәп!..

Рәүф. Бик шәбен алган идек тә... Эшләтә алмыйбыз бит әле.

Сәрия. Эшләтербез!.. Эшләтербез!..

Рәүф. Бөтен өмет синдә! Секретарь кызыбыз машинкада әйбәт баса иде дә... Компьютерда булдыра алмый әле.

Сәрия. Өйрәтербез, борчылмагыз, Рәүф абый, өйрәтербез!

Рәүф. Әнә үзе дә килде.

Энже керә.

Энже. Исәнмесез?

Рәүф. Энже, Казаннан бер дустымның таныш кызын алып кайтам дигән идем бит, менә үзе—Сәрия сеңелкәш!

Энже. *(Кул биреп).* Энже. Сезнең килүегезгә бик шатмын!

Сәрия. Сәрия.

Рәүф. Вакытлыча гына дип килде. Авылыбызны яратса, күңеленә ошаган егет тә табылса, кияүгә бирербез үзен!.. Алла бирсә! Киленебез булыр!..

Сәрия. Белмим... Белмим...

Энже. Шәһәр кызлары авылны яратмый алар. Шәһәрдән, әти-әниләре яныннан китеп, авылда яшәргә...

Ишек шакыйлар.

Рәүф. Керегез!..

Ильяс керә.

Ильяс. Рөхсәтме? Рәүф абый, кешеләрегез бар икән... Мин чыгып торыйм... Соңыннан керермен. *(Кире чыгып китмәкче).*

Рәүф. Ильяс! Чыкма! Сүзең бар идеме? Әйт, әйт! Чит кешеләр юк монда. Менә Казаннан бер кыз алып кайттым, Сәрия исемле. Компьютер белгече... Курслар бетергән. Идарә кызларын өйрәтер. Мәктәпкә дә компьютерлар алабыз. Укытучыларны да өйрәтер.

Ильяс. *(Сәриядән күзен алмый).* Һәм... һәм мине дә!..

Сәрия. Теләсәгез, сезне дә өйрәтербез!

Рәүф. Әллә сез танышлар булып чыктыгызмы?

Ильяс. Юк... ни... Әлегә таныш түгел... Танышырбыз! Шуны әйтим дип, ашыгыч кына керүем... Рәүф абый, беркөнге давылда ауган бодай кырын карап кайттым... Хәйран гына күтәрелеп килә... Минемчә, артык зыян юк... Борчылмагыз. Бер өч көннән ура башларга була.

Рәүф. Рәхмәт яхшы сүзеңә, энекәшем!..

Ильяс. Ярый, мин киттем!.. Чөгендер көтә! Чөгендер эшкәртүчеләр мәзәге: Түбән оч Фәридун абзый хатыны Гыйльмижиһан түтигә: «Еллар буе башыңа бер яулык бөркәнеп йөрисең, туйдым бу яулыгыңнан!»—дип бәйләнә икән. «Нишлим соң? Башыма синең аракы шешәңне киеп йөри алмыйм бит мин!»—ди икән хатыны. Пока! Сау булыгыз!.. *(Чыга).*

Рәүф. Безнең әнә шундый күңелле егетләребез бар! Клубта кызлар «Гөлчәчәкләр» ансамбле оештырды. Бергәләшеп җырларсыз. Дискотека да эшли. Күңелсез булмас!

Энже. Егетләр генә күңелсезлек ясап куя. Кичә Инсаф эчеп килгән иде... Магнитофонын да эшләтә алмады.

Рәүф. И дуңгыз малай!.. Әтисе белән бик каты сөйләшкән идем. Каеш белән ярам дип бик кызган иде.

Энже. Ярган диләр, каеш белән дә ярган диләр...

Рәүф. Кыйнап кына булмый ул!.. Каян алалардыр шул шайтан суын? Урак өстендә авылда аракының исе дә чыкмаска тиеш дип күпме тырышам?! Юньсез малай булып чыкты ул. Клубны ана тапшырып ялгыштым. Ярый, Сәрияне фатирга урнаштырыйк. Сәрия сеңелем, гафу ит инде, безнең

кунакханәбез юк әлегә. Үзәктән аерылып чыкканыбызга өченче ел гына. Кунакханә төзи алмадык әле. Яшьләр өчен йортлар төзибез анысы. Озакламабыз, өлгерү белән сина бүлмә бирербез. Пока сине бик әйбәт бер апага фатирга урнаштырабыз. Ялгызы гына яши. Улы бар да, Армиядә... Өе бик чиста. Үзе әйбәт хатын. Үзебезгә генә алып кайтыр идем сине, минем семья зур. Оныклар бик кечкенәләр... Бик шаяралар, шау-шу, ыгы-зыгы... Ял итә алмассың.

Сәрия. Мина кайда да ярый.

Рәүф. Энже, бар, Сәрияне Сажидә апаңнарга илтеп куй! Сөйләшенгән, килешенгән. Бүген урнаш, ял ит, иртәгә иртәнге сигезгә идарәгә кил, эшкә башла! Менә сина ачкычлар! *(Сәриягә ачкычлар бирә).*

Сәрия. Ярый, Рәүф абый! Барсы өчен дә рәхмәт!..

Энже. Киттек Сажидә апаларга! *(Сәрия белән чыгалар).*

Рәүф. *(Телефоннан сөйләшә).* Алле! Кара әле, кичә клуб малае исерек булган... Каян алды икән?.. Син саткансыңдыр димим! Мин сина ышанам. Бу дуңгыз малай каян алды икән дип аптырыйм. Складың исәнсаумы?.. Пичәтләнгән килешме?.. Давай, аракы, дип аптыратмыйлармы?.. Булгалый?.. Кемнәр?.. Син аларны мина җибәр!.. Мина!.. Пока! *(Трубканы куя).*

Икенче күренеш

Сажидә йорты. Җыйнак, чиста. Җиһазлары гади. Сәрия белән Сажидә чәй эчеп, сөйләшеп утыралар.

Сажидә. Син кызым ялындырып торма, мунчадан соң эчәсе килә бит ул!

Сәрия. Рәхмәт апа, рәхмәт! Мунчагыз өчен дә, сыйларыгыз өчен дә зур рәхмәт! Минем йокы алдыннан гомергә болай күп ашаганым, күп чәй эчкәнем юк иде. Бик тәмле булды! Сөтле чәегез дә, тәбикмәк дигән коймакларыгыз да искиткеч тәмле!

Сажидә. Амин тотыйк алайса! Әгузе ... *(Пышылдап дога укый).* Алла һәкбәр!.. *(Амин тоталар).* Яратып ашагач, үзенә рәхмәт инде, Сәрия кызым! Шәһәр кешесенә авыл ризыгы тансыктыр. Хәер, синең әниең дә авыл кызы булса, тәбикмәк, кыстыбый кебек ризыкларны оста пешерәдер.

Сәрия. Минем әнием юк, апа. Бер кемем дә юк. Мин интернатта үстем.

Сажидә. И-и-и, балакай!... Татарча бик яхшы сөйләшәсең, детдом балалары, бичаралар, үз телен онытa бит алар.

Сәрия. Онытмадым. Татар теленнән гел бишле ала идем... Алты яшькә кадәр әбием үстерде... Әбиемне бик яхшы хәтерлим. Мине бик ярата иде. Әбием сөйләгән әкиятләр онытыламы соң?

Сажидә. И балакай! бер кемең дә юк икән. Кияүгә дә чыкмадыңмы әле?

Сәрия. Юк әле! Нинди кияү ди ул мина? Былтыр гына урта мәктәпне тәмамладым.

Сажидә. Алай бер ялгызың авырдыр бит?

Сәрия. Әллә тагын. Мин өйрәнгән инде, апа.

Сажидә. Кияүгә чыгып үз гаиләң булса, алла бирсә, ялгызлыктан котылырсың әле. Әйбәт кешесе генә туры килсен... Безнең рәис әллә туган тиешлеңме дип уйлаган идем.

Сәрия. Юк, Рәүф абый безнең директорның якын танышы. Мине вакытлыча эшкә чакырды. Институтка кереп булмады бит. Конкурс бик зур. Бер-ике ел эшләп, бераз акча җыеп булса, институтка да керермен әле дип хыялланам.

Сажидә. Әйе, институтка акчасыз кереп булмый диләр шул хәзер. И институт, институт дип... институт бетермәгәннәр дә менә дигән яшиләр анысы. Минем Әмирем дә институтка керергә хыялланган иде дә... Армиягә алдылар... Бу арада хаты юк әле. Бик борчылам!

Сәрия. Кайтыр, исән-сау гына булсын! Кайткач, укыр.

Сажидә. Ярты ел гына хезмәт итте шул әле.

Сәрия *(Стенада рамага куелган*

фоторәсемгә карап). Кайда хезмәт итә?

Сажидә. Ингушетиядә.

Сәрия. Чечня якын икән...

Сажидә. Якын шул... Бик куркыта. Бердәнбер улым. Әтисез үстердем. Әтисе шофер иде. Улым Әмир дә шофер... Армиядә дә машина йөртәм дип яза...

Сәрия. Мин ятыйм инде, апа! *(Чишенеп урынга ята).*

Сажидә. Тыныч йокы, кызым! *(Ишек шакыйлар).* Болай соң кем килер икән? Керегез! Ишек ачык! *(Хәрби киемнән Әмир керә).* Улым! Улым!.. Ай Аллам! Исән икәнсең!.. *(Әмирне кочаклап ала).*

Әмир. Исән, әнкәй, исән!.. *(Чайкала).*

Сажидә. Улым!.. Тукта әле!.. Син... Син... Эчкәнсең түгелме соң?

Әмир. Эчтем!.. Эчтем!..

Сажидә. Ай Аллам! Нишләп эчтең? *(Сәрия башыннан бөркәнеп, тын гына ята).*

Әмир. Минем кайтуга шатланмыйсыңмы әллә?

Сажидә. Шатланам да, улым! Эчүеңә аптырыйм! Гомергә булмаган хәл!..

Әмир. Ну что же! Гомергә булмаган хәлләр була икән ул!..

Сажидә. Улым, әкренрәк сөйләш әле! Кеше бар бездә.

Әмир. Кеше?! Ха!.. Минем караватта йоклап ята! Кем ул? *(Караватянына килеп, юрганны ачмакчы).*

Сажидә. Иртә белән күрерсен! *(Әмирне караватянында алып китә.)* Ничек кайттың? Кайтам дип хәбәр дә бирмәдең. Гелгә, бөтенләйгәме?

Әмир. Кайта белсәң, бөтенләйгә дә кайтып була ул!..

Сажидә. Ай Аллам! Бик сәер сөйлисең, улым!

Әмир. Сәерме, түгелме, мин кайттым! Күрәм, син шатланмыйсың! Кире китәргә дә могу!..

Сажидә. Алай димә, улым, әйдә чишен, юынып ал, мунчам да ягылган. *(Әмирне чишендерә).*

Әмир. Мунча... Мунча... Эчәргә бармы?

Сажидә. Миндә нинди аракы булсын? Эчкәнең житкән бит, улым!

Әмир. Кибетче һаман да шул Мәбрүрә апамы? Үзем өенә барып, бер ярты алып кайтам.

Сажидә. Төн уртасында... Бездә әле аракы сатуны тыйдылар...

Әмир. Ничек инде тыйдылар?

Сажидә. Рәуф абыең урак беткәнче бер грамм аракы сатмаска кушкан... Сухой закон!..

Әмир. Нинди сухой закон?! Андый закон юк! Булырга тиеш түгел! Андый законны президент кына чыгарырга может!.. Кем булган ул гөмбә Рәуфе?! Сухой закон чыгарып ятарга?! Председател кисәге, несчастный!

Сажидә. Әллә кайчангы кушамат белән мыскыллама инде Рәуф абыеңны! Җитәкче кеше бит!

Әмир. Җитәкче, имеш! Нинди сухой закон уйлап чыгарып ята ул монда? Бер ярты кирәк! *(Караватка таба барып).* Кем бу? Торсын! Минем кайтуны отмечать итәбез!

Сажидә *(Аны тоткарларга тырышып).* Чү! Чү!.. Уятма, арган ул! Йокласын!

Әмир. Йокламасын! Солдат кайтты, понимаешь!.. Шатлык!

Сажидә. Кайтуың шатлык та, улым! Ничек болай?.. Ничек кайттың? Әллә, Ходаем, качып кайттыңмы?

Әмир. Юк! Качып дураклар гына кайта! Качкынны барыбер тоталар бит аны!.. Ә мин законный кайттым!..

Сажидә. Әкренрәк! Зинһар әкренрәк!

Әмир. Нәрсә? Мина үз өемдә сөйләшергә дә ярамыймы?

Сажидә. Улым, әйдә, ят, ял ит! Алгы бүлмәгә әтиең караватына урын җәям. Иртән сөйләшербез.

Әмир. Минем үз караватыма ятасым килә!

Сажидә. Бала булма инде! Анда кунак кызы йоклый!

Әмир. Кунак кызы?! Ха! Кунак кызы чибәрме?

Сажидә. Чибәр, бик чибәр!.. Шаулама гына!

Әмир. Алайса кунак кызы янына ятам!

Сажидә. Улым! Борчыма аны!

Әмир. Нәрсә? Мин кызлар янына ятмаска тиешме?

Сажидә. И Ходаем! Исереклек белән шулай сөйләнәсеңме? Әллә бозылып кайттыңмы? Мондый түгел иден бит син! *(Елый).*

Әмир. Янына ятам!.. *(Сәрия яткан караватка таба бара).*

Сәрия. *(Яткан җиреннән торып, тиз-тиз халатын кия).* Гафу итегез!

Мин сезгә комачаулыйм ахры? Китим әле! *(Ашыгып чыгарга бара).*

Әмир *(Сәриянең кулыннан тотып).* Чибәр икәнсен, кызый! Беркая китмисен!.. *(Караватка таба өстери).*

Сәрия. Җибәрегез мине!

Сажидә. Әмир! Җибәр!..

Әмир. Җибәрмим!.. Әйдә икебезгә бер ярты табып кайтабыз да... минем кайтуны отмечать итәбез!

Сәрия Әмирдән ычкынып, чыгып йөгерә. Әмир аның артыннан чыгам дип, ишеккә ташлана, тупсага абынып егылып китә. Ыңгырашып ята.

Сажидә. И Ходаем! Башынны бәрденме әллә?.. Кара төн уртасында кая китте инде бу кыз бала?! *(Елый).*

Өченче күренеш

Шомлы музыка астында пәрдә ачыла. Беренче күренештәге бизәлеш. Сәрия халаттан килеш диванда ята. Рәүф керә.

Рәүф. Сәрия?!..

Сәрия *(Елый).* Рәүф абый!.. Рәүф абый!.. Мин... Мин... Китәм!..

Рәүф. Кая китәсең?

Сәрия. Казанга кайтып китәм!

Рәүф. Нәрсә булды? Нишләп син монда? Кабинетта йокладынмы әллә?

Сәрия. Кая барырга белмәдем... Авылыгызга алып кайтуыгыз өчен рәхмәт, Рәүф абый... Китәм!..

Рәүф *(Сәриянең аркасыннан сөеп, кочаклап диярлек).* Тукта әле, кызым, алай кырт кисмә! Китеп анда нишлисең? Сәүбан абыең сине эшләргә җибәрде. Торыр жирең юк.

Сәрия. Интернатта эш табылыр әле. Мине аннан куып чыгармыйлар.

Энҗе керә дә, кире чыгып китәргә омтыла.

Энҗе. Мөмкинме? Ә... ни... әллә ярамыймы?

Рәүф. Ярый, ярый! Кер! Кер!

Энҗе. Гафу итегез! Бераздан керермен. *(Чыга).*

Рәүф. Син бит Сажидәләрдә...

Сәрия. Сажидәләрдә... Ләкин анда...

Рәүф. Нәрсә ләкин? Начар кабул иттеме әллә?

Сәрия. Юк! Яхшы кабул иткән иде... Ләкин исерек...

Рәүф. Исерек? Гомердә эчми иде бит ул!

Сәрия. Ул апа исерек түгел!

Рәүф. Әнә үзе килеп килә!

Ашыгып Сажидә керә. Кулында Сәрия сумкасы.

Сажидә. Сәрия кызым! Рәүф туганкаем! Зинһар гафу итегез безне! *(Елый).*

Рәүф. Нәрсә булды соң? Һич аңлый алмыйм!

Сажидә. Бик зур күңелсезлек булды! Менә әйберләрен... *(Сәриягә сумка бирә).*

Сәрия. Рәхмәт! *(Сумкадан киемнәрен алып чыгып китә).*

Сажидә. Сәрия кызым белән гөрләшеп чәйләр эчтек тә, ятып йокларга гына җыенган идек... *(Елый).*

Рәүф. Еламыйча гына сөйлә әле!

Сажидә. Көтмәгәндә, уйламаганда Әмирем кайтып керде!

Рәүф. Әмир кайтты? Бик яхшы булган!..

Сажидә. Бик яхшы булмады шул!..

Рәүф. Ничек инде яхшы булмады! Солдат кайту яхшы булмыйча?! Кунак кызы килгән, солдат кайткан...

Сажидә. Кунак кызы алдында хур булдык!.. Әмирем йоклап киткәч, урамга чыгып, кайда йөри икән бу бала диеп, борчылып эзләп йөрдем... Идарәдә ут булгач, тәрәзәсеннән күреп, бераз тынычландым... Әйтергә дә оят! Армиягә киткәнче, аракы дигән нәрсәне белмәгән дә бала Әмирем... *(Елый).* Кайтып керде... Ләх исерек!..

Рәүф. Исерек?! *(Сәрия күлмәген алыштырып керә).*

Сажидә. Эчкәне җитмәгән... Аракы таптыра!.. Бәйләнә!.. *(Елый).*

Рәүф. Алай... Алай икән... Ә ничек кайткан ул? Әле бер ел да хезмәт итмәде түгелме соң? Бөтенләйгәме? Ялга гына... Вакытлыча гынамы?

Сажидә. Бернәрсә дә аңламадым. Юньләп сөйләмәде. Әле йоклый. Айныгач, белербез инде. Син, Сәрия кызым, рәнжисеңдер инде мина?

Сәрия. Юк, апа, рәнжемим!.. Син үзең гафу ит, чыгып китүем яхшы булмады инде. Мин бит исерек кешеләрне сөймим!

Сажидә. Сәрия алдында оятлы булдык! Оятлы булдык!

Рәүф. Әмирең йокысыннан тору белән икәүләп идарәгә килегез! Бик ныклап сөйләшербез!

Сажидә. Ярар. Сүземне тынласа, алып килеп булса...

Рәүф. Ничек инде—алып килеп булса?.. Килер! Килергә теләмәсә... Мин үзем барып... ярты куярмын... анын янагына! *(Сажидә чыга).* Андый егет түгел иде ул. Армия бозды микән? Их! Бар иде заманнар! Без яшь чакта жебегән, хәчтерүш кенә малайлар Армиядән шундый егетләр булып кайталар иде! Егетләр түгел, бөркетләр булып! Өйгә, газиз әнкәең янына солдаттан аракы эчкән килеш, исереп кайтып керү—безнең татарда булган хәл түгел иде! Бозылды замана! Бозылды!.. Син Сәрия кызым, китәм дигән сүзеңне оныт! Бер исерек күргәнсең дә... *(Ишекне ачып.)* Энже, нишләп кермисең инде? Компьютерыгыз көтә! *(Энже керә.)* Эшли башлагыз!

Сәрия. Мин... Мин эшләмим!.. Китәм!..

Рәүф. Тукта, ашыкма әле! Алай бик китәсең килсә, китәрсең. Менә хотя бы кызларны өйрәт!

Сәрия. Ярый. Кызларны өйрәтәм. Ләкин алар өйрәнгәч тә китәм!

Энже. Нигә китәм ди?

Рәүф. Шайтан алгыры! Проблема килеп чыкты! Кара әле, Энже, Сәрияне үзегезгә генә алып кайт!

Энже. Сажидә апа...

Рәүф. Сажидә апаңнарда булмый. Булмый!

Энже. Мин бик алып кайтыр идем дә... Ни... Ни бит... Рәүф абый, үзең беләсең, әти...

Рәүф. Нәрсә? Ул туктады түгелме соң инде? Антлар итте лә!

Энже. И, анын анты!

Рәүф. Тагын башладымыни? Куам, куам мин аны фермадан! Куам! Мөдир түгел, тирес түгүче дә булып эшли алмас! Ярый, Сәрия кызым, пока үземдә торырсын. Аннары күз күрер.

Сәрия. Сезгә мәшәкать ясыйсым килми.

Рәүф. Нинди мәшәкать?! Әйдә, безгә кайтып иртәнге аш ашап, чәй эчеп килик!

Сәрия. Рәхмәт! Минем ашыйсым да, эчәсем дә килми. Әйдәгез эшкә тотыныйк!

Рәүф. Барыгыз, алайса эшли башлагыз! Бераздан чәйләп алырсыз. Фатир мәсьәләсен хәл итәрбез. Борчылма. Урамда калмассың. *(Сәрия белән Энже секретарь бүлмәсенә чыгалар.)* Шайтан алгыры!.. *(Рәүф телефоннан сөйләшә).* Алло! Мин әле... Кәбирә, бу баланы үзебезгә генә алып кайтам... Сажидәләрдә тора алмый.... Нигә икәнен, обедка кайткач, әйтермен... Син әбекәйнең караватын балалар бүлмәсенә күчер... Анда Ләлә караваты янына бер карават сыя бит... Әбекәй бүлмәсенә... Тукта әле, тукта! Тыңлап бетер!.. Ярар инде, вакытлыча гына бит... И-и, нигә шулкадәр тар күнелле булырга? Эх, Кәбирә! Мондый түгел идең бит син! Кеше дип үлеп тора торган идең!.. Туйдым дисеңме? Соң, кирәкле кешеләр бит!.. Минем бит кирәксез кеше алып кайтканым юк! Кәбирә! Кәбирә! Кызма әле син! Кызма!.. Урамда калдырып булмый бит инде аны!.. Кирәкми дә кирәкми!.. Башка сүз белмисеңме әллә? Тьфу чорт! *(Трубканы ташлый).* Мунча хәтле генә өйгә кеше килсә дә сыя идек... Болын хәтле өй салып куйгач, сыймыйбыз!.. *(Телефоннан сөйләшә)* Алло! Фәһимә!.. Өйдә икәнсең... Кара әле, Фәһимә туганкай, сиңа бер үтенеч бар. Синең әниең бер ялгызы яшәп ята... Авыргалап та ала диләр... Иптәшкә бер кыз кертик әле шуңа! Вакытлыча гына... Казаннан эш белән килде... Әйбәт кыз... Ә? Каян беләсең дип... Якын дустымның кызы... Начар кыз түгел! Үзем ручаться итәм!.. Банат тути белән бүген үк, хәзер үк барып сөйләш, Рәүф үтенде диген! Фатир өчен акча түләрбез! Пенсионер карчыкка акча мешать итмәс! Телефон кертербез!.. Килештекме? Ярый, барып сөйләш тә, шылтырат! Җавап көтәм!.. *(Трубканы куя).* Әби кеше янында әйбәт булыр!..

Шул ук күренеш. Радио аша әкрен генә уйнаган матур музыка ишетелә. Рәүф эшләп утыра. Ишек шакып Сажидә керә.

Сажидә. Рөхсәтме? Рәуф, без киллек!

Рәуф. Әйдәгез, әйдә, узыгыз!

Сажидә *(Ишек аша)*. Әйдә, әйдә, кер!.. Кер димен бит!

Рәуф. Әмирме? Нишләп керми? Ялындырамы әллә? Нигә ялындырасың, Әмир? Кер! Кер!.. Әйдә сөйләшик әле! *(Теләмичә генә Әмир керә)*. Исән кайттыңмы? Кул биреп күрешик! Үзебезчә булсын! *(Кул бирешәләр)*. Исәнме, энекәш?

Әмир. Исәнмесез, Рәуф абый?!

Рәуф. Әйдә утыр! Сажидә, син дә утыр! *(Утыралар)*. Ничек кайттың? Ялгамы? Бөтенләйгәме? *(Әмир башын иеп дәшми утыра)*.

Сажидә. Бөтенләйгә кайттым ди.

Рәуф. Ярый... Ярый... Бөтенләйгә кайткач, бик әйбәт. Ничек алай көтмәгәндә килеп чыкты соң әле ул кайту?

Сажидә. Әйт инде! Әйт! Документларыңны күрсәт! *(Әмир куен кесәсеннән документларын чыгарып, өстәлгә куя)*.

Рәуф *(Документларны карап)*. Тәк... Тәк... Күзләре начар күрә... Илле процент кына дип язганнар монда... Син бит сто процент күрә торган малай идең! Значит син хәзер инвалид. Армиягә ярамыйсың. Нәрсә булды соң синең күзләргә?

Сажидә. Бик яхшы күрә иде! Армиягә киткәнче күз турында уйлаганыбыз да юк иде.

Рәуф. Нинди дер сыйфатсыз бензин күзне боза дип әйтәләр иде. Әллә шундый бензин белән эш иттеңме? Йә, сөйләп җибәр! Күзең яраландымы әллә? Алай дисәң, болай карап торырга берни дә булмаган кебек.

Сажидә. Сөйләми. Белмим, нәрсә булгандыр?! Йошкар-Ола егете белән бергә хезмәт итәм дип яза иде. Ул егет тә шулай күзе начар күргәнгә кайткан дип ишеттем...

Рәуф. Йошкар-Ола егете... Нәрсә булды соң сезнең күзләргә?

Сажидә. Анысын белмим.

Рәуф. Гаҗәп! Икесе дә... Берәр сере бардыр... Моны ничек аңларга инде, Әмир—чибәр егет?

Әмир. Язылган бит... Күз авыртты да, кайтарып җибәрделәр...

Рәуф. Нигә авыртты соң ул? Нигә нәкъ менә Йошкар-Ола егете белән икегезнеке? Син ничек уйлыйсың, Сажидә? Гомер буена медпунктта эшләдең... Бик әйбәт медсестра идең... Нәрсә булды икән бу егетләрнең күзләренә?

Сажидә. Нәрсә дияргә дә белмим...

Рәуф. Әмир, йә, үзең әйт!

Әмир. Авыртты инде, нигә икәнен белмим.

Рәуф. Белмисең микән?! Ярый, авырткач, кайтарып җибәргәннәр. Тәк... Тәк... Военкоматта нәрсә диярләр тагы... Машинага утырмыйсың инде хәзер. Эш табарбыз анысы... Эш күп... Бусы бер мәсьәлә... Син миңа әйт, нигә өеңә, әниең янына ләх исереп кайтып кердең? Ни йөзең белән шулай кайтып кердең? Бердәнбер әниең, сине күз карасыдай карап, ялгызы тилмереп үстергән әниең янына... Фатирга дип керткән кыз баланың котын алгансың! Солдаттан кайттым дигәч тә... Кешечә, үзебезчә матур итеп кайтып керергә ярамыйммыни? Нигә дәшмисең?

Сажидә. Кичә кич котырды... котырды... Бүген айныгач, песи кебек кенә, мыштым гына утыра... Авызыннан сүзен тартып алып булмый!

Рәуф. Сажидә туганкай, күңеленә авыр алма, синең Әмиреңнең нәкъ әтисе Галимулла икән... Ул мәрхүмкәй дә... эчеп авария ясады... Эчмәсә, менә дигән кеше иде... Син үпкәләмә тагы... авырткан җиреңә кагылдым...

Сажидә. Үпкәләмим, дөрес инде... Дөрес әйтәсең... Мәрхүмкәй эчте шул... эчте... Эчмәгәндә дөнья бәясе кеше иде... Исерек чакта тузгый-тузгый иде дә, айныгач, мулла кебек иплe, җайлы иде... Үкенә иде... гафу үтенә иде... Әмир дә айныгач, бик үкенде... гафу сорады... Бүтән эчмәм дип антлар итте... Армиядән бозылып кайталар диләр... Бозылып кайтулары шушыдыр инде... *(Елый)*.

Рәуф. Йә, нәрсә авызыңа су каптың! Болай да авылда исерек күп, тагын син... Йә, әйт, дальше ничек булырга исәп?!

Сажидә. Рәуф абыең алдында ант ит!.. Әтиең кебек кеше! *(Әмир башын иеп дәшми утыра)*.

Рәуф *(Өстәлгә сугып)*. Дальше ничек булырга уйлыйсың дим!..

Әмир. Әйбәт булырга инде...

Рәуф. Кара аны, чибәр егет! Әгәр тагын бер ишетсәм!.. Миннән пощады көтмә!.. И-и, бу сугышлары да бетмәде инде! Ингушетия... Чечня... Икесе бер

чорт!.. Күпме үлем! Кайтсалар, тәмам кешелектән чыгып кайталар... Башлары исән булгач, куанабыз!... Башларында бер акыллары калмый... Бик авыр хәзер халык белән эшләү!.. Бик авыр!.. Үзәккә буйсынып, бригадир гына булып йөргәндә, жинел булган икән. Бу аерылып чыгу—каерылып чыгу булды!...

Сәрия керә.

Сәрия. Ярыймы? *(Чыгып китмәкче).* Гафу итегез!

Рәүф. Сәрия, чыкма әле, чыкма!

Сажидә. Сәрия кызым! Син... син... нит инде... Әмирне гафу ит инде!

Рәүф. Сажидә, син гел Әмир өчен үзен сөйлисең! Теле бар бит! Телсез булып кайтмаган! Сукыр да түгел! Илле процент булса да күрә! Сәриядән үзе гафу үтенсен!

Әмир. Сәрия... ни... ни... мин...

Рәүф *(Өстәлгә сугып).* Торып бас! Шундый чибәр кыз алдында җәелеп утырган килеш...

Әмир *(Торып басып).* Гафу итегез!.. Мин... Мин...

Сажидә. Сәрия, әйдә безгә, кызым! Әмир анлады инде ул... Чебен дә очмас! Тынычлап, рәхәтләнеп ял итәрсең! Авыл халкы аны-моны сөйләнгәнче, үзебездә тор, үз кызым кебек тәрбияләрмен!

Әмир. Әйе... әйе... әйдәгез безгә!

Сәрия. Рәх-мәт!.. *(Чыгып китә).*

Рәүф. Әйе, рәхмәт инде сезгә! Рәх-мәт!.. *(Сажидә белән Әмир чыга. Телефон шылтырый).* Алло!.. Туган көн?! Ә-ә. Әйе шул! Бүген синең туган көнең бит әле! Котлыйм! Котлыйм! Укытучыларның отпуска вакыты булгач та, минем бит урак өсте! Рәхмәт! Рәхмәт, керә алмыйм. Шампанскиең янында шайтанскиең да бармы? Шампанский да, шайтанский да эчмәгәнне беләсең бит! Шайтанский юк дисенме?.. Ышанам! Ышанам.. Юк! Юк! Рәхмәт, туганкай! Кырга чаптым! *(Чыгып китә).*

Авансцена. Сажидәләр ишек алды, баскыч төбе. Әмир белән Сажидә идарәдән кайтып киләләр.

Сажидә. Баскычтан иплә мен!

Әмир. Баскыч? Нинди баскыч?

Сажидә. И, улым, шул баскычны да күрмисен?!.Ниләр булды соң ул күзкәйләренә? Аттылармы? Пуля тидеме? Утыр әле яныма! Сөйлә әле! *(Утыралар).*

Әмир. Әни!.. Әнием! *(Сажидәне кочаклап елый).* Әни! Гафу ит, зинһар! Гафу ит!.. Беркемгә дә, сина да әйтмәм дигән идем, әйтмичә ничек түзим?! Үзем!.. Үзем боздым күзләремне!.. Ачулан мине! Кыйна!..

Сажидә. И Ходаем! Кеше ишетә күрмәсен!.. Ничек? Ничек итеп боздың?

Әмир. Әй, әни, сорама зинһар!..

Сажидә. Әллә ул Йошкар-Ола егете...

Әмир. Әйтсәм, әйтим инде. Ул Йошкар-Ола егете әллә нинди үләннәрнең әллә нинди хикмәтләрен белә...

Сажидә. И балам!

Әмир. Кайтасы килә бит, әни! Кайтасы килә!.. Үләсе килми!..

Сажидә. Кайтуын ярый ансы. Аз булса да күрәсен, Аллага шөкер! Хуже булып китмәсен!.. Эчмә, улым, зинһар эчмә! Эчсән, кирегә китәр. Бөтенләй сукыраерсын.

Әмир. Эчмим! Эчмим, әни!.. Кичә бит... әй!.. вокзалда таныш егетләр очрады да... кайтуынны отмечать итәбез... сыйлыйбыз дип... Кичер, әнием, зинһар гафу ит! *(Сажидәнең алдына тезләнеп).* Бүтән эчмим, әнием! Ышан, әнием, эчмим! *(Сажидәнең аякларын кочаклап елый).*

Сажидә. Тор, тор, улым!.. Елама! Күзенне бетермә!.. Ышанам, улым, ышанам! Эчмәссең, Алла теләсә. Эчмәссең. Тулькe ул үләннәр турында беркемгә дә сөйли күрмә, улым!.. Яме!..

Әмир. Син сөйләмәсәң, мин сөйләмәм, әнием!..

Сажидә. И балам! Балам!.. Нишләп бердәнбер газиз баламның серен кешегә сөйлим инде мин?! Җир йотар!.. Тсс! Капкадан кемдер кереп килә!?.

Секретарь бүлмәсе.

Радио аша әкрен генә музыка ишетелә. Шунда ук. Энже компьютерына бирелгән. Ильяс керә.

Ильяс. Ничек?! Өйрәнеп буламы?

Энже. Мин аны белә идем лә!..

Ильяс. Белгәч, нигә соң һаман машинканда шакылдаттың?

Энже. Кайбер операцияләрен генә аңлап булмый.

Ильяс. Үзе кайда соң әле?

Энже. Обедка китте.

Ильяс. Озак йөрер микән?

Энже. Нәрсә? Бик кирәк иде-мени?

Ильяс. Бик кирәк иде шул...

Энже. Ә-ә, син дә компьютер өйрәнәм диден бит әле. Нәрсәгә кирәк инде сина, анда-монда чапкан бригадир кешегә компьютер?

Ильяс. Егет кешегә житмеш төрле һөнәр дә аз!.. Компьютерда акча, доллар басып булмасмы?.. Байыйсы килә!..

Энже. Башында ялган акча, ялган доллар...

Ильяс. Заманасы шундый!.. Ялганга корылган!

Энже. Ялган кызлар!..

Ильяс. Нәрсә бик төрттереп сөйләшәсең әле?

Энже. Авылга килгән бер кыз артыннан чабам дисенме?

Ильяс. Ә синең нигә эчең поша әле ана?

Энже. Эчем пошмый... Мина димәгәең... Ләкин бусы сина тәтемәс инде!..

Ильяс. Нигә тәтемәс икән?

Энже. Иясе бар аның! Занят инде ул?

Ильяс. Нигә алай дисең? Кияүдәме әллә ул?

Энже. Һи! Кияүдәме? Кияүдә булса, бер хәл иде... Аны бит... Әй, әйтмим инде!..

Ильяс. Әйт, әйт!.. Бик сәер сөйләнәсең.

Энже. Сәер шул... Сәер... Бик сәер...

Ильяс. Нәрсә әйтергә телисең соң? Әйт инде!

Энже. Әйтсәм, әйтим! Рәүф абый тикмәгә алып кайтмаган аны...

Ильяс. Ничек тикмәгә?..

Энже. Бүген иртә белән эшкә килсәм... Халаттан килеш кенә диванда утыра... Рәүф абый кочагында...

Ильяс. Юкны сөйләмә! Әтисе кебек кеше!

Энже. Күргәнемне әйтәм!

Ильяс. Саташасыңдыр! Күзенә күренгәндер!

Энже. Саташмыйм!.. Араларында нәрсәдер бар!..

Ильяс. Гайбәт капчыгы! Тамчы да ышанмыйм!

Энже. Күзең томаланган, шуна ышанмыйсың!

Ильяс. Томаланды! Томаланды! Бер күрүдә мин аның яхшы кыз икәнен аңладым.

Энже. Күрсәтер әле ул яхшылыгын!

Ильяс. Көнләшәсең!

Энже. Көнләшәм?! Бик исем китте!

Ильяс. Энже! Безнең ара күптән өзелде. Мина катышма!

Энже. Өзелде... Өзелде анысы... Мин катышмас та идем... Җәллим үзеңне! Җыен калдык-постыкка күзен төшә. Рәүф абыйның...

Ильяс. *(Энҗенең авызын каплап).* Туктыйсыңмы син? Берәр кешегә тагын шушы сүзләреңне әйтсәң, авыл буйлап гайбәт китсә, валлаһи, буып үтерәм! *(Энҗенең муеныннан кысып ала).*

Сәрия керә. Кире чыкмакчы.

Сәрия. Әллә комачауладыммы?

Ильяс. Комачауладың шул! Кочаклап үбәргә җыенган идем!..

Энже *(Ильясны этеп җибәрә).* Үбешми тор әле!

Ильяс. Йә, Сәрия, эшләр ничек? Барамы?

Сәрия. Бара. Энже үзе дә белә ул. Мин анар кайбер авыр операцияләрне генә өйрәтәм.

Ильяс. Энжедән соң мине өйрәтерсеңме?

Сәрия. Рәүф абый кемне өйрәтергә кушса, шуны өйрәтәм.

Ильяс. Мин инде урак беткәч, өйрәнәм. Хәзер әле кызу эш өсте. Кызу эш өсте булса да дискотека эшли безнең, Сәрия! Бүген кич клубка чыгарсыңмы? Синең белән биисем килә.

Сәрия. Энжең нәрсә дияр бит! Энжең рөхсәт итсә, биербез!

Энже. Причем монда мин?! Пожалыста!..

Ильяс. Энже?! Мин синекемени?

Энже. Йә, кыланма! Минеке түгел! Син беркемнеке дә түгел! Ирекле әтәч!..

Ильяс. Ирекле әтәч шул!.. Кикери-күк! Әтәч дигәннән, Садрый абзыйга Казанда яшәүче кодалары туган көненә бүләк итеп попугай алып килгәннәр. Попугай көне-төне «Дурак! Дурак! Дурак!» дип кычкыра икән. «Гел дурак, дурак, дурак, дип мине генә мыскыллап утырма, дивана попугай, Хәдичә апана да дура, дура, дура диген, ангыра тәре!» дип, попугайны ботыннан тотып, тәрәзәдән ыргыт-

кан! Комбайнчылар янына киттем! Пока!.. *(Китә).*

Сәрия. Кызык егет!

Энҗе. Җилбәзәк!... Җинел акыллы!

Сәрия. Синең егетең дип уйлаган идем...

Энҗе. Юк! Юк!.. Күргән бер кызга сылана! Ышанычсыз!..

Сәрия *(Компьютер янына килеп).* Хәзер без синең белән җыелган текстны ничек сакларга кирәген өйрәник. «Мышка» белән файлны ачабыз... Аннары... *(Телефон шылтырый).*

Энҗе *(Телефонда)* Алло! Әйе! «Ак юл» тынлый... Кем дисез? Сәүбан Гатин?..

Сәрия. Минем директор абыем!.. *(Трубканы алып).* Алло! Сәүбан абый! Исәнмесез?! Эшне башладык... Әйбәт бара... Рәүф абый кырда, басуда! Эше күп!.. Сәламегезне тапшырырмын! Рәхмәт! Бик яхшы каршы алдылар... Әйе... Әйе... Бик яхшы урнаштым... Минем өчен борчылмагыз!.. Сау булыгыз, Сәүбан абый! *(Елап җибәрә).*

Дүртенче күренеш

Борынгы көй астында пәрдә ачыла. Банат өе. Гади генә җиһаз. Банат башын ак яулык белән кысып бәйләгән. Караватында ята. Ыңгыраша. Шәмсия керә.

Шәмсия. Көш! Көш! Нигә ишегенне ябмыйсын, кортка?! Верандаң тулы тавык! Ашарларына салмадыңмы әллә? Тормадың дамыни әле!.. Йокы чүлмәге!..

Банат. Калалып китсен тавыклары! Башым авырта! Үләм!..

Шәмсия. Минем үземнең дә ярылам-ярылам дип чатнап-чатнап авырта. Кичә кич шаярасы калмаган... Артыгын кыландык!

Банат. Кичә бәйрәм иттек бит, Шәмсия ахирәт! Хи-хи-хи!..

Шәмсия. Нинди бәйрәм?..

Банат. Кичә сулагайлар көне иде бит! Хи-хи-хи!..

Шәмсия. Һи-и! Сулагай тәре!.. Шаярып утыра әле житмәсә! Син сулагай булгач та... Мин бит унагай! Хи-хи-хи!..

Банат. Шаярмыйм! Чынлап та кичә сулагайларнын бәйрәме иде.

Шәмсия. Китсәнә! Юк сүз сөйләп утырма!.. Андый бәйрәм юк!

Банат. Бар икән шул! Хи-хи-хи! Монарчы мин дә белми йөргәнмен! Бүген генә календарьдан укыдым! Кичә Бөтендөнья сулагайларының бәйрәм көне булган! Хи-хи-хи!

Шәмсия. Һи-и! Пучтәк бәйрәм!.. Хәер, хәзер атна саен, көн саен шундый пучтәк бәйрәм!.. Бәйрәм итәргә акчаң житмәс!.. Хи-хи-хи!

Банат. Артыгын кыландык дип, син үзең бит! Бетерик инде, бетерик, кызыктырып тормасын дип, төбендә тамчысын да калдырмадын! Бераз калдырган булсак, менә бүген башны төзәтер идек!..

Шәмсия. Кичә аркам чәнчеде! Шул гына ярдәм итте. Чыгып яту белән изрәп йоклап киткәнмен.

Банат. Кибете корыды бит! Бу Гөмбә Рәүфен әйтер идем! Бөтен Рәчәй чыгармаган законны чыгарып ята! Путин да, Шәймиев тә сухой закон кирәк димәгәндә... Гөмбә тәре! Нәселләренә Гөмбә дип кушамат кушмаслар иде. Агулы гөмбә ул!.. Урак өсте, имеш! Урак өстендә наоборот кирәк ул! Бичара трактористлар көне буе эшләп арып кайткач, бераз кабып куйсалар... рәхәтләнеп ял итәрләр иде.

Шәмсия. Ярар, кая закускага нәрсәң бар? Мин бер ярты таптым. *(Алъяпкычы астыннан аракы чыгара).*

Банат. Ай маладис! Каян алдың бу җан кисәкне?!

Шәмсия. Иртәнге поездга кодагыйны озатырга вокзалга бардым бит, вокзалда сатып яталар. Машина белән килеп. Бер ярты алдым да, шәлләр белән төреп сумка төбенә салдым. Килен күрер дип кот чыга!

Банат. Икене алыр идең. Берсе мина булыр иде. Бүген дә синекен тут итәбезмени? Акча бирәм алайса!

Шәмсия. Акчаң үзендә торсын! Бүген минекен, иртәгә синекен дигәндәй... Вакланма әле!.. Икене түгел, өчне алган булыр идем дә... Акчам юк. Акча килен кулында. Пенсия китермиләр... Аннары беләсең бит, мин бер-

кая яшереп куя алмыйм! Табалар! Өй тулы кеше! Кайчакта грелкага салып, матрац астыма куям... Хи-хи-хи!.. Син ичмасам, бер үзең!.. Тор, тор, кортка! Яткач хуже ул! Закусканны куй!

Банат. Закускага шул, менә кичә калган колбаса! *(Холодильниктан колбаса китерә).*

Шәмсия. Колбаса ашатып, гөнаһка батырып бетерәсең инде! Дуңгыз кушылган бит! Ап-ак майлары күренеп тора.

Банат. Дуңгыз кушылмаган ризык юк ул хәзер! Май, маргарин, печенье, конфет—барсына да дуңгыз мае кушылган! Менә мона—иң зур гөнаһ шомлыгына жанны сатканбыз икән, колбаса гына чепуха ул! Әйдә сал, үләм!..

Шәмсия. Ходай үзе кичерер әле!.. Ураза тотарбыз, Алла бирсә!.. Бер көн ураза мең гөнаһыңны кичерер ди...

Банат. Мең гөнаһны ук кичермидер инде? Арттырасың син!

Шәмсия. Абыстай шулай сөйләде... *(Стаканнарга аракы булә).* Бүген бетермибез. Башны төзәтсәк, шул житә! Исәнлеккә-саулыкка!.. Печәнлеккә-таулыкка!.. Тут!.. *(Эчәләр. Шешәне Банатка биреп).* Бусын жыеп куй! Мин ашыгам, килен югалткандыр... Помидорлар бәйлисе бар... Кичкә таба, йокларга ятыр алдыннан керермен... Монысын да тут итәрбез, Алла бирсә! Сразы яндырып төшеп китте!.. Ай-йай-йай! *(Эчен уа).*

Банат. Яндыра!.. Минекен дә яндыра! Каты икән!.. Кырык градыс кына түгелдер бу?

Шәмсия. Кырык дип язылган бит!

Банат. Хәзер язуларның берсенә дә ышаныч юк! Бигрәк тә даруларга ялган язалар... Эчне йомшарта дип язганнары... киресенчә катыра гына... Ике таблетка эчәм... өч... биш таблетка... Юк!.. Кыймшанмый да!.. Менә шушы ишәк сөте генә әзрәк йомшарта... Хи-хи-хи!.. *(Шешәне шкафка чинаяк артына яшерә).*

Шәмсия. Биш таблетка нәрсә ул! Безнең бу корсакны хәзер биш түгел, унбиш таблетка да жинә алмый! Тегермән ташына әйләнгән!... Синең белән ләчтит сатып утырырга вакытым юк! Теге лавр яфрагын кая куйдың? *(Лавр яфрагы эзләп ала).* Шуны чәйнәп куймасам, килен сизенә... *(Лавр яфрагы чәйниләр).* Эт кебек, исне бик тиз сизә. Эт кенә түгел, аждаһа! Беркөнне бакчада шул Америка кортын жыеп бик арыгач, әз генә капкан ием, синнән аракы исе килә дип бәйләнә генә бит! Кулым сызлаганга, сөрткәнием дип көчкә котылдым! Үзе дә хәйран каба ул! Бер дә кешедән калышмый!.. Төпчек малай шуңа акылга таманрак булып туды. Беренче класста ике ел утыра, икегә икене куша белми. *(Эчен уып).* Бик катысы эләкте ахры... Яндыра!..

Банат. Минеке дә ут яна!..

Шәмсия. Мин чыгыйм әле! Пока! Сораучылар булса, сәлам әйт! Сорамасалар, нәплиевать!.. *(Йөгереп чыгып китә).*

Банат. Бу тавыкларны суеп кына бетерер идем... Һич тынгы бирмиләр! Фәһимә бит, тавык та тотмассыңмыни, әни, дип бәйләнә. *(Ишектән чыгачыга).* Көш! Көш! Көш, каһәр төшкерләре!.. *(Чыгып китә. Бераздан Фәһимә керә).*

Фәһимә. Әни, әни! Кая киткән? Урыны да жыелмаган... Авырыйдыр... Картайды... Картайды... Жиленче дистәне ваклый бит инде... *(Банат керә).* Әни, кайда йөрисең?

Банат. Тавыкларга жим генә сиптем.

Фәһимә. Авырыйсыңмы? Түшәң киткән...

Банат. Авырыйм, авырыйм...

Фәһимә. Давлениедер инде! Даруыңны эчтеңме соң?

Банат. Эчтем, эчтем...

Фәһимә. Ялгыз яшәвеңә бик борчылам. Бездә яшәсәң, күз алдында булыр идең ичмасам... Көчмим дип аяк терәп каршы торасың бит! Түбән очтан Югары очка һаман-һаман йөгереп килеп йөреп булмый.

Банат. Әле үз көчемдә бит, Аллага шөкер! Үз көчемдә чакта сезгә мәшәкать арттырмыйм. Картайгач, давление дә күтәрелер... Әкрен генә үзем кыштырдап йөрим лә!.. Менә тавыклар бик интектерә...

Фәһимә. Тавыкларыңны үземә алып китимме әллә?

Банат. Юк инде! Тавык кына карарлык хәлем бар ла анысы!

Фәһимә. Урын-жиреңне дә жыймый башладың! Әйдә урын-жиреңне жыеп, әзрәк өеңне рәткә китерик!

(Урын-җирне җыештыра, өйне тәртипкә китерә-китерә сөйләшә). Нигә теге Казаннан алып кайткан чигүле ак яулыгынны бер дә бәйләмисен. Бәйләп куй әле матур иттереп. *(Киштәдән ак яулык алып бирә. Банат яулыкны иңбашларына төшереп бөркәнеп куя).* Менә нинди чибәр әби булдың!.. Бездә торасың килмәгәч, әни, сиңа бер кыз кертергә булдык. Ялгызыңа бик читен. Ул-бу була калса, Алла сакласын! Иптәш булыр... Авырып китсәң, ярдәм итәр. Өенне җыештырыр... Бик әйбәт кыз диделәр...

Банат. Кирәкми, кирәкми!.. Кеше белән...

Фәһимә. Кеше белән торырга кирәк сиңа хәзер. Вакытлыча гына диделәр... Рәүф бик үтенде... Акча да түлим диде...

Банат. Акчасы эчне төртеп тишмәс иде, анысы...

Фәһимә. Телефон да кертәм диде.

Банат. И-и, телефон нәрсәгә миңа!

Фәһимә. Ничек инде нәрсәгә? Безнең өчен уңай булыр, гел хәленне белешеп торырбыз... Үзенә дә җайлы булыр.

Банат. Юк! Юк, кызым, үзем генә торыйм әле...

Фәһимә. Мин бит инде ризалык бирдем... Рәүф алдында мине уңайсыз хәлдә калдырма!

Банат. Ризалык биргәч, алайса үзенә керт!

Фәһимә. Әни! Ну, киребеткән син! Үзең өчен яхшы булыр дим! Әнә килеп тә җиттеләр! Бер үк кирегә сукалап утырма! *(Сәрия белән Энҗе керә).* Чибәр кызлар килеп тә җитте!.. Әйдәгез, әйдәгез, чибәркәйләрем, узыгыз!

Сәрия. Мөмкинме? Исәнмесез?

Энҗе. Банат әбекәй! Ни хәлләрдә яшәү?

Банат. Ярый, кызым, кыштыр-мыштыр яшәп ятам.

Фәһимә. Авырыбрак тора әле... Давление интектерә аны... Бүген теге магнит давылы көне диделәр бит!

Энҗе. Ул магнит көнендә минем әни дә бик интегә.

Фәһимә. Исемең Сәрия бит әле? Әйдә, Сәрия сеңлем, үз өеңдә кебек бул! Безнең әнигә иптәш кирәк иде, бик әйбәт булыр. Ир-ат юк!

Сәрия. Ир-ат булмагач, бик яхшы! Өйдә исерек кеше юк! Ин яратмаганым исерек ир!

Фәһимә. Исерек ирне кем яратсын инде?! Минеке эчми, ташлады, Аллага шөкер!.. Менә шушы караватта йокларсын. Бик тыныч, бик рәхәт булыр, Алла бирсә.

Сәрия. Менә шундый чаршаулар, пәрдәләр корган авыл өйләрен, ак яулык бөркәнгән татар әбиләрен яратам.

Фәһимә *(Сәгатенә карап).* Кызлар, минем вакыт бетте. *(Өстәлдәге самавырга күрсәтеп)* Әни, чәй куеп җибәр! Кызларның чәй эчәсе килгәндер!

Сәрия. Юк, эчәсе килми әле! Эчәсе килсә, үзебез куярбыз, борчылмагыз, апа!

Фәһимә. Чәй, шикәр, варенье шкафта әнә. Үзегез куеп эчәрсез инде алайса.. Эшкә киттем! Хәзергә сау булып торыгыз! Иртәгә килеп хәлегезне белермен. *(Чыга).*

Энҗе. Әбекәй үзе бер сүз дә әйтми әле... Банат әби, әллә без килгәнгә шатланмыйсың инде?

Банат. Бик шатланам... Бик шатланам, кызым... Тик менә... давление... *(Йокымсыраган кебек утыра.)*

Сәрия. Йокың килә бугай? Син ятып тор, әбекәй! Йоклап ал!.

Банат. Верандага чыгып ятыйм әле.

Сәрия. Анда җиләсрәктер, барыгыз, әбекәй! *(Банатны озата).* Газы да бар, самавыры да электрический... Үзем пешерәм мин! Яшибез болай булгач!.. Менә авыруы гына инде... Ныклап авырып китсә...

Энҗе. Алай авырып ятканы юк аның! Хәзерге карчыклар нык алар! Хәзер аларга авыр эш юк! Су ташыйсы юк. Колонка капка төбендә генә. Мич ягасы юк. Газ... Бик авырып китсә, икенче бер фатирга...

Сәрия. Монда да калмасам, Рәүф абый алдында уңайсыз бит инде. Бик сайлана дияр.

Энҗе. Минем бик эчәсем килгән иде. Кайнамаган су булса да эчим әле. *(Шкафтан чинаяк алганда, шешәне күреп, Сәриягә күрсәтмичә генә алып исни дә кире урынына куя).* Шкафы бай!.. Савыт-сабалары матур дим... *(Чиләктән су алып эчә).*

Сәрия. Энҗе дускай, китереп куюың өчен рәхмәт! Син бар, кайт инде.

Энҗе. Кайтырга кирәк шул, бакчага су сибәсе бар. Ямансулап

утырма! Кич клубка чык! Ильяс бик чакырды бит үзенне!

Сәрия. Юк. Чыкмыйм.

Энже. Үзен кара инде!.. Пока! *(Чыга).*

Сәрия ялгызы уйланып утыра. Ишек шакыйлар. Ильяс керә.

Ильяс. Керергә ярыймы? Исәнмесезләр?

Сәрия. Керегез!.. Ничек?..

Ильяс. Ничек белдемме? Беләсе килгәч, белдем инде!.. Банат әби безгә туган, кардәш тиешле! Аның әбисененәбисенен-әбисенен-әбисенен әбисе минем бабамның-бабасының-бабасының-бабасының бабасы белән бертуган булган...

Сәрия. Ай-һай якын туган икән!

Ильяс. Сәрия!.. Яна жыр тынлыйсызмы? *(Магнитофон уйната. Матур жыр янгырый).*

Сәрия. Әкренрәк! Әбекәй йоклый. Верандада. Авырып та тора...

Ильяс. Кай жире авырта? *(Жырны туктата).*

Сәрия. Кан басымы...

Ильяс. Монда унайсыз булыр бит... Авыргач дим...

Сәрия. Гел авырып тормас әле. *(Мич артында чикерткә сайраганы ишетелә).* Нәрсә черт-черт итә?

Ильяс. Мич артында чикерткә сайрый.

Сәрия. Чикерткә сайрый? Ничек инде ул—чикерткә сайрыймыни?

Ильяс. Әллә ишеткәнегез юк идеме?

Сәрия. Юк! Беренче тапкыр ишетәм!

Ильяс. Безнен авылда шулай: чикерткәләр дә сайрый... бакалар да сайрый...

Сәрия. Кызык икән! Юк! Бу чикерткә сайравы әллә ничек... Күнелгә тия...

Ильяс. Сәрия! Әйдәгез безгә генә!

Сәрия. Рәхмәт! Ничек инде?!

Ильяс. Әйдәгез, чынлап әйтәм. Безнең өй зур. Дөрес, кеше күп... Жиде бала үстек без... Ләкин бик тыныч бездә... Мич артында чикерткә дә сайрамый.

Сәрия. Кешедән кешегә йөрмиләр инде!..

Ильяс. Сон монда... күнелсез бит!..

Сәрия. Зарар юк...

Ильяс. Әйдәгез, Банат әбине уятып әйтәбез дә... Безгә китәбез! Үзем сөйләшәм!

Сәрия. Юк, юк! Уята күрмәгез! Йокласын!

Ильяс. Клуб ачылгандыр инде. Әйдәгез алайса дискотекага!

Сәрия. Әбине калдырыпмы?

Ильяс. Сон әби саклап дискотекага бармый өйдә утырырсызмы?

Сәрия. Утырсам сон! Мин әбиләр яратам! Әбием үстерде бит мине!

Ильяс. Бәлки мин чакырганга барасыгыз килмидер? Башка берәү чакырса...

Сәрия. Кем чакырсын мине? Монда беркемне дә белмим бит.

Ильяс. Егетегез бардыр инде... Казанда дим... Ул чакырса, барыр идегез, әлбәттә.

Сәрия. Егетем? Казанда калгач, ничек чакырсын инде ул?

Ильяс. Ике кыз сөйләшә икән... «Бер күрүдә гашыйк булуга ышанасынмы?»—ди берсе. «Кем ничектер, мин бер күрүдә гашыйк булуга ышанмыйм,—ди икенчесе.—Чөнки бер күрүдә аның күпме акча эшләгәнен каян беләсен?..» Ха-ха-ха!..

Сәрия. Мин бер күрүдә егетләрнең күпме акча эшләүләрен белә алам!

Ильяс. Минем миллионер икәнлегем йөземә чыкканмы?

Сәрия. Әйе! Миллионер икәнегез йөзегезгә чыккан! Бик күп акча эшлисез икән!

Ильяс. Бик күп акча эшлим! Бер айлык зарплатама бер машина сатып алам!.. Тәгәрмәчсез машина!

Сәрия. Тәгәрмәчсез машина буламыни?

Ильяс. Ничек булмасын?! Тегү машинасы бит ул! *(Көләләр.)* Әйдә телевизор карыйбыз! *(Телевизор тоташтырмакчы).*

Сәрия. Юк! Юк! Рөхсәтсез ярамый!

Ильяс. Рөхсәт сорыйк алайса!

Сәрия. Уятмыйбыз! Уятмыйбыз!..

Сөйләнә-сөйләнә Шәмсия керә.

Шәмсия. Кортка, әллә иртәдән бирле тормаган инде... Бәй, кунаклар бар икән?! Ильяс улым, нихәл? *(Сәриягә).* Син кем әле? Ижаудан кайттыңмы? Ижаудагы кызының кызы Диләрәсеме, Венерасымы? Ничек дәү булып үскән! Былтырларны гына борыныннан көмеш

алкалары тамып тора иде! Хи-хи-хи!

Ильяс. Диләрәсе бит, Шәмсия әби! Диләрәсе!.. Борыныннан түгел, әнә колагыннан көмеш алкалары тамып тора!

Шәмсия. Ә-ә, Диләрәсемени? Таныйм!.. Таныйм!.. Бик әйбәт! Бик матур булып үскән!.. Банат әбиләрен онытмыйлар. Рәхмәт төшкере!

Ильяс. Менә клубка чакырырга кергән идем дә... Банат әбисе верандада йоклый әле... Үзен генә калдырып чыкмыйм ди.

Шәмсия. Чыксын, чыксын! Клубка чыкмыйча, кыз бала?! Хәзер уятабыз аны!.. *(Ишекне ачып, верандага дәшә, Банатны уятмакчы).* Банат! Тор әле, кортка! Ул нинди көне буе йоклау ул?

Сәрия. Уятмагыз, авырый ул! Авырый!

Шәмсия. Авырса, тазартырбыз! Дару бар мондә!.. Хи-хи-хи! Барыгыз, бар! Рәхәтләнеп ял итегез!..

Сәрия. Әбидән рөхсәт сорамыйча... әллә ничек уңайсыз бит!

Шәмсия. Үзем рөхсәт итәм! Мин рөхсәт иткәч, законный инде! Мин ахирәте бит аның! Барыгыз! Бар! Рөхсәт!.. Рөхсәт!

Ильяс. Вот молодец, Шәмсия әби! Коткардың!

Шәмсия. Барыгыз! Бар! Бар! Яшь чакта йөреп, күңел ачып калыгыз!

Ильяс. Үзегез дә яшьлекнең кирәген биргәнсездер, Шәмсия әби?! Харрас бабакай белән! Бик мут бабай иде, мәрхүмкәй! Шәмсия әбекәегез белән аулагөйдә... ишек алдына йолдыз санарга чыккач, кочагыма кереп, иренемне мыегы-ние белән кабып үзе суырып үбә иде дип сөйли торган иде...

Шәмсия. И-и, булгандыр инде, булгандыр! Яшь чак—дәртле чак! Мыек та үпкәнбездер, кыек та үпкәнбездер!.. Хи-хи-хи!

Ильяс. Әйдә, Сәрия, Шәмсия әбинең рөхсәте белән киттек!..

Шәмсия. Барыгыз! Бар!.. Мин кич утырырга кердем... Хәзер Банат кортканы уятам да чәй куеп, телевизор карап, гөрләшеп кич утырабыз!..

Ильяс. Әбекәйләргә мешайть иткәнче, клубка киттек! Безнең авылның тагын бер мәзәген сөйлим әле. Бер көнне Сәйфулла абзый чишмәдән су алып кайтканда, хатыннар очраган: «Сәйфулла абзый, өлкән кешегә чиләк белән су ташу авыр бит, Нурулланы башлы-күзле итәргә кирәк!»—диләр. «Малайның башы да, күзе дә бар, тик менә сакалы, әй түгел лә, акылы юк»,—дигән Сәйфулла абзый!..

Шәмсия. И күңелле егет тә инде үзең!..

Сәрия. Ярый, алайса, сезнең рөхсәт белән киттек!.. *(Ильяс белән китәләр.)*

Шәмсия. Әкият сөйләп... вакыт әрәм итеп... Бик арытты!.. *(Ишек ачып).* Кортка! Банат кортка! Тор, тор! Үлем йокылары йоклыйсыңмы әллә? Тор! Аулагөй ясыйбыз!.. Кая куйдың? Тормасаң, үземә генә булыр! Хи-хи-хи! *(Аракы эзли. Җырлый).*

Әлдермешкә кайтам әле,
Кайтам әле Әлдермешкә!..

Кая куйган? Әллә мендәре астына салып яткан инде? Кортка! Тор әле, тор! Кер әле!.

Банат. *(Эчен тотып көчкә атлап керә).* Үләм!.. Эчем!.. *(Үрмәләп караватка барып ята).*

Шәмсия. Хәзер төзәтәбез! Кая куйдың Хәмдия чишмәсенең суын?! И, йокы чүлмәге!

Әлдермешкә кайтам әле,
Кайтам әле Әлдермешкә!..

(Шкафтан аракы ала) Әһә! Таптым бит!.. Нигә качып утырасың, кодагый? *(Стаканга аракы салып эчә).* Түт!.. Ах!.. Каты!.. Чуаш Микәй куган самогоннан да катырак! Кил, кортка, кил!.. Түт итеп җибәр! *(Стакан белән аракы тотып, Банатка карап җырлый).*

Әлдермешкә кайтам әле,
Кайтам әле Әлдермешкә!..

Чәй дә куеп җибәрик!.. *(Самавырга су салмый, утка тоташтыра).* Чәй эчкәч, бер авыруың да калмас!

Әлдермешкә кайтам әле,
Кайтам әле Әлдермешкә!..

Кил инде? Нәрсә ялындырасың? *(Банат янына килеп, игътибар белән карап).* Әллә үлгән инде?! Кортка! Кортка дим! Үлгән!.. Үлгән!..

Пәрдә.

Икенче пәрдә

Бишенче күренеш

Авыл урамы. Клуб алды. Утлар яна. Клубтан күңелле дискотека музыкасы ишетелә. Клуб тәрәзәсеннән кызларның биюе күренә. Бер якта качыбрак Энже басып тора. Ильяс белән Сәрия бии-бии сәхнә алдына киләләр.

Сәрия. Ильяс, гафу итегез! Мин кайтыйм инде!

Ильяс. Гафу итегез! Кайтмыйсыз әле!.. Авыл дискотекасы ошамады ахрысы?

Сәрия. Ошады. Тик кызлар гына бии, егетләрегез...

Ильяс. Егетләребезнең матур бии торганнары уракта... Ә бии белмәгән бичуралары көфер почмагы ясап, кызларның гайбәтләрен саталар... Бүген Керпе кызы Гөлфиянең...

Сәрия. Керпе кызы Гөлфия?! Һе... Керпе кызы... Гөлфия!?

Ильяс. Керпе кушаматлы алар! Безнең авылда кушаматсыз кеше юк! Шул Керпе Гөлфиясенең гайбәтен саталар: кара, кара, бүген бөтен жирен кысып, сыланып торган чалбарын кимәгән... күлмәк киеп килгән... күлмәк кимичә, әнисе чалбарын салдырып, артын кычыткан белән пешекләгән бит аның диләр.

Сәрия. Кычыткан белән? Нигә?

Ильяс. Ой, быел сабантуйда кызык булды! Керпе Гөлфиясе капчык киеп йөгергәндә, абынып егылды... Торып, капчыктан чыкканда... чалбары төшеп китте... егылганда замогы бозылган икән... Халык шаркылдап көлә... Гөлфия үзе сизми... Хәбирә түти йөгереп мәйданга чыкты да... әйттем мин сиңа сабантуйга чалбар киеп бармыйлар, ки күлмәгеңне диеп такмаклый-такмаклый, кыйный-кыйный өенә алып кайтып китте!... Ха-ха-ха!

Сәрия. Кызык икән! Ә сезнең кушамат ничек?...

Ильяс. Әйтмим! Белерсез әле!

Сәрия. Сез...

Ильяс. Сәрия! Әйдә «сез, без» дип безелдәмик әле!.. Минем «син» дип сөйләшәсем килә. Син яхшы бисен...

Сәрия. Син дә матур бисен. Мин кайтам инде. Әби көтәдер. Сау бул! *(Китмәкче).*

Ильяс. Озатырга рөхсәт итәрсең инде, Сәрия!

Сәрия. Нигә озатып йөрергә? Үзем кайтам. Кайта белэм лә! Урамнарыгыз!.. Югары оч та, Түбән оч!..

Ильяс. Мине озату бәхетеннән мәхрүм итмә инде!

Сәрия. Бигрәк зур бәхеттән!

Ильяс. Сине озату—минем өчен зур бәхет, Сәрия! *(Магнитофон уйнатып, җитәкләшеп чыгып китәләр. Энже алгы планга килә.)*

Энже. Бигрәк төче телләнә Шарлатан Ильяс... Минем белән йөргәндә, озат инде дип ялынган чакларда да ардым, йокым килә дип озатмыйча мыскыл итә иде... Нәрсәсенә кызыгадыр? Килү белән Ильяска тагылды. *(Пожар! Пожар! дигән тавышлар ишетелә. Ерактан янгын күренә.)* Пожар?! Кайда? Нәрсә яна? Югары очта!.. Аллага шөкер! Түбән очта түгел! Безгә килеп житмәс!... *(Әкрен генә ниндидер көй көйләп китә).*

Алтынчы күренеш

Шомлы музыка. Урам. Банат өе каршы. Сәхнәдә корымга буялган Ильяс, Әмир, Сәрия һәм башкалар. Янган өйнең эченнән Банат белән Шәмсиянең мәетләрен алып чыгып, жиргә янәшә куйганнар.. Җил исүе шомлы музыка белән чиратлаша.

Ильяс. Пожарникларга рәхмәт! Ярый әле тиз килеп життеләр! Юкса, күршеләргә күчә иде. Җиле бар бит.

Әмир. Әбиләр жәлке!

Сәрия. Әби! Әбекәйләр! *(Елыйелый әле бер карчык, әле икенче карчык янына килә. Аның күлмәге янып, итәге, җиңе ертылган).*

Сажидә керә.

Сажидә. Ай Ходаем!.. Каян чыккан? Ни булган?

Ильяс. Белмибез!

Сажидә. Төрткәннәрдер! Хәзер ут төртүне чүпкә дә санамыйлар!

Ильяс. Юк ла! Кем инде карчык йортына ут төртсен!

Сажидә. Әмир улым! Күлмәгең янган! Тәнең пешкән бит!..

Ильяс. Әмир молодец! Ут эченә керде!

Әмир. Син үзең молодец! Башта син кердең! Әй! Утка керүдән ни файда?! Әбиләрне коткарып булмады!

Сажидә. Бәлки жаннары бардыр әле? *(Ике карчыкның да сулышын тыңлый, пульсын тикшерә).* Юк. Юк... Икесе дә... бакый дөньяга күчкәннәр. Урыннары жәннәттә булсын! *(Чүгәләп дога укый).* «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи раажигун!»

Фәһимә керә.

Фәһимә. Әни!.. *(Банат өстенә капланып елый).* Әни бәгърем!..

Сажидә. Сабыр бул Фәһимә!..

Фәһимә. Әни!.. Әни!... Ай Аллам!.. Рәүф үзе кайда соң!.. Скорый чакырдыгызмы?..

Сажидә. Скорый помощь бернәрсә дә эшли алмый инде хәзер.

Фәһимә. Бәлки аңын гына жуйгандыр?.. Исәндер?.. Әни!.. Әни!..

Сажидә. Авыр булса да, әйтим, Фәһимә, икесе дә бу якты дөнья белән инде хушлашканнар...

Фәһимә. Әни!.. Әни!.. *(Елый).* И Ходаем! Ниләр булган соң? Нишләп чыккан ул янгын?

Ильяс. Ничек чыккан? Белмибез! Без килеп житкәндә, өй эчен ялкын чорнап алган иде...

Сажидә. Чүпрәк-чапракка ут тиз каба шул!.. Хәзер бит өйләр чүпрәк белән тулган.

Фәһимә. Тукта әле! Тукта!.. *(Сәрияне беләгеннән каты итеп тота).* Син нишләп янмадың соң? Нишләп син исән? Нишләп карчыклар гына?.. Үзең уттан чыга алгач, нигә аларны да алып чыкмадың?!

Ильяс. Сәрия өйдә түгел иде ул!

Фәһимә. Ничек өйдә булмасын? Миннән өйдә калды бит! Кая киткән ул? *(Тынлык.)*

Сәрия. Гафу итегез...

Сажидә. Гафу итәрмен мин менә! Авыру карчык янына үзең риза булып килгәнсең икән, син аны ташлап чыгып китәргә тиеш түгел идең! Без бит сине иптәш булырсың дип керттек!

Ильяс. *(Сәрияне Фәһимә кулыннан тартып алып).* Ул гаепле түгел монда! Мин аны дискотекага чакырдым! Мин гаепле!.. Аннары... Банат әби берүзе калмады бит ул! Шәмсия әби керде... «Барыгыз, яшьләр, клубка чыгыгыз! Мин кич утырырга кердем... Банат белән икәү чәй эчеп чүкердәшербез, безгә мишәйт итеп утырмагыз»,—диде.

Фәһимә. Клубта пәри туе ясарга киттегезме? Кызлар күрү белән синең күз акая инде!

Сажидә. Яшьләр бит! Яшь чакта...

Фәһимә. Син катышма яме!

Сажидә. Житте, мәетләрнең баш очында кычкырышмыйк!.. Гөнаһлы булырбыз!

Фәһимә. Әнием! Газиз әнекәем!.. *(Елый).* Их, үзебезгә генә килеп тор дидем!.. Тыңламадың сүземне! Әллә каян килеп чыккан килмешәккә ышанып... Хәзерге кызларга ышаныч бармы соң? Килгәненә ике тәүлек юктыр, кем икәнен бөтен авыл сөйли!

Ильяс. Кем сөйли?

Әмир. *(Фәһимәгә ачулы карап.)* Нәрсә сөйлиләр?

Фәһимә. Кымызны кем эчмәс, чибәр кызны кем кочмас!..

Сажидә. Нәрсә бик кинаяләр белән сөйлисең әле син?

Фәһимә. Кара, кара боларны?! Өчәүләп миңа ташланалар?! Мин аны жавапка тартам!.. Әйдә! Әйдә! *(Сәрияне тарткалый).*

Ильяс. Кая тарткалыйсың аны!

Фәжимә. Идарәгә!

Ильяс. Идарәдә бер кеше дә юк!

Фәһимә. Идарәдә кеше булмаса, милиция килеп житкәнче, мин аны... келәтемә ябып куям!.. *(Рәүф килгәнне күреп, Сәрияне ычкындыра).*

Ашыгып Рәүф керә.

Рәүф. Ah!.. Ah! Ah!.. Ерак басудан ук күреп кайттым. Ялкыны шул хәтле көчле, бөтен авыл яна шикелле. Шайтан алгыры! Машинаның бер тәгәрмәче жибәрде! Ярый, егетләр, сүндергәнсез! Жилләп тора бит! Рәхмәт!

Фәһимә. Нәрсә? Карчыкларны яндырып үтергәннәрә өчен рәхмәтме?

Ильяс, Әмир. Кем? Кем яндырып үтергән аларны?!

Фәһимә. Сез!..

Сажидә. Фәһимә, сүзенне чамалап әйт әле, пожалысты! Кешегә гаеп такма! Әгәр дә карчыклар үзләре гаепле булсалар?

Фәһимә. Нәрсә? Нәрсә әйтергә телисен?

Сажидә. Мин әйтмим!.. Мин әйтмәсәм дә, дөреслек бер ачылыр әле. Капка төпләрендә киленен күрдем. Шәмсия әбинен мәетен өемә кертмим ди... Ни өчен шулай ди икән?..

Фәһимә. Анын явыз килене нәрсә әйтмәс?!.

Рәүф. Кемнедер гаепләргә ашыкмагыз әле!... Комиссия төзербез. Тикшерербез. Ачыкларбыз! Әбекәйләр кызганыч...

Әмир. Минемчә, электр самавырыннан чыккан! Сусыз куйганнар булса кирәк. Мин күрдем ул самавырны, идәндә ята, бер тимер чүлмәк шикелле йомарланып...

Рәүф. Әмир!.. Син...

Ильяс. Ин беренче Әмир килеп житте!

Рәүф. Ярый... Ярый!

Фәһимә. Барсына да сезнен Сәриягез гаепле!

Сәрия *(Елап).* Рәүф абый! Минем бер гаебем дә юк! Их! Китеп кенә барган булсам!.. Сумкамда бөтен киемнәрем... паспортым... документларым... Янды! Янды!.. Хәзер ничек китәм инде?!

Фәһимә. Китми тор әле! Мин сине судка бирәм! Карчыклар өчен дә, йорт өчен дә жавап бирерсен!

Рәүф. Фәһимә!.. Мәсьәләне тикшерми торып, ничек син бу баланы гаеплисен?!

Фәһимә. Карчык кешене ташлап чыгып китәргә тиеш түгел иде ул. Яхшы кыз дип... сезгә ышанган мин җүләр!

Рәүф. Мин дә сине яхшы кеше дип ышандым, ә син бөтен гаепне шушы кызга өясен. Нишләде безнен авыл? Бер кешегә ышанып булмый!..

Сажидә. Безнен авыл гынамы? Бөтен ил шундый!

Рәүф. Кызым Сәрия! Кайгырма! Барсын да жайларбыз!.. Безгә кайт!?. Кәбирә апан көтә.

Ильяс. Мин аны үзебезгә алып кайтам! Әйдә, Сәрия, әйдә безгә!..

Сәрия. Берегезгә дә бармыйм! Фәһимә апа! Милициягезне чакырыгыз! Кулга алсыннар мине! Төрмәгә утыртсыннар! *(Үксеп елый).*

Җиденче күренеш

Авансцена. Бер яктан Кәбирә, икенче яктан Энже килә.

Энже. Исәнмесез, Кәбирә апа! *(Узып китмәкче).*

Кәбирә. Тукта әле, тукта!.. Кая ашыгасын? Мин сине көтеп тора идем. Телефон аша да түгел, идарәгә кереп тә түгел... бер кеше ишетмәсен өчен, урамда тотып әйтим дидем... Син нәрсә, кызый, Рәүф абыеннын яман атын сатып йөрисен? Мин сине монын өчен... Рәүфнен үзенә әйтеп...

Энже. Сез ни сөйлисез, Кәбирә апа? Нинди яман аты?

Кәбирә. Ни сөйләвенне оныттынмыни? Әйтергә тел дә бармый... Имеш, Рәүф Казаннан килгән яшь-яшь кыз белән...

Энже. Беркемгә бер сүз сөйләгәнем юк!

Кәбирә. Үзем күрдем, дип, Мыштым Мәрьямгә сөйләгәнсен! Мыштым Мәрьям Гөлбануга, ә Гөлбану мина килеп әйтте.

Энже. Ә-ә... Ни бит... Юк, мин бит болай гына... Нишләп Сәрия Сажидә апаларда кунмады икән дип... Аптыраганнан гына әйткән идем...

Кәбирә. Аптыраганнан, имеш!.. Андый хәл булмаган!.. Булмас та! Андый хәл булганда да син теленне тыярга тиеш! Юньле секретарь үзенен хужасын сатмый! Рәүф белән минем арага чөй кагарга тырышма! Тырышып караучылар синнән башка да булды! Ләкин беркем дә безнен араны боза алмады. Сәрия әйбәт кыз. Мин аны үзебезгә чакырдым. Кызларым белән бер бүлмәдә яши.

Энже. Сез ялгыш анлагансыз! Мин бит... *(Елый).*

Кәбирә. Бик дөрес анладым!.. Син астыртын! Син гайбәтче!.. Рәүф абыен сине секретаре итеп, эшкә алып, ялгышты. Зурга жибәрәсем генә килми! Теләсәм, мин бу ялгышны

төзәттерермен дә! *(Китә).*

Пәрдә ачыла.

Идарәдә Рәүф кабинеты. Рәүф белән Сәрия сөйләшеп утыралар.

Рәүф. Син, Сәрия кызым, мине гафу ит инде! Мондый күнелсезлекләр килеп чыгар дип башыма да килмәгән иде. Ярый, ниһаять бар да ачыкланды... Комиссия бик яхшы эшләде. Нәтиҗәләрен үзен беләсең инде... Карчыклар үзләре гаепле! Сина борчылырлык бер сәбәп тә юк...

Кәбирә керә.

Кәбирә. Хәерле иртәләр!.. Эшләр барамы?

Рәүф. Эш дигәнең эшләсәң бара инде ул.

Кәбирә. Кибет ачылды. Мин Сәрияне алырга кердем. Әйдә, сеңлем, нинди күлмәк ошый, нинди туфли кирәк—сайлап алабыз! Өр-яңадан киен!

Сәрия. Ни... ни... акчам юк бит минем.

Кәбирә. Акча үзем түлим!

Рәүф. Бухгалтер килгәч тә мин анар бер айлык зарплатасын бирәм.

Сәрия. Бер ай эшләмәдем бит әле!

Рәүф. Эшләрсен, Алла бирсә! Эшләрсең! Нәрсәләр аласың килә—икәүләп барсын сайлагыз!

Сәрия. Рәхмәт! Ярый алайса, акча алгач, Кәбирә апа, мин сезгә бурычымны кире кайтарырмын!

Рәүф. Нинди бурыч?! Бүләк итә ул сиңа!..

Сәрия. *(Күлмәгенә ымлап).* Миңа кызлар менә бер күлмәк бирделәр бит инде!

Кәбирә. Юк! Юк! Бу күлмәк килешми... Синеке түгеллеге кычкырып тора... Әйдә, әйдә! Матур итеп киенеп куй әле!

Рәүф. Озак йөрмәгез! Сәриягә бер сүз әйтәсем бар!

Сәрия. Нинди сүз ул?

Рәүф. Килгәч, әйтермен.

Сәрия. Ярый алайса. Бу күлмәк чынлап та килешми миңа. Киттек, Кәбирә апа! *(Кәбирә белән чыгалар).*

Рәүф. Сәүбан Хәсәнович алдында унайсыз... Ятим баланы алып китте дә, рәхәт күрсәтә алмый дияр... *(Чыга).*

Энҗе кереп, үз өстәлендәге компьютер каршына утыра. Эшли башлый. Ильяс керә. Энҗене тартып торгыза.

Ильяс. Мин сине үтерәм! *(Энҗене буа башлый. Энҗе аннан ычкынырга тырышып, кычкыра. Тавышка Рәүф керә).*

Рәүф. Нинди тавыш? Нәрсә булды?

Ильяс. Пока бернәрсә дә булмады... Ләкин булыр!.. *(Ашыгып чыгып китә).*

Рәүф. Нигә кычкырыштыгыз? Нәрсә булыр ди ул?!

Энҗе. Юк! Болай гына... Үзебезнең арада гына...

Рәүф. Үзебезнен арада гына дисен?.. Ярар, мәхәббәт мәсьәләләре булса, мин катышмыйм. Күптән әйтергә җыенам... Энҗе! Кирәк чакта сүзне өзеп кенә әйтмисең син. Бу гадәтең миңа ошамый. Комиссиягә дә «Белмим... белмим»нән башка бер сүз дә әйтмәгәнсең.

Энҗе. Нәрсә әйтим соң?

Рәүф. Банат карчыкка Сәрияне син илтеп куйдын. Ничек каршы алды? Берәр нәрсә сизелмәдеме?

Энҗе. Яхшы каршы алды. Бер нәрсә дә сизелмәде.

Рәүф. Эчмәгән идеме? Өендә аракы-мазар күрмәденме?

Энҗе. Юк... Күрмәдем... Мин бик тиз кайтып киттем... Өйдә эш күп бит...

Рәүф. *(Кәгазь бирә).* Мә! Комиссия, экспертиза нәтиҗәләре белән таныш... Оят! Бөтен авыл, бөтен район, бөтен Республика өчен оят! Эш кешеләре—механизаторлар эчми... Бер эшсез өйдә яткан карчыклар эчә... Шыпырт кына... Яшереп кенә... Ярып, анализ ясагач... сер ачылган... Ялган аракы эчеп агуланганнар... Каян алганнар?! Намазлык өстендә генә утырасы әбиләр бит! Нинди оятсызлык! *(Телефоннан сөйләшә).* Әйе, мин. Күнелсез хәбәр?.. Әйдә, әйдә, әйт! Күнелсез хәбәрләр ишетергә колаклар күнегеп беткән инде... Кабак Гарәфи?! Кайчан? Бүген иртән?... Ай-йай-йай! Ишетмәгән идем... Әле генә комбайнчылар янынннан кайттым бит. Ничек булган дисен?... Ә-ә... Алай... Мазутка барган, вокзал аша кайткан?... Багажнигында?.. Бер ящик?!. Безобразие! Кара базарнын, ялган аракынын оясы шул вокзалда!.. Кемнеңдер кулына эләккәнче, тизрәк, хәзер үк ул ящикны монда китер!..

Хатыны бирсә дисенме? Бирмәсә, үзем барып алам да, ул бер ящик агуны балта белән челпәрәмә китерәм!... *(Трубканы куя).* Шайтан алгыры!..

Энже мыштым гына компьютерда эшләп утыра. Фәһимә керә.

Фәһимә. Рәүф! Районнан алып кайттык. Күмә алмый йөрибез! Бу нинди башбаштаклык?! Хәзрәт зираттан урын бирмибез ди... Кая күмик инде?

Рәүф. Мин хәзрәт эшенә тыкшынмыйм!

Фәһимә. Ничек инде... тыкшынмыйм дип... Әйтерсең, безнең зиратка монарчы бер гөнаһсыз фәрештәләрне генә күмгәннәр? Ярты зиратта эчеп үлгән әрвахлар ятадыр. Ишеткәнсеңдер инде, бүген иртән әнә тагын Кабак...

Рәүф. Ишеттем! Ишеттем! Кабак кабарган!... Шартлаган!...

Фәһимә. Кабакка урын биргән. Безнең карчыклар гына гөнаһлы икән!.. Юри издеваться итә ул! Хәзрәт белән сөйләш!

Рәүф. Уттай урак өсте! Эшем күп! Механизаторларны кайгыртыйммы? Эчеп үлгән карчыкларны күмеп йөримме?! Жирле үзидарә хәл итсен! Үзидарәгә бар!..

Фәһимә. И Гөмбә!.. Гөмбә дип белеп кушканнар сезнең нәселгә кушаматны! Поганка!.. Әйе!.. Үзең әйтеп торасың, карчыклар кайгысы түгел синдә, озын ботлы яшь кызлар кайгысы!.. *(Пырлап чыгып китә).*

Рәүф. Уф Алла! Нинди яшь кызлар? Бар икән ишетәселәр?! *(Йөрәген тотып утыра. Шифалы су салып эчә).*

Бик матур киенгән Сәрия белән Кәбирә керә.

Рәүф. Вот!.. Шәп булган! Вкусын бар икән!

Сәрия. Кәбирә апаның зәвыгы бар! Ул сайлады!...

Рәүф. Кәбирә апаның зәвыгы булмаса, Рәүф абыең аның белән гомер итмәгән булыр иде! Бик нечкә зәвыклы минем Кәбирәм!..

Энже *(Халыкка).* Хатынын мактап утырган була... Үзенең күзе гел Сәриянең күкрәгендә!..

Сәрия. Нинди сүз әйтмәкче булган идегез?

Рәүф. Яшьләр өчен салына торган йортның бер корпусы өлгерде дияргә була. Сиңа шуннан бер бүлмә бирәм. Бөтен эшен бетереп, буяп куйдылар. Бер-ике көннән күчәрлек була.

Сәрия. Рәхмәт, Рәүф абый! Мин сездә кала алмыйм.

Кәбирә. Кая барасын? Паспортсыз, бернинди документсыз...

Рәүф. Паспорт алыйк, документларынны булдырыйк! Мин сине бу хәлеңдә беркая жибәрмим!

Сәрия. Юк, Рәүф абый, барсы өчен рәхмәт! Мин инде, ниһаять, китәм!

Рәүф. Компьютер...

Сәрия. Энже бик башлы кыз! Өйрәнде инде ул!.. Башкаларны да өйрәтә алачак! Шулай бит, Энже? *(Энже дәшми).*

Ашыгып Ильяс керә, ишек төбендә туктап, тыңлап тора.

Рәүф. Китмисен!.. *(Сәриянең аркасыннан сөеп).* Без сине әле кияүгә бирәбез! Шулай бит, Кәбирә!

Кәбирә. Гөрләтеп туй ясыйбыз!..

Рәүф. Кияүне үзем табам!.. Үзем яучылыйм!.. Загска да үзем шаһит булып барам!

Сәрия. Язылышырга паспортым юк бит! По-жар-да ян-ды!..

Рәүф. Паспорт алырбыз! Борчылма!

Ильяс. Мина яучыла син аны, Рәүф абый! Мина!.. Үзем өйләнәм мин аңа!..

Энже урыныннан сикереп торып, пырылдап чыгып китә.

Рәүф. Нәрсә булды бу Энжегә?

Ильяс. Көнләшә ул! Көнчелегенә чыдый алмый!

Кәбирә. Әйтмәм дигән идем, әйтәм инде, Рәүф, син куеныңда елан асрыйсын. Синең турыда яман хәбәр тарата бу Энже!..

Ильяс. Әйе, әйе мин дә әйтергә яхшысынмый йөрим... Сезнең хакта начар сүзләр сөйли.

Рәүф. Начар сүз? Нәрсә дип сөйли? Нигә аны миннән яшереп йөрисез?

Кәбирә. Имеш, син Сәрия белән... Әйтергә оят!..

Рәүф. Йә Аллам! *(Йөрәген тотып).* Тагынниләр ишетәсем бар икән?..

Кәбирә. *(Йөгереп Рәүф янына килә).* Рәүф!.. Рәүф!.. Нәрсә булды? Төсең киткән?!

Әмир керә.

Әмир. Исәнмесез?! Рәүф абый, эшсез ята алмыйм. Миңа эш кирәк бит инде...

Рәүф. Ә-ә... Эш... *(Йөрәген тотып, идәнгә авып төшә).*

Кәбирә. Рәүф! Рәүф бәгырькәем!.. Ильяс! Скорый чакыр!..

Ильяс *(Телефоннан).* Скорая! Скорая!.. «Ак юл»дан шылтыратам! Рәүф абыйның хәле начар! Тиз килегез!..

Кәбирә. Сәрия, су китер!..

Сәрия *(Су алып килә).* Рәүф абый! Рәүф абый!..

Кәбирә. *(Рәүфкә су эчертмәкче).* Рәүф! Кадерлем! Бер генә йот!..

Әмир *(Рәүф янына килеп).* Диванга салыйк!.. *(Күтәреп диванга сала).* Кәбирә апа! Мин башын күтәреп торам, сез су эчертегез! *(Рәүфнең башын күтәрә).*

Кәбирә *(Рәүфкә су эчертә).* Аллага шөкер! Күзен ачты!..

Сәрия. Рәүф абый!..

Кәбирә *(Торырга омтылган Рәүфне кире яткырып).* Тормыйсың әле! Тормыйсың!..

Рәүф. Үтте!.. Үтте!.. Бераз чәнчеп кенә ала.

Сәрия. И Рәүф абый!.. Куркыттыгыз!..

Рәүф. Курыкма! Синең туйда биим әле мин!..

Сәрия. Болай булгач, китмим Рәүф абый, китмим авылыгыздан!.. *(Ильяс белән Әмир арасында басып кала).*

Тәмам

«Казан утлары» елъязмасы

Гыйнвар

70 ел элек (1943) «Совет әдәбияты» журналының 1 санында **Ибрай Газиның «Авылдаш» хикәясе** укучылар игътибарына тәкъдим ителгән.

55 ел элек (1948) «Совет әдәбияты» журналының 1 саныннан **Гомәр Бәшировның «Намус» романы** дөнья күрә башлый.

50 ел элек (1953) «Совет әдәбияты» журналының 1 санында **Нәкый Исәнбәтнең «Рәйхан» пьесасы** урын алган.

45 ел элек (1958) «Совет әдәбияты» журналының 1 саныннан **Фатих Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» романы** басыла башлый.

20 ел элек (1983) «Казан утлары» журналының 1 санында Илдар Юзеевның **«Мәңгелек белән очрашу»** шигъри трагедиясе, **Әхсән Баяновның «Таш китап» романы** дөнья күргән.

Татарстанның халык шагыйре
Илдар Юзеевка 70 яшь

МОҢ ЭЧЕНДӘ АСЫЛТАШ

Моң! Бу сүз күңелне галибанә балкып аткан алсу таңнарга, Кояшның илаһи җылы нурларында хозурланган көн үзәгенә, кызгылт-комач шәфәкъ бизәгенә, айлы кичнең йолдызлар белән чигелгән зәңгәр күк гөмбәзенә... тагы да әллә нинди сихри, серле, могҗизалы дөньяга сәяхәт иттерә. Хәер, бөтен галәм моң өрфиясе эчендә изридер ул. Дөнья үзе моң катыш яралгандыр, бәлки... Җир белән күкнең кайнар мәхәббәт җимеше булган адәм баласы да үз моңы белән туа. Моңнар гаммасы композиторның көй-уйнау коралына күчә, шагыйрьнең шигърияте тукымасында кәрәзләнә.

Илдар Юзеевны еш кына «моңлы шагыйрь», «яшьлек шагыйре», «тормыш шагыйре» дип атыйлар. Шагыйрь иҗатында фәлсәфи фикер, аң дулкыны, яшәү турында уйлану «коры» сүзләр белән әйтелми, төрле поэтик бизәк, сурәтләү-тасвирлау чарасы, мәгънә, моң ярдәмендә гамәлләшә. Моң шагыйрьгә тормыш фәлсәфәсен символлаштыруга ярдәм итә.

Бер уйласаң, тормыш үзе моңнан торадыр әле. Анда—матурлык та, илаһилык та, мәхәббәт тә... барысы да бар. Илдар Юзеевның «Таныш моңнар» поэмасының исеме үк шуларга ишарә ясый. Халык йөрәгенә ул моң дулкыны булып ябырылды. Меңнәр, миллионнар шашып укыды аны. Ун елдан артык радиодан яңгырап торды. Халык аны, чыннан да, тормыш моңы дип кабул итте. Заман давылы турында язылган сәхнә драмасы кебек яңгырый иде ул радиода. Безнең якларда Резидә дигән исем ишетелми иде әле. Поэма басылганнан һәм радиодан тапшырылганнан соң, язгы ләйсән яңгырдан чистарып калган җир битендә баш калкыткан чәчәкләр кебек, Резидә исеме күбәйде дә китте. Резидә исеме халык күңеленә моң булып керде. Димәк, халык моңын җырлый белгән шагыйрь. Шул моң кәгазьгә яки басмага шагыйрьнең каләм очыннан гәүһәр булып түгелә. «Борчылу» исемле шигырьдә аның чыннан да шулай икәнлеген күрәбез.

Әрсез дигән атым таралмаган,
Тик аласын алдым.
Ни алдым:
Күктән—нурлар,
Җирдән—тәмнәр,
Табигатьтән моң алдым.
Каеннан—су,
Таңнардан—чык,
Кыңгыраудан чың алдым.

Үз йөрәгендәге моңны табигать йөрәгендәге моң белән бәйләп язу Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, Кандалыйлар заманыннан килә. Аның матур әлге-үрнәкләрен Г. Тукай, Г. Ибраһимов күрсәтте. «Күктә ни булмас дисең, очсыз-кырыйсыз күк бит ул»,—ди дә Тукай шигырьләрен җир моңы, күк йөзе моңы белән бәйләп яза. «Диңгездә» исемле хикәясендә Г. Ибраһимов болай ди: «Карыйсың да үзеңне, дөньяңны онытасың, хыялың, гүя, сине икенче дөньяларга, матурлык, изгелек белән, шигърият белән тулган яңа илаһи галәмнәргә алып китә». Матурлык, изгелек, шигърият белән тулган яңа илаһи галәм нинди ул? Зур галимнәр, алтын башлар бу хакта һаман баш

вата. Бу—бер. Икенчедән, шул фикернең эмоциональ-экспрессив куәтен Г. Ибраһимов «моң» сүзе белән дә көчәйтеп куя: «Бераздан диңгез төбеннән моң гына нурлы ай күтәрелә».

Илдар Юзеевның әлеге строфасындагы җир йөрәге белән күк йөрәге тоташ икәнлек турындагы поэтик фәлсәфәсе Тукай һәм Ибраһимовлар фикере белән аваздаш бит. Күктән—нур, җирдән тәм ала шагыйрь. Әмма көндезге кояш нуры, төнге ай нуры гына түгел бу. Кояш-ата, үз планета-балаларын ияртеп, тулпар-коштай оча-җилә бирә. Чиксез галәмдә мондый галактикалар бихисап. Алар үзәгендә—кояш кайнарлыгыннан мең-мең артык кайнар, кояш зурлыгыннан йөз-йөз кат зур булып, мөбарәк тәсбих төймәләредәй тезелгән биниһая гигант йолдызлар. Ә күк, фән һәм дин раславынча, җиде кат. Ләкин алай гына да түгел ул. Фән аның яңадан-яңаларын эзли, билгесез чиклеккә караш ташлый, хыял-фантазиясен әллә кайларга сәяхәт иттерә...

Азнакай районында очрашуларда. Сулдан: Шәүкәт Галиев, Заһид Хәбибуллин, Ләбибә Ихсанова, Илдар Юзеев, Мәхмүт Хәсәнов. 1970 ел.

Шагыйрь күңеленә нурны әнә шулардан ала. Ә шагыйрь барысын да чәйнәп салмый. Бу хакта Г. Ибраһимовның да әйткән фикерләре бар. Аныңча, язучы, шагыйрь идеяне үзе әйтеп бирергә тиеш түгел (соңгы вакытта шагыйрьләр моның белән нык мавыга), моны аның сүз серләре әйтеп торсын. «Сүзнең эче—алтын, тышы—көмеш»,—дигәнне Абай шуңа әйткәндер. Бу очракта Илдарның «нур», «тәм» дигән сүзләре эчендә, чыннан да, гаять серле фикер алтыны бар. Аз сүз белән күп мәгънә аңлатуның гүзәл бер үрнәге бу. Илдарга хас булганча, гади генә әйтелгән, әлбәттә. Шигърият гадилегендәге матурлык бу. «Җир тәме» дигәнне халык аңлый. Бу хакта ул уйлана, баш вата, бөтен матди байлыкларны барлый, хозурлана да хәтта. Ә инде күк нуры аның өчен—рухи байлыклар хәзинәсе. Ләкин күктән нур, җирдән тәм генә түгел, табигатьтән «моң»да ала шагыйрь. Моң «нур», «тәм» сүзләренә яңа эстетик зәвык өсти. Шагыйрь йөрәгенә алынган бу моң, зур фәлсәфи мәгънәгә әверелеп, поэтик юллар тукымасында нәкышләнә. Димәк, моңга бәйләнешле фикер шагыйрьнең күңел сандыгында бикләнеп калмый, басмага күчә, аннан соң миллионлаган укучылар йөрәгенә эстетик шифа булып ята. Бу фикернең каен сулары, таң чыклары, кыңгырау чыңнары белән бәйләнүе әлеге матди байлыкны, рухи халәтне киңәйтеп җибәрә, тормыш-көнкүреш, яшәеш асылы төрле яклап күз алдына килеп баса. Уртасында—Кеше дигән галиҗәнап. Биредә катлаулы-абстракт метафора да, чагыштыру да, эпитет та юк. Ә инде гомумкулланыштагы сүзләрдә образлылык та, идеялелек тә, эмоциональлек тә, аз сүз белән күп мәгънә аңлату да, җанлы картина да бар.

«Таныш моңнар»дагы яшь егет белән яшь кыз арасындагы мәхәббәтне чагылдыручы моң, өслүби-стилистик алым буларак, Илдар Юзеевның поэтик дөньясында һаман дәвам итә. Аның моңы вакыт-вакыт атабыз Адәм, анабыз Хава кавышкан, дөнья яралган чакларга да сәяхәт итеп ала. Без аның шулай икәнлеген «Мәхәббәт китабы» исемле поэмасыннан укып беләбез:

«Мәхәббәт» дип әйтү белән, беләм:
яңа җыр көтәбез җырчыдан...
Мәхәббәт ул—телдән төшми торган
Иң борынгы моңлы җыр сыман.
Уй-хисләрнең иң җылысын эзләп,
Саф дөньяга карап юл чыгам.

Әйе, моңлы җырлар бик борынгыдан килә. Аларның мәхәббәт белән бәйле булганнары да бихисап. Шагыйрь уй-хисләрнең иң җылысын эзләп, саф дөньяга карап юлга чыга. Мәхәббәткә ничә яшь булу турында сорагач, мәгарәдәге ташлар да, тынып калган вулканнар да, иске каберләр дә, дөнья тарихлары да җавап бирми. «Мирас» журналының бер санында Зыя Камалиның «Акыл һәм инану фәлсәфәсе» дигән хезмәте басылып чыккан иде. Автор анда кешенең акылы, уй-хисе, талант-сәләте, моңы... һәммәсе үзе белән бергә туу турында әйткән иде. Уңган ана баланы карынында чакта ук тәрбияли башлый. Биш айдан бала күңеле тышкы дөнья белән бәйләнә. Шул чорда ук ул ананың җыр-моңын да кабул итә ала. Димәк, якты дөньяга моң белән дә туа. Шагыйрь болай ди:

«Мәхәббәткә ничә яшь?» дисәгез,
Мәгарәдә ташлар дәшмәстер...
Мин җырларны тыңлыйм: ул, мөгаен,
Моңлы көйләр белән яшьтәштер.

Ананың илаһи-самими мәхәббәте балага карында чагында ук җыр-моң белән дә бирелә икән, бу очракта сөю-мәхәббәт, чыннан да, моңлы көйләр белән дә яшьтәш булып чыга.

Тормышта барысы да капма-каршы: яхшылык—яманлык, шәфкатьлелек—шәфкатьсезлек, аклык—каралык... Шагыйрьнең моңы да гел генә фәрештәләр канатына төялеп килгән саф-ак тойгылар түгел. Аларның каратискәре булганнары да бар. Яки моң, яшәеш кануннары таләп иткәнчә, капма-каршылыклар давылында тибрәлә. Хәер, бу үзенчәлек шагыйрьдә «Таныш моңнар»дан ук килә. Ә инде «Мәхәббәт китабы»нда моң-галәм яшәеше ташкынының уртасында:

Кыргый багланышлар хөкем сөргән,
Тыныч кына аккан дөньяда
Иң көчле дәрт, моңсу шатлык туган,
Фаҗигалар арткан дөньяда.

Абай әйткәндәй, әгәр сүзнең эче алтын, тышы көмеш булса, телнең асыл гәүһәрләре булып исәпләнгән фразеологик әйтелмәләр ул алтын һәм көмешкә яңа сыйфат-ялтыравык өсти. Алар халык иҗатында, беренче язма әсәрләрдә дә күп очрый.

Татар фразеологиясен Тукай, Такташ, Туфан, Хәкимнәр бик нык эшкәртә... Илдар Юзеев та аның матур үрнәкләрен күрсәтә. «Мәхәббәт китабы» поэмасында шагыйрь моңы соңгы чиктә хәзерге чорның авыр, тирән, социаль-фәлсәфи каршылыкларын гаҗәп үткен, образлы, мәгънәле, хис-тойгыларга бай фразеологик әйтелмәләр ярдәмендә чагылдырыла.

Югары аң хөкем сөргән җирнең йөзен
вакытлыча караңгылык чорнап алган.
Йоклый адәм балалары изрәп-арып,
миллиард акыл һәм миллиард җан ялга талган.
Берәү матурлыкны төзеп арган,
берәүләре төзегәнне өзеп арган.
Иксез-чиксез яхшылыкны күтәргән җир,

иксез-чиксез явызлыкны үткәргән җир
бервакытны яманлыктан сыгылыр сыман,
сыгылыр да күк йөзенә егылыр сыман.
Ычкынмый җир... нидер аны тотып тора,
явызлыклар яхшылыкны йотып тора...
Ә яхшылык һаман, һаман шытып тора,—
аек акыл һәм җан җирне тотып тора.

Шушы юлларда 12 фразеологик әйтелмә бар. Халыктагы «чорнап алган», «изрәп йоклый», «йотып тора» кебекләре әзер килеш кулланылган. Ләкин гел әзер белән эш итү чәйнәп биргәнне йоту була. Ул шагыйрьнең сүз сәнгате остасы икәнлеген расламый. Шуңа күрә әдип аларны үзгәртә дә. Илдарда да шулай. Аның фразеологик әйтелмәләрен төзүче сүзләр арасына башка лексик берәмлекләр керә, йә булмаса бер сүз белән алыштырыла. Халыктагы «яхшылык җирдә ятмый» дигәнне автор «яхшылык һаман, һаман шытып тора» дип үзгәртә. Илдар үзе дә яңа фразеология ясый: «югары аң хөкем сөрү», «җансыз ялга талу», «матурлык төзеп ару», «төзелгәнне өзеп ару», «җирнең явызлык үткәрүе», «яманлыктан сыгылу», «җирнең явызлыкны, яхшыны йотуы», «җирне аек акыл тотып тору».

Фәнни телдә моның термины да бар: халык иҗат иткәне—«традицион», үзгәртелгәне—«трансформацияләнгән», язучы үзе иҗат иткәне—«индивидуаль». Илдар күбрәк соңгы икесе белән эш итә. Аның шулай икәнен югарыдагы өзек тә күрсәтеп тора. Андый мисаллар башка әсәрләрендә дә бик күп. Аларны санап чыгу максатын куймадык, бер мәкаләдә бу мөмкин дә түгел. Кыскасы, татар фразеологиясен эшкәртүдә Илдар Юзеев классик өлгеүрнәк күрсәтте. Шушы бер өзектәге фразеологик әйтелмәләрдән генә күпме сүз-сурәт, мәгънә, хис-тойгы. Алар җырлап тора. Көй-моң белән сугарылган. Моң биредә югары аң белән бәйле.

Шигърияткә җан, кан өстәүче, андагы «тәмле» сүзләргә канат куючы, образлылыкны мәгънә һәм хис-тойгы ягыннан янә көчәйтеп җибәрүче, әсәргә яңа эстетик сыйфатлар өстәүче сурәтләү-тасвирлау чаралары белән эш итүдә дә Илдар Юзеев югары сәнгатьлелек маһирлыгы күрсәтте. Аның поэтик тукымасында халык иҗат иткән традицион чагыштыру, метафора, эпитетлар да бар. Шулай да ул мең мәртәбә чәйнәлгән, тапталган, бизәге җуелган, «укасы коелган» сурәтләү-тасвирлау чараларыннан качарга, телнең эчке үсеш кануннарына «комачауламаслык» итеп, үзе яңаларын иҗат итәргә тырыша. Бу, бәлки, «качу»да түгелдер. Яңача уйлау, яңача фикер йөртү, яңа эстетик идеалларның яңа поэтик бизәкләр эзләргә мәҗбүр итүедер. Әсәрнең идеяэчтәлеге, ул чагылдырган чор, яңа эстетик сыйфатлар таләп итә моны. Хәер, бүгенге хәл-әхвәл, тормыш-көнкүреш, вакыйгаларны гына түгел, дөнья яралгандагы җан ияләрен тасвирлаганда да яңа сурәтләү чаралары белән эш итәргә тырыша шагыйрь. «Мәхәббәт китабы» поэмасындагы «Адәм белән Хава очрашуы» бүлеген алыйк. Җир йөзендә әле бер генә йөрәк бар: Адәм яши. Ә табигатьтә өстен көчләр—ерткычлыклар. Шәфкатьсезлек, акылсыз дәрт хөкем сөрә. Җир буйлатып Адәм бер ялгызы килә. Ком-сәхрәләр, дала-кырлар, таулар аша. Карурманнар, дәрья-сулар артта кала.

Бервакытны сызылып алсу таң атканда,
Могҗизадан хәйран калып туктый Адәм.
Туктый Адәм, күзләр зуп-зур ачылганнар,
авыр күсәк ихтыярсыз төшә кулдан...
Нәрсә соң бу: күпме гомер кичереп тә
Җир йөзендә мондый хәлне күргәне юк:
тай ялыдай елым-елым ике толым...
Кара күзләр—ап-ак карда ике йөзем...
Тулган айдай күкрәкләре тирбәләләр,
Чәчәк сыман ачыла гөл-керфекләре...
Җиргә яңа туган сыман карый Адәм:
бу нинди ямь, нинди балкыш күрелмәгән...
Серле дөнья тәкъдим итә баласына
Табигатьнең бар сафлыгын, нәфислеген,

Юкка гына эзләгәнсең зәңгәр күктән,
Эзләгәнең син яшәгән җирдә икән...

Анабыз Хаваның кыяфәтен, образ-сыйфатын, куәтен күрергә, күз алдына китерергә кем генә хыялланмый икән?! Аны тасвирларга сурәтләү чарасы табу да авыр. «Тай ялыдай елым-елым ике толым» дигән чагыштыруда аның тышкы матурлыгы гына түгел, эчке җегәрлеге, елгырлыгы, үткенлеге дә чагылдырыла. Шагыйрьнең тайны сайлавы да образлылык ягыннан бик отышлы. Тай—атларның яшьлек чоры. Киләчәктә барлык балаларның анасы булачак Хаваның яшьлек вакыты. Ул әле яшь тайдай ярсып-ашкынып йөри. Риваятьләрдәге җир һәм күкне бер итеп гизгән Тулпар шикелле. Шагыйрь шулай да Тулпарны сайламый. Чөнки монда тарихи чынбарлык кирәк. Хаваның чәчен тай ялына чагыштыру—үзе җанлы картина, сүз-сурәт, сөйкемле-гүзәл образ. «Елым-елым ике толым» дип әйтү дә әдәбиятта очрамый кебек. «Елым» сүзлектә юк. Аны ялгыз килеш кулланып та булмыйдыр: «елым ике толым» дип әйтеп булмый. Шуңа күрә шагыйрь: парлы яки кабатлаулы сүз ясарга мәҗбүр булган. «Елым-елым ике толым»да матурлык кына түгел, батырлык чаткылары да бар. Күкрәкне (бу очракта хатын-кыз күкрәгендәге ике йомарламны) айга чагыштыру халык телендә дә юк, әдәби әсәрләрдә дә очрамый. Ә менә Хава өчен ул килешеп тора: аның һәр әгъзасы якты идеаллар белән балкый. Болардан тыш шагыйрь Хаваның рухи һәм җисмәни көчен, гүзәл сыйфатларын сурәтләү-чагылдыру өчен төрле-төрле тасвирлау чаралары куллана. Адәмнең Хавага карашында әлеге җир һәм күк йөрәгенең тоташ икәнлеге дә ачыклана:

Җиргә яңа туган сыман карый Адәм:
бу нинди ямь, нинди балкыш күрелмәгән..
Серле дөнья тәкъдим итә баласына
Табигатьнең бар сафлыгын, нәфислеген.
Юкка гына эзләгәнсең зәңгәр күктән,
Эзләгәнең син яшәгән җирдә икән...
Ашкынуың, җилкенүең шуңа: җаның
нәзакәтлек, җылылык һәм назлау көткән.

Мәхәббәттә зур шатлык та, олы йөрәклелек тә, бөек хис-тойгылар да, аларга капма-каршы булган җитди авырлык та, борчылу-кайгырулар да, җиңү-җилкенүләр дә...—барысы да бар. Бу идея Илдар Юзеевның «Таныш моңнар»ыннан килә. Шагыйрь дөнья-табигать авырлыкларын җиңә-җиңә кавышкан атабыз Адәм, анабыз Хаваның дөнья зурлык мәхәббәтен бирә ала, шундый осталыкка ирешә. Дөньяга, яшәешкә, бәндәләргә зур сөю-мәхәббәт килә. Болай ди шагыйрь:

Җирдә туа СӨЮ дигән иң гади хис,
тормыш күрке, гүзәл тойгы, акыллы ямь...
Ике җанны очраштырган Табигатькә
һәм очрашкан Адәмгә дан, Хавага дан!

Сөю моңы килә! Мәхәббәт моңы килә! Яшәү моңы килә!

... Гөл бакчасына барып керсәң, мең төрле чәчкәләргә сокланып карап торасың. Барысы да матур. Өзәргә кирәк икән, кайсын сайларга белми аптырыйсың. Илдарның поэтик бакчасында да шундый ук хис-тойгы кичерәсең. Аның үзенә генә хас поэтик бизәкләре шулкадәр күп, анализ өчен кайсын сайларга белми аптырыйсың. Язмабыздагы бу мисаллар зур гөл бакчасыннан өзгән берничә чәчкә кебек кенә.

Нәтиҗә итеп шуны әйтәсе килә: Илдар Юзеев табигатьтән халык йөрәгенә бирелгән бөтен моңны үз йөрәгенә ала да, аны халык йөрәгенә үзләренекеннән дә баерак, матуррак, мулрак итеп кире кайтарып бирә. Поэзиясе һаман тирәнәя бара. Аның поэзиясендә Кол Галиләр, Тукайлар, Такташлар, Хәсән Туфаннар моңы бар. Бүгенге диңгездәй киң татар поэзиясенә дә ул шул моңнар аша килде. Хәзер инде үзенә генә хас бай моң белән тантана итә. Киләчәк буын шагыйрьләргә аның шифалы йогынтысы булмый калмас.

Суфиян ПОВАРИСОВ,
филология фәннәре докторы, профессор.

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА—КАЛӘМДӘШЛӘРЕ

Алгы сафтагы шагыйрь

Егерменче елларда тынгысыз Такташның әдәбиятка килүе олы вакыйга буларак кабул ителгән иде. Аның кебек үк, беренче адымнарыннан үзенә игътибарны җәлеп итәрлек шагыйрь күренгәнче, шактый озак көтәргә туры килде.

Сыркыдыда, Такташның 70 еллыгында чыгыш. 1971 ел.

1955 елда шагыйрь Илдар Юзеевның «Таныш моңнар» поэмасы басылып чыкты. Ул шунда ук киң катлам укучылар арасында шөһрәт казанды. Чыннан да, Илдар Юзеев башка бик күп каләмдәшләреннән үзенчәлекле тавышы белән аерылып тора. Бу тавышта Такташ авазы да тоемлана. Илдар Юзеев халык шагыйренең җанга ятышлы традицияләрен остазы туктап калган ноктадан алып китте. Шул ук вакытта ул, шагыйрь буларак, Җәлил шигъриятен дә чит итмәде. Кыскасы, Илдар Юзеев турында һич тә икеләнмичә, ул—заман шигъриятенең иң матур традицияләрен үзенә туплаган бәхетле шагыйрьләрнең берсе дип әйтәсе килә. Илдар Юзеев иҗатында җылы лирика, героика һәм патетика белән үрелеп, үзенә генә хас стиль барлыкка китерә. Юзеев реализмы романтик ашкыну белән заман яшьләренең бай рухи дөньясын җырлауга юнәлгән.

Минемчә, Илдар Юзеев—без яшәгән көннәрнең көен, аһәңен тапкан шагыйрь. (Бу җәһәттән ул халыкчанлыгы, ихласлыгы, тирән моңы белән әсир иткән Илһам Шакировка бик якын.)

Аның шигырьләре, балладалары һәм поэмалары модернизм арбасына тагылган кайбер тәҗрибәсез яшь шагыйрьләргә дөрес юнәлеш табарга, поэзиядә үз юлыннан барырга һәм Тукай, Такташ, Җәлил линкорына күчәргә ярдәм итәрләр.

Әмма Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге лауреаты дигән исем шагыйрьгә гомерлеккә бирелә.

Илдар Юзеев комсомол бүләгенә тәкъдим ителгән «Миләүшә» җыентыгыннан соң, Муса Җәлил тормышыннан «Соңгы сынау» дигән гүзәл драматик легенда иҗат итте. Моның белән ул киләчәккә яңа биеклекләр яулау мөмкинлеген янә бер раслады.

Юзеев шигърияте әдәбиятыбыз Иделенә челтерәп аккан саф чишмәне хәтерләтә. Шагыйрь—олы бүләккә лаек...

Хәсән ТУФАН,
1968

* * *

... Башкалар да яшьлекне җырлаган. Ләкин алар үтеп барышлый гына, үзләренә кагылган өлешен генә җырлаган. Илдарның иҗаты башыннан ахырына кадәр яшьлек турында, аның чордашларыннан бу теманың стихиясенә кереп, үзенең тәмам романтикасына әйләндергән башка бер шагыйрь дә юк. Ул картайганчы яшьлектән айный алмый торган шагыйрь булып калачак.

Такташтан соң... Такташ «Урман кызы», «Мәхәббәт тәүбәсе», «Алсу»лары белән яшьлекне исертеп китте. Һәр чорның үз яшьлеге, беркайчан да кабатланмаган үз мәхәббәте, һәр чорның үзенә хас проблемалары, янулары, көюләре. Кыскасы, үз Резидәләре, Миләүшәләре, Янар чәчәкләре бар. Аларны шулар арасыннан күтәрелгән

Минзәлә педагогия училищесында очрашу. Сибгат Хәким белән. 1979 ел.

шагыйрь генә җырлый ала..

Илдар Юзеев поэмаларын күтәренке рухлы, романтик рухлы дибез. Мин, гомумән, поэзиягә соңгы елларда шушы әйбәт рухның, Такташ рухының әкренләп кире кайтуына куанам. Ул абстракт романтика түгел, ул конкрет җирлектән күтәрелә...

Сибгат ХӘКИМ,
1968

* * *

...Илдар—тынлыкны да, дөнья шау-шуын да үз йөрәге аркылы үткәреп, үзенчә тыңлый белә торган шагыйрь. Югыйсә, бездә, яңгыр артыннан тишелеп чыккан гөмбәләр кебек, шагыйрь артыннан шагыйрь «тишелеп чыгып» торган бер заманда, күп санлы шул шагыйрьләр (һәм шулар янына хикәячеләрне дә кушып) арасыннан әлегә хәтле кайсыбызның тынлык белән сөйләшә алганы бар иде? Һәм, гомумән, тынлык белән сөйләшергә мөмкинме? дигән сорау да баш калкытып куя. Ә чын шагыйрь өчен мөмкин икән ләбаса! Илдар Юзеев менә тынлык белән бик әйбәт итеп сөйләште. Мин аның «Тынлык белән сөйләшү» дигән поэмасын күздә тотып әйтәм бу сүзләрне.

...Сез Илдарның унга якын поэмасын—элеккеләрен һәм соңгы вакытта язылганнарын,—күп санлы лирик шигырьләрен, музыкага салынган җырларын игътибар белән күзәтеп—укып яки тыңлап карагыз. Аларның бөтенесе аша күзгә күренеп һәм күренмичә кызыл җеп булып сузылып үтә торган өч мотив табарсыз. Болар: күңел тирәнлегеннән агып килә торган моң—шагыйрьнең үз моңы, тамыры халык җырларына барып тоташкан җырчанлык һәм, ниһаять, яшьлек-мәхәббәт стихиясе...

Фатих ХӨСНИ,
1969

Драматургиядә дә шагыйрь

... Бер талантның шигырьдә дә, драматургиядә дә бердәй эш алып баруы алай сирәк күренеш түгел. Әйтик, Маяковский, Бурнаш, Такташ, Исәнбәт, Әхмәт Фәйзи, Мостай Кәрим...

И. Юзеев—шундый талантларның берсе. Ул драматургиядә дә шагыйрь булып калган, бу ике әдәбият төрен һич тә аерып карамый торган, сәхнәне шигърият белән баеткан иҗатчыларның берсе. И. Юзеев драматургиягә килгән 60 нчы елларда, хәтта аннан соңгы унъеллык башларында да театрга шигърият, ай-һай, җитми иде...

1982 елның декабрендә Мәскәүдә РСФСР Язучылар союзында татар драматургиясе турында киңәшмә уздырылды. Анда доклад белән чыккан драматургия белгече, сәнгать фәннәре докторы Владимир Фролов һәм башка театр белгечләре, тәнкыйтьчеләр И. Юзеевнең трагедия жанры өлкәсендә алып барган эзләнүләрен бик кызыклы һәм нәтиҗәле дип билгеләп үттеләр. Чыннан да, Г. Тукай турындагы «Очты дөнья читлегеннән» (1980-1981) исемле һәм М. Җәлилгә багышланган «Соңгы тән» (1972) дигән шигъри-фәлсәфи трагедияләр безнең драматургиябездә җитешмәгән, бездә генә түгел, бөтенсоюз күләмендә сирәк языла торган жанрда уңыш дип саналырга хаклы...

Азат ӘХМӘДУЛЛИН,
1983

Дания
Заһидуллина

ЯҢА ДУЛКЫНДА

Татар әдәбиятында соңгы ун-егерме ел эчендә пәйда булган әсәрләрнең күбесе модернизм элементларын үзенә туплаган яңа дулкында язылган. Аңа кадәрге 1970—1980 еллар әдәбияты янартылган реализмның (модернистик реализм) «авыл прозасы» дигән төрен формалаштырган һәм М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, Р. Төхфәтуллин һ. б. иҗатында шуның гүзәл үрнәкләрен биргән булса, 1980—1990 еллар чигендә исә Ф. Бәйрәмова психологик реализм агымына нигез салды. Үзәккә татарлар өчен хас проблемалар куеп (Ф. Садриев, Ф. Латыйфи һ. б.), милли реализм аваз бирде. Соңгы елларда ялгызлык фәлсәфәсен күрсәтүче, яшәеш кануннарын анализлап тормыш хакыйкатен тапкан әсәрләр (Р. Сибат) интеллектуаль реализм үрнәкләре—күренә башлады. Татар әдәбиятында төрле мәдәни юнәлешләргә, иҗат типларына, методларга хас алымнарның, күренешләрнең бергә, янәшә урнашуы, керешеп-үрелеп китүе күзәтелә. Хәтта постмодернизм алымнарына мөрәҗәгать итү үзен нык сиздерә. Яңа дулкында язылган әсәрләр арасында Н. Гыйматдинова иҗаты да бар һәм ул аерым бер урын тота. Чөнки автор кулланган иҗат методы да, аның сәнгати алымнар бөтенлегендә чагылышы да үзенчәлекле.

Сүзне иҗат ысулыннан башлыйк. Нәбирә әсәрләрендә кеше ике яссылыкта: реаль-гадәти тормышта да, аңлап-танып бетереп булмый торган серле-сихерле дөньяда да яши. Табигый һәм гадәти булмаган, гаҗәеп вакыйгаларның кушылуына нигезләнгән әсәрләрне, соңгы елларда дөнья әдәбият белемендәгечә, магик (сихри, тылсымлы, хыялый) реализм методы белән язылган дип карау дөрес булыр. Магик реализм иңләнгән һәм сәер хәлләрнең, төрле вакыт (бигрәк тә үткән һәм бүгенге), яшәү рәвеше, язмышларның кушылмасын бирә. Н. Гыйматдинова исә шушы өлкәләрне аерым сюжет сызыклары итеп үрә, аннары аларны бик оста ялгап җибәрә.

Әсәрләргә мөрәҗәгать итик. «Ак торна каргышы»—авторның иң матур һәм фаҗигале әсәрләреннән берсе. Төп—реалистик сюжет сызыгы—Арыслан, Сара һәм авыл кешеләре мөнәсәбәтләре аша үсә. Авылда аяксыз калган музыка укытучысы Сара көн күрә. Янгында Сараның хәлен, аңа карата авылдашларының битарафлыгын күргән Арыслан ярдәм итәргә, күңелендә өмет уятырга, җылы ризык һәм теләктәшлек бирергә тели. Әле Сара йөрәгендә дә терелүгә ышаныч сүнеп бетмәгән...

Ләкин Арыслан, Сара һәм авылдашлары каршылыгы—битарафлык һәм мәрхәмәт бәрелеше—аяныч тәмамлана. Сарага аякка басарга, музыка иҗат итәргә көч биргән торналарның берсен авыл хатыннары кыйнап үтерә, укытучы хатын юкка чыга, күрәсең үлә.

Реалистик сюжет сызыгы күп каршылыклар ярдәмендә 1980—1990 еллар авылындагы проблемаларны ача. Битарафлык (Сара—авылдашлары), эчкечелек, комсызлык (Сара—Сәрия), азгынлык (Сара—Фәрдәнә, Сәрия—Фәрдәнә), эчкечелек (Арыслан—Шәһиәхмәт малае, Арыслан—Шаһиәхмәт), әхлакый кыйммәтләрнең

үзгәрүе—алышынуы (Арыслан—әнисе), җәмгыятьтәге бозыклык (мулла—авылдашлары, Арыслан—авылдашлары), башкаларга иярү (Сара—мәктәп коллективы) алар. Проблемалар аша автор авыл тәнендәге яман чирләргә, тискәре гадәтләргә әрнүле сатирик бәя бирә, укучыны да борчылырга мәҗбүр итә.

Беренчесе белән янәшә башланган, аннан сонрак тәмамланучы икенче, мифологик сюжет сызыгы—кешеләр һәм торналар арасындагы мөнәсәбәтләр үсү тарихы. Гүзәллек һәм сафлык символы пар торналар, тәрәзәдән күренүгә үк, Сара күнелен жилкендерә, сонрак аны яшәүгә кайтара, аякка бастыра. Ләкин авыл кешеләре, азгынлык мәгънәсе салып, аларнын берсен кыйнап үтерә. Бу фаҗигагә табигать көчле давыл белән җавап бирә: гөнаһ кылган авыл җәза ала.

Икенче сюжет сызыгы беренчесен көчәйтеп, үстереп килә. Шунын ярдәмендә автор үз фикерен әйтә: битарафлык, явызлык-кансызлык җәзасыз калмый, үлем һәм фаҗигаларга китерә, мәрхәмәтле булырга кирәк, ди. Һәм давыл авылны—Нәбирә Гыйматдинова уйлап тапкан һәм тергезгән яшәү моделен—җимереп кенә калмый, ул мондый көнитешнен, усаллык, эчкечелек, битарафлык, кансызлык белән тулы тормышнын яшәештә булырга тиешме-түгелме икәнлеген хәл итә, опакалипсиска әверелә. Бер үк вакытта җимерелеп баручы, пычракка баткан дөньянын янадан тергезеләчәгенә, тереләчәгенә, башка юл сайлаячагына ышаныч, өмет булып янгырый. Биредә табигать биргән давыл XX гасыр ахырындагы татар авылын гына түгел, тулаем кешелекне кисәтә, юкка чыгу, бетү, ахырзаман, аңа китерергә мөмкин сәбәпләр билгеләнә. Шулай итеп мифологик сюжет сызыгы реаль, иҗтимагый проблемалар белән кушыла, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешенә әверелә.

Синтезга омтылу сюжет сызыкларында төгәлләнми. Автор реалистик сюжетта романтик геройлар—Сара белән Арысланны үзәккә куя. Ләкин гомуми әсәр тукымасында алар ят күзәнәк, ясалма сурәт булып тоелмый. Авылга кайтып урнашкан музыка укытучысы Саранын язмышындагы реалистик детальләр ышандыру көченә ия булса, Арыслан—авылдан читтә, консервациядә яшәп, үзен тәрбияләп үстергән тирәлектәге иң яхшы сыйфатларны саклап калган («Вәгыйзә балалары алар һәммәсе дә гарип-горабаны кызгана» дип әйттерә автор Фәрдәнәдән), күнелендәге романтиканы җуймаган (кечкенә чакта Шаһиәхмәтнен Сабиржан мулла түләячәк акча урынына дога кылдыру тәкъдимен Арысланнын исенә төшереп, элек авылдашларынын да башка кыйммәтләргә табынуын читтән кайткан ирдән үк хәтерләтү бик отышлы) булып аңлашыла. Әлеге геройларны укучыга «тәкъдим итү» вакытында ачкыч-сүз кулланыла: канат. Шаһиәхмәтнен «хыял канатларын кем көйдерде» дисә дә, бу сорауга җавап ачык. Саранын «сынган канатлары» белән янәшә, «канатлар үссә» гыйбарәсе китерелә.

Романтик геройлар, һичшиксез, автор мөнәсәбәтен күрсәтү, житкерү өчен кирәк. Язучы аларны «чистарта», рухи дөнья кайгысы белән генә яшәүче, матди ваклыклардан өстен, саф һәм изге җаннар дәрәҗәсенә күтәрә. Чөнки Арысланга йөкләнгән миссияне, авыл һәм җәмгыятьне гөнаһ баткагыннан тартып алуны, реалистик-геройлар башкарып чыга алмаячак. Мулла тарафыннан «мөгаллим» дип әйттереп, гөнаһына күрә җәза алган, давыл кичергән кешеләрне, авылны яна кануннар—мәрхәмәтлелек нигезендә яшәргә өйрәтү эшен Арыслан җилкәсенә салуын автор тагын бер кат ассызыклый.

Сюжетлар ягыннан охшаш: реалистик һәм романтик сюжет сызыгына сорыкай һәм ак бүре турындагы мифологик сызык кушылган «Пәри утарында» повестенын герое—Рөстәмне карасак, автор аны реалист-герой итеп тасвирлый. Чөнки Рөстәмгә хезмәттәшләр—әшнәләр белән мөнәсәбәтне янадан бер кат карыйсы, дуслык—хыянәт ясссылыгында уйланасы бар. Монын белән янәшә куйганда, Арысланга иҗтимагый вазифа йөкләтелә: ул—җәмгыятьтәге бозылган-үзгәргән кануннарны кире кайтарасы шәхес.

«Пәри утарында» повестендагы реалистик һәм романтик сюжет сызыклары бер ноктада тоенләнә: ялгызы гына урманда яшәүче Хаятнын өенә, үлгән дип санап, Рөстәмне кертеп ташлыйлар. Рөстәм—Хаят каршылыгы, романтик мөнәсәбәтләр мәхәббәткә кадәр үсә һәм югалту белән төгәлләнә. Рөстәмнен хезмәттәшләре белән каршылыгы хыянәт, шулай ук дуслыкны югалту белән бетә. Сорыкай һәм ак бүре мифологик сызыгы да шушы ук схеманы кабатлый. Өч очракта да янәшәдәгеләр, якыннар хыянәте ялгызлыкка, бәхетсезлеккә китерә.

Повесть проблемалар ягыннан да беренчесенә охшаш. Тигезсез мәхәббәт (Рөстәм—Хаят), җавапсызлык (Искәндәр—Хаят), азгынлык (Рөстәм—Җемҗемия), куркаклык (Рөстәм—Искәндәр), көнчелек, усаллык (Хаят—Искәндәрнең туганнары), комсызлык, җавапсызлык, битарафлык (Рөстәм—Фәрит Садриевич, Рөстәм—Хөсни, Рөстәм—Хәсибулла), табигатькә сак караш (Рөстәм—бүреләр) мәсьәләләре кеше белән кеше, кеше белән табигать, кеше белән җәмгыять арасындагы конфликтларда ачыла, шулай ук заман кешеләренә һәм җәмгыятькә бәя бирүгә хезмәт итә. Мәхәббәткә, дуслыкка җавапсыз карау, әхлакый кыйммәтләрнең җуелуы югалтуларга, фаҗигагә китерә дигән шушы фикер-идеясен автор өч төрле сюжет сызыгында кабатлап, көчәйтеп куюга ирешә.

Кайбер очракларда Н. Гыйматдинова мифологик сюжетның үзен башка төрле эчтәлек белән катлауландыра. Мәсәлән, «Болан» повестенда ике сюжет сызыгы бар. Акчәч һәм Рыскол мөнәсәбәтләре тарихы ярыммифологик, ярымромантик кушылма тәшкил итә. Акчәчнең үз эчендәге: җан һәм тән, яки Акчәч һәм болан каршылыгы барлыкка китергән ярдәмче сюжет сызыгы исә тулысы белән мифологик характерда.

Шулай ук синтезга нигезләнгән булса да, бу әсәр бөтенләй бүтәнчә кабул ителә. Төп сюжет сызыгында каршылыклар (Сузгын—авыл кешеләре, Сузгын—Мәүли, Акчәч—Рыскол, Сузгын—Рыскол, Сузгын—Акчәч, Рыскол—әнисе, Гатаулла—Рыскол) бер проблеманы—табигатькә, кешегә, үзенә охшамаганнарга мәрхәмәт күрсәтү мәсьәләсен төрле яклап ача. Аяклары яраланган Акчәч һәм Рысколның тау буенда очрашу вакытында төенләнгән сюжет сызыгы алар арасында мәхәббәт кабынуга кадәр үсә һәм Акчәчнең, Рыскол гомерен саклап калу өчен боланга әверелеп, үзен корбан итүе белән чишелә. Башка җәнлек-җанварның аучыны каргап үләчәген белгән кыз яраткан кешесен коткарып кала. Ләкин Рыскол язмышы да матур булыр төсле тоелмый: антын бозган ир йә акылдан шашар, йә чынлап та тере мәеткә әверелер!

Бу сюжет сызыгындагы табигатькә каршы бармаска чакыру идеясе ярдәмче сызыкта да кабатлана. Боланга сокланып, канун бозган өчен җәза алып, үзе дә ике тормыш белән яшәгән Акчәч, Рысколны коткарырга омтылып, табигатькә каршы чыга. Әлеге адым кыз гомере өзелү белән тәгаълләнә. Рыскол язмышында канун бозу явызлык, тереклеккә зыян салу булып аңлашылса, Акчәчнең мәхәббәтен яклап канун бозуы соклангыч һәм бөек соклангыч һәм бөек сурәтләнә, саф хисләргә мәдхия булып тоела.

Н. Гыйматдинова повестьларында реалистик сюжет төп, әйдәп баручы булганда, ямьсезлекне кире кагу үзәккә куелса, романтик сюжетлар өстенлек алганда, матурлыкны раслау алга чыга. Шундый әсәрләрнең берсе—«Китәм, димә».

Повестьтагы төп сюжет сызыгы—Камилла белән Сәйдәш мәхәббәте тарихы, романтик тарих янәшәсендә Камилла һәм Шарлотта мөнәсәбәтләрен сурәтләүче романтик сюжет җебе сузыла. Ярыммифологик, ярымромантик тагын бер юнәлеш—Шәңгәрәй белән Шамилә тарихы исә беренче карашка лирик чигенеш, сюжеттан тыш элемент кебек башланып китсә дә, Шәңкәле—Камилә, Шарлотта мөнәсәбәтләренә әверелеп, мөстәкыйль сюжет сызыгы барлыкка китерә. Ерак Париждагы очраклы күрешүдән соң Каратау авылына килеп чыккан биюче, танылган балерина Камилла Байчура биредә мәхәббәт, үз нәсел тармагын—бабасын таба... һәм югалта. Романтик сюжетлар фонында фәлсәфи проблемалар күтәрү белән чикләнмичә (Сәйдәш—Гөлчәчәк, Сәйдәш—Камилла каршылыгы, чын мәхәббәткә хыянәт итәргә ярамау), урын-вакытны төгәлләштерү, кеше образларын сурәтләүгә бәйләп иҗтимагый мәсьәләләр дә куела (Камилла—Нурмиев, Рәсимә—Хәнифә, Әнисә—Сәйдәш каршылыкларында намуссызлык, азгынлык, байлык артыннан куу кебек сыйфатларга игътибар ителә).

Шулай итеп, сюжет бирелеше ягыннан автор синтезга омтылса да, аерым әсәрләрдә янәшә урнашкан, кисешеп киткән җепләрнең характеры төрлечә. Мифологик яки романтик, мифологик яки реалистик, ярымромантик-реалистик җепләр төрлечә уралып бирелә. Чынбарлык һәм легенданы тоташтырып, автор легенда-хыялны, мифны чынбарлыкка әйләндерә. Акчәчнең урманда боланга әверелеп йөрүенә дә, Шәңгәрәй һәм Шамиләләр өе артындагы сукмакны берәүнең дә белмәвенә дә чынлап ышана башлыйсың. Автор уйлап табылган, хыялый-фантастик хәл-вакыйгаларны шулкадәр тормышчан детальләр белән бирә һәм тормыш кануннары белән аңлата

ки, әлеге мифологик катлам без белгән тормыш-чынбарлыкка, анда урнашкан тәртипләргә, тирә-юнебезгә, хәтта үзебезнең яшәү рәвешебезгә бәя бирә башлый.

Н. Гыйматдинова повестьларын (без югарыда телгә алганнарын гына түгел) берләштерә торган, алар өчен уртак булган бер сыйфат, элемент бар: ул—үзәк герой сурәтләнеше, аның характеры. Камилла яки Хаят, Акчәч яки Сара, Сәвилә яки Җәмилә, Мөнәвәрә яки Галия—әсәрдән-әсәргә күчүче бер тип геройлар. Башкаларга охшамаган, дөньяга үзенчә генә карый торган, изге-олы күңелле, чибәр һәм мәрхәмәтле, мәхәббәт хакына барысын да эшләргә әзер, корбанчылык сыйфаты да ят булмаган, әсәрләрдә сурәтләнгән тормышта бәхеткә ирешә алмаган бу хатын-кыз әсәрдәге башка геройларга замандаш түгел кебек тоела. Әйтерсен, Камилла—Шамилә һәм Шәнгәрәйләр яшь булган вакыттагы кеше тибы, Хаят—кайчандыр бик ерак заманнарда гына яшәгән хатын-кыз кабатланышы, Сара—хыял дөньясыннан төшкән «ак торна», Акчәч—борынгы мифлардан күчкән болан-кыз... Тәнкыйтьчеләр бу тип геройларны «җирдән аерылганнар», «табигать белән кеше арасында арадашчылар» дип тә атаган иде. Инде Н. Гыйматдинованың бүгенге иҗат байлыгы ноктасыннан торып, аның үткән заман хатын-кыз архетибын тудыруын, татар әдәбиятына үзгә бер хатын-кыз алып килүен күрсәтер чак җитте кебек.

Бу урында әдәбият белемендә билгеле «архетип» төшенчәсе хакында берничә сүз әйтеп китү урынлы булыр. Мәгълүм ки, әдәбиятта кабатланып торучы, төрле чор язучылар иҗатында күренеп ала торган образлар була. Галимнәр фикеренчә, мондый образлар борынгы кешеләрнең психологик тәҗрибәсе нәтиҗәсе булган кеше моделен тергезәләр. Гадирәк әйтсәк, бик борынгы заманнарда ук аерым сыйфатлары калку күренеп торган кеше типлары билгеләнгән, бәяләнгән. Мондый мәгълүмат аннан тыш (подсознание) тирәнлекләрдә буыннан-буынга тапшырып киленгән. Әдәби әсәрләрдә әлеге мәгълүмат, язучының таланты белән бизәлеп, янадан мәйданга чыга. Милли әдәбиятлар да үз архетипларын бирә. Татар әдәбиятында иң билгеле архетип булып Акъәбиләр образы—аклык, сафлык, корбанчылык сыйфатын калку гәүдәләндергән өлкән буын хатын-кызы һәм «ил анасы» архетибы—Сәҗидәләр (М. Галәү), Нәфисәләр (Г. Бәширов) кебек ил, милләт мәнфәгатьләре белән яшәгән хатын-кыз санала дисәк, ялгышмабыз.

Н. Гыйматдинова иҗат иткән архетип—без үткән заман хатын-кызы дип атаган образ да берничә әһәмиятле сыйфатны үзенә җыйган. Башкаларга охшамаган булу, табигать һәм йөрәк-хис кушканча яшәү, үзен мәхәббәт, башкалар бәхете хакына корбан итү—шундыйлардан. Әсәрләрдә ул берничә вазифа башкара. Беренчедән, романтик, нечкә табигатьле, хис-кичерешкә бай, рухи саф герой Матурлык, Мәрхәмәтлелек, Сафлык үрнәгенә—идеалга әверелә. Шушы образ укучыга нык тәэсир итеп, аны герой язмышы өчен борчылырга этәрә, әсәр белән мавыктыра. Әлеге төркем кешеләрнең югары уй-хыяллары, якты теләк-өметләре, тормышка гаҗәпләнүле-сагышлы карашлары, тирән хисләре хакында күбрәк беләсе килә. Бу, үз чиратында, психологик анализ (ешрак үзанализ) алымына мөрәҗәгать итеп, кызыклы һәм сәер кеше образын тулы һәм җентекле тергезүгә юл ача.

Икенчедән, үткән заман хатын-кызы хәзерге заман кешеләре тирәсендә, шулар фонында сурәтләнә. Заман кешесендәге тискәре сыйфатларга, яман гадәтчирләргә аның сыйфатлары каршы куела. Бу авторга ике төрле яшәү моделен, рәвешен янәшә чагыштырырга, берсен кире кагарга мөмкинлек бирә. Нәтиҗәдә әсәрләр ике вакытка: үткәнгә һәм бүгенгегә бүленә. Кешенең табигатьтән аерылуы, нәфес колына әверелүе, тупаслануы һәм явызлануы, моның гадәти кабул ителүе бүгенге тормышның төп афәт чыганагы буларак аңлатыла. Әсәрләрдә вакыт спираль буенча бара һәм аерым бер борылышларга кирегә, артка йөгерә башлый. Вакыт белән уйнау ярдәмендә хәзерге җәмгыятьнең ялгыш юлдан кереп китүе дәлилләнә. Еш кына әсәр ахырында автор төзегән вакыт шартлый, өзелә, туктала: давыл авылны юк итә, пәри утары җир белән тигезләнә, болан-кыз юкка чыга һ. б. Автор сурәтләгән урыннан, сер-хыялдан башка, аңсыз яшәү вакыты килә.

Архетип табигатькә һәм кешегә зыян салмыйча, үз күңелен саф-чиста тотып яшәргә омтылуның киләчәк фаҗигаләрдән котылу юлы икәнлеген ассызыклый. Алай гына да түгел, кешенең дөньяга килү максатын, яшәү мәгънәсен табу-күрсәтү баскычына күтәрелә. «Кеше дөньяга иҗат итәргә, матурлык тудырырга (Сара, Камилла), башкаларга ярдәм итәр, яшәү көче бирер өчен килә (Акчәч, Хаят). Шуны онытмасак иде» ди сыман автор.

Н. Гыйматдинова иҗатындагы архетип гуманистик, гомумкешелек идеясен белдерү мөмкинлегенә дә ия. Аның әсәрләрендә үткән заман хатын-кызлары ялгыз. Шушы ялгызлык, теләктәшләр яки аңлаучылар булмау—фаҗигагә китергән сәбәпләрнең берсе. Кешеләрнең аңлашып, берләшеп, ярдәмләшеп яшәү зарурияте укучы тарафыннан нәтиҗә кебек ясала.

Әсәрләрдә әлеге хатын-кыз белән каршылыкка кергән ир-ат төрле: Арыслан яки Рөстәм, Сәйдәш яки Рыскол—характерлары, язмышлары барысын да үткән заман хатын-кызы белән очраштырып сыный. Ир-егетләр дә сынауны һәрберсе үзенчә уза. Керәшчегә өйләнгәннәре дә (Арыслан), юл чатында, сайлау алдында калганнары да (Сәйдәш, Рөстәм), сынган-сыгылганнары да бар (Рыскол). Җир йөзендәге борынгы кешеләргә хас асыл сыйфатларны исә автор нәкъ менә хатын-кызда тергезә һәм аны матурлык-изгелек сакчысы, яшәү көче бирүче итеп күтәрә.

Архетип хатын-кыз янында заман хатын-кызлары да күп. Алар арасында күңеле белән Камиллага якын Рәсимәләр дә, капма-каршы бирелгән Сәрия яки Гөлчәчәкләр дә бар. Бу геройлар, нигездә, әсәрдә сурәтләнгән заманга, җәмгыятькә бәя бирү өчен хезмәт итәләр.

Төп геройларын яратып, символлар һәм мифологик катламнар янәшәсендә сурәтли Н. Гыйматдинова. Хаят образын гына алыйк. Аңа бәйләп, өч символик образ тудырыла: пәри утары, лампа уты һәм шәл. Пәри утары—Хаяткә күчмәләрдән нәзер булып калган, ачкычын тапшырганчы вакытлыча тору урыны гына түгел. Ул—табигатьтән аерылып, үзе язган кануннар белән яшәүче авылдагыга охшамаган, үзгә дөнья. Бу көнитештә һәр тереклек иясе—кешегә ярдәмче һәм дус. Бу дөньяда кеше—табигатьнең, тирәлекнең бер кисәге, чылбырдагы буын. Димәк, пәри утары—яшәү моделе, кешенең табигать белән кушылып көн итә алу үрнәге дә булып чыга. Ут символы, һәркөн Хаят тәрәзә төбенә яндырып куя торган лампа яктысы—Искәндәрне көтү газабы да. Ләкин аның чын мәгънәсе тирәндә: бу ут адашкан һәр кешегә юл күрсәтүче, маяк ролен үти. Шул ут кемнәрнедер үлемнән йолып кала. Ул—кеше күңелендәге изгелек, башкалардан әҗерен көтмичә эшләнә торган мәрхәмәт.

Өченчесе—шәл образы да кызыклы. Гаять чибәр Хаят йөзен шәл белән томалап йөри, шуңа күрә кешеләр аны ямьсез, чәчсез, пәри төсле дип уйлыйлар. Ләкин шәл—матурлыкны яшерү чарасы. Ул, шулай ук, яман күздән, явыз эшләрдән саклаучы да. Рөстәм дусларына күрсәткән мәлдә шәлен югалткан Хаят шундый саксызлык кыла. Образның өченче мәгънәсе дә бар. Хаятне шәлен югалтырга, матурлыгын күрсәтергә мәҗбүр итүче, фаҗигагә китерүче—мәхәббәт. Шәл мәхәббәтне күңелгә үткәрмәү, үзенне сөюдән мәхрүм итеп яшәү, аскетлык билгесе кебек тә тасвирлана.

Үзәк геройлар мифологик катламнар янәшәсендә сурәтләнә. Рөстәм һәм Хаят язмышы ак бүре һәм сорыкай мәхәббәте тарихына тәңгәл. Урмандагы соры бүреләр ыруыннан берсе Хаят туып-үскән яклардан ак бүре алып кайта. Ләкин соры бүреләр аны кабул итми: өзгәләп ташлый. Соры бүре ялгыз кала. Хаят тә үз тирәсендә, җәмгыятьтә ак бүре булып яши. Бу янәшәлек үз җиренә Хаятне алып кайтып, ташлап киткән Искәндәрне гаепләргә дә, Хаяткә соры бүре булып ташланган башкаларны: Рөстәмнең әшнәләрен, Искәндәрнең туганнарын, авыл кешеләрен—шулар аша тулаем җәмгыятьне тәнкыйтьләргә дә ярдәм итә.

Төп герой хатын-кыз һәм аңа каршы куелган ир-ат образларына карата гына психологик анализ алымы кулланып, автор алар күңелендә барган уй-фикер эволюциясен, хис-тойгы каршылыгын шәрехләп, күрсәтеп бара.

Башка геройларның эчке дөньясын күрмәү, аларны сүзләр-аралашу, эш-гамәл, үзләрен тотыш кимәлендә тасвирлау үзәк кеше образларын югарырак күтәрә, тирә-яктагылардан аерып куя. Әйтерсең нәкъ менә алар—шәхси фикер-хыялга, уй-омтылышка ия кешеләр. Бу дәрәҗәдә хис-кичереш байлыгы башкаларга хас булырга мөмкин түгел. Гадәттә, автор ике юнәлешне: төп герой булган ир-ат һәм хатын-кызның фикер, кичереш үсешен үреп алып бара. Һәрберсенең үз уйлау рәвешен, үз сөйләшү манерасын таба алу—авторның уңышы.

Кайбер әсәрләрдә хатын-кыз уйлары, сөйләшү борынгылык белән өретелгән (Акчәч), кайберләрендә югары романтика, зыялылык күзгә ташлана (Камилла). Ир-ат уйлары һәм сүзләре исә тупасрак һәм аларда һәрнәрсәнең логик сәбәбен аңлатырга омтылу үзен нык сиздерә. Ләкин биредә дә шәхси үзенчәлекләр шактый көчле. Шуның белән бергә, капма-каршы кеше типларының бер-берсенә охшамаган

уйлау, тоемлау, кичерү сөйләшү рәвеше галәти булмаган синтез хасил итә. Ләкин урыны белән авторның идеалга омтылган геройлары да шактый ук тупас сөйләшәләр, уй-хисләр нечкәлеге-югарылыгы аралашу дәрәҗәсендә кискенлек һәм катылык белән алышына. Һәм авторга каршы төшеп, уй-кичерешләре самими булган геройларның сөйләшүен үзгәртәсе килеп куя.

Нәбирә иҗатында әсәрдән-әсәргә күчеп килүче, ләкин төрле модификацияләрдә бирелә торган карчык образлары да татар әдәбияты өчен хас булмаган, үзенчәлекле дип бәяләнерлек. Сихерче карчык Акъәби яки Сузгын («Болан», «Күке төкереге»), үз күнеленә, рухына якын күреп, ярдәмгә килгән, төп геройны саклап яшәгән Шарлотта яки Камәр карчык («Китәм, димә», «Пәри утары»)—төрле кешеләр. Акъәби һәм Сузгын—мәҗүсиләр, табигать һәм кеше туганлыгына ышанып, шуны саклап яшәүчеләр булса, Шарлотта яки Камәр ышанулары ягыннан түгел, холык-фигыльләре белән ярдәмчел һәм изге. Ләкин беренче карашка төрле бу геройларны да бер сыйфат берләштерә: алар—архетипларның гомер кичкән, картайган кабатланышы. Тормышлары башка эздән китсә, язмыш юллары башкача сызылса, 30-40 елдан Камилла—Шарлоттага, Акчәч—Сузгынга, Хаят—Камәр карчыкка әверелгән булыр иде. Болар—бер чылбыр буыннары, ләкин автор тудырган дөньяда яшь героинялар язмышына мәхәббәт керә, алар үзләре өчен билгеләнгән юлдан читкә атларга җөрьәт итәләр. Шулай итеп дәвамчыларның көчле характерлы, көрәшче, үзсүзле, максатчан икәнлеге ачыклана.

Н. Гыйматдинова повестьларында геройлар бирелеше тагын бер-фәлсәфи катлам хасил итә. Ул дөньяны, кешеләрне икегә бүлеп, берәүләрне—жиргә табигать баласы булып килгән, ирек яратучы, рухи хөрлеккә омтылып яшәүчеләр дип, икенчеләрне—табигать кануннарыннан баш тартып, җәмгыять законнарына сукырларча ияручеләр дип аңлатудан башлана. Кайбер тәнкыйтьчеләрдән, беренче төркем геройларны тулысы белән мәҗүсилек баскычына куеп, әсәрләрнең ислам диненә каршына килүе хакында да фикерләр ишетергә туры килә. Ләкин авторның фәлсәфәсе ислам дине өйрәтүләренә каршы килми.

Повестьларда төп героиня белән каршылыкка керүче өлкән хатын-кызлар (Сузгын, Убыр һ. б.) дөньяны—тәмуг, кешене—аждаһа итеп күрәләр. Ләкин шушы карашка үзәк герой фикере каршы куела, аның кешене һәм дөньяны матур, саф итеп күрүе, үзгәртә, камилләштерә алырлык көчле сурәтләнеше автор фәлсәфәсенең ниндилеген ассызыклый. Тискәре хәлләрнең, күренешләрнең, сыйфатларның вакытлы, узгынчы булуына ышаныч һәрвакыт үзен сиздерә. Дөрес, кара һәм караңгы яклар әсәрләрдә җете буяулар белән сурәтләнә, тирән фаҗигаләргә китерә. Шул фаҗигаләрдә кешеләрне гаепләгән, «Әй, кешеләр! Әй, кансызлар! Әй-й-й!» дигән Сәрия артыннан автор—хикәяләүченең дә «Әй-й-й...» дип уйлануы («Ак торна каргышы») аның чарасызлык чигенә житүе хакында сөйли. Ләкин давылдан соң авылның да, кешеләрнең дә үзгәрәчәге ачык күренгән кебек (Сәрия дә үзгәрде бит), башка әсәрләрдә дә тормышның дөрес эзгә борылачагына өмет тоемлана.

Вакыйгалар эчендә дөньяны икегә: чынбарлык һәм хыял катламнарына аерганнан, чынбарлыкка караган күренешләрне материализм ноктасыннан аңлатып булмый торган эпизодлар—детальләр белән баетканнан соң (Камилланың интуитив төстә авылны табуы, яки балаларының алты тәрәзәле өен, сукмакны төшләрендә күрүе, Хаятнең бүреләр белән дуслашуы, Акчәчнең боланга әверелеп яшәве, Хаятнең үлгән Рөстәмне терелтүе, Саранын аякка басуы шундыйлардан), фәлсәфи яктан да ике чик билгеләнә. Автор яшәешне капма-каршы көчләр бүленеше итеп күзаллый. Матурлык һәм Яхшылык—табигатьтә, кеше күңелендә, жанында. Явызлыкка җәза бирерлек көч тә, ямьсезлек һәм усаллык та табигатьтә һәм Кеше жанында яши. Усаллык, Явызлык ягы баса башладымы, афәт, фаҗига, югалтулар килә. Акчәчләр һәм Саралар, үз гомерләрен корбан итү хакына булса да, шуңа каршы чыгалар. Ләкин автор Ак һәм Караны тигезләнгән үлчәү тәлинкәләре кебек карамый. Яхшылык һәм Явызлыкның, Ак һәм Кара көчләрнең тигезлеге—ислам диненә каршы килүче тәгълиматтан. Автор караны юк итү, бетерү хакында уйлана. Аның үткән заман хатын-кызлары Явызлыкка җәза бирерлек, аны жир йөзеннән юк итәрлек көчкә ия түгел. Шулай булса, әсәр ышандырмас та иде. Алар—җәмгыятьнең ялгыш юлдан китүе хакында хәбәр итүчеләр, өн салучылар, кисәтүчеләр.

Әсәрдә тагын бер каршылык: табигыйлек һәм ясалмалылык фәлсәфи планда хәл ителә. Беренче карашка эстетик мәсьәлә кебек тоелса да (королева бакчасыннан

кучерелгән роза чәчәге һәм гәзнич янәшәлеге), һәр әсәр кысасында ана кат-кат әйләнеп кайтып, автор ясалма нәрсәләрнең еш кына табигыйлекне юкка чыгаруын нәтиҗә кебек тәкъдим итә, кешелекнең киләчәккә юлын табигыйлектә күрә.

Кайбер әсәрләрдә ясалмалылык җәмгыятьнең аерым бер баскычларына бәя бирү дәрәҗәсенә җитә. Мәсәлән, «Китәм, димә» повестенда дингә каршы көрәш (ясалма кануннар урнаштыру) Шәнгәрәй гаиләсен, яки анын кебекләр тормышын гына җимереп калмый, бәлки гомумән яшәү рәвешен юк итә, аның нигез баганаларын аудара. Сәйдәшнең Шәнгәрәй йортын тергезүе—гасырлар буе формалашкан яшәеш юлын кайтару омтылышы, табигый, әхлак кануннарын иҗтимагый кагыйдәләрдән алга чыгару теләге ул. Автор табигыйлекне дә бик киң аңлата, кешенең кешелеклелек юлы белән үсү-үзгәрүе кебек бирә. Ясалмалылыкны камилләштерүнең табигыйлеккә кире кайту булмыйча, бәлки аннан ераклаша бару сукмагы икәнлегенә басым ясый.

Н. Гыйматдинова әсәрләренә хас булган аерым бер сыйфатлар, автор файдаланган әдәби алымнар хакында күп сөйләргә булыр иде. Ләкин без аның иҗат юлын билгеләү максатын куйдык. Авторның 1980 еллар ахырыннан алып 1990 еллар уртасына кадәр язылган күп кенә әсәрләренә (югарыда аталганнарыннан тыш «Сихерче», «Сәвилә», «Күке төкереге», «Каракош»ларны да кертеп) уртак сыйфатлар хас. Реаль һәм хыялый, мифологик башлангычларның бербөтенгә әверелүе хикәяләүне күпкатламлы итеп оештырырга ярдәм итә. Татар кешесенең милли фикерләве, дөньяга карашы, тормышны аңлатуы, кабул итүе, барыннан да элек, Нәбирә иҗат иткән архетип—үткән заман хатын-кызы белән бәйле. Образлар бирелешендәге уртаклыклар, автор фәлсәфәсенең әсәрдән-әсәргә күчеп, баеп-тулыланып баруын да—кабатлану түгел, бәлки язучының унышы дияр идек. Дөнья әдәбиятында Маркес, рус әдәбиятында Л. Леонов исемнәре белән билгеле магик реализм методын Н. Гыйматдинова милли сыйфатлар белән тулыландыра, төрле характердагы сюжет сызыкларын тоташтыра, татар җәмгыятенә реалистик бәя бирә һәм рухы белән бу җәмгыять вәкиле булмаган шәхесләргә карата психологик анализ алымы куллана, милли образ-сурәтләр, символлар, детальләр белән уйный. Җыеп кына әйткәндә, Нәбирә Гыйматдинова бу иҗат методы белән татар әдәбиятында үзенчәлекле, укучы тарафыннан яратып кабул ителә торган юлны тапкан.

Магик реализмны икенче төрле реализм һәм сюрреализм арасында торучы баскыч дип тә атыйлар. Н. Гыйматдинованың иң соңгы басылып чыккан әсәрләрендә дә сюрреалистик элементларның күбәюе үзен нык сиздерә. «Аргы очта, бирге очта», «Таң ата да кич була», «Елан» повестьлары авторның элеккегеләреннән үзгәрәк, янарак иҗат сукмагы тапканлыгы хакында сөйли. Бу сукмакта инде мифологик һәм реалистик яки романтик сюжет сызыклары тоташу күзәтелми. Киресенчә, сюрреалистик сюжет шундый ук ярдәмче сюжет сызыклары белән көчәйтелә. Ике хатын белән яшәү мәҗбүрияте алдында калган Мөнир тарихы («Таң ата да кич була»), чит кеше баласы үстереп, килен булып килгән үз кызын байлыкка алыштырырга омтылган Фәймә тарихы («Елан») яки яшьлек хатасына җәза алып, балаларын алмашып яшәргә риза булган Гөлнур белән Равия тарихы («Аргы очта, бирге очта...») ... Болар, беренче карашка, тормыштан ук күчереп алынган, ул геройлар янәшәбездә генә яшәп яталар төсле тоела. Ләкин реальлек эффекты тудырылса да, тарихлардагы сюжет барлыкка китергән каршылык, ситуация кешелеклелек кысаларыннан читкә чыга. Магик реализм дулкынында язылган әсәрләрдән аермалы буларак, биредә уйлап табылган хәлләр түгел, бәлки кеше җанындагы түбәнлек шаккаттыра. Табигатькә яки үзләренә охшамаганнарга усаллык кылган Рыскол яки Фәрит Садриевич кебекләр белән чагыштырганда, соңгы повестьлар геройларының якыннарына күрсәткән явыз гамәлләре—кеше ышанмаслык. Вакыйгалар ярдәмендә автор кешенең, беренче чиратта, үз-үзен харап итүен, үзенә явызлык кылуын раслый. Мондый кисәтү вазифасы тискәре образларга йөкләтелә.

Н. Гыйматдинованың язучылык тәҗрибәсе, осталыгы соңгы повестьларда да үзенчәлекле дөнья тудырырга, төгәл, урынлы кулланылган алымнар белән мәгънә көчәйтергә ярдәм иткән. Алыйк «Елан» повестен. Бакчасында тапкан елан кабыгын бала табарга җыенган күршесенә ташлау вакыйгасы—шушындый метафора ярдәмендә әсәрнең башында ук Фәймәгә бәя бирелә: үз кайгысын, үз «йөген» башкалардан күтәрүче, җиңел яшәргә омтылучы ул. Ләкин әсәр ахырына метафораның икенче мәгънәсе дә ачыла: Фәймә үзгәрде, «елан» кабыгын салды. Хәтта гомер буе төшләрендә, уйларында үчекләшеп яшәгән Хәтимә карчыкка соңгы монологта

«Хәтимә сенел» дип, ул теләгәнчә эндәште. Кабыгын салды—үкенү баскычына килде. Автор исә укучыны тискәре яссылыкта иҗат иткән героин—Фәймәне кызгануга кадәр китереп җиткерә. Үзе яхшы яктан тасвирламаган, бер-бер артлы усаллыгын, мәкерен, көнчелеген, байлыкка табынуын, кешелексезлеген күрсәтеп барган «елан»ны аңларга, җәлләргә чакыра автор: кичерешләрен, уйларын күрсәтеп, психологик анализ ярдәмендә эчке дөньясына алып керә. Әсәрнең башында ук Хәтимәнең «Оланыңны ике кат югалтырсың» дигән юравын китереп, вакыйгалар барышында аны берничә кат кабатлап узу алымы да уңышлы. Фәймәнең өметләре акланмаячагын, Мәрвиянең әнисен кичермәячәген белгән укучы боларга мөнәсәбәтен үзгәртә, аларны кире кагу, йөз чөерү баскычыннан аңларга тырышу дәрәҗәсенә күчерә.

Соңгы повестьлардагы каршылыклар да кеше—кеше арасында туып, иҗтимагый түгел, бәлки шәхси сыйфатларга бәя бирү өчен хезмәт итә. Автор исә нинди дер урын-вакыт белән төгәлләштерелгән мәсьәләләрдән гомумән кешегә хас проблемалар күтәрүгә таба борыла. Ләкин әсәрләр тәмамланганда аларның күбесе чишелеш тапмый, укучыга «уйлап бетерү» өчен кала. Төп геройларның киләчәк тормышы да билгесезлек эчендә өзелә, автор укучысын уенга чакыра: әйдә, үзең күзаллап кара—балаларын алмашкан Гөлнур-Равияләр, кызын тапкан Фәймә, ике хатыннан иракка качкан Мөнир һәм Нурбикә белән Әминә алга таба үз язмышларын ничек корыр—боларны үз идеалың яктысында уйлап бетер, ди сыман.

Нәкъ менә үз идеалың—укучы идеалы, чөнки соңгы повестьларда язучы идеалы—үткән заман хатын-кызы архитибы юк. Аның белән бергә сагышлы-хыялый, тылсымлы—ак дөнья да югала. Әйтерсең лә бу әсәрләрдә Акчәч һәм Саралар фани дөньяны кичкәннән, Хаят һәм Камиллалар гаеп булганнан соң, аларсыз гына ага башлаган тормыш сурәтләнә, һәм бу тормыш Н. Гыйматдинова иҗатындагы асыл матурлык—шул Хаятләр һәм Акчәчләр җаны, рухи байлыгы икәнен тагын бер кат искәртеп тора. Укучы буларак, соңгы повестьлар белән танышканда да әлеге сәеррәк һәм самими затларны эзлисең, аларсыз сурәтләнгән яшәеш исә гади-гадәти, буш һәм җансыз булып тоела.

Әсәрләрдә авторның фәлсәфи фикере дә үзгәреш кичергән. Соңгы повестьларда кешенең кешелеклелеккә кайтуы, явызлыктан баш тартып, яхшылыкка омтылу мөмкинлеген язучы тулысы белән аның үзенә бәйли. Елан кабыгын салган кебек, шәхес тә йөзен, битлеген үзгәртә ала, хаталарын аңлап, үкенеп, башкача яши башларга аңа беркайчан да соң түгел, ди сыман автор.

Соңгы повестьлар, Н. Гыйматдинованың бөтен иҗаты фонында караганда, эзләнү төсендәге әсәрләр кебек тәэсир калдыра. Дөрес, талантлы язучының эзләнүләре дә кызыклы, алар да татар әдәбиятында яңа сүз, яшәешкә яңа караш кебек килеп чыккан. Яңа дулкында иҗат итүче, татар укучысын әдәби табышлары белән сөендерүче Н. Гыйматдинова иртәгә кайсы сукмакны сайлар—монысы билгесез. Ләкин ул сукмакның укучыны моңа кадәр таныш булмаган, төшләрдә-хыялларда күрмәгән гаҗәеп урыннарга ияртеп китәчәге, мавыктыра-мавыктыра уйга салачагы шиксез.

Әдәбият тарихына

Хатыйп Миңнегулов

филология фәннәре докторы, профессор

СУЛМАС ГӨЛЛӘРНЕҢ БЕРСЕ

КОТБНЫҢ «ХӨСРӘҮ ВӘ ШИРИН» ӘСӘРЕ ЯЗЫЛУГА 660 ЕЛ

Олуг талантлар тудырган сәнгать әсәрләре гасырлар агышына, рәхимсез Вакытның көз һәм кышларына да карамастан, картаймыйча, һаман да яшь булып калуын дәвам итәләр. Әйтерсең лә, бу ядкярләргә мәңге төкәнмәс жегәр, очкын, хуш ис салынган. Һәр олуг әсәрнең укучысы, яңа буын вәкиле белән очрашуы, гүя ки, ике арада бәйләнеш, үзара хәрәкәт, диалог тудыра. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре дә (1342) һәр чор укучысының күңелен кузгатырлык, җанын хушландырырлык әнә шундый ядкярләрнең берсе. Кара язмыш, көнләшкәндәй, бу хуш исле гөлне үз жиреннән, үз халкыннан аерырга, вакыт туфрагына күмеп калдырырга тырышты. Гәрчә ул өлешчә үз максатына ирешсә дә, ахыр чиктә барыбер жинелеп калды: «Хөсрәү вә Ширин» XX гасыр урталарында янә үз жирлегенә, үзенең газиз укучысына кабат кайтты. Һәм хәзер инде ул татар рухи тормышының аерылгысыз бер өлешенә, күп төрле гөлләрне берләштергән татар әдәбияты букетының гүзәл бер чәчәгенә әверелде.

Котб хакында мәгълүматлар сакланмаган диярлек. Хәзерге фәндә аның туу вакыты якынча 1297 елның сентябренә, ә үлеме XIV гасырның урталарына нисбәт ителә. Кайбер хезмәтләрдә авторның исемен Котби, Котб Харәзми дип язу очрый. Әмма мондый бирелеш нигезсез. Әсәрендә автор үзен бары тик Котб рәвешендә генә яза. Ә инде Харәзми кушаматы—тәхәллүсе—бер генә чыганакта да очрамый. Бу—аерым галимнәрнең, аеруча кайбер үзбәк филологларының үзләре күрергә теләгәнне бар дип тәкъдим итү нәтиҗәсе генә. Котб сүзен Котбеддин исеменнән кыскартып ясалган дип тә уйларга мөмкин. Әмма чынлыкта исә ул исем түгел, кушамат, әдәби тәхәллүс булса кирәк. Аны фәндә берничә төрле аңлату очрый.

Мөселман дөньясында, шул исәптән төрки-татарларда элек остазларны, күренекле затларны, мәшһүр фикер ияләрен һәм суфиларны, диннең күренекле әһелләрен «котб» дип тә атап йөрткәннәр. Әмма тарихта бу сүзне тәхәллүс итеп алу бик күзгә ташланмый.

Алтын Урда чорында Урта Иделнең уңъягындарак Котб исемле шәһәр дә булган. Итальян сәүдәгәрләре бертуган Пициганолар төзегән картада (1367)[1] бу кала Котоба рәвешендә теркәлгән. Әдип-галимнәр төбәк, авыл яисә шәһәр исемен үзләренә кушамат итеп алганда, тәхәллүс, кагыйдә буларак, нисбилек кушымчасы ярдәмендә белдерелә: әйтик, Баласагун—Баласагуни—Баласагунлы; Болгар—Болгари; Утыз Имән—Утыз Имәни. Бередә исә, әйткәнебезчә, «Хөсрәү вә Ширин» авторы үзен Котб рәвешендә яза. Кушамат Котби шәкелендә теркәлгән булса, бу мәсьәлә тәмам хәл ителгән булыр иде. Шулай да Котб тәхәллүсенең Идел-йорттагы шәһәргә нисбәтән алынуы хакыйкатькә ныграк якын тора. Әсәр телендәге аерым сүзләр һәм формалар да (төн ката; сала, камгак; баргым; кайтмага һ. б.) бу карашны куәтли. Аерым галимнәр фикеренчә, «Хөсрәү вә Ширин»дә татар теленең хәзерге Пенза, Мордовия төбәгенә хас шивә элементлары ныграк гәүдәләнеш тапкан. «Котоба» каласы да нәкъ әнә шул җирләргә нисбәт ителә.

[1]Франциско һәм Доминико Пициганолар төзегән бу карта «Фән һәм тел» журналында да басылып чыкты *(2002, N 2).*

Алтын Урданың Харәзми, Мәхмүт Болгари, Мәхмүд Сараи Гөлестани, Сәйф Сараи һәм кайбер башка әдипләре кебек, Котб та бер урында гына яшәмәгән: сәяхәт кылган, төрле авыл-калаларда булган, белем алган, төрле шөгыль ияләре белән очрашкан. Бу хакта аның әсәрендә дә кайбер факт-мәгълүматлар бар: «Сәфәр рәнжен күрдем үзем кач әййам (күп көннәр)[1]; «Ничә кем килдем ирсә мән, вәләкин Төгәл килдем, төгәллек яхшы уш чын» (I, 30 б.).

«Хөсрәү вә Ширин»нең кайчан, кайда язылуы төгәл күрсәтелмәгән. Әсәр шактый күләмле, житди. Авторның аны язарга ниятләве генә дә «берничә ел»ны үз эченә ала:

Ничә ел булды—жаным үскәр *(кузгалган)* ирде,
Күнелдә ошбу әндишә *(уй-ният; теләк)* бар ирде *(I, 29 б.)*.

* * *

Әсәр хәзерге фәндә 1342 елда Алтын Урданың башкаласы Сарай шәһәрендә төгәлләнгән дип исәпләнә. Мәгълүм ки, Котб үз дастанын Тенибәк ханга багышлаган. Бу зат исә Алтын Урда белән, әтисе Үзбәк хан үлгәч (ул 1342 елның мартында вафат була), бер елга якын идарә итә. Ә инде Сарай шәһәре—һәм Алтын Урданың, һәм аның көнбатышындагы «Ак Урду»ның башкаласы. Тексттан шагыйрьнең үз әсәренә шушы шәһәрдә нокта куюы ачык сизелеп тора.

Билгеле булганча, басма китап—соңгырак дәвер жимеше. Элек текстлар кульязма рәвешендә таралган. Котб әсәре ни дәрәжәдә үз укучыларына ирешкәндер—анысы мәгълүм түгел. Әмма аның шул чор һәм үзеннән соңгы төрки-татар әдәбиятына тәэсире сизелә. Мәсәлән, XIV йөзнең урталарында ижат иткән Харәзми мәхәббәтне, нәкъ Котб кебек, абсолютлаштыра, анда инсан яшәешенең төп асылын, мәгънәсен күрә. Сәйф Сараи да (1321—1396) «Гөлестан бит-төрки» әсәрен язганда «Хөсрәү вә Ширин»гә хас аерым ижат принципларын куллана. Бу төр мисалларны әдәбият тарихыннан күпләп китерергә мөмкин.

«Хөсрәү вә Ширин»нең хәзерге фәнгә бары бер кульязмасы гына мәгълүм. Ул һижри белән 785 елда сәфәр аеның 25 көнендә, хәзергечә 1383 елның ахырларында төгәлләнгән. Күчереп язуны Мисырда Бәркә Фәкыйһ дигән берәү башкара. Чыгышы белән ул үзен Идел-йорттан, «Дәшти Кыпчак» иленнән («аслым кыпчак») дип күрсәтә. Мисырга Алтынбога бик дигән кеше белән килә. Тарихта Алтын Урда белән Мәмлүкләр Мисыры арасында ике гасыр буена тыгыз мөнәсәбәтләр урнашкан булуы мәгълүм. Шуна күрә башка бик күп иделлеләр—төрки-татарлар белән бергә, Бәркә Фәкыйһнең дә Каһирә, Искәндәрия якларына килеп чыгуы, бiредә белем алуы, яшәп калуы табигый хәл. Бәркә Мисырда хокук *(фикъһе)* белгечлеген үзләштерә һәм шуңа мөнәсәбәттә үзенә Фәкыйһ тәхәллүсен ала. Ул әдәби ижат белән дә шөгыльләнә. «Хөсрәү вә Ширин» күчермәсенең ахырына теркәлгән 51 бәетлек (строфалык) шигырь—шуның ачык мисалы. Бәркә Фәкыйһ биредә үзенең тәржемәи хәлен, рухи халәтен тасвирлый, хата-кимчелекләре өчен укучыдан гафу үтенә.

«Хөсрәү вә Ширин»нең Бәркә Фәкыйһ күчергән нөсхәсе (ул 238 биттән гыйбарәт) ниндидер юллар белән Париж Милли китапханәсенә барып эләгә. Фәнгә ул XX гасырның беренче чирегеннән генә мәгълүм. «Хөсрәү вә Ширин» хакында А. Зайончковский (Зайачковский), Г. Таһиржанов, Х. Госман, Ә. Нәжип, Х. Миннегулов, Э. Фазыйлов һәм кайбер башка галимнәрнең мәкалә-хезмәтләре бар.

Котб әсәре тәүге мәртәбә узган гасырның 50 елларында Варшавада А. Зайончковский тарафыннан нәшер ителде. Ул фотокүчермәдә һәм транскрипциядә бирелгән. Сүзлеге дә бар. «Хөсрәү вә Ширин»нең Казан басмасы 1969 елда дөнья күрде. Гарәп хәрефләре белән нәшер ителгән бу китап басмага Х. Госман һәм З. Максудова тарафыннан әзерләнгән. Котб әсәренең кайбер башка басмалары да бар[2].

[1]Котб. Хөсрәү—Ширин хикаяте: Ике кисәктә // Фәнни редакторы—профессор Х. Усманов. —Казан: КДУ нәшрияты, 1960.—30 б. Алга таба бу чыганакның томы һәм битләр саны жәяләр эчендә генә күрсәтеләчәк.

[2]"Хөсрәү вә Ширин»нең өйрәнелү һәм басылу тарихы хакындагы библиографик мәгълүматларны Р. Исламовның «Алтын Урда һәм Мәмлүкләр Мисыры: язма мирас, мәдәни бәйләнешләр» исемле китабыннан таба аласыз *(Матбугат йорты, 1998, 41—48 б. б.)*.

* * *

Әгәр дә соңгы дәвер реалистик сүз сәнгате өчен сюжет яналыгы төп эстетик таләпләрнең берсе булса, элеккеге чор өчен ул мөһим түгел. Киресенчә, Борынгы һәм Урта гасыр әдәби традицияләре укучыларга һәм тыңлаучыларга билгеле сюжетларга әсәр иҗат итүне алдын күргән, хәтта бу күренеш поэтик канун дәрәҗәсенә күтәрелгән. Шунысы кызыклы: сюжетның да теләсә нинди түгел, ә тетрәндергече, гыйбрәтлесе, кагыйдә буларак, егет белән кызның мәхәббәт газапларын эченә алганы. Йосыф—Зөләйха, Ләйлә—Мәҗнүн, Таһир—Зөһрә, Сәйфелмөлек—Бәдыйгылҗәмал хакындагы мәхәббәт тарихлары—әнә шундыйлардан. Авторлар үзләренә кадәрге бу төр фольклор яисә язма истәлекләрдән этәрелеп, аларга таянып, яңа әсәрләр тудырырга омтылганнар.

Котб мөрәҗәгать иткән Хөсрәү—Ширин сюжеты Шәрык дөньясында киң таралган мәхәббәт тарихларының берсе. Галимнәр аның билгеле бер реаль җирлеге булуын да искәртәләр. Төп геройның прототибы итеп сасанидлар династиясенең соңгы шаһларыннан берсе—Хөсрәү II Пәрвиз карала. Ул 590—628 елларда Иран белән идарә итә һәм соңыннан үзенең улы Шируя тарафыннан үтерелә. Чыганакларда Ширинның искиткеч сылу булуына аеруча басым ясала.

Чынбарлыктагы Хөсрәү—Ширин вакыйгасы үзенең эчтәлеге, фаҗигалелеге белән төрле легенда-риваятьләр, хикәятләр тууга китерә. Әкренләп алар бербөтенгә оеша башлый. Бу процесста профессиональ әдипләр дә актив катнаша. Фирдәүсинең «Шаһнамә» әсәрендә (X—XI гасырлар), мәсәлән, Хөсрәү Пәрвиз тормышына бәйләнештә Ширин турындагы легенда да бәян ителә. Бу мәхәббәт тарихы турында Әмир Хөсрәү Дәһләви, Җами, Нәваи һәм башка авторларның әсәрләре бар. Болар арасында иң мөхтәрәм урынны фарсы-әзәрбайҗан шагыйре Низаминың (1141—1209) фарсы телендәге «Хөсрәү вә Ширин» поэмасы (1181) биләп тора.

Котб төп чыганак итеп Низами әсәрен ала. Ул анда, гомумән, Алтын Урда чоры төрки-татар укучысының рухи ихтыяҗларына җавап бирерлек материал тапкан. Үз әсәрендә Котб фарсыча яркярдәге сюжетны, персонажларны, шигъри үлчәмне һәм гомуми идея эчтәлеген саклаган. Композицион берәмлекләрнең дә күпчелеге уртак. Әмма иҗат процессында икенчел чынбарлык, ягъни Низами әсәре Котб дәверендәге чор һәм җирлек ихтыяҗларына шактый яраклаштырылган, төрки-татар шагыйренең иҗади эшкәртүенә «дучар» булган. Нәтиҗәдә сәнгати яктан камил, мөстәкыйль яңгырашлы өченчел бер чынбарлык туган. Анда Котбның үз тавышы ишетелә, үз шигъри фикерләве, шәхси стиле ярылып ята. Әсәрдә Алтын Урда, Идел-йорт, төрки-татар яшәеше белән турыдан-туры бәйләнешле сурәтләр, детальләр, шигъри чаралар күп. Дастанның Сарай ханы Тенибәккә (Тәнибәккә) һәм аның хатыны Мәликә бикәгә багышлануы, алар хакында махсус мәдхияләр бирелүе дә күп нәрсә хакында сөйли. Күләм һәм эчтәлек ягыннан аермалар аеруча тәүге һәм соңгы кисәкләрдә күп. Төп өлештә дә аерым кыскартулар, өстәмә юллар, бүлекчәләрне кушып җибәрүләр күзгә ташлана[1]. Кыскасы, Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре һич тә без күнеккән тәрҗемә төшенчәсенә туры килми. Ул—тәрҗемә, нәзыйрә, контаминация (ялгау), оригиналь һәм башка әдәби принциплар һәм иҗади башлангычлар белән тудырылган катлаулы күренеш. Шуңа күрә Котб әсәрен ярым тәрҗемә, ярым оригинал ядкяр дип атау дөресрәк булыр. Мондый төр әсәрләр язу әдәбият тарихы өчен чит түгел. Сәйф Сараиның Сәгъдигә, Татар Гали Әфәндененң (Шәриф Гамидинең) Фирдәүсигә, В. Жуковскийның Көнбатыш Аурупа әдипләренә, Г. Тукайның төрле шагыйрьләргә таянып язган әсәрләре шуның ачык мисалы.

* * *

Иң әүвәл әсәрнең исеме һәм жанры турында берничә сүз әйтеп үтик. Автор үзе аны «хикәят», «кыйсса» («Сүзең башла янә, кыйссаны әйгъел».—1,200 б.), «дастан» («Бу гыйшкым берлә башлап дастанны».—1,31 б.) дип атый. Фәнни әдәбиятта Котб әсәрен «Хөсрәү вә Ширин поэмасы» дип атап йөртү киң таралган.

Әмма бу ядкяр үзенең күләме (кульязмада ул 233 биттән гыйбарәт), куелган

[1]Фарсыча һәм төркичә текстларның үзара мөнәсәбәте хакында фикер-күзәтүләр, конкрет мисаллар безнең «Котб иҗаты» дигән китапта бар *(КДУ нәшрияты, 1976.—34-57 б.)*.

проблематикасы, идея эчтәлеге, сюжеты һәм композицион төзелеше белән чын мәгънәсендә шигъри роман дип атарлык. Хөсрәүнен тууыннан алып үлеменә кадәрге тормышы, эш-гамәле, Ширин белән озын тарихлы һәм каршылыклы мәхәббәте әсәрдәге вакыйга-хәлләрне бергә туплап, бер бөтен итеп тора.

«Хөсрәү вә Ширин»нен үзәгендә—мәхәббәт. Ул каһарманнарның үзара мөнәсәбәтләре, хис-кичерешләре, эш-гамәлләре, әдипнен фәлсәфи уйланулары, лирик чигенешләре аша төрле яклап ачыла. Автор фикеренчә, чын сөю—инсанилыкның төп асылы. Роман башыннан алып ахырына кадәр эчке бер диалогка, персонажлар, фикер-хисләр арасындагы бәхәскә корылган. Әсәрнең төп, мәгънәви конфликтын мәхәббәткә, яшәешкә, гомумән, инсанилыкка карашлар төрлелеге тәшкил итә.

Роман каһарманнары Ширин белән Фәрһад тышкы матурлыклары белән генә түгел, ә күркәм холыклары, бай табигатьле, олы җанлы булулары белән дә аерылып торалар. «Рухи кардәш»тәй бу ике затка тугрылык, ихласлылык, күңел сафлыгы һәм пакьлеге, кыюлык, гаделлек, вөҗданлылык кебек сыйфатлар хас. Аларның мәхәббәтләре дә бөек, соклангыч. Бу ике зат өчен сөю-мәхәббәт—яшәү, илһам чыганагы. Фәрһад вә Ширин үз мәхәббәтләре өчен көрәшәләр, бу изге юлда фидакарьләрчә һәлак тә булалар. Аларның үлеме мәхәббәтнен бөеклегенә гимн булып яңгырый. Автор мондый затларны үрнәк, өлге итеп куя: «... Гыйшыкда Фәрһад булгыл; Антик *(аның кебек)* кичмәде гыйшкында садикъ» *(II, 258 б.)*. Ширин үлеме унае белән Котб: «Монын тик тансук эш һич булмышы юк,»—ди *(II, 425 б.)*. Ярты гасыр үткәннән соң язылган «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанының авторы да Фәрһад—Ширин фаҗигасенә тарыган каһарманнарының үлемен нәкъ шул рәвештә бәяли: «Улырмы сәүге (сөю) һәм, бел, шундан артук; Ки иккесе кыйлар җаныны тартук (ягъни, бер-берсе өчен корбан итү).»[1]

Хөсрәүдә исә Фәрһад һәм Шириндәге кебек мәхәббәт тә, кыюлык та, көч тә юк. Фәрһад белән конфликт шаһнын түбәнлеген, әхлакый яктан көчсезлеген, эгоистик сөюнен чын мәхәббәт түгеллеген һәм була да алмаганлыгын шактый тулы ачып бирә.

«Хөсрәү вә Ширин»нен мөһим бер үзенчәлеге һәм кыйммәте тагын шунда: биредә мәхәббәтнен инсанны үзгәртергә, рухи яктан камилләштерергә мөмкин булган шифалы көч икәнлеге дә раслана. Ширинненң олы мәхәббәте Хөсрәүнең табигатен сафландыра бара, аның мәсләксез тормышына мәгънә кертә, кылган һәм кыласы эш-гамәлләре өчен вөҗдан җаваплылыгын арттыра.

Романда мәхәббәт темасының тирән фәлсәфи һәм социаль мәгънәсе ачыла. Шагыйрь карашынча, чын мәхәббәт дөньясында золым-башбаштаклыкка урын юк, социаль тигезсезлек, тәҗ-тәхет мөһим түгел *(«Гашыйклык берлә шаһлык раст килмәз»—II, 316 б.)*, анда хисләр, бер-беренә ихласи бирелгәнлек, инсанлылык, гаделлек кенә хөкем сөрә. Автор кешеләрдә мәхәббәт хисләрен кузгатып, үстереп, җәмгыятьне сафландырырга, иҗтимагый-социаль мөнәсәбәтләрне мәхәббәт кануннарына нигезләргә омтыла. Нәкъ менә шуңа күрә дә ул мәхәббәт темасына мөрәҗәгать итә, кешеләрне, җиһанны гыйшыкка өнди («Бу гыйшксыз өрмәгел зинһар, бер дәм *(сулыш)*»—*II, 258 б.)*.

Ширин образында Котб хатын-кызны олылый, ана дан җырлый. Мөһин Бану да үзенең кешелеклеге, кыюлыгы, иҗтимагый эшчәнлеге белән унай тәэсир калдыра. Бу зат сеңлесе Ширин турында аналарча кайгырта. Шунысы мөһим: һәм Мөһин Бану, һәм Ширин—гадәти хатын-кызлар гына түгел, ә хөкемдарлар да. Димәк, хатын-кыз теләсә нинди эшне башкарырга сәләтле:

> Тәлим *(күп)* хатун кем ирдин артукы бар,
> Йирен табса, йөз ирнен эшен эшләр *(II, 424 б.)*.

«Хөсрәү вә Ширин»дә, мәхәббәт темасына бәйле рәвештә, башка мөһим мәсьәләләр дә гәүдәләнеш тапкан. Шундыйларның берсе—Урта гасырның күп кенә әдипләрен борчыган гадел хөкемдар проблемасы. Автор халык (рәгыять) турында кайгыртучы, көчле, укымышлы, гадел патша идеясен алга сөрә:

> Теләсән гыйззәт илгә, барча *(барчага)* бул яр,
> Сакынгыл *(уйла)*, кылма күб ил күнлен азар *(рәнҗетмә)*.

---

[1]Сәйф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан.—Таткитнәшер, 1999.—128 б.

Кешеләр кем синең хөкемеңдә булгай,
Аларны куйма һич кем көч кылгай *(I, 196 б.)*.

Чөн баш булдың, тәпүгчы *(хезмәтче; буйсынган кеше)* ил-азак (кул-аяк) ул,
Анлар гайбенә даим күз-колак бул.

Күр үз гайбен, азиндин *(үзгәдән)* эзләмәгел,
Кеше гайбен катигълап *(каты)* күзләмәгел *(I, 197 б.)*.

Үкеш (күп) ил кайгысын алма, сакынгыл,
Рәгыять асрамак яхшы ирер, бел *(II, 397 б.)*.

Кайу хандин рәгыять булса азар *(җәфа чиксә)*,
Тимешләр кем: калыр ялгыз булыб хар.
(Ялгыз, түбән калыр,—дип әйтерләр» *(II, 397 б.)*.

Котб бер урында «жиһан халкын» «тән», ә шаһны шуның «жаны» белән тинли *(II, 402 б.)*.

«Хөсрәү вә Ширин» авторы мәхәббәт һәм хакимият төшенчәләрен үзара яраклаштырырга, алар арасында инсани гармония булдырырга да тырыша. Шагыйрь уйлавынча, күңелен изге сөю хисләре биләгән Ширин һәм әсәр соңындагы Хөсрәү кебек инсаннар гына чын, гадел хөкемдар була алалар. Кызганыч ки, андыйларның шаһлык гомере кыска. Әсәрнең сюжеты бозык, мәкерле, явыз Шируяның тәхеткә килүе белән тәгәлләнә. Мондый бетем, бер яктан, авторның кырыс чынбарлык белән исәпләшүен күрсәтсә, икенче яктан, гадел хөкемдар идеясенең чагыштырмача утопик характерда булуы хакында да сөйли. Урыны белән әсәрдә мәхәббәт һәм хакимият төшенчәләренең үзара яраша алмавы да искәртелә.

«Хөсрәү вә Ширин»—синкретик табигатьле ядкяр. Анда вакыт агышы, яшәү мәгънәсе, галәмнең чиксезлеге, тән һәм жан берлеге, хис һәм акыл нисбәте, шигъри сүз һәм башка төрле проблемалар хакында гаҗәеп кызыклы күренешләр һәм уйланулар бар.

Автор вакыт агышын объектив процесс рәвешендә күзаллый. Шуңа мөнәсәбәттә инсанның тууы, яшәве һәм үлеме дә табигый хәл итеп карала: «Бу төн, көн ала ат тик йөгрер, калмаз»; «Ата үлде, угыл калгаймы һәргиз?» *(I, 186 б.)*; «Һич эш бу адәм углыдин котылмаз, Мәгәр үлмәк кем анда чара булмаз» *(II, 226 б.)*; «Ажун *(дөнья)* җәүрендин ике ир кортылды *(котылды)*: Бере ул—кем тугмады, бер ул—кем үлде» *(II, 411 б.)*.

Дөнья кеше өчен, кеше дөнья өчен яратылган. «Сәнең өчен ирер бу барча галәм, Кечекләп күрмәгел үзенне сән кәм» *(II, 413 б.)*. Инсан—галәмнең олуг заты, ул үзен түбәнлеккә төшерергә тиеш түгел. Кеше, дөньяга килгән икән, гыйлем тупларга, һөнәр үзләштерергә, игелекле гамәлләр кылырга, холкын пакьләргә, адәм балаларына шатлык-куаныч китерергә, сөяргә һәм сөелергә, кыскасы, тулы канлы итеп яшәргә бурычлы. Бары шунда гына инсан, гәрчә жир йөзеннән китеп барса да, буыннар хәтеренә, жәмгыять зиһененә «игү ат» *(игелекле исем)* белән кереп кала. Әдип фикеренчә, чын кешеләр нур чыганагы, шәм кебек булалар, гомерләрен янып, үзгәләргә яктылык биреп уздыралар. Алар—Фәрһад, Ширин кебек затлар. Шуңа күрә дә андыйлар онытылмый.

Әсәрдә шәраб тематикасы, күңел ачу күренешләре шактый зур урынны алып тора. Бу берничә сәбәп белән аңлатыла. Беренчедән, әсәрдә исламга кадәрге борынгы Иран, Куһистан тормышы сурәтләнә. Мәгълүм ки, Хөсрәү Мөхәммәд пәйгамбәрнең мөрәҗәгатен кире кага. Әсәрдә шаһ гомеренең аянычлы тәгәлләнеше билгеле бер дәрәҗәдә шуның белән дә аңлатыла. Икенчедән, мәҗлес, шәраб, жыр, музыка—элеккеге әдәбиятта яшәешне, тулы канлы тереклекне гәүдәләндерү чаралары да. Әмма автор эчеп акыл жуюга, әдәпсез гамәлләр кылуга каршы. «Булыр искрекдә *(исерек чакта)* ничә билгә *(акыл иясе)* уссыз *(акылсыз)*, Анар аш анда ни тозлы, ни тозсыз» *(II, 384 б.)*. Хөсрәү зөфаф кичәсендә, исереп, кем белән ятканын да белми һәм оятка кала. Роман авторы, гомумән, гыйффәтлелекне яклый, азып-тузып йөрүне, зина кылуны гаепли: «Ирәнләргә зина кылмак хәрам ул, Зинака *(зина кылуга)* һич милләтдә юк ул юл» *(II, 289 б.)*. Хөсрәү, өйләнгәч, үзенең сарайдагы жария хатын-кызларын башкаларга өләшә, Ширин белән генә гомер кичерә башлый.

«Котадгу белек» (1069), «Нәһжел-фәрадис» (1358), «Гөлестан бит-төрки» (1391),

«Төхфәи мәрдан» (1539), «Нуры содур» (1542), «Мәҗмагыл-әдәб» (1839) ядкярләрендәге кебек, «Хөсрәү вә Ширин»дә үз-үзеңне тоту, сөхбәтләшү, гомумән, әдәп-әхлак мәсьәләләренә зур урын бирелә. Автор тугрылыкны, юмартлыкны, тыйнаклыкны, кин күңеллелекне, ихласлылыкны һәм башка шундый унай сыйфатларны, эш-гамәлләрне мактый, аларның капма-каршыларын антитеза ысулы белән тәнкыйтьли: Бу дөньяга «мәгъррүр булма» *(I, 195 б.)*; «Камуг эш эчрә сән әндазә *(үлчәү, чама)* сакла» *(I, 195 б.)*. Шагыйрь сүзне уйлап сөйләргә, яман сүзне әйтмичә калдырырга, серенне тышка чыгармаска чакыра, яман холыклы берлә утырмаска өнди. Иң мөһиме: үз-үзеңне саклап, үзеңә дошман күзе белән кара: «Сакынгыл, зинһар, үзеңдин саклан»; «Бакыб дошман күзе берлә йөзеңгә, Бел үз гайбеңне, көлдермә үзеңгә» *(II, 290 б.)*.

«Хөсрәү вә Ширин»дә сабырлык ике төрлерәк гәүдәләндерелә. Бер яктан, автор бу төшенчәне мактый, түзем, сабыр булырга чакыра. Икенче яктан, шагыйрь бу сыйфатка тәнкыйди мөнәсәбәтен дә белдерә. Ялгызлыктан, сагынудан җәфа чиккән Ширин, үз-үзен битәрләп, сабырлык белән гомер кичерүнең кыенлыгын, «аксак» аяк белән калу кебек булуын искәртә *(I, 214 б.)*.

«Дөньяда тереклек кылган һәр нәрсәдә һәлакәт билгесе ята»,—ди мәшһүр философ Гегель. «Хөсрәү вә Ширин»дә дә бу хакыйкать ачык гәүдәләнә. Андагы геройлар да туа, яши, үлә. Гомер ага. Яшәү никадәр татлы булса да, ахыры—үлем. Әсәрнең азагына таба автор дөньяның вафасызлыгы, гомернең чикләнгәнлеге хакында ешрак уйлана башлый, бар булганына канәгать булырга кирәклекне искәртә: «Кеше кем кылды дөньяда канәгать, Һәм ул табды бу аҗун эчрә *(дөньяда)* рахәт» *(II, 412 б.)*.

«Хөсрәү вә Ширин»—сурәтлелек, тел байлыгы, стиль нәфислеге белән искиткеч әсәр. Романда кулланылган образлар, шигъри чаралар, поэтик детальләр, ничектер, табигый агып, сурәтле фикерләү белән органик кушылып тора. Автор хикәяләү һәм тасвирлау, төш күрү, әңгәмә, лирик чигенеш, фәлсәфи уйлану, антитеза һәм башка ысуллардан һәм чаралардан иркен файдалана. Пейзаж, нигездә, вакыт агышын белдерүгә, геройларның рухи халәтен, үзара мөнәсәбәтләрен ачуга хезмәт итә.

Әсәрнең тәэсир көчен арттыру, укучының зиһенен баету юнәлешендә автор кулланган төрле чаралар арасында традицион образлар да, мона кадәр бик күзгә ташланмаган сурәтләр дә бар. «Хөсрәү вә Ширин»дә, рухи халәтләренә карап, геройлар Ягъкуб, Йосыф белән чагыштырыла. Мәсәлән, Иранга баргач, Ширинне тау-таш арасына урнаштыралар. Бу урында шагыйрь болай ди: «Йосыф тик казгу козыгынга *(коесына)* атылмыш» *(I, 114 б.)*. Фәрһад Шириннең сөйләмен ишетү белән сабырсыз кала. Чөнки кызның сүзе Әфләтүн кебек акыл ияләрен дә зиһенсез калдырырлык *(II, 224 б.)*.

Урта гасыр язма әдәбиятында төркиләр еш кына Әфрасияб образы аркылы да бирелә. «Хөсрәү вә Ширин»дә дә бу очрый. Мөһин Бану, Ширингә үгет биреп, Хөсрәү хакында болай ди: «Әгәр *(ул)* Кәйхөсрәү ирсә, без—Әфрасияббез» *(I, 132)*. Куһистан патшасы үзен дә, сеңлесен дә төрки кешесе дип саный.

Мөселман дөньясында гарәп хәрефләренең язылу рәвеше сәнгати чара рәвешендә дә файдаланыла. «Хөсрәү вә Ширин»дә дә без моның аерым үрнәкләрен күрәбез. Мәсәлән, мәхәббәттән Шириннең әлиф кебек зифа, төз буе ләм хәрефе кебек бөгелеп төшә: «Әлиф тик бузым *(буем)* уш булды...ләм» *(I, 67 б.)*. Хөсрәү белән Шириннең кавышу кичәсен автор әлиф һәм ләм хәрефләренең язылу рәвеше белән бирә: «Кочышыб ләм-әлиф тик ул ике йар...» *(II, 391 б.)*.

Урта гасырның күп кенә әдипләре кебек, «Хөсрәү вә Ширин» авторы да тәрбияви, әхлакый тормыш тәҗрибәсе бирү ягын күздә тотып, үз әсәрендә кызыклы, тирән фикерле мәкаль-әйтемнәр, канатлы сүзләр китерә: «Казгу козгусына *(коесына)* төштем» *(II, 408 б.)*; «Ук нишанга *(мишеньгә)*... атылыр» *(II, 410 б.)*; Җил иссә, яшь үләнгә *(«утка»)* рәхәт, кипариска кыен булыр *(II, 410 б.)*; «Белек берлә күңелдин казгу китәр» *(II, 411 б.)*; «Карын теш ите берлә туймаз» *(I, 208 б.)* һ. б.

Әсәрдәге күп кенә юллар афоризмдай, мәгънәле янгырый:

Борынгы зәүкъ һич соңра табылмаз,
Карыйлыкда егетлек кыйлса булмас *(I, 144 б.)*.

Ничә татлигъ терелсәң *(яшәсәң)*—ачигъ үлгү *(үлем ачы)* *(I, 187 б.)*.

Вәли дөнья өчен кылма күңел тар,
Күңел тарлыгы казгу китерер, әй йар *(I, 186 б.)*.

Эчем—сув ирсә, ялгыз эчмә, зинһар,
Кем ул ялгыз йийган *(ашаган)* ялгыз үләр зар *(II, 274 б.)*.

Йир орлык алмаенча бирмәз ашлык,
һава дәрьядин алса—сон бирер чык *(II, 379 б.)*.

Угыл изгү-яманны кылса, андин
Кире үз углы яндыргай җәзасын *(I, 41 б.)*.

Котб үз әсәренең кыйммәтен үзе дә яхшы тойган. Романнын ахырында ул бу ядкярен «Каләмнең күзендин... бәгърем канын» агызып яздым ди; бу төр «кыйссалар»ның күп булуын искәртә. Әмма,—ди шагыйрь,—«аларнын катында бу—җәүһәр» кебек *(II, 434 б.)*.

Котб әсәре үзеннән соңгы төрки-татар сүз сәнгате үсешенә зур йогынты ясады *(Х. Миңнегулов. «Ни белгәйләр сине сүзләтмәсәң тел»: Алтын Урда әдәби традицияләре // Мирас.—1996.-№ 5-6.—202-215 б.б.)*. Харәзми, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр, Әбелмәних Каргалый кебек әдипләр, мәсәлән, гарәп-фарсы әдәби казанышларын үзләштерүдә Котбка хас иҗат принципларын да (тәрҗемә, нәзыйрә, ялгау...) иркен файдаландылар. «Хөсрәү вә Ширин» Алтын Урда әдәби теле үсешендә мөһим роль уйнады. Котб әсәренә хас идея-тематика, сурәтләү һәм тасвир чаралары, шигъри детальләр һәм поэтик фигуралар төрле дәвер татар әдипләре тарафыннан эшкәртелде, иҗади рәвештә кулланылды. «Хөсрәү вә Ширин»дә еш кына «золымдин моңлыны азад кылу», халыкка «йар булу», «ил күнлен рәнҗетмәү» хакында сүз бара. Бу мотив Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр һәм Тукай әсәрләрендә дә бар. Котб болай ди:

Кеше ни кем кылыр булса кешегә,
Килер бер көн һәм ул анын башынга *(II, 260 б.)*.

Шушына охшаш фикер «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмаларында да очрый: «Үзенә ни теләсән, үзгәгә аны сакын *(телә)*»; «Коюг казып, үзе төшкәй» һ. б.

Ш. Бабичның «Зәңгәр күк—таҗым, чуар җир—тәхтем!» юлы күпләргә таныш. Шуна тартым чагыштыру «Хөсрәү вә Ширин»дә дә бар:

Әгәр булсаң бу тәхте таҗга мохтаҗ,
Сәна йир тәхет ирер, юкары күк—таҗ *(II, 414 б.)*.

Дөнья хакында уйланып, Котб болай ди:

Карый хатын тик ул бу дөнья мәккар (мәкерле),
Сөчүклек берлә ул сине алдар *(II, 242 б.)*.

Дөньяны яшь, назлы күренергә теләгән карчык белән чагыштыру Мәүла Колый, Шәмсетдин Зәки һәм кайбер башка шагыйрьләрдә очрый.

Романнын бер бүлекчәсендә картлык *(карыйлык)* хакында нәни генә хикәят бар *(II, 394 б.)*. Бер егет карт кешедән *(пирдән)*: «Әгәр дә син карт диеп, ярың качса нишләрсең?»—дип сорый. Карт ана: «Ул качмаса, син аннан үзең «борынрак» качарсын»,—дип җавап бирә. Моңа охшаша мотив Сәгъди һәм Сараинын «Гөлестан»ында да күзгә ташлана.

Котб кешеләрдә булырга тиешле сыйфатлардан аеруча тугрылыкка *(вафага)* игътибар итә:

Вафа ирлек нишаны *(билгесе)* ул, бел, әй йар,
Тәлим ирдә ма чыкмаз бер вафадар.
(Күп ир арасында, бер тугрылык иясе дә чыкмас.)—*(I, 203 б.)*.

Шагыйрь тугрылыкта, гайрәтлелектә хәтта хатын-кызларга өстенлек тә бирә. Галиәсгар Гафуров-Чыгтайның (1867—1942) «Тутам» повестенда да нәкъ шушы мәсьәлә үзәккә куела. Анда без түбәндәге юлларны укыйбыз: «Яхшы тикшерелсә, вафасызлык бәлки ирләрдә күбрәк булыр...—Ирләрдә булган истигъдад *(сәләт, булдыклылык)* вә кабилиятнең барчасы да хатын-кыз таифәсендә бардыр... Һәр нәрсәне эшләргә кулларыннан киләдер...[1]

[1]Татар мәгърифәтчелек әдәбияты.—Казан: Таткитнәшер., 1979.—357, 379 б.

* * *

Табигатьтәге һәм җәмгыятьтәге һәр нәрсә кебек тел дә, вакыт агышына нисбәтән, теге яки бу дәрәҗәдә үзгәреп тора. Шулай да XX йөз башына кадәрге татар әдәби телендә чагыштырмача тотрыклылык, традиционлык өстенлек итә. Мәсәлән, Кол Гали, Мәхмүд Болгари, Мөхәммәдъяр, Утыз Имәни, Шәмсетдин Зәки, Гали Чокрый әсәрләренен телендә житди аермалар юк. Аларның шигырь һәм хикәятләрен гадәти татар укучысы да бернинди тәржемәсез укыган, аңлаган. Кызганыч ки, Октябрь инкыйлабыннан соң халкыбыз үзенең күпгасырлык рухи тамырларыннан, мәдәни мирасыннан шактый аерыла. Гарәп, фарсы һәм төрки телләрен өйрәнү тәмам диярлек туктатылды. Атеистик пропаганда, искелеккә, «милләтчелеккә» каршы көрәш, ясалма бәйнәлмиләлчелек (интернационализм), бердәм совет халкы булдыру сәясәте хәтер, традицияләр дәвамчанлыгына, милли мәдәни үсешкә шактый тискәре йогынты ясады. Моның аяныч нәтиҗәләрен без телебездә дә ачык күрәбез. Сөйләм һәм язма телебез шактый ярлыланды. Гасырлар буе кулланылган сүз-гыйбарәләрне, шәкелләрне онытып, сөйләмебезне урынлы-урынсыз алынмалар белән чуарлап бетердек. Шуның нәтиҗәсендә хәзерге укучы белән элеккеге яркярләр арасы ерагайды. Хәтта күп кенә татарлар Тукай әсәрләренең телен дә тиешенчә аңламый. Мондый шартларда Октябрьгәчә чор әдәби мирасны бүгенге укучыга житкерү мөһим бурычларның берсе булып тора. Бирелә элеккеге әсәрләрне, аеруча шигъри текстларны сүзлек-аңлатмалар ярдәмендә оригиналда житкерү—нәтиҗәле, ышанычлы юл. Бу очракта укучы әдәби ядкяр белән бернинди арадашчысыз, үзе очраша, аның идея-эстетик эчтәлеген, тел-өслүбен турыдан-туры үзләштерү мөмкинчелеге ала. Шуның белән бергә, киңрәк катлам укучыларны күздә тотып, элеккеге текстларның хәзерге телгә әдәби тәржемәләрен бирү дә гамәлдә очрый. Мәсәлән, Кол Гали, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр, Утыз Имәни әсәрләренең бу төр тәржемәләре бар. Әмма бу очракта зарури бер таләпнең катгый үтәлүе мәҗбүри: ул да булса—оригиналга тугрылык, мөмкин кадәр аның байлыгын, лөгати үзенчәлеген, чор, жирлек колоритын саклау. Дөрес, тәржемә дә иҗадилыкны сорый. Әмма бирелә сүз бер тел эчендәге тәржемә хакында бара. Ике теллелек белән бәйләнешле тәржемә принциплары монда бик үк уңышлы түгел. Әгәр дә оригинал хезмәтен үтәүче текст үзе дә башка телдән тәржемә булса, эш тагын да катлаулана. Чөнки бу очракта тел-стиль, шәкел, фикер үзенчәлеген саклау, аларга тугры калу аеруча мөһим.

Авыр аңлаешлы элеккеге текстларны хәзерге укучыга житкерүнең аеруча үтемле фәнни бер юлы бар: ул—оригиналны һәм тәржемәне янәшә бирү. «Кыйссаи Йосыф»ның Ф. Фәсиев әзерләгән 1983 елгы басмасы—моның күркәм бер мисалы. Рифкать Әхмәтжанов—тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор. Ул лексика, тел тарихы, чагыштырмалы лингвистика буенча хезмәтләре белән мәгълүм. Әдәбияттан да хәбәрдар. Ул Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрен хәзерге телгә тәржемә итеп, «Мирас» журналының 1992—1993 елгы саннарында *(5-12, 1-5 саннар)* инде бастырган иде. Тәржемә укучылар һәм җәмәгатьчелек тарафыннан, гомумән, уңай кабул ителде. Аннан аерым өзекләр төрле дәреслек-хрестоматияләргә, әсбапларга да урнаштырылды.

Р. Әхмәтжанов, гәрчә тәржемә өлкәсендә тәжрибәсе аз булса да, Котб әсәренең идея-сәнгати байлыгын бүгенге укучыга житкерү юнәлешендә уңышлы адымнар ясый. Романның интонацион яңгырашы, нигездә, сакланган. Чор, жирлек белән бәйләнешле төшенчәләр дә ярыйсы гына торгызыла. Кыскартулар да чагыштырмача аз.

Хәзерге телгә аударылган текст, гомумән, үзбашка әйбәт. Әмма аны оригинал белән чагыштырганда, бәхәсле яклар да туа. Төп нәсхәнең күпчелек сүзләре, сурәтләре, шәкеле бүгенге укучы өчен аңлаешлы. Тәржемәче исә, ни сәбәптәндер, (әйтерсең, тәржемә әсәре белән түгел, ә башка телләге текст белән эш итә) иҗади якны көчәйтеп җибәрә: еш кына оригиналдагы таныш сүзләрне һәм формаларны да яңалары белән алыштыра. Мона мисаллар бик күп булса да, бирелә шуларның бер-икесен генә китерәбез:

> Гашыйклык берлә шаһлык раст килмәз,
> Кеше кем гыйшкы юк бу серне белмәз *(11,316 б.)*.

Р. Әхмәтжанов бу юлларны болай «тәржемәли»:

> Гашыйклык һәм дә шаһлык төрле-төрле,
> Гыйшыксыз жан гына белмәс бу серне *(Кульязма, 207 б.)*.

Элеккеге текстагы «Ни йирдин без, янә канда (кая барырбыз?» мисрагы *(11,399 б.)* хәзерге телгә «Каян килдек һәм алда ни күрербез?» рәвешендә бирелгән *(Мирас.—1993.—№ 5—15 б.)*. Р. Әхмәтҗанов тәрҗемәсендәге аерым юллар оригиналдан шактый ерагаеп та киткән. Төп текст: «Һавада тикмә зәррә кем очар, бел» *(11,257 б.)*. Биредәге зәррә сүзе тузан, ком бөртеге, атом мәгънәсен белдерә.

Тәрҗемә: «Чырак тотма һавада—сүндерер җил» *(Мирас.—1992.—N 12.—22 б.)*

Төп нөсхә:

> Бу мәнзилдин ушал галәм ерак ул,
> Рәва юк сүзләмәк сүз күрмәдин юл *(11,399 б.)*.

Биредәге мәнзил сүзе тора торган урын, бу очракта җир мәгънәсен белдерә. Ушал—шул, теге, башка, ә рәва юк мөмкин түгел төшенчәләрен аңлата.

Тәрҗемә:

> Мәкаль бар: Шам *(Сурия; Дәмәшекъ:—Х. М.)* ерак бу Минзәләдән,
> Сөйләр юкны, барып кайтса бер адәм[1].

Тәрҗемәдә оригиналның стиле, эчтәлеге, мәгънәсе белән бик үк ярашмаган башка төр «иҗади» моментлар, артык «заманчалаштырулар» да очрый: «Ирер ай берлә хатынлар эше бер» *(11,345 б.)*—«Кәҗәлектә хатын да, ай да—бер ул» *(Мирас.—1993.—№ 3.—28 б.)*; «Булаен мән битәррәк *(начаррак)* йөз гәз *(тапкыр)* этдин» *(11,372 б.)*—«Булыйм дуңгыз, тәмам эт булыйм актык» *(Мирас.—1993.—№4.—17 б.)*; «Никаб *(пәрдә; бөркәнчек)* алса йөзендин ул тулун ай» *(11,279 б.)*—«Вуален алса йөздин ул матур ай» *(кулъязма, 182 б.)* һ. б. Гомумән, тәрҗемәдәге букет, хор, пикник, нектар, пахут *(поход)*, парад, октава, кисть, император кебек сүзләр текстның рухына, стиленә бик үк туры килеп бетмиләр. Бозорг Өмид атамасын Бөек Мобед дип алу да бәхәсле.

Кыскасы, «Хөсрәү вә Ширин»нең хәзерге телгә тәрҗемәсе, гәрчә фәнни максатларга тулысынча җавап бирмәсә дә, әсәрнең эчтәлеген, идея-эстетик байлыгын бүгенге укучыга ирештерүдә билгеле бер мөһим роль уйный. Журналда басылган текстка Р. Әхмәтҗанов аерым өстәмә-төзәтмәләр керткән. Әмма әле тәрҗемәне тагын да камилләштерү сорала.

* * *

Котб—Алтын Урда җирлегенең һәм чорының күренекле вәкиле. Мәгълүм сәбәпләр аркасында бу кодрәтле дәүләт рәсми тарих китапларында, аеруча дәреслекләрдә төрлечә хурланды, аны милләтебез тарихыннан аерып кую өчен «күп эш» башкарылды. Әмма хакыйкатьне томалап булмый. Аккан су юлын табар дигәндәй, ул да ачыла, ул да иртәме-соңмы адәм балаларына мәгълүм була. Татарстан президентының Икенче Бөтендөнья татар конгрессында һәм Мөхәммәдьяр кичәсендә ясаган *(28—29.08.1997)* докладларында Алтын Урданың татар тарихында һәм мәдәниятендә тоткан урыны рәсми рәвештә югары бәяләнде: «Татарларның Алтын Урда дәүләте—бөтендөнья тарихында тирән эз калдырган дәүләт»,—диде Президент. Һәм ул Кол Гали, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Тукай, Дәрдмәнд кебек бөек шагыйрьләр белән янәшә хаклы рәвештә Котб исемен дә атады.

«Хөсрәү вә Ширин» авторы мәхәббәтне җәмгыятьнең юлдашы, кешелек яшәешенең асылы дип саный:

> ... Гыйшк берлә терек ошбу галәм,
> Әгәр гыйшк булмаса, булмаз ирде адәм.

Әйе, моннан җиде гасырлар элегрәк якты дөньяга килгән Котб хаклы. Мәхәббәт кенә кешене яшәтә; гаделлеккә, инсаниятә корылган мәхәббәт кенә җәмгыятьне үстерә.

СӘХНӘ СӘНГАТЕНӘ БЕР КАРАШ

Татар профессиональ театрынын мәйданга килүе Оренбург труппасынын эшчәнлеге һәм татар сәхнәсенен беренче артисткасы Сәхибжамал Гыйззәтуллина-Волжская ижаты белән нык бәйле.

Оренбургта милли театр оештыру эше 1905 елда ук башланса да, бу хәрәкәт зур каршылыкларга очрап, тукталып кала. Аннан сон, елдан артык вакыт узып, Ильяс Кудашев-Ашказарский Санкт-Петербургка барып рөхсәт алып кайтканнан сон гына, театр хәрәкәте янадан күтәрелеп китә.

Ильяс Кудашев-Ашказарский— артист. Яшьлек еллары

Мәгълүм булганча, 1907 елнын 10 февралендә Халык йортында мәдәни кичә оештырыла. Бу кичәгә урысча афиша да чыгарыла. Аны биредә төп нөсхәдә басылганча китерү мөһим. Менә ул: «Программа. Народный дом. В субботу 10 февраля 1907 г. труппою драматических артистов, при участии любителя мусульманина Ильяз Бека Ашкадарского дан будет спектакль с отчислением 10 % чистого дохода в пользу голодающих; поставлено будет «Женитьба» [...] «Ары таба уйнаучылар исемлегендә бишенче булып «Кочкарев ...—Ильяз Бек Ашкадарский [...]», диеп күрсәтелгән. Кичәнен икенче бүлегендә шәрекъ моннары янгыраячагы хәбәр ителә. Ин соныннан, кичәне оештыручылар хакында: «Администратор—А. Юдин, режиссер—И. Ашкадарский», диелгән *(Татарстан милли музее. И. Кудашев-Ашказарский фонды, №119—760).*

Бу афишадан күренүенчә, Ашказарский урысча уйналган спектакльдә урыс телендә чыгыш ясаган.

Сонрак, апрель аенда да тагын шундый берничә кичә оештырыла. Озакламый Тирәк бакчасынын җәйге театрында, 1907 елнын 19 маенда, янәдән спектакль уйнала. Ана да урысча афиша чыга. Анын эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт: «Летний театр. Тополевый сад. 1907 г. 19 мая. Труппою мусульманских драматических артистов и любителей с участием Ильяс Бека Ашкадарского дан будет благотворительный спектакль на усиление средств Оренбургского санитарно-благотворительного попечительства. Поставлена будет пьеса местного автора Ильяс Бека Кудашева «Свет и тьма». Комедия в двух действиях [...]». Кичә өч бүлектән гыйбарәт булып, анын икенче бүлегендә урыс артистлары тарафыннан урыс мөхәррире әсәре уйналачагы, өченче бүлекнен тулаем шәрекъ моннарыннан гыйбарәт булуы билгеләнә. Бу кичәнен дә режиссеры итеп И. Кудашев-Ашказарский күрсәтелә (*Татарстан милли музее. И. Кудашев-Ашказарский фонды, № 119—760).*

Афишадагы мәгълүматнын ин мөһиме шул: кичәнен «Ильяс Бәк Ашказарский катнашында мөселман драма артистлары труппасы һәм һәвәсләләр катнашында була», диеп күрсәтелүе.

Аннан сон труппа май азагында Оренбургтан гастрольгә чыгып китә. Сембердә уйналган спектакльнен афишасына игътибар иткәндә, ул да урысча чыгарылган: «г. Симбирск. В летнем театре. В воскресенье 24 июня 1907 г. Первою в России труппою Мусульманских драматических артистов под управлением Ильяс Бека Кудашева-Ашкадарского дан будет спектакль на татарском и русском языках. Представлены

будут на татарском языке: «Свет и тьма» или «Наданлар иля галимлэр», комедия в двух действиях, переводная переделка Ильяс Бека Кудашева-Ашкадарского [...]».

Кичәнен икенче һәм өченче бүлекләрендә А. Чеховның кече күләмле әсәрләренең урыс телендә уйналачагы игълан ителә. Афишаның азагында: «Дирекция Ильяс Бека Кудашев-Ашкадарского»,—диелгән.

Шушы 1907 елның 24 июнендә куелачак спектакльгә чыгарылган афишада И. Кудашев-Ашказарский соңыннан зур ыгы-зыгыга сәбәп булган хата ясый, ул: «Первою в России труппою мусульманских драматических артистов под управлением Ильяс Бека Кудашева-Ашкадарского дан будет спектакль [...]»,—диеп, Оренбурглылар труппасын халыкка үз исеме белән тәкъдим итә.

Казанда 13 июльдә уйналачак спектакльнең афишасында да труппа шул исем белән атала. Бу—хата була. Труппа житәкчесе Ильяс Кудашев-Ашказарскийның яшьлеге аркасында үз шәхесе белән артык мавыгуыннан туган хата.

Труппа Казаннан соң Чистайда бер спектакль уйнап, Түбән Новгородка китә. Анда да спектакльләр күрсәтелә. Чираттагы 24 августта уйналачак спектакльгә дә урысча афиша чыга; анда: «Восточный вечер. Вторая гастроль. 24 августа 1907 г. Нижегородская ярмарка. Первой в России передвижной труппой мусульманских драматических артистов, под управлением Ильяс Бека Кудашева-Ашкадарского дан будет второй спектакль на татарском языке; представлено будет «Оят яки күз яше» («Уят яки кюз яши») «Стыд или слезы», драма в 4-х действиях, сочинение А. Вали [...]»,—диелгән.

Мөгаллим Хәбибрахман Зәбиринең 26 августта уйналган «Указ бәласе» спектакленә дә урысча афиша чыгарылып, труппа янадан шул исем астында тәкъдим ителә.

Ә инде шуннан соң чыккан афишаларда труппаның исеме бөтенләй төшерелеп калдырылып, күрсәтелми башлый.

Моннан шул ачыклана, И. Кудашев-Ашказарский беренче профессиональ татар театр труппасын оештырып, аны житәкләп, спектакльләрен башка төбәкләрдә яшәүче халыкларга да күрсәтүче, труппа эшчәнлеген шәфкатьлелек юнәлешенә кертеп жибәргән мөхтәрәм шәхес. Бу эштә аның беренчел урыны бәхәссез. Урыс телендә уйный башлап, әкренләп үз халкына мәдәни хезмәт итүгә керешүе дә, аның эшчәнлегенең гүзәл бер сыйфаты. Әмма шуны да әйтеп китми булмый, яшьлеккә хас ашкынуы белән ул ялгышуга да дучар була. Монсы—аның төрки халыклар мәдәниятеннән мәгълүматы житенкерәмәүдән килә.

Сәхибҗамал Гыйззәтуллина, Габдулла Кариев. 1908 елның көзе.

Үзе житәкләгән труппаны, дүрт-биш спектакль куйгач та, аны «Русиянең беренче мөселман драма артистлары труппасы» дип атавы шуның ачык дәлиле. Чөнки бу вакытта төрки халыклар арасында күптән эшләп килгән профессиональ труппа булуы мәгълүм. Әйтик, Әзәрбайжан халкының Гасанбәк Мөлеков-Зәрдәби житәкләгән профессиональ театр труппасы 1873 елдан ук яшәп килә.

Барлык төрки зыялыларга, укымышлы кешеләргә бу билгеле вакыйга. Шул вакыттагы матбугат—Кырымда 1883 елдан чыгып килгән «Тәржеман» газитәсе бу хакта тәфсилле мәгълүмат биреп килгән. Шуна карамастан, Ашказарский алда күрсәтелгән эчтәлекле афишалар чыгарып, барлык төрки дөньясын гажәпкә калдырган. Аны труппадан китәргә мәжбүр иткән төп сәбәп тә шушы. Башка каршылыклар барысы да тормыш-көнкүреш белән бәйле вак-төяк кенә.

Менә шушындый катлаулы вазгыятьтә труппага Сәхибжамал Гыйззәтуллина килә. Әлбәттә, бу гайрәтле, фидакарь сәнгатькяр

шундый тәвәккәл һәм кыю адымны үз рухиятенен кушуы һәм күңел омтылышы белән ясый.

Ул—Казан кызы. Аның ятимлек ачысы белән тулы үсмер еллары да шул шәһәрдә уза.

Драматик артистка буларак, ул сәхнәдә үзешчәнлек чорын узмыйча, турыдан-туры профессиональлектән башлый. Бу—сәхнә хакында аның бөтенләй хәбәре булмаган, дигән сүз түгел. Аның үсмер вакытында үк дус кызлары белән урыс театры спектакльләренә шактый еш баруы билгеле. Профессиональ сәнгатьнең хореография төре аша махсус мәктәп узып, Европа биюләрен үзләштерүе дә мәгълүм.

Сәхибҗамалның этисе Гыйззәтулла Хәмидуллин чыгышы белән Идел арьягының (хәзерге Яшел Үзән районы) Әрә авылы кешесе булып, Казанда аларның йортлары Яна бистәдә (кызганычка каршы, ул урам хәзер сакланмаган) Фатих Әмирханнар йорты белән янәшәдә торган.

Ильяс Кудашев-Ашказарский труппасының 1907 елны Казанга килеп 13 июльдә куйган «Галимнәр һәм наданнар» спектаклен карарга да ул дус кызлары һәм Фатих Әмирхан белән бергәләп бара. (Ул вакытта әле булачак әдип авыру түгел, аның аяклары шул елның августыннан йөрмәс була.)

Фатих Әмирхан тәкъдиме белән диеп уйларга кирәк, алар спектакль тәмамлангач та, таралып, өйләренә кайтып китмиләр, труппа житәкчесе Ашказарскийның чыкканын көтеп алалар һәм ана үзләренен дәгъваларын да белдерәләр: ни өчен сәхнәдә хатын-кыз рольләрендә ир-егетләр уйный?

Үз чиратында, Ашказарский хәлне һич яшерми анлата һәм шунда ук тәкъдим дә ясый: менә сезнен кебек туташларыбыз сәхнәдә уйнарга риза булса, без бу уңайсыз хәлдән чыгар идек, ди. Фатих Әмирхан исә, аның бу фикерен күтәреп үк ала һәм куәтләп, бер дә икеләнергә урын калдырмыйча, Сәхибҗамалны артистка булырга өнди.

Менә шушы ике кешенен алдан сүз берләштермичә, бер авыздан сәхнәгә димләүләре, Сәхибҗамалның киләчәген хәл итә. Дөрес, башта ана үзен тәрбиягә алган кешеләрнен каршылыгын җинәргә, аннан этисенен ризалыгын алу өчен дә күп көч куярга туры килә. Соныннан, өйләренә Ашказарскийның килеп, берничә кабат үгетләүләреннән сон, Сәхибҗамал иптәш кызы белән бергә труппага керергә ризалык бирә.

Казаннан китеп, Чистайда бер спектакль куйганнан сон, труппа Түбән Новгородка юнәлә.

Оренбургта оешкан труппада бары биш кеше була. Хатын-кыздан берәү дә булмый. Бу хакта Казан матбугатында ачыктан-ачык языла: «Дүрт ир-егет, бер үсмер бала»,—диелә анда. Ә афишаларда исә дистәләрчә кеше күрсәтелә. Шулар арасында дүрт-биш хатын-кыз фамилиясе дә бар. Мона гажәпләнергә туры килми. Мондый «шагыйрәнә ялган» труппаның эшен җинеләйтү, шәһәр түрәләреннән спектакльләргә рөхсәтне тизрәк алу өчен эшләнә. Гамәлдә исә, алда әйтелгәнчә, труппада бары биш кеше, барысы да Оренбургтан, барысы да ир-егетләр була.

Соңгы вакытта С. Гыйззәтуллинаның Ашказарский труппасына килүе, гомумән, аның иҗатына бәйле төрле язмалар дөнья күрде. Бу шатлыклы күренеш. Беренче артистканың иҗаты һәм тормыш юлы күпләрне кызыксындыра. Арада күңелне рәнжеткәннәре дә юк түгел. Объектив булмаган бәяләмәләрне язма авторларының үз намусларына калдырып, кайберләренә генә тукталып, мөһим моментларны ачыклап үтү зарур.

Мисал өчен, «Октябрьгә кадәрге татар театры» китабында С. Гыйззәтуллинаны беренче мәртәбә сәхнәгә 1907 елның 2 сентябрендә уйналган «Өч хатын белән тормыш» спектаклендә Мәрьям ролендә чыга, диеп фаразлана (*Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1988, 54 б.*). Бу—бөтенләй сафсата. Шунда ук «Галимнәр һәм наданнар» спектаклендә Ә. Кулалаев башкарып килгән Шәмсекамәр роленә чая гына бер татар карчыгын табып, әзерләп кертү дә, үеннын табигыйрәк чыгуына ярдәм итә»,—диелә. Бу рәвешле фикер йөртү балалар өчен язылган әкиятләрдә бәлки ярыйдыр да, ә житди язмалар өчен һич урынлы була алмый.

1907 елда кем, нинди карчык шундый «денсезлеккә» риза булсын? Аны шул көнне үк мәхәллә мулласы бәддогага дучар итәчәк. Туганнары, таныш-белешләре аннан йөз чөерәчәк. Ул вакытта, европалашкан гаиләләрнен яшь-яшь гимназистка кызлары

да һәвәскәр спектакльләрдә тәхәллүс (псевдоним) белән чыгыш ясаганда, татар карчыкларыннан мондый адымны көтү—бу мөмкин булмаган хәл.

Мондый төгәлсезлекләрне ачыкларга шул чорның матбугаты ярдәм итә. Бер үк вакытта истәлекләрне дә күз уңаенда тотарга туры килә.

Труппа Түбән Новгородка килеп, беренче спектаклен уйнагач, Казанда «Йолдыз» гәзитәсендә бу хакта мәкалә басылып чыга. 26 август санында дөнья күргән бу мәкаләдә: «Узган сишәмбе көн 14 августта, Макарьяда Фоли-бержер бакчасында Ильяс бәк Кудашев-Ашказарский риәсәтендә татарча театр уйналды. Бунда да Ашкадарский Казанда бер мәртәбә мөвакыйг тамашага куелган уеннардан «Галимнәр илә наданлар» комедиясене тамашага куйды»,—диелә анда. Бу мәкалә Ашказарский труппасының Түбән Новгородтагы беренче гастроль спектакленең кайсы көнне куелуы, нинди әсәр уйналуы хакында төгәл мәгълүмат бирүе белән мөһим. Шушы мәкаләдә спектакльдә карчык ролендә нинди дер карчык уйнавы хакында язылa. Бу чынлап та шулаймы? Мәсьәләне ачыклау өчен шул вакытта труппада уйнаган артистларның истәлек язмаларына мөрәҗәгать итәргә туры килә.

Труппадагы биш кешедән Ашказарский язмалар калдырмый. Н. Гайнуллин, Ә. Кулалаев (Ишморатов), Н. Ахундов (Хәйретдинов)ларның да нинди дә булса язмалары билгеле түгел. Ә менә В. Мортазин-Иманскийның язмалары билгеле.

Анда В. Мортазин 1907 елда Түбән Новгородта куелган «Галимнәр һәм наданнар»ның татар театры тарихында хатын-кыз катнашында куелган беренче профессиональ спектакль булуы хакында яза. Шушы спектакльдә Сәхибҗамал Гыйззәтуллинаның тәү башлап профессиональ сәхнәгә аяк басуын күрсәтә. Бары спектакльнең уйналу көнен генә ике көнгә алга күчереп, 12 август диеп яза *(В. Мортазин, Т. Ченәкәй. Татар театры тарихыннан.—Мәскәү, 1926, 44 б.).*

«Йолдыз» гәзитәсенең үз вакытында үк спектакльнең төгәл уйналу көнен теркәп калдыруы инде мәгълүм.

Шушы ике чыганакны чагыштыру беренче артистканың тәү башлап сәхнәгә чыгу көнен төгәл ачыкларга ярдәм итә.

Бу—1907 елның 14 августы (хәзерге стиль белән 27 август). Инде янадан «Йолдыз»да басылган мәкаләгә мөрәҗәгать итик. Анда: «(...) сонра да Казанда уйналганда нә дә рус вә нә дә татар карчыгына охшамаган бер кыяфәт бу уенда юк иде. Бу уенда, кыз ролене (кыз), карчык ролене карчык уйнаганлыктан, бик табигый сурәттә чыкты», диелә.

Күренә ки, кыз сүзе клишеда махсус төшерелеп калдырылган. Октябрь инкыйлабына кадәрге мөхәррирләр бу мөһим фактны тарихта теркәп калдыру өчен бик сак эш итәргә мәҗбүр булганнар. Бердән, матбугатны һәртөрле урынсыз бәйләнүдән сакларга кирәк булса, икенчедән, яңа оешкан труппага килгән беренче татар артисткасының язмышын кыл өстенә куймау өчен дә кирәк була бу. Ничек итсә иткәннәр, барыбер юлын тапканнар. Алдагы сүз төшерелеп калдырылгач, карчыкны карчык уйнаган булып чыга.

Бу очракта труппа җитәкчесе Ашказарский да сокланырлык тапкырлык белән эш иткән. Бер үк көнне, бер үк спектакльдә яшь артистканы бер-берсенә капма-каршы характердагы, яшь аермасы бик зур булган ике рольдә сәхнәгә чыгарган: мөгаллим Моратовның яшь кызы Әминә ролендә һәм Моратовларның фатир хуҗасы Шәмсекамәр карчык ролендә. Ашказарский моңа мәҗбүр була, чөнки труппа урыс театрларыннан аермалы буларак, дәүләт яклавыннан тыш, яшь һәвәсләләр тырышлыгы белән генә мәйданга килә.

Ни өчен С. Гыйззәтуллина үзенең истәлекләрендә бу рольләрне искә алмый, беренче сәхнәгә чыгып уйнаган образы итеп башка рольне күрсәтә, дигән урынлы сорау туарга мөмкин.

Бердән, аның истәлекләре беренче гастрольдән соң утыз елга якын вакыт узгач языла. Хәтергә килмәве мөмкин. Икенчедән, төп сәбәп шул диеп уйларга кирәк, ана кадәр бу рольләрне Әхмәт Кулалаев һәм Нурулла Гайнуллин уйнап киләләр. С. Гыйззәтуллина өчен бу рольләр кердеш рольләр (хәзерге профессиональ артистлар «ввод» диеп йөртәләр). Мәгълүм булганча, артистлар үзләренең беренче сәхнәгә чыккан рольләре турында искә алганда танылган әсәрләрдә, мөһим образларда чыгыш ясауларын күрсәтергә тырышалар. Бу эмоциональ хәтернең бер үзенчәлеге. Ә матбугатка килсәк, ана фактны тарих өчен теркәп калдыру мөһим. Шуннан С.

Гыйззәтуллинаның үз истәлекләрендә һәм галим Гази Кашшафка сөйләгәндә ни өчен беренче уйнаган образы итеп Нәмыйкъ Кәмалнын «Кызганыч бала» фаҗигасендә Шәфыйка образын атаганы аңлашыла. Әмма бу ялгыш. Хәтер ялгышы.

Ашказарский труппасының Түбән Новгородтагы икенче спектакле—Ярулла Вәлинең «Оят яки күз яше» 24 августта (хәзерге стильдә 7 сентябрьдә) уйнала. Бу спектакльгә дә махсус афиша чыгарыла. Анда уйнаучылар арасында бишенче булып: «(...) Магрифа, молодая девица, горничная у купца Ильяса—госпожа Иззатуллина, (...)», диеп күрсәтелгән *(Татарстан милли музее, И. Кудашева-Ашказарский фонды, N 119—760).*

Афишада беренче артистканың фамилиясе Иззатуллина диеп, «И» аша язылган. Бу аның рәсми афишада беренче күренүе. Анда аның Мәгърифәне уйнаячагы игълан ителсә дә, 24 августта куелган спектакльдә бу рольне ул уйнамый.

Тәнкыйтьче Габдрахман Кәрам «Макарьядан мәктүб» мәкаләсендә *(«Йолдыз», 1907, 12 сентябрь)* спектакльдә чыгыш ясаган һәр артистның уенына аерым тукталып, тулы анализ ясый. «(...) Бән беренче уенда, мәгаттәәссеф (үкенечкә—Ф. К.) булунмадым. Шунын өчен «Наданлар илә галимнәр» пьесасы хакында бер хөкем вирмәем. Ләкин бу икенче уен зарарсыз, вә, гадәтә, бәгъзе бер ерләре маһирәнә уйналды (...). Драманың каһарманы улан Мәгърифәне уйнаган егет беренче пәрдәдә гүзәл бер сурәттә уйнады исә дә, актык пәрдәсендә дикъкатьне җәлеп итә алмады (...)»,—диелә анда. Өзектән күренүенчә, 24 август спектаклендә Мәгърифәне егет кеше уйный.

Ашказарский труппасында амплуа бүленеше була. Ул вакытта хатын-кыз рольләрендә күбрәк Әхмәт Кулалаев чыгыш ясый. Димәк, Мәгърифәне дә ул уйнаган булырга кирәк.

Труппа Түбән Новгородта барлыгы дүрт спектакль уйный. Уйналган спектакльләр Шәрекъ кичәләре исеме астында бер шәлкем тәшкил иткәннәр. Өченче шәрекъ кичәсе 26 августта булып, тамашага мөгаллим Хәбибрахман Зәбиринең «Указ баласе» уйнала. Афишада С. Гыйззәтуллина исеме юк, чөнки әсәрдә хатын-кыз рольләре юк.

Дүртенче кичәгә дә афиша чыга. 31 августта Г. Камалның «Бәхетсез егет» әсәре куелырга тиеш була. Афиша чыгарылса да, бу әсәр уйналмый. Дүртенче, саубуллашу кичәсе диеп янадан афиша чыга. Бу кичәнең икенче сентябрьгә тәгаенләнгәне, тамашага «Өч хатын белән тормыш» исемле биш пәрдәле драма куелачагы хәбәр ителә. Пьеса авторының исеме үзгәртелеп, Мухаммедгазиз Исхаков диеп басылган. Бу аңлашыла, чөнки әдип Гаяз Исхакый ул чакта иректә түгел.

Афишада рольләр бүленеше төгәл күрсәтелмәгән. Шуна күрә, кайсы артист нинди рольдә чыгыш ясаганын белүе авыр. Бары шуны төгәл күрсәтергә мөмкин: беренче артистканың фамилиясе уенда катнашучылар арасында 12 булып, бу очракта урысча төгәл итеп, Гиззатуллина диеп басылган. Бу аның рәсми афишада икенче күренүе *(Татарстан милли музее, И. Кудашев-Ашказарский фонды, № 119—760).*

Алда әйтелгәнчә, Ашказарский труппасы Түбән Новгородта барлыгы дүрт спектакль күрсәтә. Бу спектакльләрнең тәүге өчесе—труппаның әүвәлге репертуарында булган әсәрләр. Ә соңгысы, икенче сентябрьдә куелганы, бенефис иясе Ильяс Кудашев-Ашказарский шәрәфенә багышланып, яна премьера буларак тәкъдим ителә.

Түбән Новгородта башка бер әсәр дә уйналмый. «Бәхетсез егет» тә, «Кызганыч бала» да, труппа репертуарында булмаганлыктан, 1907 елгы гастроль вакытында уйналмыйлар. Гәрчә «Йолдыз»да 26 августта «Кызганыч бала» уйналды, диеп игълан ителсә дә, спектакль булмый. Һәм, шулай ук, «Бәхетсез егет»кә афиша чыкса да, 31 августта бу спектакль дә куелмый.

Түбән Новгородтан соң Ашказарский труппасы гастролен дәвам итеп, Касыйм шәһәренә килә. Бирелә ике спектакль куела. «Галимнәр һәм наданнар»ның Шәһәр манежы театрында 14 сентябрьдә уйналуы шул спектакльгә чыгарылган афишадан билгеле. Кичәнең татарча уйналган беренче өлешеннән соң, икенче бүлегендә урысча А. Чеховның «Хирургия» һәм «Касль» («Злоумышленник») исемендәге кече күләмле әсәрләре уйнала. Бу хакта вакытлы матбугатта үз вакытында язган. Алда күрсәтелгән афишада анонс белән мондый игълан бирелә: «В воскресенье 16 сентября последний спектакль. Представлено будет «Оят яки күз яше» («Стыд или слезы»). Драма в 4-х

действиях Яруллы Вали *(Татарстан милли музее, И. Кудашев-Ашказарский фонды, № 119—760).*

Касыйм шәһәрендә башка спектакль уйналмый. «Октябрьгә кадәрге татар театры»нда «Кызганыч бала»ны шул шәһәрдә куелган диеп күрсәтү («Октябрьгә кадәрге татар театры. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1988, 56 б.) дә хата.

Рязаньдә бер спектакльгә дә рөхсәт бирелми. Мәскәүдә Аквариум театры сәхнәсендә «Өч хатын белән тормыш» һәм икенче бүлектә урыс телендә «Гашыйклар» («Влюбленная парочка») белән «Касдъ» («Злоумышленник») уйналганы мәгълүм.

Кызганычка каршы, Мәскәүдә унынчы ноябрьдә уйналган бу спектакль труппаның 1907 елны куйган соңгы спектакле булып тарихка кердә. Күренә ки, Ашказарский труппасының репертуарында «Кызганыч бала» әсәре булмый. Бу труппа ул әсәрне һичкайда уйнамый. Димәк, Д. Гыймранова язганча, С. Гыйззәтуллина беренче тапкыр 1907 елда «Кызганыч бала»да Шәфыйка ролендә чыгыш ясый диеп күрсәтү *(Татар календаре, 2002 ел, 14 май бите)* дә хата фикер.

Сәхибҗамал Гыйззәтуллина—Гөлчәчәк Волжская образында. 1916 ел.

Сәхибҗамал Гыйззәтуллина Ашказарский труппасында тәү башлап 1907 ел 14 август (27 августта) Түбән Новгородта уйналган «Галимнәр һәм наданнар» спектаклендә яшь кыз Әминә һәм Шәмсекамәр карчык образларында сәхнәгә чыга. Ары таба икенче сентябрьдә куелган «Өч хатын белән тормыш» спектаклендә дә хатын-кыз рольләренең берсен уйнап катнаша.

Касыйм һәм Мәскәү шәһәрләрендә кабаттан куелган шушы спектакльләрдә янәдән шул образларда һәм кече күләмле сәхнә әсәрләрендә чыгышлар ясый.

Оренбургта 1907 елда И. Кудашев-Ашказарский оештырган труппаның, билгеле сәбәпләр аркасында, гомере озын булмый. Әмма бу мөхтәрәм шәхеснең татар профессиональ театр сәнгате үсешендә алтын багана булып урын алуы бәхәссез. Аның эшчәнлегенең һичкем тарафыннан инкарь ителә алмый торган асыл һәм мөһим сыйфаты бар. Ул беренче татар артисткасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллинаны сәхнәгә күтәргән фидакарь сәнгатькяр.

Труппаның алга таба гамәлендә һәртөрле кыенлыклар өстәлә генә барып, Мәскәү шәһәрендә матди кыенлыкларның үтә кискенләшүе аркасында, Ашказарский труппасын җуярга мәҗбүр була.

Оештыручысыз калган труппаны Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин үз канаты астына ала. Юллык акча җибәреп, аларны Җаекка чакыра. Җаекка алар 16 декабрьләрдән соң, Ашказарскийдан кала, җиде кеше киләләр.

1907 елда Җаекта бер спектакль дә куелмый. Бары 1908 елның гыйнварыннан гына янадан спектакльләр уйнала башлый. Җаекта уйный башлаган труппаның исеме дә башка: «Мөсафир артистлар җәмгыяте». Җаекта 1908 елның 12 гыйнварында беренче мәртәбә Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасының яңа варианты куела. Шулай ук шәһәрдә Сәхибҗамал Гыйззәтуллинаның беренче бенефисы була. Гаяз Исхакыйның 31 гыйнварда куелган яңа әсәре—«Алдым-бирдем» спектаклендә артистка Галия образын иҗат итә. Татар драматургиясендә хатын-кыз образларының иң тәүге җәүһәрләреннән булган бу гүзәл образны артистка шул спектакльдә кабатланмас итеп уйнап, труппа репертуарының да кыйммәтле энҗесенә әверелдерә.

Җаек каласындагы уңышлы чыгышлардан соң, озакламый труппа Кырымга юл ала. Кырымда алар Керчь, Феодосия шәһәрләрендә булып, Карасубазар (Белогорск)да берәр спектакль уйнап, Ак мәчеттән (Симферополь) соң, Кырымның йөрәге булган Бакчасарайга киләләр. Анда аларны Зөһрә Акчура һәм Исмәгыйль бәк Гаспралы каршы алалар.

Исмәгыйль бәк артистларның эшен җинеләйтүгә күп тырышлык куя. Шәһәр башлыгыннан спектакльгә рөхсәт алып бирү, бушлай афишалар бастыру белән генә чикләнмичә, труппаның алга таба хәрәкәт итүе өчен дә ин кирәкле ярдәмне ул күрсәтә. Үз газитендә 31 мартта уйналачак «Бәхетсез егет» хакында берничә мәртәбә тәфсилләп яза.

1883 елдан ук чыга башлаган «Тәрҗеман» газитәсе ул вакытта бик зур абруйга ия була. 1908 елның беренче апрелендә чыккан мәкаләдә труппаны «Казаннан килгән мөселман театр һәйәте» исеме белән үз укучыларына тәкъдим итеп, бу матбага әлеге труппаны барлык төрки дөньяга яна бер сыйфатта таныта. Чынында труппа Җаектан килә, аның төп көчләре дә Оренбургта оешкан әүвәлге труппа артистларыннан гыйбарәт була. Абыз кешедән гыйлем йогар, дигән борынгылар. Бу очракта да нәкъ шулай.

Ильяс Кудашев-Ашказарский XX гасырның утызынчы елларында.

Исмәгыйль бәк Гаспралы үз вакытында Париж, Вена, Берлин, Истанбул, Петербург, Мәскәү театрларының спектакльләрен күп тамаша кылган зыялы шәхес буларак, труппага алга таба дөрес юнәлеш алырга ярдәм иткән киңәшләр бирә. Труппадагы С. Гыйззәтуллина, Ф. Шәһимәрданова, Барый Болгарскийларның Казаннан булуларына аеруча игътибар иткән. Исмәгыйль бәк Гаспралы труппаны «Казаннан килгән мөселман театр һәйәте», дип атап, аның киләчәген милли мәдәни мәркәз—Казан белән бәйли.

Бу—Казанда профессиональ татар театрының беренче нигез ташын куюга тин адым була.

Казан милли профессиональ театрлы шәһәр булсын өчен, шул артистларга әле бик күп көч куярга, фидакарь хезмәт белән күп тир түгәргә, чын осталык мәктәбен үтү кирәк була. Осталык мәктәбенә ирешү юлын аларга шушы ике зыялы зат—Зөһрә Акчура һәм Исмәгыйль бәк Гаспралылар күрсәтәләр. Шул рәвешле труппа Кавказга сәяхәт итәргә ният итә.

Труппа Ялтадан Батумга, аннан Тифлиска юл ала. Бу калада гөрҗиләр белән бергә әүвәлгедән аның шактый зур өлешендә әзәрбайҗаннар һәм башка төрки халыклар яшәгән. Анда татар мәхәлләсе булуы да мәгълүм. Каланың исеме дә төрки сүз: «тыйблы (дәвалы, шифалы) су» дан хасил булган. Әзәрбайҗан артистлары биредә еш булганнар. Җәйлеккә бу шәһәргә килеп спектакльләр куюны алар гадәт итеп алганнар.

Сәяхәт итүче татар артистлары белән әзәрбайҗан артистларының тарихи очрашуы да шул калада була.

Фәүзия КАДЫЙРОВА,
сәнгать фәннәре кандидаты.

37—САФФАТ (САФЛАР) СҮРӘСЕ

Саффат сүрәсе 182 аятьтән тора. Сүрәнең беренче аятендә сафка тезелгән фәрештәләр турында сөйләнә. Исеме шуннан килә. Саффат—бер сафтагылар, дигән сүз. Мәккәдә иңгән.

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

1. *(Гыйбадәт кылырга, дип)* саф-саф тезелгән фәрештәләр исеме белән; **(2)** һәм яманлыктан тыйлыгып, **(3)** *(Коръән укып, Аллаһны)* зикер иткәннәр исеме белән ант итәмен ки: **(4)** Хакыйкать шулдыр—сезнең Тәңрегез бер генә. **(5)** Күкләр һәм Җир арасындагы бөтен барлыкның хуҗасы бер Аллаһ. Кояшның чыгышы да Аллаһ әмерендә.

6. Хактыр ки, Без иң якын Күкне зиннәтле йолдызлар белән бизәп куйдык.

(Димәк, без Җирдән күргән йолдызлар, йолдызлыклар—беренче кат Күкнең бизәкләре. Безгә күренә торган яктылык чыганаклары миллионлаган яктылык елы ераклыгында урнашкан. Күкләрнең һәр каты арасында миллионлаган яктылык елы ятса, Күкнең башка катына хәтле триллионлаган яктылык елы аралыгы ята. Бу—чиксезлек дигән сүз. Галәмнең чиксезлегенә, вакыт чиксезлегенә, вакытның шартлылыгына Корьәндә ишарәләр күп. Аллаһ янындагы вакыт белән Җирдә яшәүчеләр вакыты арасында илле мең ел ята. Галимнәр (Эйнштейн) бу фикергә әле шушы гасырда гына килде. Моны могҗиза, дими ни диярсең!)

7. Шулай итеп, Без аны *(Күкне)* итагатьтән чыккан һәр шайтаннан сакладык. **(8)** Алар *(шайтаннар)* күкләрдә киңәшүче фәрештәләрнең сүзләрен ишетеп тормасын өчен, йолдыз ташлары белән атылып) куылдылар. **(9)** Алар иге-чиге булмаячак газапка дучар булачак. **(10)** Мәгәр ки, *(шайтаннарның)* берәрсе берәр сер эләктереп кача башласа, аны бер чаткы *(атылган йолдыз)* эзәрлекләячәк.

11. Инде син *(Мөхәммәд)* алардан *(мөшрикләрдән)* сора:
—Юктан бар итеп яралту эшләрендә алар *(сыннар, потлар)* куәтлерәк ясалганмы, әллә *(фәрештәләр, күкләр, Җир үзе һәм алар арасындагы)* бөтен барлыкмы?—диген. Хактыр ки, Без аларны *(кешеләрне)* үзле балчыктан яралттык.

12. *(Пәйгамбәр буларак танымаганнарына, Аллаһны инкарь иткәннәренә)* син гаҗәпләнәсең. Шуңа күрә, алар мыскыл итеп синнән көлә.

(«Мөхәммәд инкарьчыларның кирелегенә, ап-ачык хакыйкатькә инанмаганнарына гаҗәпләнә».

Шәех Ногмани белән Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

13. *(Корьән аятьләре ярдәмендә)* үзләренә вәгазь укылса да, үгет бирелсә дә, кабул итмәсләр. **(14)** Алларына *(Аллаһның могҗизасы булган аятьләрне)*

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

чыгарып куйсаң да, мәсхәрә итәрләр. **(15)**—Бу—күз буудан башка берни дә түгел,—диделәр. **(16)**

—Үлеп, туфрак булганнан соң, черек сөяк өеменә әверелгәч тә без янадан тереләчәкбезме? **(17)** Борынгы бабаларыбыз да шулай тереләчәкме?—диделәр.

18. Син әйт аларга:

—Әлбәттә *(тереләчәксез)*. Тереләчәксез дә, хурлыкка да калачаксыз,—диген.

19. Шуннан соң бары тик бер каты аваз килер *(Сурга икенче тапкыр өрелер)*. Һәм аларның күзе ачылыр *(алар үзләре кылган яманлыклары өчен нинди җәза биреләчәген ап-ачык күрер)*. **(20)**

—Эшебез яман, җәза Көне килеп җитте,—диярләр. **(21)** (Шуннан бер аваз яңгырар):

—Әйе, бу сез ялганга санаган *(яхшыны—яманнан, гөнаһны—саваптан)* аеру Көнедер! **(22)** (Фәрештәләргә әйтербез):

—Бөтен кяферләрне—залимнәрне һәм аларга иш булганнарны: **(23)** Аллаһтан башкага табынган нәрсәләрне *(потлар, сыннар, илаһ урынына тотыла торган һәйкәлләрне)* бергә туплагыз да, җәһәннәмгә алып бара торган юлга чыгарыгыз. **(24)** Ләкин аларны *(Сират Күпере янында)* тоткарлагыз. Чөнки алардан сорау алыныр. **(25)**

—Сезгә ни булды? Ни өчен сез (дөньядагы кебек) бер-берегезгә ярдәм итешмисез?—дип сорарлар. **(26)** Хәер, ул Көнне алар мескен хәлдә, буйсынулы кыяфәттә булыр. **(27)** Алар (бу дәһшәтле хәлне күреп) бер-берсе янына килеп, сораштыра башлар. **(28)** *(Юлдан яздырганнар үзләрен аздыручыларга)*:

—Дөресе шул, сез бит *(дөньяда чакта)* безнең янга уң яктан *(яхшыга өндәүче булып)* килдегез,—дип әйтерләр. **(29)** *(Тегеләр исә)*:

—Юк, сез үзегез имансыз кешеләр идегез, **(30)** сезне ирексезләрлек көч бездә юк иде. Киресенчә, сез үзегез *(табигатегез белән)* азгын халык идегез; **(31)** шуңа күрә, Раббыбызның вәгъдә сүзе *(газабы)* чынлыкка ашты. Шик юк ки, без газабыбызны татыячакбыз. **(32)** Чөнки без сезне *(бозылырга теләгәнегезгә күрә)* юлдан яздырдык. Чөнки без үзебез дә юлдан язган кешеләр идек,—дип әйтерләр. **(33)** Шик юк, боларның барысы да ул Көнне уртак газапка дучар ителер. **(34)** Без гөнаһкярларның барысын да шулай итәчәкбез. **(35)**

—Аллаһтан башка *(Илаһи кодрәткә ия һәм)* Тәңре булырлык һичберкем юк. Һичбер тәңре юк,—дигәндә алар йөз чөерде һәм әйттеләр: **(36)**—Без тилергән бер шагыйрьгә *(Мөхәммәдкә)* ышанып, табынганнарыбыздан ваз кичәргә тиешмени?—диделәр.

37. Юк, ул фәкать Хакыйкать алып килгән кеше иде, *(үзеннән әүвәл килгән)* бөтен пәйгамбәрләрнең хаклыгын раслады. **(38)** Әлбәттә, сез хәтәр җәзаның түмен татырсыз. **(39)** Шунысы хактыр ки, сез кылган гөнаһларыгыз күләмендә генә җәза алачаксыз. *(Нахакка җәза биреләчәк түгел.)*

40. Ихластан иманлы булган кешеләр җәзаланмас. **(41)** Алар өчен мәгълүм җәннәт ниргъмәтләре әзерләнгән. **(42)** *(Җәннәт әһелләре)* төрле ләззәтле җиләк-җимеш ашап, нәфесләрен теләгәнчә канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә мәртәбәдә булырлар. **(43)** Нигъмәт тулы җәннәтләрдәге, **(44)** кара-каршы урнаштырылган култыксалы көрсиләргә утырып торганда, **(45)** аларның һәрберсенә тустаганнарга салынган саф чишмә суы өләшеп йөрерләр. **(46)** Ап-ак, утә күренмәле, бәллүр кеби саф эчемлекләрне татыганнар чиксез ләззәт алыр. **(47)** Аны эчкәннәрнең башы да авыртмас, алар исермәсләр дә. **(48)** Аларның янында оялчан карашлы, зур күзле хатыннар булыр. **(49)** *(Аларның йөзе Кояш нурына күрсәтмичә)* сакланган *(тәвә кошының)* йомыркасы кебек ап-ак төстә булыр. **(50)** Алар якыная төшеп, бер-берсеннән сораштырыр. **(51)** Араларыннан берәүсе сүз башлар:

—*(Фани)* дөньяда минем бер танышым бар иде. *(52) (Бер көнне бу миңа әйтә)*:

—Үлгәннән соң янадан терелүгә син дә нык ышанасыңмы?—ди. **(53)**—

Үлеп, туфрак булгач, сөяк өеменә әверелгәч, чыннан да, без терeләчәкбезме? Шуннан соң җәзаланачакбызмы?—ди. **(54)** *(Бу хикәяне сөйләгәне әңгәмәдәшенә)* әйтте:

—Син аның хәлен күреп белергә теләмисеңме?—диде.

55. Карауга ук ул *(теге инкарьчының)* тәмуг утының уртасында янганын күрде. **(56)** *(Сөйләүче мөэмин утта янучысына карап)* әйтте:

—Валлаһи, син мине дә һәлак итә яздың; **(57)** әгәр Раббымның рәхмәте булмаса, мин дә *(синең белән бергә утка)* атылганнар арасында булыр идем,—диде.

58. *(Җәннәткә кергәннәрнең берсе әйтте):*

—Без бер үлеп терелдек бит инде, чынлап та, без тагын үлмәбезме? **(59)** Тагын газапка дучар булмабызмы?—диде.

60. Шик юктыр ки, бу, чыннан да, бөек котылышның үзедер. **(61)** Гамәл кылучылар менә шушы максат өчен тырышсыннар. **(62)** Шушындый бер Сәгадәткә ирешү хәерлерәкме, әллә зәккум агачымы? *(Зәкъкум—тәмугта үсә торган, әче, агулы агач).* **(63)** Хактыр ки, Без аны *(зәкъкумны)* залим кяферләр өчен бер Ахирәт газабы буларак яраттык. **(64)** Шик юк, ул агач тәмугның төбеннән үсеп чыга. **(65)** Аның җимешләре шайтаннарның башына охшаган булыр. **(66)** Шунысы хак, алар *(гөнаһкярлар)* шушы җимешләрне ашап, карыннарын тутырачак. **(67)** Шуннан соң аларга *(сусаганнарга)* кап-кайнар эчемлек бирелер. **(68)** Сонра, аларны тагын җәһәннәмгә ташларлар. **(69)** Хакыйкатән, алар аталарының юлдан язганын күрер. **(70)** Үзләре дә аталары артыннан *(җәзага)* куып китерелер. **(71)** Чыннан да, алардан әүвәл яшәп үлгәннәрнең дә күбесе азгын юлда иде. **(72)** Шуңа да карамастан, хактыр ки, Без *(аларны яманлык кылудан тыяр өчен)* кисәтер өчен (пәйгамбәрләр) җибәрә тордык. **(73)** Карап бак, ул кисәтүләрнең нәтиҗәсе ничек булып бетте. **(74)** Ихласлыкка ирешеп, Аллаһка гыйбадәт кылганнар бу газаплардан азат.

75. Хактыр ки, Нух Безгә ялварып дога кылды да, Без аның догасын кабул әйләдек. *(Без догаларны кабул итүчеләрнең иң хәерлесе.)* **(76)** Без аның үзен һәм дә аның якыннарын хәтәр афәттән коткардык. **(77)** Аның нәселен *(Җир йөзендә)* яшәргә калдырдык. **(78)** Аннан соң килгәннәргә *(пәйгамбәрләр һәм аларның өммәтенә дә)* аның турында яхшы истәлекләр калдырдык. **(79)** Галәмнәрдәгеләрдән Нухка сәлам. **(80)** Шик юк, Без игелек кылганнарны менә шулай бүләклибез. **(81)** Дөрес, ул мөэмин бәндәләребезнең берсе иде. **(82)** Ахырда башкаларны *(иманга килмәгәннәрне)* батырдык.

83. Хактыр ки, Ибраһим да аның *(Нухның)* кавеменнән иде. **(84)** Чөнки ул Раббысына саф-пакь күңел белән килде. **(85)** Ул атасына һәм халкына әйтте:

—Сез ни-нәрсәләргә табынып ятасыз?—диде. **(86)**—*(Халыкны)* алдар өчен, сез Аллаһны инкарь итеп, үзегез ясаган тәңреләрегезгә табынасызмы? **(87)** Галәмнәрнең Раббысы хакында сез ни уйлыйсыз? **(88)** Шуннан соң ул йолдызларга бакты.

(«Ибраһимның халкы йолдызларга карап, күрәзәчелек кыла иде. Бәйрәм вакытларында алар үзләре ясап, табына торган потларга атап, ризык калдырып китәләр һәм шул ясалма илаһларыннан бәрәкәт, ярлыкау көтәләр иде. Соңра яңадан потлары янына килеп, калдырган ризыкларын үзләре ук ашап бетерәләр иде. Бәйрәмгә Ибраһимны да чакырдылар».

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

89. *(Ибраһим)* әйтте:

—Мин, чыннан да, авырып торам әле *(бәйрәмгә чыга алмам)*,—диде. **(90)** Тегеләре *(аның авыруы безгә йокмасын, дип)* аңа арка куеп, *(бәйрәмгә)* китеп барды. **(91)** Шуннан соң ул ясалма тәңреләр янына шыпырт кына килеп эндәште:

—Әй, сез! Нигә үзегезгә куелган ризыкларны ашамыйсыз? **(92)** Сезгә ни булды, сез нигә сөйләшмисез?—диде.

93. Ул уң кулы белән сыннарга орды *(җимерде).* **(94)** Барча халык йөгерешеп потлар янына килде. **(95)** *(Ибраһим)* әйтте:

—Үз кулларыгыз белән юнып ясаган нәстәләргә табынасызмы? **(96)** Гәрчә, сезнен үзегезне дә кулларыгыз белән ясаган ул нәрсәләрегезнен барысын да Аллаһ барлыкка китерде,—диде. **(97)** Әйттеләр:

—Бер бина корыгыз да, ут төртеп яндырыгыз һәм *(Ибраһимны)* ялкынга атыгыз,—диделәр. **(98)** Шулай итеп, алар мәкерле хәйлә корды. Без исә алар корган мәкерне хур иттек. *(Ибраһимны уттан коткарып калдык.)* **(99)** *(Ибраһим)* әйтте:

—Мин Раббым тарафына китәмен. Ул мина тугры юлны күрсәтер,—диде. **(100)**—Йа, Раббым, мина пакь күнелле бер угыл бирсәнә,—дип дога укыды. **(101)** Без анын бик тә итагатьле *(Исмәгыйль исемле)* углы булачагы турында куанычлы хәбәр бирдек. **(102)** Углан йомышка ярарлык булып үскәч, Ибраһим әйтте:

—Улым, мин төшемдә сине **(Аллаһка)** корбан урынына чалганымны күрдем. Син бу турыда ни уйлыйсын?—диде. Углы әйтте:

—Атакаем, сина *(Аллаһтан)* килгән әмер ничек булса, шулай кыл. Иншаэалла, минем сабыр һәм Аллаһка итагатьле икәнемне күрерсен,—диде. **(103)** Шулай итеп, алар икесе дә *(Аллаһның әмеренә)* буйсынды һәм *(Ибраһим)* углын йөзтүбән яткызды. **(104)** Без эндәштек:

—Әй, Ибраһим!—дидек. **(105)**—Син төшенә тугры калдын. Шөбһәсез ки, Без игелекле гамәлдә булганнарны бүләклибез,—дидек. **(106)** Хактыр ки, бу каты бер сынау иде.

107. Без аңа олуг бер корбанлык *(тәкә)* җибәрдек. **(108)** Аннан сон килгәннәргә Без анын турында яхшы истәлекләр калдырдык. **(109)** *(Бездән)* Ибраһимга сәлам. **(110)** Без игелек кылганнарны әнә шулай бүләклибез. **(111)** Ул, чыннан да, Безнең мөэмин бәндәләребездән иде. **(112)** Без анын Исхак исемле углынын дөньяга киләчәге һәм анын изге кеше, пәйгамбәр булачагы турында сөенечле хәбәр бирдек. **(113)** Һәм анын үзенә дә, һәм Исхакка да муллык, үрчем-бәрәкәт бирдек. Ләкин һәр икесенен нәселендә игелек кылганнары да, үзләренә турыдан-туры яманлык кылганнары да *(кяферләр дә)* бар иде.

114. Хактыр ки, Без Мусага да, Һарунга да нигъмәтләр *(пәйгамбәрлек, дини дәрәҗә һәм дөнья малы)* бирдек. **(115)** Аларны вә кавемнәрен хәтәр бәлаләрдән *(суга батып үлүдән)* коткардык. **(116)** Аларга ярдәм иттек һәм алар җинеп чыкты. **(117)** Һәр икесенә дә *(дөреслекне)* ап-ачык итеп аңлата торган бер Китап *(Тәүратны)* бирдек. **(118)** Һәр икесен дә тугры юлга күндердек. **(119)** Алардан сон килгәннәргә *(яхшы)* хатирәләр калдырдык. **(120)** Мусага да, Һарунга да Бездән сәлам *(аларга иминлек)* булсын. **(121)** Дөресе шул, игелек кылганнарны Без әнә шулай бүләклибез. **(122)** Шик юк, икесе дә мөэмин бәндәләремнәндер.

123. Шөбһәсез, Ильяс та пәйгамбәр булды. (124) (Ильяс) халкына әйтте:

—Сез Аллаһтан *(гөнаһ кылудан, җәза алудан)* курыкмыйсызмы?—диде. **(125, 126)**—Юктан бар итүчеләрнен иң игелеклесе булган, сезнен дә Раббыгыз булган, сездән әүвәл килгән ата-бабаларыгызнын да Раббысы булган Аллаһны инкарь итеп, Ба-алга табынасызмы?

(«Ба-ал—Шамда Бәк исемле шәһәрдә яшәүче халыкның табына торган алтын сыны—пот. Бу шәһәр бүген «Ба-албәк» дип йөртелә».

Хәсән Чантай тәфсиреннән.

«Ба-ал—ул Кояш алласы, Тәңреләштерелгән Кояш».

Мөхәммәд Али тәфсиреннән.)

127, 128. Ләкин алар аны *(Ильясны)* ялганчыга чыгарды. Шуна күрә, Аллаһнын ихлас колларыннан башка, аларнын һәрберсе *(җәһәннәмгә)* китереләчәк. **(129, 130)** Аннан сон килгән халыклар арасында анын турында яхшы истәлек калдырдык:

—Ильяска Бездән сәлам!—дидек. **(131)** Хак, игелек кылганнарны Без

әнә шулай бүләклибез. **(132)** Чөнки ул безнең иманлы бәндәләребездән иде.

133. Лут та, һичшиксез, пәйгамбәр иде. **(134)** Исегездәме, ничек итеп Без аның үзен һәм нәселен коткарып калдык? **(135)** Артта калганнар арасындагы карчыктан *(Лутның хатыныннан)* башка. **(136)** Калганнарның барысын да һәлак иттек. **(137, 138)** Әлбәттә, сез иртә-кич аларның *(хәрабәләре)* янында үтеп-сүтеп йөрисез. Әле һаман акылга килмисезмени? *(Суриядәге кәрван юлы өстендә һәлак ителгән ул шәһәрләрнең хәрабәләре бар.)*

139. Хактыр ки, Юныс та күндерелгән пәйгамбәребез иде. **(140)** Ул шыгрым тулы *(йөк төялгән)* көймәгә утырып *(җәзадан)* качып китәргә теләде. *(Диңгезгә чыккач, көймә кинәт туктый. Көймәчеләр: көймәбездә качып киткән бер кол бар икән; аны табып, шобага салыйк та, диңгезгә атыйк. Шуннан соң гына көймәбез юлын дәвам итәчәк, диделәр.)* **(141)** Көймәдәгеләр арасында аны шобага тоттылар һәм дингезгә ташладылар. Ул юкка чыкты. **(142)** *(Көймәгә рөхсәтсез менеп, җәзадан качарга маташканына ул бик үкенде)* шул вакыт аны бер балык йотты. **(143, 144)** Әгәр дә ул үкенеп *(тәүбә итеп)*, Аллаһка тәсбих әйтмәгән булса, Кыямәт көненә чаклы балык карынында калган булыр иде. **(145)** Без аны хәлсез рәвештә коры җиргә чыгарып ташладык. **(146)** Өстенә *(күләгәсе төшәрлек итеп)* киң яфраклы агач үстердек. **(147)** Аны йөз меннән артык кешегә пәйгамбәр итеп күндердек. **(148)** Соңыннан ул кешеләр иман китерде. Шулай итеп, Без аларны беркадәр вакыт дәвамында яшәттек.

149. *(Потпәрәстләрдән, кяферләрдән)* сора:

—Аллаһта кызлар гына, аларда гел угыллар гына булып чыгамыни инде?—диген. **(150)** Әллә соң Без фәрештәләрне алар карап торганда хатын-кыз буларак яралттыкмы? **(151, 152)** Дикъкать ит, алар катгыян ялган сөйли:

—Аллаһ бала атасы булды,—дип. Шик юктыр, алар ялганчы. **(153)** Угылларга караганда Аллаһ кыз балаларны хуп күргәнме әллә? **(154)** Сезгә ни булды? Сез бу турыда ни уйлыйсыз? **(155)** Һич тә башыгызга барып җитмиме шул? **(156)** Әллә соң сезнең кулда ачык дәлилләр бармы? **(157)** Әгәр *(дәлилегез)* булса, китабыгызны китерегез.

158. Аллаһ белән җеннәр арасында кардәшлек бар, дип әйтәләр. Хактыр ки, хисап тотар өчен җеннәр дә *(Аллаһ каршысына)* китереләчәкләрен бик яхшы белеп торалар. **(159)** Аллаһ алар уйлап чыгарганнардан бөек, пакь. **(160)** Аллаһның ихласлыкка ирешкән *(мөэмин)* бәндәләре алар кебек түгел *(газапка тартылмаслар)*. **(161, 162, 163)** Сез үзегез дә, сез табынган нәрсәләр дә—һичберегез җәһәннәмгә керәчәк кешеләрдән башкаларны аздырып, Аллаһка каршы котырта алмассыз. **(164, 165, 166)** *(Фәрештәләр)* әйтә:

—Һәрберебез өчен билгеләнгән урыныбыз бар. Шик юк, без анда саф-саф торабыз *(намаз укыйбыз)*. Хактыр, без Аллаһка тәсбих әйтәбез. **(167, 168, 169)** Дөресе шул, мөшрикләр, потпәрәстләр әйтә:

—Әгәр дә бездән элек яшәгәннәргә бирелгән кебек, безгә дә Китап бирелгән булса, һичшиксез, без Аллаһның ихлас коллары булыр идек,—ди. **(170)** Менә, *(Коръән килде, ләкин алар)* аны инкарь итте. Әмма алга таба *(көферлекләренең газабын)* беләчәкләр. **(171)** Чыннан да, бәндәләребезгә ярдәм итәчәкбез, дип сүз биргән идек. **(172)**

—Алар җиңү казаначак,—дидек. **(173)**—Безнең гаскәребез, һичшиксез, өстен чыгачак,—дидек. **(174)** Шуна күрә, син *(ий, Мөхәммәд)* унай форсат чыкканга чаклы алардан читләш,—дидек. **(175)**—Син аларны күзәт. Алар да тиздән күрәчәк. **(176)** Чыннан да, алар җәзабызны һичкичекмәстән татырга телимени? **(177)** Газабыбыз аларның йортына килеп төшсә, кисәтеп тә игә килмәгәннәрнең таңы нинди яман таң булыр. **(178)** Хәзергә син аларга якын барма. **(179)** Аларның хәлен күзәтеп тор. Алар да тәкъдирләрендәге күрәчәк. **(180)** Бөтен кимчелекләрдән азат булган, гыйззәткә, кодрәткә ия Раббың алар уйлап чыгарган гайбәтләрдән өстен.

181. Күндерелгән пәйгамбәрләрнең барысына да *(Аллаһтан)* иминлек булсын. **(182)** Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһка дан булсын!

Үткен мәсьәлә

ТОТАЛИТАРИЗМ ШӘҮЛӘСЕ

Егерменче гасыр башында мәшһүребез Габдулла Тукай "Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр" дип язган иде. Һәм менә тагын йөз елдан соң Русиянең кара көчләре татар халкын тагын бер кат тәклиф иттеләр, ягъни көчләделәр, үзе теләмәгәнне эшләргә мәҗбүр иттеләр. Русия Дәүләт Думасының һәм бераз соңрак Федерация Советының Русия халыклары телләре турындагы законга өстәмә кертүен башкача бәяләп булмый. Шунысы игътибарга лаек, монархчы "латин керсә ярый, кермәсә ярый" дибрәк йөргән кайбер кемсәләр дә латинчылар ягына басты. Моны редакциягә килгән байтак хатлар һәм үзара аралашканда кылынган мөсәхәбәләр бик ачык күрсәтә. Рәсәй хакимиятенең бу гамәленнән егерменче гасырда үзенең канлы азау тешләрен күрсәткән, күрсәтү генәме, канлы тешләрен халыклар бугазына батырган дәһшәтле тоталитаризм исе килә. «Коммунистлар партиясе манифесты»нда язылганча, "Европада шәүлә йөри, коммунизм шәүләсе" дигәндәй, Русия өстендә тоталитаризмның килбәтсез шәүләсе торган саен ачыграк тоемланмыймы?! Күз алдына хәтердә мәңгелеккә уелган шомлы еллар килә, күңелдә шик дигән җирәнгеч хис баш калкыта. Бүген кайсы халыкка нинди хәреф белән язарга кирәклеген өйрәтеп утырган түрәләр иртәгә синең кайда һәм ничек яшәргә, нәрсә укырга тиешлегеңне, нәрсә хакында сөйләшергә яраганлыгын, нәрсәләрнең ярамаганлыгын да билгеле бер закон кысалары арасына кертеп утыртмасларммы?! Матбугат чаралары турындагы законның Дума коридорларында кат-кат әйләнүе, утырышларда чәйнәлүе дә күңелгә өмет, яктылык өсти торган гамәл түгел.

Закон һәм хокук, юриспруденциянең чытырманлыклары ай-һай катлаулы, аңлап бетерерлек кенә түгел. Хәер, юстиция дигән сүз татарчага турыдан-туры тәрҗемә иткәндә "гаделлек" дигән төшенчәне аңлата. Хокук һәм закон һәркайда һәм һәркемгә карата гадел булырга тиеш дигән мәгънә салган ана борынгы римлеләр. Егерменче, утызынчы елларда, мәсәлән, Татарстан АССРның юстиция министрлыгы үзебезчә "Гаделия министрлыгы" дип атала иде. Ләкин... Нишлисең, Русиядә татар халкына карата гаделлек булмады һәм була да алмый торгандыр инде ул. Инде хәзер үзебез теләгән хәрефләр белән язарга да хокукыбыз калмадымыни?! Юриспруденциядә "закон не имеет обратной силы" дигән, ягъни, бүген кабул ителгән закон кайчандыр кылынган гамәлләргә карата кулланылмый дигән, аксиомага тиң тәгъбир дә бар. Гадирәк, аңлаешлырак итеп әйткәндә, ягъни мәсәлән, поезд инде киткән. Шулай булгач, Татарстан Президенты тарафыннан әле 1999 елның 15 сентябрендә үк кул куелган "Латин алфавиты нигезендә татар алфавитын торгызу турында"гы закон бүген кемнәрдер тарафыннан үзгәртелә дә, юкка чыгарыла да алмый. Чөнки инде ул үзенең эшен эшләгән. Дистә меңнәрчә балалар латин имласында уку-язу күнекмәләрен үзләштерде, яңа латин имласында дистәләрчә исемдә яңа китаплар басылып чыкты, "Әлифба" һәм уку ярдәмлекләре, дәреслекләр дөнья күрде. Ул гына да түгел, татар укучылары латин имласының телебезгә никадәр якын икәнлеген, аңа ябышып торганлыгын күрделәр. Бу имлада урыс хәрефләре белән

язылганча укыганда килеп чыга торган *сәгать, канәгать, Рифгать* кебек, урыс теленең "что делать" соравына җавап булып яңгыраучы мәгънәсезлекләр, урыс мохитендә яшәүче шәһәр балаларының башын катырган *авыл, тавык, матавык* кебек аңлаешсызлыклар бетте, барысы да үз урынына утырды. Телебездән утызынчы елларда сөрелгән *Q, Ğ, W* авазларын белдерүче хәрефләр әйләнеп кайтты, машинка яисә компьютерның татарча клавиатурасында кирәксез урын алып торган Ь, Ъ, Ц, Щ, Я, Ю, Ё, Э хәрефләре белән дә җиңел генә хушлаштык. Шулай итеп, ниһаять, телебезнең барлык үзенчәлекләренә, фонетик төзелешенә җавап бирүче, бар яктан камил алфавит булдыруга ирештек. Хәрефләр саны шактый кимеп, нибарысы 33 кә калды.

Ирексездән бер усал анекдот искә төште әле.

"Ни хикмәт беләндер, ком чүлендә америкaн, урыс һәм француз очрашканнар. Су чыкмасмы дип казынганда комнан балчык чүлмәк табып алганнар болар. Чүлмәктән ажгырып җен килеп чыккан. Әйткән:

—Коткарганыгыз өчен һәрберегезнең берәр теләген үтим. Теләгез,— дигән.

Француз теләген әйткән:

—Хәзер үк миңа шушында өч йөз бүлмәле, өч катлы вилла булсын, һәр бүлмәдә миңе бер чибәр көтеп утырсын!

Күз ачып йомганчы алларында яшеллеккә чумган вилла пәйда булган.

Америкaн исә туган шәһәренә хәтле асфальт юл һәм алты йөзенче "мерседес" сораган.

Чират урыска житкән. Башын кашып торган-торган да ди бу, әйткән:

—Шиш!—дигән.—Алар гына рәхәтләнмәсен әле. Вилласы да, "мерседес"ы да кирәкми, алдыбызда бер яшнек аракы булсын!

Күз ачып йомганчы вилла да, «мерседес» та юкка чыккан. Күктән дөмбердәп бер әрҗә аракы килеп төшкән, ди".

Менә, нишләптер, Русия Думасының тел мәсьәләсендәге бу гамәле шушы анекдот героен хәтерләтте дә куйды. Татарга гына әйбәт булмасын әле, дип, юри, үчләшеп кабул ителгән законга охшый ул.

Камил гакыл кысаларына сыймаган әлеге закон хәтта чит ил белгечләрендә дә гаҗәпсенү уятты. Татарстан Дәүләт Советы РФ Президенты В. В. Путинга мөрәҗәгать кабул итте. "Бу законны кабул итү РФ субъектлары карамагындагы мәсьәләләргә тыкшыну булып тора һәм Русия тарафыннан танылган халыкара хокукый актларга туры килми",— диелә анда.

Әмма ничек кенә булмасын, латин имласының уңайлыкларын татып өлгергән укучыларыбыз бездән латин хәрефләре белән язмалар урнаштыруны дәвам итүебезне сорап мөрәҗәгать итә торалар.

Укучылар сүзе безнең өчен канун. "Казан утлары" журналы киләчәктә дә латин имласында классик мирасыбыз үрнәкләрен һәм бүгенге язучыларның әсәрләрен бирүне дәвам иттерәчәк. Тукайча әйткәндә: "Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе ру сияһ![1]"

Флүс ЛАТЫЙФИ,
баш редактор урынбасары.

---

[1]Ру сияһ—кара йөз *(фарсыча).*

Yumor-satira

Ləbib Leron

Mədərris Əğləmgə

(Şağirnen Aqqoş külendə yəşəp icat itüenə işarə)

Qarağız sez Mədərriskə!
Küregez sez Əğləmne:
Aqqoş küle reyxstagına
Elgən şiğri ələmne!

Xatip Minneğulovqa

(Borıńğı şağirebez Səif Sarainıń icatın tiränten əyrənüenə ışarə)

İ Sarai...
Sində—şağir,
Sində ğalim xərlege:
Xatip Minneğullı itten
Yazuçılar berlegen...

Zəlfətkə

(Şağirnen sońğı waqıtta matbuğatta şiğerlərə küpləp basıluına işarə)

Berəzleksez şiğer yazıp,
Kitməsen, dim, əzlegep...
Əy, tənqıitçe! Totçı Anıń...
Qanatlı at tezgenen!

Waxit İmamovqa

(Tarixi əsərləren uqıp tə'sirləngəç)

Tarix həm Waqıt turında
Uylanğan çaqta gelən,
Sez niçek uylıysız—belmim...
Min şunı yaxşuq beləm:
Waxitlar tabılmıydır
Yaqut belən.

Məğsum Xucinğa

(«Tatar xikəyələre antologiəse»
çığuı uņayınnan)

Ezləp... Tabıp... Uqıp... Saylap...
Şərexləp iələren,
Kitap itterep çığardın
Tatar xikəyələren.

Antologiəgə küplər
Şundıy «bəha» birdelər:
—Nik minem xikəyə yuq?—dip,
Teņkəyenə tidelər...

Fakil Safinğa

(«Sataşıp atqan taņ» romanı həm «Məydan»
jurnalının soņğı sannarın uqığaç)

Qazanda—İrek məydanı.
Çallıda—Fakil «Məydan»ı:
Sataşıp taņnar atmasa,
Taralır əle danı.

Şamil Mannapqa

(Yazuçı-şağirlər turında məzəklər
tuplap bastıruına işarə)

Yazuçılar arasında
Yəri əybət ğəybətlər.
Şundıy əybət ğəybətlərne
Terkisen sin həybətləp.
—Əllə qayan kürenep tora:
Bu—Şaman eşe!—dilər,—
Şiğer yazuın belmibez,
Nu, haman eşli!—dilər...

Rədif Səğdigə

(Soņğı waqıtta jurnallarda basılğan,
səxnədə uynalğan əsərləren küzdə totıp)

Povest'-p'yesalar yazdı da
Romanğa kitte kerep...
Şiğergə genə totına
Kürməsen inde berük!

Uqucı süze
Укучы сүзе

“Казан утлары” журналының узган елгы 8,9 саннарында И. Таһиров, Ф. Гарипова, А. Хәлим мәкаләләре басылып чыккан иде. Халык санын алуга әзерлек унаеннан дөнья күргән бу язмалар кызыклы, бай мәгълүматлы иде. А. Хәлимнеке бигрәк тә эмоциональ көче белән аерылып тора. Бу хәлләр аның йөрәгә аша үткәне күренеп тора.

Шул мәкаләләр унаеннан минем бер сорау бирәсем килә: кем ул “Казан утлары”н алдыручы? Аны татар булырга үгетләргә кирәкме? Минемчә юктыр кебек Хәер, мәсьәлә, беренче карашка гына бик гади күренә. Чынлыкта исә ул катлаулы, үтә катлаулы.

Мин үзем, мәсәлән, тумышым белән Илеш татары. Әткәй мәрхүм “без припущенный башкортлар” ди торган иде. Сонрак, кызыксына торгач белдем: “припущенниклар” башкорт җирләрен озак вакытка арендага алган татар һәм башка милләт кешеләре булган икән. Бабаларыбыз Татарстанның Салагыш якларыннан икән дигән истәлекләр дә бар. Аннан килгән өч гаилә авылның типтәр ягына (Көрпә елгасының ун ягы) нигез салган, сул якта башкортлар. Патша заманында “башкорт” дип язылганнар билгеле бер ташламалар һәм өстенлекләрдән файдаланган. Совет чорында исә алар бетерелде. Бер үк тел, бер үк мәктәп, бер мәчет, бер кибет, бер колхоз. Укыту татарча, китаплар Казаннан кайта. Авыл халкы кол. Паспорты юк. Авыл советы китабына секретарь малай нәрсә яза, шул закон. Безнең гаиләдә, мәсәлән, бер ата-анадан алты бала. Шуларның өчесе татар, калган өчесе башкорт дип язылган. М. Шакиров заманына кадәр бу беркемгә дә берниндн дә зыян китермәде. Аның заманында җиде ел балалар “сакауланып” алды, аннан соң барысы да үз урынына кайтты. Хәзер исә бу мәсьәлә тагын калкып чыккан. Баштарак А. Хәлим язганнарга ышанасым килмәгән иде. Үз башыма төшкәч белдем. Минем кече энем Үзбәкстаннан кайтмакчы иде Уфага. Урнаша алмады, чөнки татар. Кызганычка каршы, татарга каршылык югары эшелонда гына түгел, ул хакимиятнең барлык баскычларына диярлек үтеп кергән.

Башкортлаштыру—татарларга каршы тискәре караш—соңгы еллар күренеше генә түгел. Бу соңгы гасырлар буена татарның урыс кулында корал булып йөргәне өчен Алланың җәзасыдыр (каһәре) дип тә уйлап куям. Менә хәзер башкортлар Мәскәү кулында уенчык, алар кулы белән Мәскәү татарны талата, ботарларга тырыша. Бу каһәр аларга да төшмәсме?!

Татарстанның байлыгы Башкортстанныкыннан ким түгел. Милли сәясәткә башкортлар акча-көч җәлләми. Мәсәлән, безнең якларда башкорт журналына язылу ике-өч мәртәбәгә арзанрак. Бусы сүз унаеннан гына.

Татарның Мәккәсендә—Казанда булганым юк. Ишеткәнемчә, анда да татар теле бик үк почетта түгел икән. Уфада исә үз телендә чегән яки кавказлылар гына сөйләшә. Бүтәннәр ватып-җимереп булса да “урысча” гына җиффәрәләр. Хәзер эш татарның санында гына да түгел. Сүз татарның калуы яисә бетүе турында бара. Латин алфавиты белән дә суздыгыз да суздыгыз. Җәһәтрәк эшлисе иде. Бүген татарның менталитеты—төшенкелек, үз көченә ышанмау. Ә тарих безгә шанс биргән иде. Файдаланып кала алмадык. Андый мөмкинлек тиз генә кабатланмастыр. Үзебезнең тар карашлы дин әһелләре Русия исламын бүлгәләп, һәрберсенә үз мөфтиятләре төзеп, үзләрен көлкегә калдырып йөргән арада Русия мәгариф министры мәктәпләрдә “православие культурасы” дәресләре кертү турында кәгазь җибәргән. Менә хәтта урыслар үзләре дә каршы чыкмакчы. Шикләнмим, моны беренче булып татар чиновниклары эшкә ашыра башламагайлары. Чөнки ни Казан, ни Уфа тарафларыннан ник бер протест ишетелсен?!

Ирексездән Г. Тукай шигыре искә төште:

> Безнең Гали бигрәк тату Кәҗә белән,
> Менә Кәҗә карап тора тәрәзәдән.
> Гали аны чирәм белән кунак итә,
> Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә.

Бу шигырьнең азагы юк бит. Вакытлар узгач Гали үзенең “дустын”—кәҗәне суеп ашаячак. Бу кәҗә татарга, йә булмаса бүгенге башкортка охшамаганмыни?! Гали дус чакта бу “дуслык”ка ләббәйкә дип торыйк микәнни? Менә шундый сәер уйлар килде әле башка.

Эшегездә уңышлар, барчагызга саулык-сәламәтлекләр телим.

Н. НОГМАНОВ,
Ярославль шәһәре

2003 ЕЛДА «КАЗАН УТЛАРЫ»

Кайда яшәүләренә карамастан, барлык татар язучыларының иҗатын пропагандалауны, төрле кыйтгаларга сибелгән халкыбызның милли рухын, әдәби-эстетик зәвыгын тәрбияләүне төп максаты санаган "Казан утлары" журналы 2003 елда да кыйбласына тугры кала.

Рухи тормышыбызның төп тармакларын эченә алган, безнең өчен 2003 елда да мөсләк саналачак кайбер нигез-принципларны, юнәлеш-рубрикаларны исегезгә төшерәбез:

—мең еллык чал тарихлы татар әдәбиятының күркәм традицияләрен дәвам иттереп, хәзерге заман язучыларының иң яхшы әсәрләрен, әдәби мирасыбызның гыйбрәтле сәхифәләрен бастырып чыгару;

—дәүләт теле буларак татар телен киң кулланышка кертү;

—Татарстанның дөньядагы роле, икътисады, социаль хәләте турында язмалар, Россиядәге һәм чит илләрдәге татар хәяты белән укучыларны даими таныштыру;

—театр, музыка, сынлы сәнгать казанышларын яктырту; сәнгать өлкәсендәге олуг шәхесләрнең иҗатлары турында язмалар урнаштыру;

—халкыбызның әхлагын, гореф-гадәтләрен саклау юнәлешендә максатчан эш алып бару;

—дөнья әдәбияты классикасының иң яхшы үрнәкләре белән таныштыру;

—яшь язучыларның иҗат үрнәкләрен дөньяга чыгару; чит төбәкләрдә туган телебездә иҗат итүче талант ияләренә аерым игътибар итү.

Әлбәттә, монда журнал эшчәнлегенең барлык тармакларын да тәфсилләп күрсәтеп бетерү мөмкин түгел. Боларга өстәп, шунысын әйтү дә җитәр, журнал әдәби процессны барлау, үсеш тенденцияләрен ачыклау, әтрафлы тәнкыйть мәкаләләре бастыру, яңа китапларга рецензияләр һәм күзәтүләр оештыру, күренекле әдипләрнең юбилейларын, гомумән, татар дөньясындагы атаклы шәхесләрнең истәлекле даталарын билгеләп үтү, иҗтимагый-мәдәни тормыш вакыйгаларын объектив һәм оператив яктырту кебек эшчәнлеген дә элекке рәвештә дәвам иттерәчәк.

Редакция папкасында киң катлам укучыларыбызны кызыксындырырлык романнар, повестьлар, хикәяләр байтак. Аерым алганда, Сезне 2003 елда прозаиклар **Факил Сафин** ("Саташып аткан таң", III кисәк), **Камил Кәримов** ("Сакау күке"), **Рафаэль Сибат** ("Инабәт") романнары, **Әсгать Сәлах** ("Каеннар юлы"), **Рәшит Ибраһимов** ("Җир белән күк арасы") **Халисә Мөдәррисова** ("Яр") повестьлары белән очрашулар көтә. Мөслимдә яшәп язучы яңа авторыбыз **Роза Хәбибуллина**ның "Яшьлегем серләре" дигән повесте да күпләр өчен кызыклы яңалык булыр дип өметләнәбез. **Фоат Садриев, Галимҗан Гыйльманов, Барлас Камалов, Заһид Мәхмүди** һәм башка прозаиклар да ел дәвамында редакциягә яңа әсәрләрен китерергә вәгъдә итәләр.

Шигърият сөючеләргә **Г. Афзал, И. Юзеев, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Ә. Баян, Р. Харис, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Гаташ, Р. Мингалим, Г. Рәхим, Зөлфәт, М. Әгъләм, Л. Шагыйрьҗан, З. Мансуров, Р. Низамиев, Г. Морат** һ. б.ның яңа поэмалары һәм шигырьләре тәкъдим ителәчәк.

Публицистика, фән һәм сәнгать рубрикаларында укучыларыбызны татар тормышы һәм бүгенге вәзгыять хакындагы язмалар, Казанның мең еллыгын каршылау уңаеннан әзерләнгән сәхифәләр, туган

телебезнең бүгенге халәте һәм язмышы хакындагы уйланулар, мәдәният һәм әдәбият өлкәсендәге эзләнүләр, хәзерге заман әдәбияты торышына кагылышлы мәкаләләр көтә. Авторларыбыз арасында күренекле язучылар, галимнәр, сәнгать эшлеклеләре **И. Таһиров, Ә. Борһанов, Р. Фәхретдинов, М. Зарипов, М. Рафиков, Ш. Монасыйпов, Л. Гайнанова, Н. Сафина, А. Кәримова, Г. Арсланов, Р. Шаһиева** һәм башкалар бар.

Ел саен журнал битләрендә шагыйрьләр һәм прозаиклардан тыш өч йөздән артык автор: әдәби тәнкыйтьчеләр, публицистлар, тарихчылар, сәнгать белгечләре, икътисадчылар һәм сәнгатьчеләр катнаша, укучыларның хатлары басылып чыга. Быел журнал укучылардан килгән хатларга игътибарны тагын да көчәйтергә җыенабыз. Россиянең төрле төбәкләрендә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең хатлары ул якларда көн күрүче кан-кардәшләребезнең нинди уй-фикерләр белән яшәвен ачык күзалларга ярдәм итәр.

Казанның 1000 еллыгына әзерлектә башкалабыз исемен йөртүче журналның үз урыны бар. Фәнни-публицистик эшчәнлегендә юбилейга әзерләнү һәм борынгы шәһәргә нигез салынуның тарихи аспектлары, аның бүгенгесе һәм киләчәге киң яктыртылачак. Аларны әзерләүгә РФ һәм ТР Фәннәр Академияләренең күренекле галимнәре–тарихчылары һәм тюркологлар, күренекле язучылар һәм сәнгать белгечләре җәлеп ителә, шулай ук республикабыз һәм Казан шәһәре хакимияте җитәкчеләре белән күләмле әңгәмәләр үткәрү күздә тотыла. Менә бу юнәлештәге кайбер рубрикалар:

Архивлар ни сөйли?—Мәскәү, Казан, Санкт-Петербург, башка шәһәрләрнең архивларында Казан тарихына кагылышлы документлар, язучылар һәм галимнәрнең шәхси архивларындагы язмалар һәм мәгълүматлар.

Дәверләр алышынганда.—Гомумяшәеш, халык язмышы, милли әдәбият-сәнгатьнең үткәне һәм киләчәге турында анализлы мәкаләләр сериясе.

Казан Кремле нинди төс алыр?—Казан Кремлен реконструкцияләүнең барышы, перспективалары, проблемалары.

Халык буларак татар кайчан оешкан?—Моңарчы тупланган тарихи, археологик һәм чиктәш фәнни мәгълүматларга нигезләнгән аналитик язмалар.

Кыскасы, редакция хезмәткәрләре журналны кызыклы һәм бай эчтәлекле, тирән һәм хак-дөрес мәгълүматлы итеп чыгару өчен бөтен көчләрен куячаклар.

Кадерле укучыларыбыз! Бар дөньясын, яшәешебезне малтабарлык һәм корсак мәнфәгатьләре белән яшәү шаукымы баскан ыгы-зыгылы, матавыклы бу заманда татарның асыл журналы "Казан утлары"на язылгансыз икән, димәк сез халкыбыз язмышына, әдәбиятыбыз һәм мәдәниятебез киләчәгенә битараф түгел. Киләчәктә дә бергә булыйк. Бергәләп XXI гасырның өлегә авыр һәм болгавырлы чорларын узыйк, бергәләп рухи дөньябызны баетыйк, яшәвебезгә ямь өстик, татарны дөнья халыклары арасында лаеклы урынга күтәрү өчен иңгә-иң торып бергәләп көрәшик, телебезне саклыйк һәм үстерик. Бу юлда безгә Алла куәт бирсен!

«Казан утлары» архивыннан

Язучыларның иҗат һәм ял йортлары урнашкан «Аккош күле»ндә 60 нчы елларда яшәгән язучылардан бер төркем. Сулдан уңга: Фатих Хөсни, Риза Ишморат, Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Нәби Дәүли һәм Зәки Нури (улы белән).

Замандашлар, фронтовиклар: шагыйрь Нури Арсланов, язучы Ибраһим Гази. 1969 ел.

Татарстанның мәшһүр зыялы шәхесләре. Сулдан уңга: табиб профессор Әбүбәкер Терегулов, химик академик Александр Арбузов, язучы Кави Нәҗми. 1951 ел.

Замандаш-якташ шагыйрьләр:
Әхмәт Гадел һәм
Кадыйр Сибгатуллин.
1977 ел.

Атаклы шагыйрь
Михаил Львов
(Габитов Рифкат Дәүләтша
улы) Тукай һәйкәле янында
уздырылган шигъри митингта
чыгыш ясый.
Янәшәсендә Фарсель
Зыятдинов (хәзерге көндә
галим һәм язучы) чыгышны
магнитофонга яздыра.
60 еллар ахыры.

Аталы-уллы Хәкимовлар:
шагыйрь Сибгат Хәким,
сәясәтче Рафаэль Хәкимов.
80 еллар башы.

ПРЕЗИДЕНТКА МӨРӘҖӘГАТЬ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының ноябрь ахырында узган пленар сессиясендә депутатлар «Россия Федерациясе халыкларының телләре турында»гы Россия Федерациясе законының 3 нче маддәсенә өстәмә кертү хакында» федераль законны Дәүләт Думасының кабул итүенә һәм Федерация Советының хуплавына бәйле рәвештә Владимир Путинга мөрәҗәгать җибәрү турында карар кабул иттеләр.

«Әлеге законның асылы Россия Федерациясендә кириллица нигезендәге алфавиттан файдалануга кайтып кала,—диелә проектта.—Без Россия Федерациясе Конституциясенең 73 нче маддәсе нигезендә Россия Федерациясе республикаларының төп халыкларының үз Конституцияләрендә дәүләт телләре буларак билгеләнгән туган телләре турындагы мәсьәләләр һәм аларның алфавитлары фәкать Россия Федерациясе республикалары карамагындагы мәсьәләләр булып тора дип саныйбыз. Әлеге федераль закон Россия тарафыннан танылган БМОның Гражданлык һәм сәяси хокуклар турындагы халыкара пакты, «Төбәк телләре һәм азчылыкларның телләре турындагы Европа хартиясе», Европа Советы әгъзалары булган дәүләтләрнең «Милли азчылыкларны яклау турындагы кысалы конвенция» кебек халыкара хокукый актлар белән ярашмый», диелә мөрәҗәгатьтә.

КОМИССИЯ ЯҢАРТЫЛДЫ

Премьер-министр Михаил Касьянов боерыгы белән Россия хөкүмәте Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек комиссиясе составына үзгәрешләр кертте. РМК-Новостис агентлыгы хәбәр иткәнчә, комиссия составына Россия Фәннәр академиясенең иҗтимагый фәннәр буенча фәнни-мәгълүмат институты кинәшчесе В. Виноградов, Президентның Идел буе Федераль округында вәкаләтле вәкиле урынбасары Л. Гильченко, Эчке эшләр министры Б. Грызлов, банк рәисе С. Игнатьев, Президент каршындагы баш территориаль идарә житәкчесе А. Попов, төзелеш һәм торак-коммуналь комплексы буенча дәүләт комитеты рәисе Н. Кошман, финанс савыктыру һәм банкротлык буенча федераль хезмәт житәкчесе Т. Трефилова, спорт буенча дәүләт комитеты рәисе В. Фетисов кертелде. А. Блохин, В. Геращенко, П. Рожков, Г. Таль, А. Шамузафаровны комиссия составыннан чыгарырга карар ителде.

РӘССАМНАР БЕРЛЕГЕ СЪЕЗДЫ

Ел ахырында Казанда Рәссамнар берлегенең XII съезды узды. ТР Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева Татарстан Республикасы Президенты, ТР хөкүмәте һәм Дәүләт Советы исеменнән съездда катнашучыларны котлады. З. Вәлиева билгеләп үткәнчә, Рәссамнар берлеге каршында чишелергә тиешле мәсьәләләр шактый. Проблемаларны Берлек идарәсенә генә аудармыйча, бергәләп, һәр рәссам катнашы белән хәл итү вакыты килде.

Съездда Татарстан рәсем сәнгатенең бай мирасын тарату мәсьәләсе турында фикер алышынды. Казанда югары сәнгать уку йорты, заманча сәнгать музее ачу турында да әйтелде. «Казан» милли мәдәният үзәге каршындагы милли сәнгать музеена матди ярдәм кирәк. Съезд аренда түләвенә, рәссамнарның иҗат остаханәләренә коммуналь түләүләргә ташламалар карау үтенече белән республика хөкүмәтенә мөрәҗәгать итте.

ТР Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе итеп янәдән Абрек Абзгильдин сайланды.

ИСЕМНӘРЕ ҮЗГӘРӘ

Ноябрь ахырында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетын тәкъдир итү тантанасы булды. Анда Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев бу яна университетны югары статус алуы белән котлады (ачылган елларда культура институты, соңрак академия исемен йөртте) һәм әлеге уку йортында озак еллар эшләгән бер төркем педагогларга Татарстан Республикасының Мактау Грамоталарын тапшырды.

МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР ДӨНЬЯСЫНДА

Баш архив идарәсенең конференцияләр залында «Татарстан бүләкләре» дигән күргәзмә булып узды. Анда Татарстанның 1920 елдан башлап гамәлгә кертелгән дәүләт бүләкләре—Мактау билгеләре, Мактаулы дәрәҗәләр һәм грамоталар тәкъдим ителгән иде. Күргәзмәнең үзәк өлешен милли архив фонды документлары тәшкил итә. Биредә шулай ук «Ачлыкка каршы көрәшүче» билгесе, «Татарстанның социалистик төзелеш каһарманы» дәрәҗәсе һәм республикабызның башка аз санлы мактаулы грамоталары исемнәренең асыл документлары, Татарстан архивчылары тарафыннан Казанның 1000 еллыгына багышлап нәшер ителгән китаплар бар иде.

БОРЫНГЫГА СӘЯХӘТ

Татарстанның Милли китапханәсендә Болгар чорына багышланган күргәзмә ачылды. Ул Урта Идел буенда IX-XIV гасырларда чәчәк аткан Болгар дәүләтенең тарихи һәм археологик истәлекләре белән таныштыра. Шәрык һәм Аурупа телләрендәге басма һәм кульязма китаплар чал гасырлар турында сөйли. Биредә Шиһабетдин Мәрҗани, Н. Загоскин, А. Риттих, В. Смолин, В. Казаринов, И. Березинның борынгы чорга багышланган фәнни хезмәтләре бар. Массальскийның «Идел буе» китабында Болгар ханлыгының җентекләп ясалган картасы аеруча игътибарга лаек. Экспонатлар арасында Г. Гельмольтның «Инсаният тарихы» китабында сурәтләнгән атлы болгарлар рәсеме бар. Аның оригиналы Ватиканда саклана.

АВЫЛДАШЛАРГА—КИТАПХАНӘ

Түбән Кама районының Ташлык авылында Татарстан халык депутаты, язучы Разил Вәлиев булышлыгы белән яңа китапханә ачылды. Китапханә ачу тантанасында күренекле драматург, Татарстан халык депутаты Т. Миннуллин, «Нижнекамскшин» берләшмәсе генераль директоры Р. Ильясов, мәдәният министры урынбасары И. Ибраһимов, район һәм шәһәр җитәкчеләре, республиканың район һәм шәһәр үзәк китапханәләре директорлары катнашты.

—Әгәр дә безнең яктан Рафаэль Сәхабиев, Алмаз Хәмзин, Зөлфәт Хәким кебек күренекле кешеләр чыккан дибез икән, моның өчен барыбыз да авыл китапханәсенә, мәктәпкә, мәдәният йортына бурычлыбыз. Милли рухыбызның, милли мәдәниятебез, әдәбиятебезнең, сәнгатебезнең чишмә башы авылда,—диде Дәүләт Советының фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе рәисе Разил Вәлиев яңа китапханәне ачу тантанасында.

ТӨРКИЛӘРНЕҢ ГЫЙЛЬМИ ҖЫЕНЫ

9-12 октябрьдә Әхмәд Ясәви исемендәге университетның ачылуына 10 ел тулу уңае белән (1992 елда Көньяк Казакъстанның Төркестан каласында—мәшһүр шагыйрь һәм суфый Әхмәд Ясәви ватанында халыкара казакъ-төрек университеты ачылган иде. Анда хәзер дөньяның 29 иленнән 17 мең студент белем ала, аларны бер меңнән артык укытучы, шул исәптән 97 фән докторы, профессор укыта. Әхмәд Ясәви исемендәге бу университет хәзер югары дәрәҗәле кадрлар әзерләүнең, фәннең, аеруча тюркология гыйлеменең мөһим мәркәзенә әверелеп бара. Анда ике айга бер мәртәбә казакъ, урыс, төрек телләрендә «Төркология» журналы чыга башлады.) Төркестан каласында Беренче Халыкара тюркологик конгресс үткәрелде. Мәртәбәле бу җыенның эшендә, Төркия, Казакъстан, Үзбәкстан, Кыргызыстан, Мәскәү, Каракалпак, Якутия, Хакас, Тува һәм башка илләрнең, төбәкләрнең галимнәре белән берррәттән, Татарстан вәкилләре дә катнашты. Казан университеты галимнәре Хатыйп Миңнегулов «Татарстанда Борынгы һәм Урта гасыр төрки әдәбиятын өйрәнүнең торышы», Фәһимә Хисамова «Рәсәйнең көнчыгыш дипломатиясендә татар теленең роле», Фәнүзә Нуриева «Алтын Урда чоры язма истәлекләренең телен өйрәнү тәҗрибәсе («Нәһҗел-фәрадис» мисалында)» темаларына докладлар белән чыгыш ясадылар.

ТАТАР КИТАБЫНЫҢ ЯШЕ ОЛЫ

Санкт-Петербургның «Нур-Плюс» татар милли-мәдәни җәмгыяте һәм Россия милли китапханәсе «Татар китабы» фестивале программасы буенча беренче дәресен үткәрде. Ул беренче татар китабы басылуга 280 ел тулуга багышланды. Дәресләр Россия милли китапханәсенең милли бүлегендә үтте. Татарларның XVIII—XIX гасырлардагы матбугат эшчәнлеге турында кызыклы мәгълүмат белән китапханәнең татар әдәбияте фонды хезмәткәре Вил Таһиров таныштырды.

Татар китабы тарихы 1722 елдан, Петр I нең Фарсыга походы вакытында татар телендә басылган манифестыннан башлана.

КИТАПЛАРДА БЕЗНЕҢ ЯЗМЫШЛАР

26 ноябрьдә Татарстан Язучылар берлегендә әдәби тәнкыйть һәм проза остаханәләренең (җитәкчеләре М. Вәлиев һәм М. Маликова) киңәйтелгән утырышы уздырылды. Көн тәртибенә татар китабын пропагандалау һәм тарату мәсьәләсе чыгарылган иде. Соңгы елларда үтә актуаль проблемага әверелгән бу мәсьәлә турында сөйләшүгә Татарстан китап палатасы директоры Х. Әшрәфҗанов, Татарстан китап нәшрияты һәм редакция вәкилләре, шулай ук әдипләр, тәнкыйтьчеләр килгән иде. Проблеманың үтә өлгергәнлеген һәм җитдилеген искә алып татар китабын пропагандалау һәм таратуны яхшырту чаралары турында язучыларның махсус җыелышын уздырырга карар кылынды.

«КАЗАН УТЛАРЫ» НУРЛАТТА

Ноябрь ахырында журналның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, редколлегия әгъзасы Тәлгат Галиуллин, бүлек мөхәррире Марат Закир Нурлатта булдылар. «Казан утлары» вәкилләрен район башлыгы Фатих Сибагатуллин кабул итте, журнал һәм район хезмәтчәннәре белән хезмәттәшлек турында җитди сөйләшү булды. Шул ук көнне шәһәрнең сәнгать мәктәбендә татар әдәбияты укытучылары, китапханәчеләр, җирле интеллегенция вәкилләре белән иҗади очрашу үтте. Икенче көнне Казан кунаклары Нурлатның Картлар йортында, сөт комбинатында, Кычытканлы авылында булдылар, бүгенге татар әдәбияты турында сөйләделәр, «Казан утлары» эшчәнлеге белән таныштырдылар.

МӘХӘББӘТ БӘЙРӘМЕ

18 ноябрьдә Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасында «Таһир-Зөһрә» газетасына—5, «Сәхнә» газетасына 1 ел тулу уңаеннан «Мәхәббәт бәйрәме» дип

исемләнгән әдәби-музыкаль кичә узды. Кичәдә танылган җәмәгать эшлеклеләре, әдәбият-сәнгатьнең күренекле вәкилләре катнашты. Әлеге басмаларның баш мөхәррире Зиннур Хөснияр тамашачыларны бәйрәм белән котлап чыгыш ясады. Талантлы сәнгать осталары катнашында үткәрелгән бу тамашаның режиссеры—Айдар Хафиз.

РӘСЕМНӘРДӘ ТАРИХ СУЛЫШЫ

Татарстан Рәссамнәр берлегенең Күргәзмәләр залында рәссам Фиринат Халиковның шәхси күргәзмәсе ачылды. Сәнгатькәр иҗатына 20 ел тулуга багышланган күргәзмәгә 60 картина куелган. Рәссам иҗатының төп юнәлешләре—тарихи темалар һәм портрет нәкыше. Аның болгар тарихына багышланган картиналары зур сәнгати осталык белән иҗат ителгән.

МУЗЫКА БЕРЛӘШТЕРӘ

Санкт-Петербургның Композиторлар йортында фортепиано музыкасы кичәсе булды. Анда аерым концерт белән талантлы Петербург музыканты, милләттәшебез Ринат Сәгыйть улы Шакиров чыгыш ясады. Концерт «Шүрәле» балеты авторы, күренекле татар композиторы Фәрит Яруллинның тууына 90 яшь тулуга багышланган иде.

Концертта Рөстәм Яхин, Ренат Еникеев, Рәшит Кәлимуллин әсәрләре башкарылды. Р. Шакировның «Шүрәле» балетыннан сюиталарны үз эшкәртүендә башкаруы да тамашачылар өчен зур ачыш булды. Кичәдә Казан консерваториясенең татар музыкасы кафедрасы житәкчесе, Фәрит Яруллинның бертуган энесе, талантлы композитор Мирсәет Яруллин да катнашты. Үзенең чыгышында ул Фәрит Яруллинның якты истәлеген хөрмәт иткән Санкт-Петербург тамашачысына олы рәхмәтен белдерде. Чыннан да, Петербургның Мариин театрында инде ничә дистә еллар буена «Шүрәле» балеты сәхнәдән төшмичә уйнала.

Ф. Яруллин истәлегенә багышланган бу концертны татар эшкуарлары—«Нур-Свет» газетасының баш мөхәррире Ринат Рәүф улы Мәһдиев һәм жаваплылыгы чикләнгән «Старт» җәмгыятенең президенты Сәлим Талихан улы Хәсәновның матди ярдәме белән «Русская традиция» ассоциациясе оештырды.

ДӘРДМӘНД ТУГАН ҖИРДӘ

Декабрь аенда Татарстанның халык депутаты шагыйрь Ренат Харис белән «Мәгариф» Милли нәшрияты директоры Мөдәррис Вәлиев Салават каласы хакимияте чакыруы буенча татарның мәшһүр шагыйре һәм миллионеры Дәрдмәнд истәлегенә багышланган чараларда катнашу өчен Башкортстанда булып кайттылар. Билгеле булганча, Салаваттан унике чакрым гына ераклыкта урнашкан Җиргән авылы—Дәрдмәнднең кендек каны тамган җир. Очрашулар Салават шәһәренең Мәдәният сараенда Уфадан килгән танылган артистлар, Дәрдмәнд исеме белән бәйле төбәкләрдән килгән кунаклар катнашында зур кичә белән төгәлләнде.

Р. Харис һәм М. Вәлиев шулай ук шәһәр хакимияте житәкчеләре һәм милли хәрәкәт вәкилләре белән очраштылар.

«ЗЫЯЛЫЛАР КЛУБЫ»НДА

Мәскәүнең «Татар зыялылары клубы» шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов иҗатына багышланган кичә белән үзенең унынчы сезонын ачып җибәрде. Кичәдә катнашу өчен Татарстаннан байтак кеше килгән иде: Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, шагыйрьләр М. Миншин, А. Юнысова, артистлардан—И. Әхмәтҗанов, Р. Ильясов, К. Хәйретдинова, «Рухият» фондының башкарма директоры И. Хәйруллина, шагыйрьнең туган ягы—Баулы районы вәкилләре. Сәхнәдән шагыйрьнең шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады.

«Зыялылар клубы»нда мондый кичәләр элегрәк Сара Садыйкова, Рөстәм Яхин, Алмаз Монасыйповлар иҗатларына багышланып үткәрелгән иде.

ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

21 ноябрьдә ТР Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында татар шагыйре Егор Уткинның тууына 70 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе булды.

Аның турында истәлекләр белән Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миннуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, Менделеев район хакимияте башлыгы урынбасары Лилия Галиева чыгыш ясады. Кичәдә шагыйрь Илдар Юзеевка Е. Уткин исемендәге әдәбият премиясе тапшырылды.

Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гәрәй Рәхим алып барган бу кичәдә ТР халык артисты Георгий Ибушев, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Николай Храмов, керәшеннәрнең «Бигәш» (Менделеев районы) халык ансамбле башкаруында Егор Уткин шигырьләренә язылган җырлар яңгырады.

Тышлыктагы сурәтләр

Тышлыкның беренче битендә: Әлмәт шәһәрендәге мөселман дини-мәгърифәт үзәге.

Тышлыкның дүртенче битендә: шагыйрә Гөлшат Зәйнашева.

ЯҢА КИТАПЛАР

УРМАНЧЕ Фатих. **Татар халык иҗаты.**— Казан: Мәгариф, 2002.—335б. Тиражы—2000 данә.

Халык иҗаты турында күләмле хезмәтләр элегрәк елларда да чыккалаган иде (*«Татар халык иҗаты»—1951, «Татар халкының поэтик иҗаты»—1967, һ. б.).* Әмма соңгы чор идеологиясендәге принципиаль үзгәрешләр халык иҗатына, аның проблемаларына яңача—милләт, халык язмышы күзлегеннән якын килүне таләп итә. Сиксәненче елларга хәтле язылган хезмәтләрнең күбесе яңача бәяләүне сорый. Дәреслек буларак тәкъдим ителә торган бу китап—махсус фәнни монография. Татар фольклористикасы тарихында беренче тәҗрибә буларак язылган китапның нигезен татар халык иҗатына, аның аерым жанрларына халыкчанлык, милли-мифологик, тарихи һәм тарихи-этнографик якын килү принцибы тәшкил итә.

Хезмәт югары уку йортлары, лицей һәм колледж укытучыларына, студентларга адреслана. Мәктәп һәм гимназия укытучылары һәм укучылары да бу китаптан нәтиҗәле файдалана алалар.

ӘХМӘДУЛЛИН Азат. **Офыклар киңәйгәндә.** Әдәби тәнкыйть мәкаләләре.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.—239б. Тиражы—1000 данә.

Бу җыентыкка күренекле әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче А. Әхмәдуллинның соңгы елларда язылган мәкаләләре тупланган. Китап өч бүлектән тора: драматургия һәм театр сәнгате, әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть, матур әдәбият һәм мәктәп. Галимнең татар драматургиясенең торышына кагылышлы бәяләмәләре, әдәбият белеменең үсеш юлларын ачыкларткан, мәктәп программалары төзүнең үзенчәлекләре турында язылган хезмәтләре әдәбият сөючеләр өчен һичшиксез файдалы булыр. «Ни генә булмасын, иҗтимагый-икътисади һәм сәяси хәл никадәр катлаулы булмасын, әдәбиятыбыз яңа үрләр яулый. Аның нәзари-методологик нигезләрен эшкәртүдә дә уңышлар юк түгел. Шуларның кайбер якларын беркадәр генә булса да укучы күз алдына бастыра алса, бу җыентык авторы буларак, мин канәгать хасил кылыр идем» ди автор. Китап галимнең 70 еллык юбилее уңае белән нәшер ителгән.

Индекс 73210

Гөлшат Зәйнашева

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)